# Казан утлары

2 февраль 1968

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ҖИДЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

**2**

ФЕВРАЛЬ

1968

## Бу санда:

ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬЛӘР

Х. Туфан. Шигъри елъязмалар . . . . . . . . 3
Ә. Касыймов. Бир кулыңны, дустым!.. Повесть. 19
К. Мостафин. Исәп; Апрель; Теләк; Унҗиденче елның матрослары. Шигырьләр . . . 38
Б. Рафиков. Җир тынычлык тели; Яшел шәлен салып иңбашына; Мәңге бетмәс яралар; Берәүләре күккә чөеп. Шигырьләр . . . . . . 40
Р. Закиров. Омтылыш; Шул да бәхет; Син килмәдең; Тынгы белмим; Кем уйлаган; Китмәскә иде. Авылым кызына; Сорамагыз; Вакыт үтә; Дуслык хисе. Шигырьләр . . . . . . 41
Е. Уткин. Тик йөз адым; Бишек сиртмәсе; Юк, син даһи түгел; Романтикам; Син Җир кебек; Төнге яшен; Печән өсте. Шигырьләр . . . . . 45

Ф. ХӨСНИГӘ 60 ЯШЬ

Ә. Еники. Безнең Фатих . . . . . . . . . . 49
Ф. Хөсни. Кичке дога. Хикәя . . . . . . . . 51

СОВЕТ АРМИЯСЕНЕҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

Г. Балакин. Лидия Сәйфуллина ант итә . . . 55
М. Рафиков. Төркемле рәсем . . . . . . . . 58
Г. Латыйп. Җыр үткәндә. Шигырь . . . . . . 64

МУСА ҖӘЛИЛ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП

Р. Мостафин. Уньөченче. Очерк . . . . . . 68

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

М. Васютин, Ж. Рәхимов. Депутат. Очерк . 89

БЕЗНЕ ОКТЯБРЬ ҮСТЕРДЕ

М. Максуд. Кайбер истәлекләр . . . . . . . 96
З. Сәйдәшева. Бәхет биргән җирем . . . . . 101

ӘДӘБИЯТ ФӘНЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

А. Фәтхи. Мәгърифәт төбәкләре һәм әдәби бәйләнешләр . . . . . . . . . . . . . 103

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Т. Галиуллин. Поэманың барыр юллары . . 123

КИТАП КҮЗӘТҮ

М. Госманов. Гаделлек җырчысы Мөхәммәдъяр . . . . . . . . . . . . . . 132
Н. Ханзафаров. Көлү — үткен корал . . . 137

ТӨРЛЕСЕННӘН

Ә. Кәримуллин. Кульязма мирасыбызның кайбер мәсьәләләре . . . . . . . . . . 140

УКУЧЫЛАР ИҖАТЫ

5

Г. Камалов. Тайгада. Кара урман. Шигырьләр . 145

БЕЗНЕҢ ИНТЕРВЬЮ

Әдипнең уңышы . . . . . . . . . . . . . . . 146

Яңа китаплар . . . . . . . . . . . . . . . 149

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Ә. Синегулов. Гиз эль-Габиднең тууына 50 ел 151

САТИРА ҺӘМ ЮМОР

Ш. Шәрәпов. Линейка-рецензент; Мин хатынның кушканнарын; Чәч турында такмаклар. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 154
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 155
Бу санның авторлары . . . . . . . . . . . . 160

*Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый*

---

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Җаваплы редакторы Рафаэль Мостафин

Редколлегия: Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники,
Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский,
Сибгат Хәким, Нил Юзиев

Производствога бирелде 15/XII-1967 ел. Басарга кул куелды 25/I-1968 ел. ПФ 09005.
Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 65 246 экз.
Заказ М-2017. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1968 ел.

*Хәсән Туфан*

# ШИГЪРИ ЕЛЪЯЗМАЛАР

## Җилкәнен киерә Кораб

...Төн вә көндез
Ул йөзәдер...

Дәрдмәнд.

Диңгезен чиксез Заманның,
Упкынын кичте Кораб,
Мәгънәви малын-маясын
Аралап ничә кабат.

Тартса да кайбер гасырлар
Җан сорап төпкә табан,
Ауса да өлкән, асыллар,
Юл һаман исән-аман.

Ил-ара ярлар ягына
Юл яра ялсыз Кораб:
Нурлана чорлар чатында
Яңалар маяк-маяк.

*1961—67*

## Атларым

Атларымның тезләрендә
Иске яра эзләре...
Без шуларда гизгән идек
Сездә, дала җилләре,
Без шуларда кичкән идек
Сезне, бәла җирләре:
Атларымның тезләрендә
Иске яра җөйләре...

Пар пегасым, толпарым син,
Нәфрәтем-мәхәббәтем! —
Шигъри илһам дип аталган
Иң мөкатдәс нәрсәнең, —
Тик бүген бит, тик бүген мин
Тәкъдим итәм рәхмәтен.
Син гафу ит соңлавымны,
Нәфрәтем-мәхәббәтем...

Шигъри Тауга тик шуларда,
Пар канатта бар фәкать:
Тик шуларга үз булуда
Һәр әдәби бәрәкәт,
Тик шуларга күз йомуда
Һәр иҗади һәлакәт,
Парнасыңа пар канатта
Пар пегаста бар фәкать!

Атларымның тезләрендә
Эссе юллар эзләре.
Без шуларда гизгән идек
Сездә, еллар, элгәре,
Без шуларда кичкән идек
Сезне, заман җилләре,
Тулпарымның тезләрендә
Изге яра эзләре...

*1967*

## Күлмәгең талда

Үләрмен... тик (үкенмим!) бер теләк бар:
... Бу күлмәк каплаган изге йөрәк бар.
Аңардан акты күлмәккә бу каннар.
Алырсыз сез аны миннән мин үлгәч,
Эләрсез бер биек т а л г а — күренсен...

М. Җәлил («Үлем алдыннан»).
1922

Көнне илгә, ә шигырьгә бары
Төнне генә биргән елларда,
Уртак иде безнең һәрбер учак,
Тукайлардан калган кырларда.

Менә тагын синең янында мин,
Мәйдандагы Муса янында.
И, ничек син үскән, үзгәргәнсең
Утлар аша үткән чагында.

Ә шулай да — таныйм,
Бу — син, Җәлил.
Нәкъ үзең күк синең сурәтең.
Тик күлмәгең... үзең әйткәнчә үк...
Кан эчендә калган, күрәсең.

Күлмәгеңне, — чылбыр өзгән җирдә,
Кан эчендә калган күлмәкне, —
Илләр аны Дөнья күләменә,
Биегенә талның күтәрде!

Карый да Ил
Һәйкәлеңә, Җәлил,
Үзен күрә синең төсеңдә:
Ул да шулай — кулын бәйләтмичә
Гомер итә бу җир йөзендә.

*1967*

# Еракларга алып киттеләр

Кара да гына урман, караңгы төн...
Халык җыры.

* * *

Карурманның калын, кара төнен
Җаяү генә дә лә үтәрсең,
Заманалар авыр, еллар ябык...
Шундый чакта нихәл итәрсең...

Әзерләнеп торган
Заман, наян,
Карурманның аргы ягында.
Маңгайларга — тәүге тамгаларын,
Башкайларга — кайгы салырга.

Сузылып ятып офык артларына,
Яшереп кенә кара башларын,
Карап торган
Безнең — яшь буынның
Ил хәлләрен аңлый башлавын.

* * *

Авыл аша узган юлаучылар
Яңа хәбәр биреп киттеләр:
— «Бубиларны... кара болыт басты,
Мәдрәсәне тар-мар иттеләр...
Китапларны каткан итек белән
Таптый-таптый төяп чанага...
Үзләрен дә богау белән бәйләп
Апкиттеләр... Әллә каяга...»

Карурманнар аша болыт килә
Кыр казлары юлы буеннан.
Карасана — нинди сәер болыт! —
Бубидандыр ла ул, Бубидан.

Болыт булып әзләп йөри төсле
Безнең якны, безнең турыны,
Һәм каядыр дәшә, өнди кебек,
Яшь буынны, яңа буынны,
Яндырылган якты китапларның
Һаваларда калган корымы...

Чыдам син Ил:
Киләчәкне гәрчә,
Күрмәсә дә әле күзләрең,
Төннәр артындагы таң сызыгын
Күңелләрең күрә, күрәсең.

* * *

Авылларны баскан гамь сөреме
Таралмаган иде тамчы да,
Заман гамьнең икенчесен инде,
Өр-яңасын китереп тапшыра...

Бозлы хатлар килде Бодайбодан
Ленадагы хәлләр турында,
Канлы хәбәр язган авылдашлар,
Чук-чук сәлам язар урынга...

Чамалыйлар кайбер карыс картлар:
— Бунт, кордашлар, намаз түгел шул.
Бармый каламыни татар аңа! —
Бунт дигәнең бездәй чаяларга
Сабан туе гына кебек ул.

Уйга бата халык:
— Шулай шул, әй,
Безнекеләр читтә калмаслар:
Атылганнар өеме арасында
Ничәү икән безнең якташлар...

* * *

Бу хәсрәтнең әле ил эчендә
Сүрелмәгәндә үк сөреме,
Сагышларның Заман менә тагын
Өченчесен китереп өлгерде.

Абына-сөртенә
Яңа хәбәр килде:
— «Ямаш вафат... Ямаш Хөсәен!..
Әмма, ләкин...
Үлмәгәндер лә ул,
Үтергәннәр аны, мөгаен...
Мажик дусы, яшьләр дусы иде,
Өметләрнең тәрәге иде.
Кем тигәнен шундый кешебезгә,
Кем икәнен беләсе иде!..»

* * *

Уникенче елны кичтек инде,
Елмай инде, Кояш! — дигәндә:
Җирне тырнап, тәгәрәп лә, аунап
Апрель елый яңа чирәмдә...

Иңе сыгыла илнең:
Гамьнең бусы
Барыннан да авыр ләбаса.
Әйтерсең лә, җеназасы аның —
Тукаеның
Үтеп бара авыллар аша...

Асыр да бит, түзәм.
Нигә түзәм!
Бирмәсә дә җавап йөрәгем,
Төннәр артындагы таң сызыгын
Күңел бераз күрә, күрәсең.

* * *

... Карурманның калын, кара төнен
Җәяүләп тә бәлки, үтәрсең.
Заманалар авыр, еллар ябык,
Шундый көннән кая китәрсең!

Кая булсын — я Уралга инде,
Я Себергә — бакыр базына.
Туры килдең арык, җиңел яшьлек,
Замананың авыр чагына.

Капчыгымда минем — шикәр дә чәй
Юлга дигән күмәч янында.
Күрми Кояш:
Ничә төрле кайгы —
Җанымдагы чемоданымда!

Анда — Буби, Лена, Ямаш, Тукай.
Анда — матәм, олы дүрт матәм.
Аларны мин
Абына-егыла гына,
Көчкә-көчкә генә күтәрәм.

Пароходта — каты идәндә мин,
Вагонында — ишек төбендә.
Төрмәсендә генә Дөнья миңа
Урын бирермени — түрендә!..

Кайберәүнең — күзе тибә миңа,
Кайберәүнең — йөзе нур сибә.
Бер генәдер дисәм, түгел икән,
Әллә ничә икән Русия:

Лаканнан да юан тавыш белән,
Чәйни берсе безнең исемне,
«Божецаряхрани» дигән сүзне
Улый торган монах шикелле.

Ә мин түзәм, ишетмәгән булам,
Кызарса да
Татар йөзләрем:
Төн эченә төшкән таң шәүләсен
Күңел инде сизә, күрәсең.

Беренче кат кердем пароходка,
Беренче кат күрдем вагонны.
Еракларга алып киттеләр лә
Шулар минем яшьлек чагымны.

*1967*

# Зыя[1] идең, якты идең син

Ничек өздек уйлауда да
коллык җебен?
Г. Тукай

Йолдыз атыла җиргә. Ник атыла!
Бәрмы моның берәр мәгънәсе!
Бар билгеле: «Фирештәләр шулай
Шайтаннарны дөмби» — янәсе.

Менә шундый сукыр иман белән
Башны бөгеп галәм каршында,
Яктылыкка юллар эзләгәндә,
Романовлар төне астында,
Килеп кердең, балкып шахтабызга,
Йөрәкләргә безнең нур биреп,
Шырпыга да мохтаҗ урамнарда
Өйдән-өйгә күчкән ут кебек.

Ә без анда, — илләр төрмәсендә —
Типкәләнеп үскән үчләләр,
Белем кылычлары бирүчегә,
Мәгърифәткә мохтаҗ үсмерләр,
Күтәрелеп астан — забойлардан,
Кырдан, чүлдән, таулар артыннан,
Юнәлдек без
Уфа ярындагы
Син кабызган яңа яктыга[2].

Кышның эт тә, шпиклар да йөрмәс
Буран купкан аулак кичендә
Тәрәзләрен залның эчтән каплап,
Сакчы куеп тышкы ишеккә, —
Әле дә истә, — төнге җыелышларда
Мәгърифәткә — таңга дәшкәнең,
Хөрриятка ашкынучыларны
Киләчәккә әзерләшкәнең
Әле дә истә.

Гарәп теле сәгатьләрендә дә
Фәнгә күчереп дәрес темасын,
Җаныбызга фикер хөрлегенең
Орлыкларын салып куйгансың.
Мәгърифәтләү иде төп теләгең
Инородец илләр баласын.
Сиздең микән үзең бу мәгърифәт
Безне кая алып барасын!..

---

[1] Зыя Камали. Ярлы игенче гаиләсеннән чыгып, югары белем алуга ирешкән күренекле галимнәрнең берсе. 1905 ел революциясеннән соң Уфада «Галия» мәдрәсәсен нигезләп, үзенең тормышын мәгърифәтче кәдрлар үстерүгә багышлаган остаз.

[2] «Галия» гә — югары уку йортына.

Изге юл! — дип озатып калган идең.
Кайттык та без
Килгән якларга,
Коммунарлар юлын сайлап алып,
Гомер иттек алгы сафларда.

Күреп тордың
Синең шәкертләрнең
Комиссарлар булган көннәрен.
Хәерле юл теләп калган идең
«Кабул» булган, димәк, теләгең!

Тыйнак идең, ләкин мәгърур хәлдә
Үлгәнсеңдер
Безне хәтерләп:[1]
Мазлумнарга бәхет яулашуга
Хезмәт итте синең мәгърифәт.

Әгәр һаман көн итәбез икән
Яктыртышып яңа тормышны,
Без — меңнәрчә дәһри шәкертләрең,
Моның өчен сиңа бурычлы.

Безнең өчен — үзең Сократ идең,
Ә мәдрәсәң — университет.
Царизмның сине әзәрләве
Очраклы хәл түгел иде бит.

Метеор кебек янып бетсәң дә син
Тундраларның төпсез төнендә,
Синнән калган нурлар яши әле
Йөрәкләрдә безнең бүген дә.

*1964*

## Истәдер

Сыйфатың шундый күрәсең,
Җитсә дә меңгә яшең,
Аккынам, пагым, сафым! — дип,
Аклыны үзсенәсең.

Күзләрең пакька күнеккән,
Карый да күреп ала:
Кем яман — аның идәнгә
Карасы төшеп кала.

Истәдер, бәлки, тарихың
Канаган идәннәрең,
Аклысын салып киемнең
Карасын кигәннәрең.

---

[1] Вафат булганнан соң акланды.

Истәдер илләрбасарның
Илеңне яндырганы,
Болгарың мәйданнарында
Көл-күмер калды бары,
Селтегә әверелдерелде
Күгеңнең яңгырлары.

Олылый һәрбер бөек ил
Үзенең үткәннәрен.
Ә синең, халык буларак,
Юкмыни өлкәннәрең!
Азмыни күркәмнәрең!

Тарихың анналларында
Азмыни асылларың! —
Гасырлар юлы буенда
Чайкала каеннарыңда
Асылган батырларың...

Атналар, айлар буенча
Яндылар Биләрләрең,
Корымга батты, корымга
Айларың, җидегәннәрең.

Истәдер, бәлки, тарихың,
Башыңны игәннәрең,
Аклысын салып киемнең
Карасын кигәннәрең.
Ак күгәрченне кулымнан
Алдылар дигәннәрең...

Йөрәгең күпкә күнеккән,
Күзләрең таный ала:
Кем яман — аның идәндә
Кап-кара эзе кала.

Сыйфатың шундый, күрәсең:
Үтә дә үтә заман,
Ә синең дәртле, бөек җан
Яшәрә бара һаман.

*1967*

## Юлчылар

*(Ибраһим Газига)*

Мәгърур Болгар шәһәрләре бер дә булмаган төсле, кырылдылар да беттеләр. Әмма бу — кыйммәтле Мирас дигәнебез халык шигырьләрен туплар да ватмады, уклар да кадамады.

Г. Тукай.

Туктапып бер
Җилле, күзге кичтә,
Сахрадагы юлчылар кебек,
Исеңдәдер, шәфәкъ ялкынында

Кул җылытып утырган идек,
Кичкә калган юлчылар кебек.

Йолдызларга урын бирә-бирә
Күзәтте дә, күк йөзен бераз,
Кайтыр өчен киткән классик күк,
Офыкларга күмелде кояш,
Моңсулатып җир йөзен бераз.

Күңел күзе ләкин бу кичләрне,
Алтын-сары көзләрне түгел,
Офыклардан аргы-еракларны,
Киләчәкне күзәтә күңел,
Көзге алсу кичләрне түгел.

Мин дә аңа — ерак киләчәккә
Сүзсез генә
Сораулар бирәм:
— Безгә анда — яңа гасырларда —
Укучылар очрарлар микән!
Мин дә шундый сораулар бирәм...

Гүя шунда, — кем ул, — Алып сыман
Турая да офыкка баса!
Һәм шәфәкъка, һаман саны арткан
Укучылар авазы аша,
Киләчәкнең җавабын яза:

«Ут та алмый, туп та ватмый торган
Байлыгымны бәгыремә салып,
Мин түгелме, тулы гасырларның
Тугызлабын сау кичкән халык,
Җырларымны җаныма сарып!!»

Офыкларның аргы якларын да
Төсмерләгән юлчылар кебек,
Исәндәдер, шәфәкъ утларында
Җан җылытып утырган идек,
Юлы чиксез юлчылар кебек...

*1967*

## Отелло

Алсу буран аша утка таба,
Таңга таба юллар ярганда,
Киләчәкнең болай булачагын
Һич кенә дә юрамаганда,
Уфаларда күргән идем аны
Көтмәгәндә-уйламаганда.

Ул үзе дә, төсе кебек сәер,
Кырыс иде, кызык иде дә,
Төсе түгел ләкин, көр тавышы,
Өне калды минем исемдә.

Мин укучы гына, ә Ул инде
Катип[1] иде рәсми урында.
Арысланның алгы аякларын
Хәтерләткән кырыс кулында
Чәчәк иде...
Тышта әле буран улаганда —
Яз чәчкәсе — зәңгәр миләүшә...
Арыслан һәм... чәчәк! — дигән сыман,
Ят тоелды миңа бу нәрсә.

Ә күзләре...
Күзләрендә Аның ниндидер гамь,
Ниндидер үч
Һәм зар бар иде.
Арысланның ярсу йөрәгенә,
Әйтерсең лә, сахра тар иде.

Бу беренче күрү иде әле.
Байтак еллар үткәч шуннан соң,
Царизм да, буржуа да беткәч,
Аның белән тагын очраштым.

Үз кырын ул
Тапкан иде инде:
Менә кинәт
Сәхнә артыннан
Килеп чыкты күкрәп «Отелло»да,
Теге тавыш, теге арыслан...

Ул көннәрне карлар күмгән инде.
Шулай да ул
Әле хәзер дә,
Мутин түгел, ә Отелло булып,
Гамлет булып яши хәтердә.

ЕракларДан кайтып килә дә ул,
Күңелләргә килеп керә дә ул
Көзге җилдә, кичке җилләрдә,
«Булмый!.. Булмый ялгыз!..»[2] — дигән
сыман,
Ярсый-ярсый ашлык җилгәрә...

---

[1] Катип — секретарь.
[2] «Булмый, булмый» — шагыйрь Сириннең Мохтар Мутин ага репертуарында зур урын билэгэн атаклы шигырьләреннән берсе.

Күзләрендә аның ниндидер моң,
Ниндидер гамь
Һәм зар бар иде.
Чамадан тыш олы йөрәгенә,
Әйтерсең лә, тәне тар иде.

*1967*

## Сез кая барасыз, йолдызлар

Җемелдәмә, искә төшермә лә,
Ансыз да бит
Исемдә минем:
Мин ул төндә әни итәгендә,
Син кибәннәр өстендә идең...

Аннан бирле
Кайда булмадым мин,
Кайсы утта, кайсы упкында...
Ә син, Җидегән, Азия күгендә дә,
Себердә дә, — шул ук урында.

— «Дала тынды... Учак әмәллә дә,
Ял ит инде, кеше!» — дисәң дә,
Булмый, Җидегән:
Кайда калды икән,
Бер сыерым тулмый исәпкә.

Эзне кая, итекне дә хәтта
Күреп булмый... Шундый караңгы.
Күктәгеләр күрми минем хәлне,
Ә мин күрәм, күрәм аларны.

Планеталар нидер ымлашалар
Күкләргәрәк, өскәрәк менеп,
Кайларгадыр барган йолдызларның
Җитәр җирен күзләгән кебек...

Әйтерсең, бу чиксез мәңгелектә
Берәр чиккә җитәргә мөмкин! —
Әйтерсең лә, орбитаңнан чыгып,
Кая булса китәргә мөмкин...

Кая гына тибәрсә дә язмыш,
Этәрсә дә адәм баласын,
Әйтерсең лә, тугры юлдан аны,
Орбитадан сөрә аласың!

Мөмкин түгел иде
Безне кичә,
Мөмкин түгел бүген, иртәгә,
Мөмкин түгел безне, мөмкин түгел
«Юлдан язган кеше» итәргә!

Ә син, Җидеган, беләсеңме шуны!
Юк, белмисең: сиңа — караңгы..
Күктәгеләр күрми безнең хәлне,
Ә мин күрәм, күрәм аларны...

Планеталар, нәкъ сабыйлар сыман,
Түбәгәрәк, үргәрәк менеп,
Кайларгадыр киткән әтиләрнең
Кайтуларын көтәләр кебек,
Кайтуларын...

Әйтерсең лә, берәр максаты бар,
Теләге бар
Бу йолдызларның...
Буталалар чиксез мәңгелектә
Бер максатсыз, бер юлсыз, җаным.

Ә кешедә — олы максатлар бар.
Якындыр да арам аларга...
Кеше менә — сыер көтә әле
Аюлар да гизгән далада...

Җемелдәмә, искә төшермә лә! —
Ансыз да бит
Хәтердә минем:
Без Казанга: «Сау бул...» дигән төндә,
Син болытлар артында идең,
Болытлар артында...

*1953—67*

## Әстерхан кремлендә

Коймаларың нигә калын таштан!
Капкаларың нигә тимерле!
Корган сине комсыз монархия
Мәңге шунда торыр шикелле.

Ник бу кадәр биек сез, диварлар!
Ник бу кадәр киңнәр, калыннар!
Нинди көчле, үчле булган бунтлар,
Сезнең өскә килгән давыллар.

И, борынгы изге, иске ташлар! —
Кайда иде туган илегез!
Кайсы хәрабәнең нигезе сез,
Кайсы гүрдә билге идегез!..

*1966*

# Гүзәл гамь

Атналыкның соңгы кичәсеннән
Әстерханга кайтып барабыз.
Кем белгән соң аны!.. Бу кичәдән
Шундый тирән эзләр каласын...

Остазларым Хайям һәм Ширази!
Реаль сурәт сездә аз дисәм,
«Керфекләре уклар шикелле лә» —
Дигәнегез реаль, рас икән.

Озын керфекләре очы белән
Чәнечкедәй итеп дөньяны,
Алларыма килеп басуларын
Онытмамдыр, ахры, мин аны.

Кем рәнҗеткән моны! — дип уйладым,
Карадым да моңсу йөзенә:
Зур үпкәсе бардыр кебек иде,
Әллә илгә, әллә үзенә.

Әйтерсең лә, бәхет өләшкәндә
Язмыш аны читтә калдырган,
Әдәбият күперләре аша
Үз теленә кайтыр алдыннан...

Беренче кат, — бәлки соңгы каттыр, —
Синең белән шунда
Күрештем.
Кичәдәге китап базарында
Сиңа бәхет эзләп йөрештем.

Синең төсең, яз шикелле иде. —
Яшел иде кигән күлмәгең...
Төсләреңнән битәр, сүзең белән
Исләремдә калдың син минем.

Син көендең: — Беткән лә бит! — ди-ди, —
Мин эзләгән китап беткән бит...
Мин сөендем: илдә миңа шундый
Гүзәл гамь дә исән икән дип.

Кичә бетте, китәр вакыт җитте.
Алып китте безне юлыбыз.
Автобуска тотынып килә кебек
Моңлап тавыш, моңлап «Ху-шы-гыз!..»

Хуш түгел лә бүген минем хәлем.
Сызлана да йөрәк, сызлана:

Исемеңне дә белми киттем бит мин,
Адресны да синең, кыз бала...

Без дә уйчан,
Автобус та сүрән.
Уйлый микән ул да югыйсә:
Яр-Түбәнең кырый өйләренә
Килерме, дип, тагын бу кичә...

Шатлык кына алып чыгармын дип
Керсәм илнең кырый өенә,
«Китапсыз ла яшим...» дигән моңнар
Өелә дә җанга, өелә.

Гүзәл гамьнәр, — әйтмим генә, сеңел, —
Йөрәгемне телеп бетерде...
Кем идең син!
Ничек сузыйм сиңа,
Үз телеңә илткән күперне!..

*1966*

## Антимирда түгел

*Белла Ахмадулинага*

Антимирда түгел, ә Җирдә,
Шыгрым тулы залда, Казанда
Туктап торды заман, күпмедер,
Халык белән синең араңда.

Тынып торды, кыймаган сыман
Эндәшергә, исәнләшергә,
Кабатланмас гаҗәп гүзәл мәл
Калсын диптер, мәңге хәтердә,
Туктап торды.

Залда шулай
Халык һәм шагыйрь
Очраштылар тәү кат күзгә-күз.
Ике як та — сүзсез елмайды:
Карасана, нинди үз лә, үз!..

Аннан... Синең тылсымлы тавыш
Ал чишмәдәй, акты да акты.
«Сак» белән «Сок» беренче тапкыр,
Әйтерсең лә, бер-берсен тапты...

Рахметовлар токымы икәнең
Чатнап тора агат күзеңдә.
«Тап» түгел бу, сеңел, «тап» түгел,
Тик матур «миң» шигъри йөзеңдә!

Мәдхия дә түгел, сеңелкәй,
Мадригал да түгел бу Сиңа:
Яратам мин һәр чын талантны! —
Син шул яктан күбрәк үз миңа.

Ышанычлы, башлы сеңел, Син:
Сиңа серне чишәргә мөмкин,
Син дигәндә — Пегас суярга,
Рубиконны кичәргә мөмкин!

Синнән яшерен сүзләр юк минем:
Җан капкасы шар ачык Сиңа.
Утырыйк әле әйдә, сеңелкәй,
Туганнарча сайрашып кына.

Тарих бирдек Сиңа — бүләкләп:
— Татарыңны таны! — янәсе,
Вакыйгасы иске булса да,
Бүгенгечә анда һәммәсе.

Укы, сеңел, ләкин чамала:
Хәтере йомшак, диктер, Тарихның:
Усал ягын онытмаса да,
Яхшы ягын күрми халыкның.

— һава ничек, дисең, Казанда!
Санап була — сафка, әйбәткә:
Урчи алмый мондый һавада
Модернистик вирус, әлбәттә.

Илгә күптән таныш нәрсә ич —
Модернистлар «азат» формасы.
Фил сөягемени! — Эрзац бит
Ул «башня»ның арматурасы.

Тырыша алар импорт фикердән
Шактый сәер товар ясарга,
Бәлки юллар табар әле, дип,
Экспортка — «иркен базар»га...

Космополит алар асылда,
Ә яшиләр Совет илендә,
Кликушалар наказын үтәп,
Кучум-Ханны сатып шигырьдә.

Модернизм кустарьларының
Алласы да, ватаны да күп.
Төкерә белик без дә шуларга
Анна апаң Ахматова кук.

Нигә безгә Анна ападан
Һәм Пушкиннан үрнәк алмаска!
Традиция ватанчысы без,
«Антимир» юк безнең
Запаста.

Юк, үгет тә, бүтән дә түгел,
Тик үз итеп әйтү — бу сиңа: —
Битникларга «муза» булганчы,
Асрау булу яхшы Пушкинга.

*1965*

Эдуард Касыймов

# БИР КУЛЫҢНЫ, ДУСТЫМ!..

*Повесть*

## «Бәладән башаяк...»

Кич булды исә Роберт, кинога-мазарга бармаса янсә нефтьчеләрнең тулай торагындагы телевизордан футбол ярышын күрсәтмәсәләр, сабакташы Борисларга килә. Нефтьчеләр каласына килеп урнашуына әле күп үтмәгән, таныш-белешләре юк диярлек, кая барсын кеше?

Борис та, Светлана да аны һәр чакны, ипи-тоз якты йөз дигәндәй, бик ачык чырай һәм эчкерсез гаделлек белән каршы алалар. Бу өч җанга әлегә бары да, югы да уртак. Тик теленә чуан чыккан Светлана гына кайчакларны: «Үзеңә бирәр кыз тапсаң иде, ичмаса. Монда да, Казандагы кебек үк, каңгырып йөрисең бушка. Шул хәтле җебегән димме, туң йөрәк димме, булырсың икән», дип егетнең бәгырен чемтетереп ала. Тегенең җавабы булмый, күзлек пыяласын кулъяулыгы белән сөртергә тотынып, моңсу гына елмаеп куя. Кулына диплом алгач та ул, әллә яшьләр арасындагы бер төрле модага ияреп, әллә үзенең артык малайчыл кыяфәтенә беркадәр олылык-ирлек сыйфаты кертергә теләп, борын астыннан тар гына мыек үстереп җибәрде. Сызылып киткән кара мыек иясенә ни рәхәт бирә торгандыр, әмма Светланага ара-тирә тел кычытуларын басу өчен бик шәп бер сәбәп кенә иде.

Роберт үзе дә сүзгә-телгә дигәндә, алай күршегә керә торганнардан түгел. Ул Светлананың тел кычытуларын бик тиз баса алыр иде. Әйтик, яшь хатынның «кыз табалмый каңгырып йөрисен» дип бәйләнүләренә каршы: «Бер үткененә эләгеп, менә Борис шикелле, башым култык астында кысылып калыр дип куркам», дисә, тегене чалкан салып ташламас идемени?

Ләкин аның җинүе, хакимлеге бүтән яктан.

Гитарасын муенына асып, күпләр ишеткән-белгән янсә һичкем белмәгән-ишетмәгән, тик аның үз җимеше генә булган җырларны тамак төбе белән генә көйләргә тотынса, билләһи, тегеләрне эретә дә җибәрә. Светлананың күзләрендәге наянлык, үткенлек чаткылары югалып, ул шундук моңсу бер төс ала. Роберт гитара кылларына житез һәм шома чирткәләп рус җырларына күчсә, Светлана раскладушкага утыра да башын иренең җилкәсенә тидереп, нәзек, көчсез тавышы белән җырга кушыла, аның соңында җырны Борисның калын күкрәк тавышы күтәреп ала. Алар шулай сызылып киткән кара мыеклы, күзлекле егет ихтыярында калып, ул тудырган дулкыннарда җай гына тирбәләләр һәм мондый халәт сирәк булмый...

Гитара Робертныкы, ләкин ул Светлана кулларында: бер алып калганнан соң, егеткә бирми, үзенең баш очына элеп тота. «Ә нигә ул сиңа? Тулай торагында малай-шалай арасында шуны уйнап ятыр

---

Ахыры. Башы журналыбызның 1 нче санында.

иденме? Исеңә кил, инженер-геолог бит син, житмәсә, мыеклы инженер, дәрәҗәңне төшермә», дигән була. Нигәдер үлеп ярата торган булды әле Светлана гитара моңын... Роберт бер-ике көн күренмәсә, ул ире Бориска: «Кая югалды әле безнең мыекбай? Чакыр әле үзен, бер чиертеп китсен әле», дип назланып, тегенең тенкәсен корыта башлый...

Баштарак Борис белән Светлана нефтьчеләр гостиницасында яшәгәннәр иде. Әмма анда гаилә тормышын корып буламыни? Бердән, кеше өсте, тыгыз, үз-үзеңә хуҗа түгел, икенчедән, хакы кыйбат: эшләп-эшләп тә шәрә калуың бик ихтимал...

Йөри, үтенә, дулый торгач, ике-өч атнадан ук аларга дүрт катлы йорттан бер бүлмәле квартираны бушатып бирделәр. Әлбәттә, Светлананың үткенлеге, наянлыгы һәм тиешле җирендә усал була алуы аркасында гына эләкте ул фатир. Юкса, Борис ише бозауга ышанып торса, ятырлар иде әле гостиницада болай да буш кесәләрен такырайтып...

Фатирны алдылар алуын, әмма аны ни беләндер азмы-күпме җиһазландырырга да кирәк бит.

Ирнең Казандагы, хатынның Йошкар-Оладагы туганнары, боларның хәлен ишетеп, ярдәм кулы сузарга ниятләгәннәр иде дә болар икесе бердән:

— Бик рәхмәт! Ләкин без тормышыбызны үз көчебез белән генә корып җибәрик инде! — дип кырт кистеләр.

Беренче хезмәт хакларын алган көннәрендә үк фатирга бер кухня өстәле, бер раскладушка һәм ике табуретка кереп утырды. Аннары олы якка Светланага дәрескә әзерләнү һәм дәфтәрләр тикшерү өчен, ике зур гына ящикны бергә кушып, өстәл әмәлләп куйдылар: рәхәтлән, абыстай! Килгән кеше була-нитә калса, рәхим ит, утыр: күн тышлы йомшак чемодан сиңа...

Хуҗаларга ничек тоелгандыр, әмма Роберт бүлмәдәге күренешкә гаҗәп бер соклану белән күз йөртеп чыкты да:

— Вот, ичмасам, тормыш башлау бу!.. Романтика! — дип бармакларын шартлатты һәм тизрәк тулай торагына гитарасын алмага чапты.

Шушы көннән алып гитарасы Светлана кулында торып калды да инде...

Буйдак һәм ялгыз ир-егетнең төрле чагы була. Өстәвенә Робертның хезмәте дә тынгысызрак: бораулау конторасында участок геологы ул. Буровойларда аңа көндезләрен дә, төннәрен дә булгаларга туры килә. Кайчакларда эт урнына хәлдән таеп, алҗып һәм бүре аппетиты белән кайтып төшә ул. Аның җан атып көтеп торган кешесе юк, димәк, нурлы караш та, җылы ризык та юк, ашханәләр күптән ябылган, кибетләрнен ишегендә чабата хәтле йозак, ә тулай торактагы тумбочкасында кибеп беткән сынык-саньк тычкан килгәнне көтеп ята... Мондый чакларда ул дуслары өендә ут күренсә, ничек аларга сугылмыйча үтсен, ди! Ә дуслары аны һәрчакны үз итеп, якын итеп каршылыйлар.

Борис та — инженер-геолог, әмма ул нефть промыселлар идарәсенең геология бүлегендә эшли. Берсе заказчик, икенчесе подрядчик дигәндәй. Һәм алар арасында еш кына бәхәс тә кубып ала. Гадәттә сүзне, заказчик буларак, Борис кузгатып җибәрә:

— Менә, ди, фәлән скважина да суны күбрәк бирә башлады, ди. Эх, бу бораулаучыларны, җыенысын бер капчыкка тутырып, Камага гына батырасы иде, — ди.

— Тагын авыш скважинадыр әле, — дип куя Роберт гамьсез генә.

— Авыш ни, туры ни... Юньләп карамыйсыз, ни пычагыма тоталардыр бораулау конторасында геологларны? Йоклап ятыр өченме? — дип текәлә Борис.

— Кем күбрәк йоклый торгандыр әле, — дип тәрттереп ала Роберт. Шуннан кабынып китәләр инде...

Светлана аларның бәхәсеннән берни аңламый, аңа ике геологның баш орып бәхәсләшүе кызык һәм көлке тоела. Кызарып бүртенгән иренең сары чәчләрен кирегә таба сыпырып:

— Министр булгач, бик ансат хәл итәрсең, яме! Тик аңарчы шартлап әрәм була күрмә инде, жаным, — дип кыстыра.

Бу исә тегене бераз суындырып куя:

— Безгә министр булу тагы...

— Министр да барын белеп житкермәве ихтимал... Ныклап, энәсеннән җебенә тикле тикшерәсе, өйрәнәсе, беләсе нәрсәләр байтак әле безнең, — дип беркадәр дәртен баса төшә Роберт та. — Ләкин бик ашыгыч белергә кирәк. Юкса, әллә нинди байлыкларны әрәм-шәрәм итеп куюыбыз бар...

Светлананың дәфтәр тикшереп утырган чагы булса, алар гәпне бик әкрен, пышылдап кына диярлек кузгаталар, ләкин тора-бара, кулларыннан йөгәннәре ычкынып, тау астына дөбер-шатыр тәгәрәгән арба шикелле, ватыла-җимерелә башлыйлар. Ахырда Светлана, кабынып китеп:

— Колакларым тонып бетте, күземә хәреф күренмни инде, сүзегез булса, әнә урам бар сезгә, — дип тегеләрне жәһәт кенә тышка себереп чыгара. Ә инде үзе дә алҗыган булса, аны-моны әйтми, барып стенадан гитараны ала да Робертка китереп тоттыра: булды-житте, инде бүтән төрле дөньяга күчик, янәсе... Кызып, куерып, иң югары ноктасына житеп килгән гәп, кинәт өзелеп, талгын янсә дәртле музыка белән алмашына...

Ә кайсы бер көннәрдә алар тыныч кына элекке дусларын, сабакташларын искә төшереп утыралар. Мондый чакларда Робертның иреннәре күбрәк кысык була, йөзе моңсу, боек төскә керә. һәм ул тизрәк кулына гитарасын алырга ашыга...

* * *

Светлана икенче сменада укыта. Мәктәбе шәһәрнең бөтенләй икенче читендә урнашкан. Ул соңлабрак кайтасы көннәрдә, мәктәбенә кадәр үк бармаса да, Борис аны автобус тукталышына чыгып каршы ала.

Ә бер кичне Борис аның каршысына чыкмады.

Роберт белән гәп куертырга җыенып утыралар иде. Ләкин гәпләре кызып, куерып китәргә өлгермәде, Светлана кайтып керде.

Тышта шайтан җиле исә: суык, ачы, юеш... Светлананың йөзе кызарган, маңгае өстенә төшеп торган бер учма чәче тузгып тора. Гадәттәгечә, ачылып-чәчелеп китмәде, Робертка:

— Нихәл, мыекбай? — дип бик коры гына баш кагып кухняга үтте.

— Әйбәт әле, синең хәер-фатихаңда... Ә үзең ничек соң? Эшләр тәгәриме?

Ишетмәдеме, әллә ишетеп тә ишетмәмешкә салындымы, Робертның соравына Светлана эндәшмәде.

Гәпләре шып өзелгән иде, Борис белән Роберт сәерсенеп, бер-берсенә карашып куйдылар.

Уңайсыз хәлдән котылып калу нияте белән Роберт:

— Янгыр яумый торгандыр бит, Светлана? — дип сорады.

Кухня ягыннан:

— Юк... — диган коры пышылдау гына ишетелде.

Борис утырган җиреннән торып, кухняга керде:

— Ни булды әле сиңа, Света? Авырмыйсыңдыр бит?

— Юк.

— Мәктәбеңдә, классыңда берәр хәл булдымы әллә?
— Юк.
— Ә нигә болай балтасы суга төшкән кеше күк?
Борис соравына җавап ишетмәгәч, акланырга тотынды:
— Миңа үпкәләгәнсең дияр идем, гаебем юк: теге атнаның бу көнендә эшең сигездә беткән иде, ә хәзер, күрәсең, сигезенче ярты гына... Шулай булгач...
— Сезнең халык гомергә гаепсез, — дип бүлде аны Светлана, сүзен теш аралый сыгып һәм әйткәненә тирән бер мәгънә салып.
— Һе...
Борис киң җилкәләрен тартыштыргалап, кире залга чыкты, ә Роберт күңеленнән: «Буран булыр, ахрысы», дип уйлап куйды.
Ялгышмаган егет: кухняда чәй эчкәндә үк кузгалды.
Светлана ямьсез бер чырай белән җылыткыч батареяларга кулын тидереп алды да бөтен гәүдәсе белән калтырангандай булды:
— Үлек суыклары бар. Кайчан җан кертерләр инде моңа, — дип сукранып куйды.
— Берәр атнадан җылы бирә башларлар дип ишеттем мин, — диде Роберт.
— Аңарчы котельныйларын төзәтеп бетерә алсалар... — дип белдерде Борис.
Светлана боларның сүзенә илтифат итмәстән, тагын бер тапкыр уфылдап алды:
— Ичмасам, кешенеке кебек иркенләп, җылынып ятырдай урының-җирең булса икән...
— Булыр әле...
Иренең бик гамьсез төстә әйтелгән бу сүзенә яшь хатынның яман да ачуы чыкты, ахры, эчәргә дип күтәргән чәйле чынаягын шылт иттереп кире өстәлгә утыртты.
— Менә болай синең шикелле кул кушырып: «Алма — пеш, авызыма төш», дип ятсаң, булыр, булмый ни... Әнә магазинга рижский мебель кайткан, ди.
— Кайтса соң. Аны кредитка бирмиләр бит.
— Сөйләшә белсәң, ничек кенә бирәләр әле! Безнең Варвара Степановнаның ире ОРС башлыгы белән сөйләшепме-ничекме, менә дигән гарнитурны кредитка алып кайткан, ди. Син дә ир кеше ләбаса, синең дә телең бар лабаса. Кер дә сөйләш.
«Хикмәт әнә нидә икән», дип уйлап алды Роберт, проблеманың бик гади нәрсә турында икәнлегенә эче пошып...
— Шул ОРС башлыгы каршысына бил бөгеп барыйммы? Гомердә дә булмас ул.
Борис та яртылаш кына эчелгән чәйле чынаягын юан бармаклары белән өстәл уртасынарак этәреп куйды.
Хатыны аңа бер генә яндырып карап алды да:
— Кирәк булса, билеңне түгел, әллә ниләреңне бөгәрсең әле. Тормыш башлана гына... — дип тотынды яудырырга, тотынды яудырырга, билләһи, әллә нәрсәләрне исенә төшерде гайрәтле һәм ачулы яшь хатын...
Робертка мондый хәлдә өстәл артында утыруы уңайсыз да, күңелсез дә иде. Ул олы якларына чыгып, караңгылыкка күмелде. «Тыштагы буран буранмыни ул, өеңдә буран булмасын дигәннәре шулдыр инде», дип уйлады егет, бу хәлдә үзен кая куярга белмичә.
Борис, таш янгырына эләккәндәй, көрәк хәтле куллары белән башын кыскан хәлендә бер ара тын гына утыргач, авызын кыйшайтып:
— Терпи, казак, атаманом будешь! — диде, кызарып янган муен артына суккалап. — Ярый әле, рус кешесенең шул сүзе бар...

— Рус, имеш! Мин дә рус... Ә синдә рус кешесенең нинди сыйфаты бар? Череп беткән ялкаулыгыңнан бүтән, ә? Дөрес бит, Роберт?

Олы яктан дөресләгән аваз ишетелмәгәч, Светлана янәдән эндәште, ләкин янәдән тынлык... Шул чак икесе дә айнып киткәндәй булып, олы якка чыгып, ут яндырдылар. Роберттан җилләр искән иде...

Ир белән хатын, гаепле кешеләр сыман телсез калып, ачу катыш үкенүле карашларын бер-берсенә кададылар...

* * *

Җил басылды һәм Светлана, күңелендә авыр юшкын тоеп, бер төрле хәлсезлек белән раскладушкага барып утырды. Әйтергә теләгәне шул идемени? Юк өчен, чүп өчен тавыш куптарып маташты. Роберт ни уйлар? Хәер, Роберт булмаса, бәлкем, болай вакланмыйча, иренә көндез уйлаганнары, көндез кичергәннәре хакында ярып әйтер, ныклап киңәшер иде... Роберт, Роберт дус, кайчакны син дә артык булып куярсың икән... Юк, болай ярамый, кызмыйча, бар зиһенне җиеп, бер-бер чара күрергә кирәк. Әйе, дөньяда чүп-чар бетмәс, кадалып китми рижский гарнитурлары, кадалып китми ОРС башлыклары, бүтәннәре... Ләкин ире аны аңлармы, булышырга теләрме? Ул аның бердәнбер таянычы да, ышанычы да, — димәк, тиешле!

Беркадәр вакыт үткәч, Светлана тәмам сүрелгән тавыш белән иренә эндәште:

— Борис дим, кил әле, утыр әле яныма. Синең белән сөйләшәсе сүзем бар.

Борис коридорга чыга торган ишек яңагына сөялеп, папирос көйрәтеп торган җиреннән иренеп кенә борылып карады:

— Ни тагы? Әле генә сайраган идең бит. Колакта әле һаман чыңлап тора.

— Кил инде, кил. Анысына үпкәләмә, узган эшкә салават, диләр. Монысы андый чүп турында түгел. Кил инде, акыллым.

Борис шикле бер кыяфәттә, каш-маңгайларын җыерып, хатыны янына раскладушкага килеп утырды.

— Ну?

Светлана иркәләнәсе-назланасы килепме, әллә әйтер сүзен ничек башларга белмичә нәүмиз калгангамы, иренең таза иңбашына кызган яңагын куеп, тын калды, әмма бу халәт озакка сузылмады, хатын кинәт сискәнеп кузгалды да Борисның сыек зәңгәр күзләренә үткен, сынаулы карашын текәде.

— Борис, мин сораганнарга син дөресен, дөп-дөресен генә әйтерсең, яме!

Тегесе аптыраган хәлдә күзләрен йомгалады.

— Ә минем кайчан алдаганым бар?

— Бар, димим. Сүз синең үзең турында түгел дә... Әйт әле, акыллым, син Әхсәнне бик шәп беләсеңме?

— Белмәскә, биш ел бүе бергә укыдык ла без... Ә нигә ул сиңа?

— Ниндирәк бәндә ул синең Әхсәнең? Шәп спортсмен, ярыйсы гына әйбәт активист — боларын үзем дә беләм. Кешегә мөгамәләдә ничек дим?

— Әйбәт... Андый иптәшне эзләп табасы бар әле!

— Егетләргә шулайдыр... Ә кызларга?

— Кызык та кеше син: кыз ни, егет ни — барыбер түгелмени?

— Барыбер булса, син миңа өйләнмәс идең. Юкны лыгырдама! Берсен башлап, берсен ташлап йөридер идеме?

Борис чиксез гаҗәпләнүен белгертү өчен кулларын җәйде:

— Каян белим инде аны?

— Юк, мин синнән сорыйм: студент чагында кемнәрнең башына житте ул? Яле, исеңә төшер әле! — Светлананың тәкате югала барып, күз кырыйларында зәһәрләнү җыерчыклары калыкты.

— Булмаганны ничек исемә төшерим, ди? Кызлар үзләре аның муенына асылынырга торалар иде. Ну, бит моны сукыр да күргәндер... Теләсә кемгә бәйләнергә ахмак түгел лә ул...

— Мактыйсың? Әүлия дисең? Ә беләсеңме, синең шул әүлияң безнең алтын бәһасе торырдай кызыбызның башына җиткән, ә? — Светлана җәһәт кубарылып, тәрәзә төбендә өелеп яткан дәфтәрләр арасыннан бер хат табып алды да иренә тоттырды: — Мә, укы! Монда ялган булмас!

Хат ерак авылда укытып яткан Гөлсинәдән иде. Светлана аны Борис эштә чагында көндез үк алган һәм күңелендә ярсып бөтерелгән өермә дә шуның сәбәбеннән иде.

Кыз: «Синнән якын сердәшем юк, түзәр әмәлем калмады, безнең хәлләр монда бик мөшкелләнеп китте әле — Әлбинәбез Әхсәннән йөкле икән бит», диган дә, «сиңа барын-барын язам, Әхсән сездән ерак түгел, бәлкем, аңа бер төсле йогынты ясый алырсыз, әле соң түгел», дип үтенгән. Гөлсинә хатында, чыннан да, барын да әйтеп язган иде...

Светлана иренең укып бетерүен башын түбән иеп һәм юка иреннәрен кыскан хәлдә түземсезләнеп көтте. Теге хатны тәрәзә төбенә китереп кую белән үк аңа калтыранган тавыш белән утта кыздырылган хәнҗәрдәй яндырып кадалды:

— Я, ни әйтерсең? Шәпме дустың?

Борис иң әүвәл папиросына ут кабызды, шырпысын сызганда аның бармаклары сизелерлек дерелди иде.

— Ә бәлкем гаеп аңарда да түгелдер. Кыз үзе теләмәсә...

— Ә?! Ни сөйлисең син?

— Дөньяда булмый торган эш түгел дим...

Светлана бәбәкләрен агартып иренә карады.

— Әле һаман яклашасыңмы? Юк инде. Булдыра алган икән, баласының атасы да була белсен! Аның белән шаярмыйлар, бәбекәм!.. Сиңа шул: иртәгә үк барасың, ныклап, миенә, бәгыренә сеңәрлек итеп сөйләшәсең — акылына килә икән, килсен, килмәсә, битлеген ертып, подлец, эт җан икәнлеген фаш итми калмабыз...

Борис, тотлыгып пышылдады:

— Син нәрсә, син нәрсә? Баш кода булып, бил бөгеп барыргамы?

— Ә нигә бөгәргә? Дусың бит, якасыннан эләктереп сөйләш.

— Юк, бармыйм!

— Юк, Борис, барасың. Дусыңа яхшылык теләсәң, бармыйча булдыра алмассың, — диде Светлана һәм иренә якын ук килеп, кулын аның иңбашына салды. Аннары әчке бер пышылдау белән әйтте: — Бәлкем, аңына килер?

Борис беравык иренен чәйнәп, дәшми торды, аннары:

— Ну, ярый, барып сөйләшеп карармын, — дип, сүнгән папиросына ут алды.

Икенче көнне Борис, эшеннән рөхсәт сорапмы, әллә беркемгә әйтминитми генәме, төш үтү белән үк Әхсән янына чыгып китте. Ара артык ерак түгел — автобуста сәгать ярымлык юл, кичкә кайтып житәрмен дип ышандырды. Светлана аның кайтуын түземсезләнеп көтте... Акылына килерме инде теге бәндә кисәге? Борис сөйләшә белсә генә ярар иде...

Бу көндә, бу сәгатьтә тегендә Әлбинә нишли, ниләр кичереп, ниләр уйлап ята микән? Ана буласы кеше... Бала, бала... Туармы, тудырырмы? Әллә үзенә хат язаргамы? «Бернигә карама, тудыр, ана бәхете ике килми ул, аңла», дип? Беренчесе бит... Тукта, сабыр итик, көтик әле, Әхсән ни дияр бит тагы... Бала, бала... Дөнья яме, дөнья күрке

бала... Светлана үзенекен музыкант булыр дип хыялында тота. Кыз булса да, малай булса да... Борис аны «футболист» булыр, ди, җүләр... Ә ул тегендә кемне көтә? Дөньяда иң изге бер нәрсәне хурлык, бәла, һәлакәт дип кабул иткән ирсез яшь хатын кемне көтәргә тиешле соң?.. Ох, Әлбинә, күңел кошым, ничек абайламадың, ничек бу хәлгә төшәрлек булдың соң син? Күңелең артык саф, артык пакь һәм артык матур булгангамы, кешеләргә артык ышанучан булуың беләнме?..

Борис: «Кичке унайга әйләнеп кайтырмын», дигән иде. Ләкин вәгъдәсендә тормады. Светлананың түземе ахыр чиккә җиткәндә, төн урталарында гына шактый ук шәбәреп кайтып керде ул. Светлана өмет белән иренә текәлде:

— Я, ни булды? Ничегрәк ди?

— Ни булсын, футбол карадык. Шунда бераз кәгеп тә алдык. Әлмәтлеләр — молодцы, шәп уйнадылар...

— Күрәм... Сөйләштеңме дим?

— Әһе, Әлбинә турында димсен... Сөйләштем.

— Нәрсә ди? Кушылырга исәбе бармы?

— Нишләп кушылсын? «Минекеме, түгелме әле ул — алла белә», ди... Әйттем бит мин сиңа бармас ул аңа дип...

Светлана янәдән ярсуына буыла башлап, тамак төбеннән тик пышылдау гына сыгып чыгара алды:

— Кабахәт!.. Сволочь!

Борис ирennәрен бөрештереп һәм кулларын киң җәеп хатынына якынлашты:

— Ә син миңа үпкәләмә, сылуым. Минем бер тамчы да гаебем юк...

Светлана аңа арты белән борылып тәрәзә янына барып басты... Инде ни кылырга? Шушы хәлендә, кемәне борынына төртелергә торганда, үзе барсынмы? Оят. Оят булса соң... Ну, барса, күрсәтер күрмешен... Каны кызган, чигә тамырлары авырттырып ук тибә. Юк, дуларга, ярсырга, чыгырдан чыгарга ярамый. Акыл белән, акыл белән!.. Күз алдына кинәт Роберт килеп басты. Тукта, менә кем бар бит әле. Пешмәгән бәлеш булмас. Кемнең кайчан дус, кайчан дошман булырга тиешлеген аңа төшендереп торасы юк. Аннан күз күрер...

* * *

Бораулау конторасында эш көне башланып киткән генә иде әле. Робертка коридорда аны ниндидер бер хатын көткәнлеген әйттеләр. Егет, бу хәбәргә хәйран калып, күзлеген бер маңгаена менгезде, бер үз урынына борыны өстенә утыртты, аннары, бүлмәдәшләренең мыек астыннан гына елмаешуына игътибар итмәстән, өстәлгә җәеп салган карталарыннан аерылып, коридорга чыкты. Чыкса, Светлана...

— Ни булды, Света? — дип сорады Роберт, хатынга баштанаяк күз йөртеп һәм яман бер хәл ишетәсен күңеленнән сизеп.

— Бераз сөйләшеп алырга вакытың бармы, Роберт? Булса, бакчага гына чыгыйк әле, — дип үтенде Светлана.

Контора янындагы куе агачлы бакчага чыктылар. Баш очларында инде шәрәләнеп бетә язган өрәнге ботаклары селкенә, җиргә сары яфраклар түшәлгән. Кунган яфракларны сыпырып, эскәмиягә утырдылар.

Светлана бу егеткә сүзне ерактан, дуслык һәм иптәшлек, вөҗдан һәм намус дигән нәрсәләрдән ук башларга ниятләп килгән иде, янәсе, студент чакларында аз бәхәс куптармаган һәм канга сеңәргә тиешле әйберләрне искә алу зыян итмәс...

Ләкин ул, эскәмиягә утырып, Робертның күзлек аша да эчкерсез нур бөркеп караган акыллы һәм уйчан күзләрен күргәч:

— Беләсеңме нәрсә? Ни... — дип беравык тотлыгып торды да, әлгәреге исәбенә кул селтәп, вакыйганың-хәлнең эченә турыдан-туры алып кереп китте...

Роберт берни сорамады, бүлмәде, иреннәрен кысып, хәрәкәтсез утыра бирде. Башта аның йөзенә кызыллык йөгерде, агарынып катып калды...

— Институттан аерылдык дигәч тә, кешене ташларга ярамый бит. Анда булса, эшне йөртә белер идек... Әхсән, бәлкем, шуңа исәп тоткандыр да... Әлбинәне беләм мин — бик әйбәт кыз ул. Тик бу хәлендә әллә ниләр эшләп ташлавы бар... Бәладән башаяк... Син, Роберт, Әхсән белән ныклап сөйләшеп карасаң иде, бәлкем, сине тыңлар, акылына кайтыр... Бориска үземнең дә өметем юк иде. Ә син бөтенләй бүтән бит... Сөйләшерсеңме, булдырырсыңмы шуны, Роберт, акыллым?

Егет аяк астындагы сары яфракларга текәлгән көенчә, агарынып-каткан йөз белән һаман бер хәлаттә утыра да утыра. Ниһаять, аның сызылып киткән тар кара мыек тирәсенә җан кереп, селкенеп алды:

— Ярый, Светлана...

## «Башыңа тай типмәгән булса...»

Нефтьчеләрнең үзәк каласы Робертны караңгы чырай белән каршы алды.

Табигатьнең елак чагы: ачы җилдә дулкын-дулкын булып сибәләгән вак яңгыр, асфальт өстенә меңгән ике илле үзле туфрак белән катышып изелгән сансыз яфраклар, шул измәдә сак-сак басып атлаучы адәмнәр... Багана башларына утырган электр фонарьларына хәтле тонык яна бүген...

Ничек ирешкәндер, Әхсән нефтьчеләр гостиницасында бер үзенә аерым номер алып яши. Ләкин ул өйдә юк иде. Дежур апа каршысына баскан күн тужуркалы, күзлекле егеткә бер генә күз атып алды да:

— Юк дим бит, юк... Ышанмасаң, менә ачкычы, — дип тиз генә котылырга ниятләде.

— Ә сез аның кайчан кайтасын әйтә алмыйсызмы? — дип төпченеп карады Роберт.

— Белмим. Аның ялгыз башы...

Хәерсез, килүе бушка булыр микәнни? Нишлисең, «ялгыз башы» кешенең... Роберт үзе дә шундый бит....

Шәһәр урамнарында юеш һавада, пычрак изеп байтак йөрергә туры килде Робертка. Бер әйләнә дә тагын килә гостиницага, ләкин теге һаман юк та юк... Техника йортында татар спектакле башланды. Халыкның шушындый алама кичне дә агылып килүенә һәм ара-тирә ычкынгалаган сүзләренә караганда, спектакль күңелле булырга тиешле. Робертның татар спектакленә бармаганына байтак инде. «Әхсән качмас әле, аның белән сөйләшергә төн бар», дип, Роберт халык агымына кушылырга ниятләде, әмма аягындагы күн итекләргә күз салгач, кул селтәде. Күрмәгәне түгел...

Гастрономия кибете яныннан узган чагында аны ике адәм туктатты. Берсе, брезент киеме өстеннән җилкә аша күн сумка асканы, күкрәк турысына өч бармагын куйды, ә икенчесе, яньчелгән эшләпәсен кыек салганы, каш сикертеп ым какты... «Кәефнең дә начар чагы, кыюлык өчен дә зыян итмәс иде... Ләкин аек акыл кирәк шул... Юк, ярамый, ярамый...»

Тегеләр күн итекләре белән асфальтка шакы-шокы басып, ашыкмыйча гына китеп барган күзлекле егет артыннан: «Җүләр, өенә кайткач, мең үкенерсең әле», дип шыңгырдап калдылар.

Урамда болай кангырып йөрүдән файда чыкмас. Ичмаса, кинога кереп утырырга кирәк. Әнә сигез дә утызда башлана, дигән. Ул арада Әхсән дә кайтып өлгерер.

Роберт барган жиреннән капылт борылып, кинотеатрга табан юл алды.

Кинотеатрга барып житәр-житмәстә, егет кинәт туктап калды: каршысына тигез, эре басып һәм кулларын киң селкеп, көткән кешесе килә иде. Өстендә болони плащ, әмма башы ялангач... Теге дә ерактан ук Робертны күреп, танып алды һәм авызын колагына тикле ерды.

— Вот очрашу, ә? Ничек болай? — диде ул, бер кулы белән Робертның кулын кысып, икенчесе белән аның жилкә тамырына дусларча якынлык белән суккалап.

— Килдем менә... Мин сине байтактан көтеп йөрим инде.

— Шулаймы? Эш муеннан бит, туган. Беләсең, спорт эшләрен тактылар мина... Волейболчыларны туплый алдым, инде баскет калды. Тренировкалардан үлсәң дә ычкынып булмый, дип зарланып алды Әхсән һәм иптәшенә шундук шелтә дә белгертеп куйды: — Киләсенне әйтеп, алдан шалтыраткан булсаң, болай кангырып йөрмәс идең. Үзеңә үпкәлә, туган!

— Зыян юк. Төн безнеке, — дип акланырга тиеш тапты Роберт.

— Дөрес, төн безнеке. Миндә генә куныp китәрсең. Ә хәзер, ә хәзер.. Очрашуны коры уздыру килешмәс, киттек ресторанга! Шәп булды әле бу, үземнен дә кәефсезрәк чак иде.

Лэкин Роберт ресторанга барудан баш тартты:

— Күзгә күз текәп сөйләшәсе сүзләр бар, үзеңдә генә утырыйк, — диде.

Әхсән, иптәшенә сәерсенеп карап алгач, артык кыстап тормыйча:

— Ярый, ихтыярың. Анда да әмәлли белербез, — дип чигенде тагын.

Әхсәннең бүлмәсе ярыйсы гына шәп хак түләп яшәүчеләр өчен жайланган, хәтта йомшак диванга тикле бар. Хужа кунак егетне әнә шул диванга утыртты да:

— Син чак кына көт, ә мин хәзер әйләнәм. Ресторан буфетында дуслык шәп минем, — дип чыгып китте.

Роберт бөек художник тарафыннан төшерелеп тә, меңләгән куллар тарафыннан өзлексез күчерелә килгән мәһабәт нарат урманы күренешенең тагын бер шыксыз һәм зәвыксыз ясалган вариантына чак кына карап торды да карашын түбән төшерде. Ялтыравык буяулы киң тахта, аның өстендә чип-чиста ике мендәр... «Тормышын үз жаена корып жибәргән бу...» Шул күренештәнме, әллә уеның ямьсезлегеннәнме, Робертка кинәт бик күнелсез булып китте... Нигә килде ул? Сөйләшүенең файдасы булырмы?

Әхсәннең буфетта дуслыгы чыннан да шәп икән. Кулына акка чорналган зур гына кәрзинкә күтәреп килеп керде дә, күз ачып йомганчы түгәрәк өстәлне тәмле һәм туклыклы ризыклар белән тутырып, уртага шалт иттереп елык-елык нурланган бер «столичный»ны утыртып куйды. Аннары, бары да булганмы дип, бер тын күз йөртеп торды да, бармагын шартлатып, кунагына эндәште:

— Әйдә, Роберт, күченеп утыр!

Роберт өстәл янына күчеп утыргач, гаҗәпсенүен яшереп кала алмыйча:

— Байларча торасың икән... Әкәмәт! — дип куйды.

— Байларча дип... гел алай түгел инде ул. Кунак хөрмәтенә генә... Монда килгәч, безнең әйбәтләп утырган да юк бит әле. Борис белән генә булды бер. Күпкә китсә, үзең дә беләсең, Касимский Ибрай кебек, штансыз калуың да бик мөмкин...

— Юк, мин синең яшәү шартларың турында әйтәм әле...

Әхсән калын көрән кашлары астыннан иптәшенә сынаулы караш ташлап алды, янәсе, нәрсәгәдер төрттерүе түгелме...

— Ә нәрсәсенә шаккатарга? — диде ул, гамьсезрәк төс сакларга тырышып. — Гостиница үзебезнеке ләбаса. Җайлый-сөйләшә белсәң, ул хәтле каерып алмыйлар. Берәр тулай торакка урнашсаң да булыр иде, ләкин, ни генә димә, монда үзеңә-үзең хуҗа инде. Әлегә сүз кузгатмыйлар. Мин аларга, геолог булуым өстенә, спорт камытын да муенга таккансыз икән, инде бу ягын да кайгырта белегез дип, бик нык терәдем. Тик бу рәхәтләр озакка сузылмастыр кебек: яңа йорттан квартира бирергә җыеналар.

— Әллә өйләнеп җибәрергә исәпме?

— Өйләнеп? Башны бу яшьтән элмәккә тыгаргамы? Хе-хе, син Роберт, бигрәк инде... -- Әхсән озын муенлы рюмкаларга аракы салып чыкты да иптәшенә ым кагып елмайды: — Әйдә, очрашу хөрмәтенә, синең саулыкка!

— Әйдә, уңышлар өчен!

Бераз капкалап алгач, Әхсән өстәлгә ята төшеп Робертка текәлде:

— Өйләнәм дисәң, монда, парень, отбой юк. Менә дигән ике врач кыз бар, бу елны гына бетереп килгәннәр. Аннан тагы төзүчеләр трестында берәү... Ну, күрсәң иде! Бер кашык су белән йотарлык! Таныштырыйммы әллә үзеңне? Шалтыратыйкмы?

— Рәхмәт, кирәкми... Ә теге ни белән... — Роберт, тамак төбенә кунган төерне йотып җибәргәч, эчке бер калтырану аша сорап куйды: — Әлбинә белән ничек дим?

Тегенең йөзе-кыяфәте үзгәреп, аскы иренен тешләде.

— Әлбинә... Әйбәт кыз, чибәр кыз, акыллы кыз иде... Җәл... Ул анда, мин монда дигәндәй... Ну, ярый, юк белән башны катырмыйк, куеп торыйк аны...

Җепнең кулга эләккән очын ычкындырырга ярамый иде, Роберт, тавышына ничектер ныклык, катылык кертә алып, Әхсәнгә кадалды:

— Түгел, юк эш түгел! Әйт әле син миңа: нишләмәкче буласың аның белән?

— Нишлим, ди? Вот интересно! Ул үз ирегендә, мин үз ирегемдә... Булган — беткән! И нечево монда...

— Бетмәгән! Син аңа өйләнәм дип акыл сатып йөргән көннәреңне исеңә төшер... Әллә без төшерикме?

— Туктале, ни дип бәйләнәсең? Бер көнне Борис, бүген син... Яучылар, имеш! — Әхсән утырган җиреннән кызуланып торды да бүлмәсен бер-ике әйләнеп килде. — Аңла син, аңла: күңелемдә, йөрәгемдә берни юк минем, бернинди хис, бернинди яну, бернинди теләк, омтылыш... Элекке романтик, буш, коры мавыгу гына булган, күрәсең. Ул үзе дә моны аңларга тиеш. Мондый хәлдә өйләнешү үзе ахмаклык ул...

— Алайса, Әлбинәне икенче берәүгә алмаштырдың?

— Юк дим, юк! Күкрәктә берни юк дим... Тик авыр җәрәхәт кенә...

— Нинди җәрәхәт икән ул, әйтсәң иде?.. — Роберт моны авызын кыйшайта төшеп, мәсхәрәле бер тонда сорады.

Әхсән аның тавышына игътибар итмәдеме, бик зур хафага калган кеше кебек, уйчанланып бер ноктага текәлгән хәлдә сыкранып алды:

— Үкенү җәрәхәте... Шул кызыйга кагылмаган булсам икән...

Роберт, Әхсәннең ясалма кыланышына җавап итеп, теш аралый сыгып чыгарды:

— Бигрәк мескен икән син...

— Ярар, мыскылыңны куй. Таптың сөйләшер сүз. Әйдә, күтәрик тә берне, үз эшләребез хакында сөйләшик лучше. Без бит геологлар... Әйе, прежде всего геологлар...

Роберт сузылган рюмканы кире үз урынына утыртып куйды. Аның эчендә янәдән ярсу кузгалып килә һәм ул күңеленнән: «Кызмыйк,

ярамый, ярамый», дип, нервыларын кулга алырга тырыша иде. Шулай да күңелендә айкалган сорауны ярып салды:

— Ә син аның баласының атасы икәнеңне беләсеңме? Беләсең. Ә ул ни хәлдә ятырга тиешле? Укытучы башы белән? Авыл җирендә? Шул хакта уйлаганың бармы?

Авырткан сөяленә бастыларымы, Әхсәннең кашы-күзе тагын җимерелде, хәтта ухылдап ук куйды.

— Ана, имеш, ата имеш... Укыта, имеш... Һаман бер нәрсәне чәйнилләр. Гарык булдым. Әйтерсең, гаеп миндә генә, әйтерсең, ул фәрештә...

— Башыңа тай типмәгән булса, акылыңа кил, Әхсән! Әле соң түгел.

— Куркытма, яме! Безнең нәсел үзе дә чәйнәми өзми, — Әхсән үзе дә кызып китүдән файда булмаячагын төшенеп, ахры, кисәк пышылдап гыжлауга күчте. — Ә син беләсеңме соң үзең: бер ялгышып кагылсаң, кызлар гел шулай алар? Муеныңны гына куй, хәзер килеп асылыначаклар... Ә мин кемнәрнеңдер сүзенә карап, башымны элмәккә тыгыйммы?

Әхсән «ялгышкан-саташкан» кызлар хакында тагын әллә ниләр тезеп алып китте, әмма һәммә әйткәне пычрак, пычрак, пычрак атудан гыйбарәт иде...

— Житте, Әлбинәгә тимә син! — дип буыла башлады Роберт.

— Эһе, яклыйсың... җәллисең, — диде Әхсән көлемсерәп һәм, зур сер әйтергә җыенган кеше кебек, кунак егет колагына таба иелә төшеп, өзеп-өзеп пышылдады: — Ә мин бик яхшы беләм, парень. Син аңа үзең дә муеннан гашыйк идең. Ләкин кайгырма, дускай: берни югалтмадың. Миңа кадәр дә кыз түгел иде, значит, миннән соң да... Ә син ата бул, дисең... Нечево тужить безгә!

«Чеп-чи ялган!... Юха елан син, елан!» — дип кычкырасы иде, әмма Робертның авызыннан тавыш чыга алмады. Ул, эчтә нәрсәнеңдер кайнап шартлавын тойган хәлендә, үз-үзен белешмичә, күз алдында елмаеп җәелгән йөзгә сугып җибәрде. Мондый хәлне Әхсән көтмәгән иде булса кирәк, артка таба чигенеп, бер мизгел күзләрен акайтып катып торды, аннары:

— Моңа кадәр миңа кул тигезгән кеше юк иде... Ах, көчек! — дип, яман сүгенеп алга ыргылды да кунак егетне бер селтәнүдә әллә кая почмакка тәгәрәтеп җибәрде. Нидер җимерелде, нидер коелып төште...

Күз ачып йомган арада алар — баһадир гәүдәле бүлмә хуҗасы һәм тар җилкәле, чандыр кунак егет — авыр сулап, яңадан сугышып китәргә әзерләнгән этәчләр шикелле, бер-берсенең каршысында басып торалар иде инде. Ләкин эш тагын да зурракка китмәде.

Әхсән үзен тизрәк кулга алды. Ул Робертның идәнгә төшеп калган күзлеген алып, иясенә сузды да елмаерга тырышып:

— Булды, аңлаштык... Юк кына нәрсә өчен араларны бозмыйк, давай күтәрик әле, — дип өстәл янына килде.

Роберт аңа күзлек аша яндырып карап торды да моңарчы әйтә алмаганын җан ачуы белән сытып чыгарды:

— Кан төкерәсе көннәрең алда әле, белеп тор!

Күн итекләре белән гостиница идәненә шакы-шокы басып атлаган егет артыннан ялыну катыш үкенгән тонда ачы тавыш янгырады:

— Роберт дим, Роберт! Туктале!..

Ләкин Әхсәндә кунак егетне туктатырлык көч тә, әмәл дә юк иде инде...

* * *

Кыеклатып искән әче җилгә каршы асфальт юл белән шакы-шокы атлады да атлады ул. Төнге шәһәр, тоныкутлары белән балкып, артта калды. Атлаган саен, каты асфальтка шак-шок баскан саен, зиһенендә бөтерелгән чуалчык уйлар, күңелен айкаган яман хисләр ничектер

куера, тыгызлана һәм бер тәртипкә килеп, катлам-катлам урнаша бара сыман, гүя җир-ана артык вак, артык чүп нәрсәләрне үзенә суыра-йота да егетне арындырырга, сафландырырга тырыша иде... Юл туры, юл нык, ышанычлы, әмма ул алда соры караңгылыкка китеп югала. Тик сирәк-мирәк кенә ул караңгылыктан утлы шарлар атылып, тәгәрәп киләләр дә Роберт яныннан выжлатып үтеп китәләр. Егет читкә тайпыла, артларыннан карап кала... Юл уңаена тәгәрәгәннәренә дә кул күтәрми, туктатмый: аның ашыгыр җире юк...

Шактый юл алгач, үр битенә менгәндә, тукталып, артка табан борылып карап торды.

Шәһәр әллә кайларга кадәр сузылып киткән. Меңләгән утлар балкый, меңнәре инде сүнгән. Кешеләр тыныч йокыларына талганнардыр...

Яшәү гомере чирек гасыр да исәпләнмәгән яшь һәм данлы кала, үзләренең батыр йөрәкләре һәм фидакарь эшләре белән шул аз гына арада да ил тарихына иң күркәм, иң калку сызыкларны сала белгән кешеләр... Кала, кала, кешеләр, кешеләр... Беләсезме, сезнең арада берәү бар — ул сезнең изге җирегезгә орлык салып, тамыр җибәрергә килгән. Сез аның килеш-килбәтенә, шома теленә сокланырсыз, спорт мәйданнарында күрсәткән гайрәтенә хәйран калырсыз, бәлкем, хезмәтендә дә сезне шаккатырыр нәрсәләр китереп чыгара алыр ул... Ләкин иң матур теләк-омтылышларыгызны, иң якты һәм иң мөкатдәс хисләрегезне аяусыз таптап йөриячәк, рәхмәт урынына йөзегезгә төкереп үтәчәк... Вакытында күрә алырсызмы, саклана белерсезме, кешеләр?

Вуз, дибез, институт-университет, дибез, баш ярып бәхәсләшәбез, үсәбез-тәрбияләнәбез, чын рухлы кеше булабыз, дибез, ләкин анда еш кына бары да шома һәм ыспай үтә, үткен тырнаклар яшеренгән көе кала бирә, аждаһа күңелләр чуар пәрдәләргә төренеп, посып ятуын белә... Шул ышыктан, шул рәхәт түбә астыннан чыгып, олы юлдан тормыш дигәннәренең тар, аулак сукмакларына баскач кына кемнең нигә сәләтлелеге, кемнең асыл кемлеге чын йөзе белән калкып күренә башлый. Аяныч, бик тә аяныч... Әмма Робертның, болай дип, акланырга хакы бармы соң? Ни генә булмасын, ул бәндәнең тамырын, ныгып һәм җәелеп киткәнче, тоз сибеп корытырга кирәк. Моның өчен аның таянычы юк түгел: Светалар, бүтәннәр бар, комсомол бар...

Әлбинә, Әлбинә... Син бу минутларда ни кыласың, ни уйлыйсың икән? Аны уйлыйсындыр, һаман да аңа өмет итәсеңдер, аны көтәсеңдер әле... Көтмә, уйлама син аны. Әхсән үлгән, беткән дип исәпләсәң, үзеңә җиңелрәк булыр... Кайчандыр сөйгән, «җаным-бәгырем» дип йөргән кешесенә тагын кемнең шул хәтле пычрак атарга кулыннан килер иде микән? Аны ишетсәң, тетрәнер, юк, шартлап ярылыр идең... Бәхетең, андый бәндә белән тормыш җепләрең үрелеп китмәгән. Хәзерге авыр һәм аяныч хәлең алдагы язмышыңда ихтималы зур булган тагын да аянычрак һәм дәһшәтлерәк афәтләрдән саклап калуыдыр, бәлкем... Куаныч түгел бу сиңа, тик йөрәгеңнең авыр җәрәхәтенә бер тамчы дару гына...

Әлбинә, Әлбинә... Инде ничек ярдәм итәргә, ничек терәк булырга сиңа? Робертның күңелендә сиңа багышлаган шигырь һәм җырларның саны юк... Сине күреп яшәгән чагында да, күренмәс булгач та, озын керфекле, мөлаем елмаючан кызны хыял күгендә, күңел түрендә кадерләп саклап, һаман да шул җыр-шигырьләрне исенә төшереп яшәде ул. Шуларны җибәреп юатыргамы әллә үзеңне? Ләкин ни файда, ни файда?

Асфальт юлдан шакы-шокы, шакы-шокы атлый да атлый егет.

Алда, бер үр аша үтүенә, караңгылык пәрдәсен кысрыклап янган бер факел күренде. Бөтен бер урман итәгенә ут капкан сыман...

Адымын тизләтте.

Бүтән вакытларда нефть җирләрендә янган бихисап факелларга ничектер исе китми, ул аларга инде күнеккән, тик кайчакларда гына: «Никадәр байлыкны харап итәбез, шайтан», дип йөрәге әрнеп куя иде.

Бүген ул әче җилдә котырынган факел ялкыныннан күзен алмады. Тизрәк аның турысына барып җитәсе килде.

Җиткәч, юлдан чак кына тайпылып, каршысында тукталды... Каты яна, шашынып яна. Ахры, берничә скважинаның газыдыр. Нефтькә ияреп чыккан газ. Ияреп чыккан ялкын, шашыну, ярсу. Дәһшәтле шашу... Роберт кинәт үзен шушы ярсып шаулаган факелга тиңләде. Ул да бит шулай кемнәрнеңдер мәхәббәтенә, кайгы-хәсрәтенә җинеллек итәм дип, ияреп кенә яна, ияреп кенә көя... Ялкыны көчле, куәтле, әмма аңардан кемгә рәхәт, кемгә бәхет?.. Бер тиен файдасыз яну... Ә нигә, ә нигә? Теләсен, күнсен генә, хәзер Роберт аны үз ялкыны җылысына, үз яктысына суырып кына алыр иде... Әлбинә, Әлбинә... Бәлкем, чыннан да, ә?!

Роберт дәһшәтләнеп дөрләгән зур ялкынга текәлгән хәлендә үзенең эчендә каяндыр бик тирәннән, төптән бик әһәмиятле һәм гайрәтле бер нәрсәнең кузгалып, күтәрелеп килгәнлеген тойды. Әлегә, эрегән металлныкы шикелле, аның чикләре дә юк, ныгып та өлгермәгән, тик олы бер теләк-омтылыш кына, әмма ул озакламас, суына төшеп, корычтай ихтыяри көчкә, ныклы, чигенмәс карар рәвешенә килер... Кинәт егет, җанына рәхәт итеп, арган гәүдәсенә канатлар үсеп чыккандай хис итте...

Арттан юл уңаена ике ут шары тәгәрәп килә иде. Егет кул күтәрүгә шарлар, куркыныч шыгырдап, шып туктадылар. Кузовка басып, йөзен каты җилгә каршы куйган егет, бераз юл алгач, борылып артына карады. Һәм ихтыярсыздан газ факелына кул болгады. Теге дә караңгылык пәрдәсен үрсәләнеп ялаган телләре белән аңа хушлашу сәламен җибәрә иде сыман...

* * *

Светлана Робертның әлеге сәфәргә барып кайтканлыгын ире Персистан ишеткән иде инде. Ләкин менә ике-өч көн инде күзлекле егетнең килеп күренгәне юк: буровойлардан көн-төн кайтмыйча ята, ди. Робертның уңышсызлыкка очравы аны гаҗәпләндермәде. Әхсәннән юньле нәрсә көтәрлек түгел, күрәсең... Светлана, күңелендә ачуы соң дәрәҗәдә кабарып, Берләшмәнең үзендә җил-давыллар уйнатырга әзерләнеп тора: «Белсеннәр атаклы спортчыларының ни белән дә данлы икәнен!» ди, тузына, ләкин Роберт белән сөйләшмичә торып, зәһәрле сәфәргә чыгуын кичектереп килә, чөнки Әхсән белән соңгы сөйләшүнең бөтен ваклыкларына хәтле ишетмәс-белмәс борын андый җитди нәрсәне куптарырга ярамас дип исәпли иде.

Ниһаять, «мыекбай» аның каршысында... Алҗыган, тәмам беткән кыяфәт, төн йокылары да әләкмәгән, ахрысы: күзлек аша да күзләренең шешенеп-кызарып торганлыгы әллә каян беленә.

Светлананың сорауларына җавап итеп, ул кул гына селтәде:

— Сагынып сөйләрлеге юк... Аңардан өметенне өз!

— Мин аңа өметләнмим дә... Бөтен коллективы алдында яктыга чыгарып, якасыннан селкәм мин аның!.. Болай булгач, иртәгә үк китәм!

— Ярый, китәрсең, якасыннан тотып селкерсең, — дип авызын кыйшайтып елмайды Роберт һәм кинәт җитди төс алып, яшь хатынның беләгеннән тотты: — Тик син минем Әлбинә янына барып кайтканны гына көт инде...

Хатын, егетнең кулын алып, артка чигенде:

— Әлбинә янына? Ничек алай?

— Шаярта ул, — дип сүзгә кысылды Борис.

— Шаяртмыйм, чынлап әйтәм. Юлларын өйрәндем, барып кайтырга мотоцикл да сөйләштем. Ике йөз чакрым арамыни ул?

— Эшеңнән җибәрәләрме соң? — Моны хатыны аңга килгәнче Борис сорап куйды.

— Анысын да сөйләштем. Иртәгә буровойның эшен бетергәч, берсекөнгә юлга чыгам. Ике көн отгулым бар минем... Анда барып кайтырга бик җиткән!

— Роберт, акыллым, сәбәбе ни? Әйт инде, яшермә, — дип, кулларын күкрәгендә кушырып, төпченергә тотынды Светлана.

— Кайткач, Светлана, кайткач... Әлегә үзем дә ни буласын белмим. Тик ни... сез мина бер егерме сум биреп торыгыз әле. Юлда кирәк булуы ихтимал.

— Менә әкәмәт...

Тагын сораша башлап, серенең төбенә төшәрләр дип курыктымы, Роберт кулына акча керү белән үк саубуллашып чыгып китте. Светлана белән Борис, бу хәлне ничек юрарга белмичә, бер-берсенә карашып, тәмам аптыраган кыяфәттә басып калдылар.

## «Мин синеке, ләкин...»

Юл азабы — гүр газабы, диләр. Ләкин Роберт юлда артык җәфа күрмәде. Аның бәхетенә, иртән башланган пыскак яңгыр, ничектер озакка сузылмыйча, туктый белде, төш якынлашканда хәтта күк гөмбәзе беркадәр ачыла төшеп, ара-тирә кояш нурлары күренгәләде. Әмма иң кадерлесе ул утырган «Иж»ның шәплеге иде: мотоцикл, нясенең кая һәм нигә ашыкканлыгын белгән җанлы да, аңлы да бер нәрсә шикелле, күкрәгендә ярсу нәфрәт кайнатып, һаман да алга ыргылуында булды. Озын юл тизлек белән кыскара барды, кыскара барды...

Менә, ниһаять, берничә сәгатьләр буе дерелдәп-очынып килгән юлчы таш юл белән киң һәм зур сулы елга ярына җитеп туктады.

Монда гына егетнең бәхете йоклаган булып чыкты: паром әле генә бу ярдан кузгалып киткән иде. Бөтенләй буш диярлек. Аръякта да автомашиналар әллә ни күренми. Хәерсез, бу паром дигән нәрсәкәй тиз генә әйләнеп килмәс, ахрысы...

Каршы якта озын үр бите буйлап җыйнак кына шәһәр җәелеп ята. Урта тирәдәрәк, пристань турысында йортлар икешәр-өчәр катлы күренә, байтагы сарылы-яшелле агачлар арасында күмелгән. Яңа йортлар шәһәр читендәрәк бушрак җирләрдә калкып утыралар. Нишләптер барысы да сап-сары төстә.

Шушы шәһәргә килеп йөри инде ул, шушыннан аның кебекләр белән җитәкчелек итәләр. Тагын егерме-утыз чакрымлык юл. Авылы олы юлдан бераз читтәрәк аның. Анда артык израэтмәдеме икән?.. Әлбинә, Әлбинә... Чак кына сизенәме икән кем киләсен? Телеграмманы алгач, Әхсән дип уйлагандыр әле. «Якын дустың» дигәнне тагын ничек юрарга мөмкин соң аңа?

Елга шаулый. Җил су өстендә куәтлерәк исә, ахры, елганың уртасында чал сыртлы дулкыннар кайнаша... Робертның кинәшенә колак салырмы, тәкъдименә риза булырмы ул? Ничек тә иплән, үпкәләтмичә, намусына каты кагылмыйча гына сөйләшергә кирәк. Булдыра алса, ярый инде.

Гәүдәдә шактый ук арганлык сизелә. Күзләр, әллә кызу юлдан соң кинәт туктап калганга, үзләреннән үзләре йомылалар. Паром әйләнеп килгәнче бераз тын алу зыян итмәстер. Сәфәренең бормалы һәм билгесез юллары алда бит әле.

Мотоциклын яр читендә утырган тәбәнәк кенә бер өй янынарак күчереп утыртып куйды да, үзе шул өйнең җилдән ышык ягына, коры нигез почмагына сөялеп утырды. Йчмаса, бер-ике машина килеп чыкса, паромдагылар ашыга төшәр иде. Көт менә хәзер ул пошмас җаннарны. Хәер, аларга дөнья йөзендә Роберт дигән бәндә үз ялкынында янып йөри ни дә йөрми ни...

Елга шаулый, колак төбендә җил сызгыра, күкрәктә җан сыкрый... Әмма әкренләп һәммәсе дә ниндидер йомшак һәм рәхәт томан эчендә кими, тоныклана, югала бара...

Имеш, поездда баралар. Әлбинә аскы сәкегә яткан. Ул кулларын баш астына куйган да Робертка күзләрен тутырып карый, үзе рәхәт бер елмаюда балкый. Тышта яшел агачлар, телеграф баганалары, болын-кырлар артка чабалар. Менә Әлбинә дә торып баса. Аның соргылт чәчләре тәрәзәдән искән җилдә тузгына... Ул да түгел, пароход, имеш... Себернең киң һәм мул сулы елгасында баралар. Төмән нефтьчеләре ягына кузгалганнар, имеш... Елгада, алтын кояш нурларында, чал сыртлы биек-биек дулкыннар тәгәрәшә... Шундый киңлек, күңелгә шундый рәхәт... Әлбинә кулы белән алга ишарәләп күрсәтә. Анда куе нарат-чыршы урманы эченнән поселок калкып чыга. Менә пароходлары караңгы урман эченнән киң һәм якты дәрья йөзенә карап утырган шул поселок ярына якынлашып та килә һәм калын, күкрәк тавышы белән, һаваны ярып, гудок бирә...

Роберт татлы төшеннән аерылып, әйләнә-тирәсенә күз салды. Яр читенә бер «МАЗ» килеп туктаган икән. Шоферы түзмәс җаннардан иде булса кирәк, тагын берничә рәт шаулатып, сузып гудок бирде. Роберт янына килеп баскач, ул йөзендә чамасыз ачу чагылдырып:

— Гомергә шул: ярга бер килеп сылансалар, аерылып китә алмыйлар, нәгъләтләр, — дип сүгенде.

— Әнә аерылдылар түгелме инде? — диде Роберт.

— Аермасаң, аерыла беләмени алар? Хатын-кыздан да хуже...

«Ахмак» дип уйлады Роберт һәм бу бәндә янында сүз катып торуны мәгънәсезлеккә санап, бер читкә китте.

Бер читкә китте дә елга битендә шаулаган дулкыннарга текәлгән хәлендә әле генә күргән төшен исенә китерде.

Кызык, аны юратсаң, ни диярләр иде микән? Хәер, нигә юратып торырга. Төмән якларына китүне ул күптәннән инде хыялында тота һәм озакламыйча аның тормышка ашачагына һичбер шиге юк. Тик Татарстан җирләрендә алдынгы бораулау конторасында берәр ел эшләп тәҗрибә генә туплап алсын... Әлбинә... Сөер дә соң бу төш дигәннәре: билгесез һәм томанлы бер нәрсәне шундый тиз, шундый җиңеллек белән ап-ачык итеп каршына китерә дә куя. Монысы да хыял, дөресе, хыял иде. Аның мәхәббәт чәчкәсе тапталган, изелгән инде. Роберт, Әхсәнне исенә төшереп, шиңмәс нәфрәт аша тешләрен шыгырдатты... Юк, сулмасын, үлмәсен ул чәчкә! Аңа шифалы су сибеп, яңадән терегезергә, яшәртергә кирәк. Нигә генә булмасын!

Әйе, яшәсен, гөрләп чәчәк атсын, орлыклар бирсен ул гөл!.. Олы мәхәббәте хакына...

Асылда кеше язмышы хәл итәлә бит, кеше язмышы.

* * *

Менә, ниһаять, мул сулы инеш буенда үзәнлектә җәелеп утырган авыл. Менә тыкрык түрендәге өч тәрәзәле, яңа капкалы өй.

Сораша-нитә торгач, егет сәфәренең азаккы ноктасына килеп терәлде шикелле.

Мотоциклын сүндерүгә, капкадан кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә бер апа чыкты.

— Исәнмесез! Укытучы Әлбинә Вәлиева шушында торамы?

Рабига жиңги, урам якта мотоцикл гөрелтесен ишетү белән, әллә улы Вильдан кайттымы дип, ашкынып-кабаланып килеп чыккан иде. Каршысында улы урынына күн тужуркалы, күзлекле һәм тездән пычракка баткан ят бер кешене күргәч, апа гаҗәпсенеп, каушап калды һәм юлчының соравына ашыкмыйча, сузып кына:

— Әлбинәме? Ием, миндә тора, миндә... Тик өйдә юк бит әле ул,— дип җавап кайтарды.

— Кайда?

— Мәктәптә.

Егетнең кашлары җыерылды:

— Нишләп, кичен дә укытамыни?

— Укытмый. Бездә кичен укытмыйлар,— диде Рабига жиңги, бу адәмне кем дип юрарга да белмичә, һаман да аптыраган кыяфәттә.— Октябрь бәйрәменә концерт куялар диме, спектакль диме, шуны әзерлиләр... Чакырып алдылар. Озакламый кайтып та житәр, бәлки. Үзем дә самоварлар куеп көтеп тора идем әле.

— Бик шәп, бик әйбәт,— дип елмайды егет һәм күн перчаткалы кулларын мотоциклының руле өстенә куйды.

Рабига жиңги кинәт юлчыга усал караш ташлап алды: юньлегә килүеме, юньсезгә килүеме бу ала карганың? Ни булса да, тикмәгә түгел...

— Соң сине үзеңне кем дип белик инде? — дип текәлде ул ана.

— Нефть чыккан җирләрдән мин, апа. Менә вакыт табып, Әлбинә белән бер күрешеп кайтыйм әле, дидем... Кая, апакай, капканы киңрәк ачып җибәр әле, мотоциклны ишек алдыгызга кертеп куйыйм әле...

— Әйдүк, әйдүк, керт! Урамда тотмассың ич аны,— дип капкасын киң ачып, артка таба чигенде жиңги. Юлчы егет мотоциклын утын сарае ышыгына кертеп урнаштыргач, аның алҗыган кыяфәтен күреп һәм күңелендә кузгалган җенне куып, апа аны өенә дәшергә тотынды.— Туңып та беткәнсең икән, әйдә дим, өйгә керик. Чәйләр эчкәч, җылынып китәрсең... Ай-һай, ерак юллар үткәнсең икән үзең дә!..

— Булды инде, үттек инде, апа... Ә чәй дигәнеңнән баш тартмам мин. Үзебезнең сый бит ул... Тик менә күн итекләрне юып, өс-башны чистартып, кеше төсенә керим әле...

Өйдә Рабига жиңгинең ак самовары чыннан да гөжләп-җырлап утыра иде. Табын артында Роберт иң әүвәл ападан тормыш хәлләре турында сорашты, аннары гына:

— Ничек соң Әлбинә, әйбәт укытамы, үзе сау-сәламәтме? — дип сорап куйды.

— Укытуымы? Һи, улым... Бик тә инде! Укучылары да ярата, халык та... Шулай була гына күрсен инде алдагысы көнендә дә. Юкса монда әллә кемнәр дә килеп китә... Ием, Әлбинәгә сүз әйтерлек түгел... Мина да булышырга жаен-вакытын таба,— дип Рабига жиңги квартирант кызыннан бик канәгать булуын сөйләргә керешге.

Мондый сүзләрне ишетүе Робертка рәхәт тә, тансык та иде.

— Шундый булырга тиеш тә ул, апа! Беләм мин аның холкын,— дип кушылды ул апаның сүзләренә.

Әмма Рабига жиңгинең йөзе кисәк караңгырак төс алды:

— Тик менә саулыкка туя алмый шикелле... Соңгы арада ябыгып-агарынып китте. Тамагына да юньләп капмый диярлек, юньле-башлы йокысы да юк...

— Ни булды икән? Болай сау-сәламәт иде лә ул,— диде Роберт, тының кысып.

— Белмим инде. Әле үткән ялында совхозга иптәш кызы янына барган иде. Аннан да сырхаулап кайтты. Янгырга эләгеп чыланган икән дуамал баш... Бу суыкта. Тилереп йөри инде шунда. Әйткән идем йөр-

мәсәң иде дип... Икенче көнендә сабак укытырга да бара алмыйча ятты. Юкә чәчәкләре кайнатып, кура җиләге каклары белән чәйләр эчергәч кенә рәткә керде... Яшьлек шул, яшьлек. Саулык турында бер генә дә уйлап карамыйлар...

Рабига җиңги кушучына таянып, ак самоварына текәлгән хәлдә квартирант кызы турында әнә шулай бераз гына зар түгеп алды да, кунак кеше яман нәрсә уйламасын тагы дип бугай, ашыгып әйтеп салды:

— Үзе бик тә уңган кыз инде. Ием. Үлсәм дә, мәктәп юлында үләрмен, ди. Сырхавы бетмәс борын ук китте. Менә нинди җан ул безнең...

— Нигәдер озаклады әле, — диде Роберт, апага тәмле чәе өчен рәхмәт әйтеп һәм чынаягын бер кырыйга этәреп. — Әллә барыйм микән? Еракмы мәктәбегез?

— Монда гына, инеш артында гына ул, — дип, бер якка кул изәп күрсәтте җиңги. — Ә син нигә ул хәтле сабырсызланасың? Кайтыр әле. Менә миңа иптәшкә тагын берәрне каплап куйсаң, Әлбинәң яныңда булыр...

Роберт күңеленнән Әлбинәне мәктәптә, һич югында, мәктәптән кайткан чагында очрату уңайрак булыр дип уйлап куйган иде, шунлыктан өстәл артыннан кузгалырга ниятләде.

— Шулай да барыйм әле мин, апа...

— Һәм бу тиклем кыбырчык булырсың икән! Анда теге ни... репетитсәсе генә бетсен, минуты тормый кайтып җитәчәк. Аның бит әнә терә өстәл тулы дәфтәре көтә.

— Көтсә дә... •

Рабига җиңги маңгай җыерчыкларын ишәйтә төшеп, кунак егеткә сәер генә күз атып алды да тел очендә эленеп торган соравын, ниһаять, турырак рәвештә биреп куйды:

— Баягынак әйтеп бетермәдең: кеме буласың инде син безнең Әлбинәнең?

— Минме? Аныңмы?.. Ни... — Роберт кузгала башлаган җирендә киредән урындыгына сеңде. Аннары, битенә кайнар кан йөгерүен тойган хәлдә, бер кулы белән күзлек кысасына ябышты һәм тәвәккәлләп ярып салды: — Мин аның иң якын кешесе, апа...

— Кеме, туганымы әллә?

— Түгел... Иптәше...

— Ничек иптәше дип? — күзләрен мелт-мелт йомгалады җиңги. — Әллә тормыш иптәше димәкче буласыңмы?

— Әйе, шулайрак, апа... Үлемнең иптәше булмый бит. Без җәй көне үк инде, — дип көлемсерәде Роберт, колакларының утта янганлыгын тоеп. Әмма ул сер бирмәс өчен шундук җитди, хәтта кырыс төс алды.

Бу хәбәргә тәмам хәйран калган Рабига җиңги, өнемме-төшемме дигәндәй, чигәләренә ябышты һәм миңгерәүләнгән бер караш белән кунакка текәлде:

— Менә тамаша!.. Ә мин аны... ә мин аны кыз баладыр дип йөри идем ләбаса... Әнә ничек икән әле... Менә бит ишетәсең булса ходаның бер көнендә!..

Аннары ул капылт кына урыныннан купты:

— Олы да кунак икәнсең үзең, әйтмичә азапладың!.. Юк, үзем барыйм әле, сөенечен алыйм әле!

Кунак аңга-миңгә килгәнче, апа, җәһәт кенә өстенә элеп, чыгып та китте. Дөресен әйткәндә, Рабига җиңгинең сөенче алудан бигрәк үзе өчен бик күңелсез яңалыкны ничектер зиһенендә тизрәк кайнатып уздырасы килә иде.

Роберт су савытын табып, ярты чүмеч салкын су эчте дә ишек алдына чыкты. Хәерсез, уйламаганчарак булды әле бу. Ул иң әүвәл Әлби-

нәнең үзен күреп сөйләшергә тиеш иде бит югыйсә. Тик шуннан соң гына... Үпкәләмәсә ярый инде... Ә бәлкем ул кадәр үк ачуланмас?

Озак көтәргә туры килмәде, Рабига җиңги тыр-тыр кайтып та керде. Болдыр баскычыннан менгән чагында әллә кунак егет өчен, әлле үзе өчен:

— Әнә бит нинди хәлләр... Тукта, тизрәк плитәмә ягып җибәрим әле, ит-ашлар куймый булмас, — дип сөйләнеп алды.

Ул арада ачык калдырылган капкадан Әлбинә үзе дә атылып килеп керде. Кичке эңгердә йөзе-түше аермачык беленми, тик яулыгы артка шуып төшкән дә, чәчләре тузгыган сыман... Керде дә егет каршысында шып туктады, сулышына буылып эндәште:

— Роберт, син!.. Ничек болай, нигә болай? Ниләр әйттерден син апага? Нигә әйттерден?

— Иң башта күрешик, Әлбинә, — диде Роберт, аңа якынаеп.

Кыз күрешкән чагында тәрәзә яктысында Әлбинәнең күз төпләрендә яшь бөртекләре чагылып китте. Тавышы да үксегән сыманрак чыкты:

— Соң бит апа килеп керде дә: «Анда киявең көтә, тизрәк кайт!» дип сөенче алмакчы булды. Пышылдабрак әйтсә дә, аны бүтәннәр дә ишетмичә калмагандыр... Нишләп син алай, Роберт?

— Шулай кирәк, Әлбинә!.. Мин барын да беләм, барын да... — диде Роберт, тавышында ныклык чагылдырырга тырышып, әмма калтыранган пышылдаудан уздыра алмыйча. — Хәлеңне белгәнгә күрә килдем дә менә... Уйламасыннар. Ире бар икән, һич югы, булган икән дисеннәр. Синең бит укытасың да бар әле... Әйе, мин синеке, Әлбинә, ләкин... ләкин тагыла дип уйлама...

— Соң... соң... син үзең турында да уйладыңмы, Роберт? — дип сорады Әлбинә, ачынып. — Мин ярый инде... беткән баш беткән...

— Миңа нәрсә? Мин әлегә һавадагы кош кебек... Синен дә баш бетмәгән. Бир кулыңны, Әлбинә, бир, дустым!.. Барысы да алда әле. Башны югары тотыйк, дим...

Әлбинә кисәк ике кулы белән битен каплап, иңрәп төште:

— Мондый хурлыкларга калырмын дип кем уйлаган, Роберт! Белсәң иде хәлләремне!

— Ярый, Әлбинә, җебемик. Ичмаса хуҗа апаң каршында сынатмыйк инде. — диде Роберт, Әлбинәнең дерелдәгән иңбашларын кочагына алып.

* * *

Төнгә Рабига җиңги аларны икәүдән икәү калдырып, үзе күршегә кунмага кереп китте.

Икәүдән икәү аулак өйдә...

Роберт, Рабига җиңгинең ятагына яткан җирендә, изелгән-ватылган гәүдәсенә, төтенсез янган җанына хәл җыярга ирек биреп, шундук йокыга чумды. Әлбинә исә үз койкасында байтак боргаланды. Аның күнел дулкыннары тына алмый, ул һаман өзгәләнеп уйлана иде...

Әле узган якшәмбедә генә ул, башына төшкән хурлыктан котылу юлын эзләп, дусты Гөлсинә белән бергә совхоздагы врач хатын янына барып кергән иде. Әмма ул хатын аның теләген йомшак кына итеп кире какты. «Үзеңнең тәнең кызган, температураң күтәренке, үзен шундый эш артыннан йөрисең, — диде. — Аннан соң, мин беренче балага узганнарга кагылмыйм... Алдагы тормышың турында уйла, сәламәтлек белән шаярмыйлар, синең ана булу бәхетеннән бөтенләйгә мәхрүм калуын бар, сеңелем», — диде... Йомшак сыйпап, каты екты...

Ә бүген менә язмыш ана бөтенләй уйламаган яктан шәфкатьле кулын сузды. Ичмаса, язылышмаган булса да, ире бар икән, диярләр...

Шулай итеп, аның трагедиясе кэтмэгэндэ комедия төсен алды. Ләкин бик кызганыч комедия... Бәлкем, драмадыр? Язмышында тагын ни булыр? Белми, белә дә алмый...

Әхсәнне исенә төшерде. Аның янына Роберт килеп басты. Зәһәр мәкерлек, хыянәт һәм киң күңелле яхшылык. Этлек һәм кешелек...

Кисәк яшь хатын эчтә, нәкъ йөрәге астында, нәрсәнеңдер кискен кузгалып, авырттырып тибүен тойды һәм куанычтанмы, әллә каушауаптырауданмы, кычкырып җибәрүдән чак кына тыелып калды...

...Рабига җиңги, үзе турында күрше-күлән арасында яман сүз чыга күрмәсен тагы дип, таң тишегеннән торды да мунча ягарга кереште. Үзенчә, кияү мунчасы...

Һава аязып, чак кына чираткан иде.

Таң атып, кояш чыгарга торганда, апа ишек алдында мотоцикл гөрелтесен ишетте һәм бакчада мунча юлында чиләк-көянтәләрен калдырып, ашыгып ишек алдына кайтты. Кайтса, капка ачык, капка төбендә иценә пальтосын элгән Әлбинә басып тора, ә тыкрык буйлап мотоциклында, арттан җиргә сыек төтен сеңдереп, кияү егет китеп бара иде.

Рабига җиңги сулышына буылып:

— Нәрсә, әллә китте дәме? — дип сорады.

— Китте, апа.

— Бәлеш! Соң мин сезгә мунча ягып йөрим ләбаса, — дип бот чапты җиңги.

— Рәхмәт инде, апа... Нишлисең, ашыкты бит, эшкә чыгасы бар, ди...

— Эшкә? Менә бит замана, кешегә иркенләп кияүләп ятырга да ирек бирмиләр.

— Октябрь бәйрәменә кайтырга тырышырмын, диде. Бәлкем чыннан да кайта алыр, көтеп карыйк, апа, — диде Әлбинә, ничә көннәргә беренче тапкыр тулы һәм ачык елмаеп.

Кинәт ул үзенең җиңел гәүдәсенә янәдән канатлар үсеп чыккандай хис итте һәм тирән бер зарыгу белән борылып, мәктәп ягына күз салды. Анда, шәрә калган агачлар артында, зур яшел түбәдәге акшарланган матур морҗалардан һавага куе зәңгәр төтен күтәрелә иде. Күрәсең, укырга-укытырга җылы булсын дип, бу елны беренче тапкыр мәктәп мичләренә ягып чыкканнар иде.

*1967 ел. Алабуга*

●

*Камил Мостафин*

## Исәп

Сугыш үткән карурманда
күке
еллар санын саный һаман да.
Урман тыңлый...
Монда каберлектә
яшь солдатлар йоклый аланда.

Алар өчен тырыша, ахры, күке,
алар өчен саный елларны.
Ил уллары
һаман уянмыйлар,
җирне коча һаман куллары.

Ел исәбен өзеп,
тына күке,
очып китә, эзләп исәнне...
...Урман белә:
күкеләргә кадәр
шрапнельләр өзгән исәпне...

Ләкин исәп нигә?
Солдатларның
бармаклары калган курокта,
ө тәүлекләр, еллар һәм гомерләр —
барысы сыйган
актык минутка.

## Апрель

Урамда яз, дускай, һава аяз,
хисләр ташый, күңел ашкына...
Борыласың юеш җилгә каршы
һәм атлыйсың тамчы астына.

Гөлләр дә юк әле,
чирәм дә юк,
каеннар да шәрә ботаклы...
Ник омтыла күңел әллә кая,
нигә йөрәк шаша бу чаклы?

Чыгасың да пычрак сукмак буйлап,
тая-тая, атлап китәсең...
һәм туктыйсың. Ерак юлга карап,
бер бик әйбәт хәбәр көтәсең.

Ә хәбәрче кайда?
Юлдадыр ул.
Маршрутын яхшы беләдер.
Умырзая алып киләдер ул,
кояш нурын тотып киләдер.

Ул шагыйрьдер яки гүзәл кыздыр,
яз хәбәре булмас бүтәндә,
яз юлларын уза һәрбер кеше,
һәр яшь буын ашыга үтәргә...

## Теләк

Ана карчык... Аның ялгыз улы
һәлак булган сугыш утында,
тик ышанмый ана бу хәбәргә,
яз булдисә, чыгып өй янына,
һаман улын көтеп утыра.

Һаман улын кайтарасы килә,
һәм бу теләк көчле шулкадәр, —
бар корбаннар терелеп кайтыр иде,
әгәр Җирдә барлык кешеләр дә
шундый итеп тели белсәләр!

## Унҗиденче елның матрослары

Унҗиденче елның матрослары
ал бантларын саклый сандыкта.
Ә үзләре инде картайганнар,
туялмыйлар һаман саулыкка.

Өй янында, оныкларын җыеп,
сөйли алар Ленин турында:
менә кызыл байрак, менә Ильич, —
речен дәвам итә, алга карап
һәм кепкасын кысып кулына...

Ә бәйрәмнәр житсә, карт матрослар,
ал бантларын тагып пиджакка,
ашыгалар урам, мәйданнарга,
оныкларын тотып кулларыннан,
оныкларын өндәп еракка...

... Онытыла картлык... Матросларның
тик бер генә көбек бурычы:
алар гүя кабат каршы ала
унҗиденче елның Ильичын.

●

*Басыйр Рафиков*

## Җир тынычлык тели

Кояш, кояш, җылыт!
Язда күңел эри.
Ак күбектә шомырт,
Җир тынычлык тели.
Завод гудоклары
Иртән эшкә өнди,
Кырда иген шыткан,
Җир тынычлык тели.

Бишегендә бала:
— Әүвә... әүвә... — сөйли,
Шушы бала өчен
Җир тынычлык тели,
Пушка давы безгә
Әллә тансыкмыни?
Тынсын Вьетнам да,
Җир тынычлык тели.

●

Яшел шәлен салып иңбашына,
Юл читендә үскән ак каен
Читкә киткән авыл егетләрен
Озатырга чыга көз саен.
Кышлар үтеп, язлар килү белән,
Оясына кайта сыерчык.
Егетләр юк һаман, каен көтә, —
Күсәсендә арта җыерчык.

## Мәңге бетмәс яралар

Истә еллар
Дошманга
Каршы корал
Тотканга.
Үткән гомер —
Искән җил.
Шулай да ул
Истә гел.

Истә корбан
Булганнар,
Кайтмый калган
Туганнар...
Истә алар...
Бар алар —
Мәңге бетмәс
Яралар.

●

Берәүләре күккә чөеп
Мактадылар.
Берәүләре җиргә салып
Таптадылар.
Ә мин һаман басып торам
Аягүрә,
Ике якның хаталарын
Күрә, күрә.

●

*Рифгать Закиров*

## Омтылыш

Тормыш — диңгез.
Анда барсы да бар:
Дулкыннар да,
Давыл,
Тын яр да...
Мин яратам дулкын кочагында
Штормнар тавышын тыңларга.

Серле аваз гүя чакыру булып,
Ашкындыра мине каядыр...
...Ярсып алга йөзәм —
Менә-менә
Ачармындыр төсле Яңа Җир!

Борчылу юк! —
Бу юл авыр булсын,
Хәтта булсын шомлы, куркыныч...
Шашкын теләк барда
мәңге шулай
Алга әйдәр мине омтылыш!

## Шул да бәхет

Никтер карыштың — бергәләп
Болынны әйләнмәдең:
Тартылдың читкә, өзелеп
Коелды сәйләннәрең.

«Эх, сәйлән җыйганчы бергә!
Бу бәхет азмы сиңа!!» —
Дидем дә иелдем җиргә
Сөенеп язмышыма.

## Син килмәдең

Бары безгә генә мәгълүм төшкә
Алданрак килдем. —
Көндәгечә, сиңа юл күрсәтеп,
Фонаремны элдем.

Үзем көттем сине, үзем никтер
Каушап качып тордым;
Я бер: сине озак торсың, дидем,
Я бер: ашыктырдым...

Әмма син килмәдең... Бу көтүдән
Тик бер тойгы калды:
Төне буе фонарь түгел, гүя
Мәхәббәтем янды...

## Тынгы белмим

Җиде сәгать хезмәт белән
Бетми әле эшем минем:
Кеше өчен дә,
Күрше өчен дә
Тынгы бирми кешелегем!

Борчыламын: ник кешеләр
Һаман саран җылы сүзгә?..
Ник күршеләр
Тиенмиләр
Ачык чырай, якты йөзгә?!

Ә кайчакта фил булуы
Өтек гайбәт әнчегенең
Шундый итеп
Авырттырып
Йөрәгемә чәнчи минем?!

Әгәр берәү ишетә икән
Хаксыз җавап,
Кискен җавап —
Бу барыбер миңа газап —
Бар шатлыгым була харап...

Барысы өчен шулай янып,
Тик... үземне оныткамын.
Чөнки шунсыз
Хисапланмас
Идем кеше булып та мин!..

## Кем уйлаган

Боз эләсе аша тышка карыйм,
Бөтен дөнья ап-ак кар гына;
Кар яктысы гүя өшеткәндәй
Йөрәгемә килеп кагыла.

Әйткән иде әле кичә генә:
«Аерылабыз, бүтән эзләмә...»
Кем уйлаган, кинәт кар явар дип,
Икәү бергә йөргән эзләргә...

## Китмәскә иде

Күрешү емет итеп йөргән чакта,
Китканеңне белдем;
Шуңа көне буе урын тапмый
Ямансулап йөрдем.

Белсәм дә мин төп гаепнең бары
Синдә икәнлеген,
Күңелем барысын кичерергә әзер
Булган икән минем!

Үпкәләшү булган икән әле
Ярты кайгы гына.
Ә китүең гомерлеккә газап
Булып калды миңа...

## Авылым кызына

Мин кайттым сине сагынып,
Сөюем сүрелмәде...
Элеккечә ялан аяк
Каршыма йөгер әле!
Йөгер әле, пар канаттай
Кагынсын толымнарың.
Йөгерүдән, шат көлүдән
Кабынсын сулышларың!
Килеп җит тә, елдагыча
Сарылып муеныма,
Сора: «Абый, нинди бүләк
Алдың, — дип, — быел миңа?»
Тик кая син, быел тагы
Качтыңмы полосага?
Чык тизрәк, я, булма, зинһар,
Ел саен бала-чага!
Беләм инде: куркытмакчы
Буласың мине юри...
Чү! Кем ул басу түрендә
Чәчәкләр җыеп йөри?
Син икән бит, авылым кызы!..
Ахры, шулай итеп,
Каршылыйсың мине быел
Җитлегеп, буйга җитеп!
Килче тизрәк, ашык кызый,
Күземдә күрәсеңме:
Ничә еллар зарыгып көткән
Бүгенге сурәтеңне?!.

## Сорамагыз

Сорамагыз: «Каян аласың, — дип, —
Син бу кадәр моңны?»
Мин ишетәм тормыш төбендәге
Бабам чирткән кылны...

Сорамагыз: «Синең күңел ничек
Шулай нечкә?» — диеп.
Димәк, әбкәм бик еш бирелүчән
Булган хискә элек...

Сорамагыз: «Син ник ярсу, — диеп, —
Болай көчле?» — диеп.
Соң мин дә бит яуда һәлак булган
Абый төсле егет!

## Вакыт үтә

Вакыт үтә...
Шуңа куеп торып
Кырылып яткан кырык эшемне,
Булышам мин кулдан килгән кадәр,
Сөендерим, диеп, кешене.

Вакыт үтә...
(Үткән кире кайтмый.)
Менә бүген шуның өчен дә
Ашыгам мин: мөмкин чакта барысын
Биреп калыйм, диеп, кешегә.

Вакыт үтә,
Үтә сизелмичә...
Тик үткәннәр кала хәтердә.
Шуңа ашыгам, кешегә җылы сүзне
Үз вакытында телим әйтергә!..

## Дуслык хисе

*Гали Хуҗиевка*

Дус дигәнем дошман булып, кайчак
Телгәләнгән чакта бәгырем,
Син тагы да миңа якынаеп,
Арта гына бара кадерең.

Гүя минем йөрәк яраларым
Вакыт үткән саен яңара. —
Сүнмәс дуслык хисе белән шулай
Калдырдың син мәңге янарга...

*Егор Уткин*

## Тик йөз адым...

*Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган А. Уткин истәлегенә*

Мин дә инде
Шактый юллар үттем,
Синең юлың булган бик кыска.
Йөрәгеңне тыңлап,
Унсигездә
Атлагансың канлы сугышка.

Юлың кыска булган.
Окобыңнан чыгып,
Дусларыңа аваз салгансың.
Тик йөз адым...
Дошман узалмаган,
Син мәңгегә ятып калгансың.

Тик йөз адым
Синең үткән юлың.
Илем солдатының
Һәр адымы данга күмелгән.
Йөз адым җир азат иткәнсең син,
Йөз сабыйны саклап үлемнән.

Тик йөз адым,
Солдат йөз адымда
Нинди дәһшәтләргә юлыкмый...
Еллар аша
Орденың да кайтты,
Батыр улын Ватан онытмый.

## Бишек сиртмәсе...

Ялгыз,
Чал анага
Колхоз йорт салдырды,
Тузган өйдә гомер итмәсен...
Барыннан да элек,
Бүлмәгә ул
Элеп куйды бишек сиртмәсен.

Булышырга япь-яшь кызлар килгән
Төпчеңәләр,
Кызык аларга.
«...Берданберемнеке...

Ул тирбәлеп үсте,
Куйдым төсе итеп карарга...
Туфрак булды ярман якларында...»
Эх, бу сугыш,
Чирек гасыр инде аналар
Сиртмәләргә карап,
Төштә күреп,
Һаман көтә,
Һаман яналар.

## Юк, син даһи түгел...

*Алабуга районы Фрунзе исемендәге колхоз механизаторы Шакировка*

Юк, син даһи түгел,
Шагыйрь халкы
Даһиларны тиңли кояшка,
Ә мин сине тиңлим,
Арттырмыймын, —
Монда мәгънә башка,
Эш башка.

Юк, син даһи түгел,
Авылның бер
Тынгы белмәс гади малае.
Кышың үтә ферма тирәсендә,
Җәең, билгеле инде, комбайн.

Ярты җәең үтә иген урып,
Аннан салам җыеп кибәнгә.
Кайда булма, сиңа елышалар,
Һәрчак кеше була тирәңдә.

Кем килсә дә китми синең яннан
Бозлы күңел, моңлы йөз белән.
Кояш та бит күләгәсез, җылы,
Ә син
Җылытасың шаян сүз белән.

## Романтикам

Тормышның мин тигез, такыр юлын
Бүгенгәчә әле күрмәдем.
Текә булса, кайнар тиргә батып,
Тешем кысып, өскә үрләдем.

Җиңел бәхет, маҗаралар эзләп
Туздырмадым юллар тузанын...
Кыр тутырып игеннәрем шаулый,
Башакларын сыйпап узамын.

Җир читендә түгел, монда туа
Тургай моңы тулы ал таңнар.
Романтикам: илдә икмәк белән
Ярылырга торсын амбарлар.

•

Син Җир кебек,
Әнкәй.
Без сизмибез
Аның бертуктаусыз
Хәрәкәтен, юлын.
Җирдә югалту күп,
Синең күңелеңдә дә
Шундый хисләр тулы.

## Төнге яшен

Караңгы төн.
Яңгыр коя.
Чатнап, янып
Яшен яшьни,
Яшен күзне камаштыра.
Кинәт кенә яктырта да
Юл күрсәтә.
Сүнә, күз яуларын алып,
Адаштыра.

Тагын күкне
Ярып үтә,
Юл күрсәтә.
Юлны эзләп,
Ява яңгыр,
Коя яңгыр...

Чит карашлар
Әллә күзне камаштырды,
Сиңа илткән сукмагымнан
Адаштым бер.
Адаштым да
Бүгенгәчә
Таба алмыйм.
Синсез — һавасыз
Бушлыкта яшим кебек.
Ул сукмакны
Табар идем,
Әгәр хисләр
Кабатлана алса,
Төнге яшен кебек.

## Печән өсте...

Печән өсте — бәйрәм төсле,
Яшьләр көтә бу чакны...
Өч якның болыны монда,
Әйтерсең, бу юл чаты.
Өч як болыны тоташкан —
Чаллы,
Бондюг,
Минзәлә.
Болыннарның межасы бар,
Яшьлекнең юк,
Эзләмә.
Көндез һәркем үз җирендә,
Эшли,
Тирдә коена.
Кичен бар да тын урынга —
Күл буена җыела.
Юынырга,
Киенергә
Өлгерәләр кай ара.
Тал-куаклар ышыгында
Вәгъдәләре яңара.

Өч якта да талантлар бар:
Җырчылары,
Шуклары.
Һич югында булмый калмый,
Берәр сугыш чукмары.

Печән өсте — бәйрәм төсле,
Димәгән юкка картлар.
«...Көннәр, һай, сизелми үтә...»
Авылга атлый атлар.
Кайтканда бер як сафында
Бер килен арткан була.
«Югалту» я теге яктан,
Яки бу яктан була.

Өч як болыны тоташкан —
Чаллы,
Бондюг,
Минзәлә.
Болыннарның межасы бар,
Яшьлекнең юк, эзләмә.

# Фатих Хөснигә 60 яшь



## БЕЗНЕҢ ФАТИХ

Фатих Хөснигә 60 яшь тулды

Бу шактый озын гомер, бу гомер эченә ике революция, өч сугыш, социализм төзү, коммунизмның нигезен салу — җыеп кына әйткәндә, яңа заманның илле еллык тормышы керә. Фатих туганда әле иске заман хөкем сөрә — ул менә шул заманның да хәллехәлсез крестьян агайларын, һөнәрчеләрен, вак сәүдәгәрләрен (алма сатучыларын), байларын, мулла-мәзиннәрен, хәлфәләрен, мәчет-мәдрәсәләрен, ярминкәләрен, базарларын күреп кала... Фатих туганда әле Тукай исән була, «Ялт-йолт» чыга, «Аң», «Ак юл» һәм башка бик күп төрле нәрсәләр чыга; Фатих әдәбиятка аяк баскан елларда гына Фатих Әмирхан үлеп китә (Фатих, син аны күрдеңме?); Тукайның замандашлары Галиәсгар Камал, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Сәйфи, Садри Җәләл, Шәриф Камаллар белән Фатих танышып, аралашып, бер үк елларда эшләп калырга да өлгерә. Ә революциядән соң Фатих күреп кичергән вакыйгаларны санап чыгарлык та түгел. Ул вакыйгалар, әйтик, гражданнар сугышы, НЭП заманы, колхозлашу еллары, бишьеллыклар, Ватан сугышы — болар һәркайсы үзенә бер тарихи чор булып санала. Ә Фатихның үз замандашлары арасында без кемнәрне генә күрмибез!.. Һади Такташ, Гадел Кутуй, Фатих Кәрим, Муса Җәлил һәм башкалар, һәм башкалар... Шуларның барысы белән дә Фатих йөргән, аралашкан, бергә утырган, бергә эшләгән кеше. Я, моннан соң безнең Фатихыбыз гаҗәп бай, озын гомер кичерде дип, ничек әйтмәскә мөмкин ди?!

...Тагын шунысы кызыклы, Фатихның күргән-кичергәннәре аның үз әсәрләрендә үк бик ачык ярылып ята. Менә карагыз: «Йөзек кашы», «Җәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы ел», Ватан сугышына багышланган хикәяләре һәм, ниһаять, «Минем тәрәзәләрем»... Болар, («Минем тәрәзәләрем»нән башкасы), әлбәттә, чын сәнгать әсәрләре, ягъни автор хыялы белән иҗат ителгән әсәрләр, әмма аларның һәркайсында Фатихның үзен һәм нәкъ ул үзе күргән тормышны шактый ачык тоеп, белеп була. Гомумән, Фатих ни генә язмасын, һәр әсәрен үзенең шәхси уй-кичерешләре белән бик мул сугарып, һәр әсәрендә үз җанын, үз табигатен бик нык сиздереп яза торган әдип, минемчә... Аның әсәрләрен имзасыз да танып була. Бу җәһәттән, ягъни үз йөзен шундый ачык итеп саклау җәһәтеннән, бездә Фатихка тиңләшерлек бүтән язучы бар микән?

Шуңа күрә әйтәсе килә: алтмыш яшь Фатих өчен бик аз әле!.. Аның таланты бер дә картаюны белми, аның таланты һәрвакытта таза, сәламәт. Без моны аның иҗади эшчәнлегеннән бик ачык күреп торабыз. Өлгер, нык кулы белән ул безгә хикәя артыннан хикәя, мәкалә артыннан мәкалә биреп кенә тора. Кырык елдан артык инде Фатих шушы дәртле, тынгысыз эшчәнлек сәләтен саклап килә. Ә бит ул кайнар язучы, янып-яшьнәп язучы, сүрелә башласа да гаҗәп булмас иде. Ләкин, юк, нефть кырларындагы факел кебек яна да яна әле ул!.. Дөрес, аның романнар язып булмас инде дип зарланганы бар. Ләкин мин моңа ышанмыйм. Фатихтан барысын да көтәргә була. Тик ходай аңа сәламәтлек кенә бирсен!

Талантның серләренә төшенүе бик читен. Мин менә Фатихны язучы итеп тә, кеше итеп тә бик күптәннән һәм бик якыннан беләм. Бергә яшәдек, бергә йөрдек, бергә ашадык-эчтек. Әмма шуңа карамастан, Фатихның бай таланты нидән гыйбарәт, нәрсәләр аңа хас? — моны әйтеп бирергә мин бик кыенсынам. Гомумән, язучы турында дөрес һәм тулы сүзне әйтеп бетерә алу мөмкин микән?!. Һәрхәлдә, бу бер кеше, хәтта бер буын кешеләр эше генә түгел.

Шулай да мин Фатихның талантында нәрсә күрәм, нәрсәсе сокландыра мине?.. Иң элек бу — тынгысыз талант, бик актив талант. Барысына да өлгерә ул... Фатихның гомере буена заман белән бергә атлап, бай чорыбызның катлаулы вакыйгаларына художник буларак үз мөнәсәбәтен тиз‍рәк билгеләве, үз сүзен әйтергә ашыгуы шул хакта сөйли түгелме соң? Бер генә мисал. Без колхозлашу чорын кичердек. Бу халык тормышында гаять зур һәм, әйтергә кирәк, шактый газаплы бер тарихи вакыйга булды. Гадәттә мондый вакыйганы үзләштерү, колачлап алу өчен язучыга еллар белән исәпләнгән күпмедер вакыт кирәк була. Ә менә Фатих, колхозлашуның иң кайнар эзләреннән барып, үзенең «Җир тыңлый» дигән романын язып та чыгарды. Бу романга караш төрлечә булырга мөмкин, әмма ул роман кайчан, ничек язылуы белән Фатих өчен гаять характерлы бер иҗади факт булып кала дияр идем мин... (Дөрес, автор аны күп еллардан соң яңадан эшләп, «Утызынчы ел» исеме астында бастырып чыгарды, ләкин аңа карап кына әлеге факт әһәмиятен һич тә югалтмый.)

Мондый өлгерлек һәм тынгысызлыкны без Фатихның иҗатында өзлексез күреп килабез. Роман-повестьлары, пьесалары, бик күп хикәяләре һәм мәкаләләре шуның ачык мисалы... Кыскасы, Фатих чын мәгънәсендә әдип-гражданин ул!

Тагын нәрсә?.. Актив талантка чын оптимизм хас булырга тиештер инде... Чынлап та, Фатих тормышны бик ярата ул, кешеләрне бик сөеп яза, дөньяны ничектер бик бизәкле итеп күрә белә...

Фатихның моннан кырык ел элек язган бер шигыре бар. «Дөнья матур миңа» дип атала. (Фатих әдәбиятка шагыйрь булып килеп кергән иде, прозага күчкәч тә, барыбер шагыйрь булып калды...) Бу шигырьне кайчандыр мин дә күңелдән генә кабатлап йөрергә ярата идем... Менә ул:

Кирәк булса, биек тауга менеп,
Таштан уклар ясап атыгыз,
Тәннәремә кызыл билге салсын
Очлы чуер ташлар ватыгы.

Кирәк булса әгәр, муеным бирәм,
Бугазымны килеп бусыннар,
Кирәк булса, менә йөзем куям,
Агу белән йөзем юсыннар.

Шунда да мин һаман шат булырмын,
Үз сүземне үзем сөйләрмен,
Дөнья матур, дөнья күләч әле,
«Яшим әле мәңге!» диярмен...

. . . . . . . . . . . . .

Күрәсез, Фатих дәртләнеп, кайнарланып, хәтта бераз яшьлек дуамаллыгына бирелеп язган бу шигырендә үзен ничек дөрес «тотып ала белгән», нинди кыюлык белән үзенең асыл кредосын ап-ачык әйтеп салган!.. Үз сүземне үзем сөйләрмен, яшим әле мәңге диярмен, — әйе, алтмышка җиткән Фатих хәзерге көндә дә нәкъ әнә шундый ул!

Бу оптимизмның тагын бер сере булса кирәк. Фатих бик нечкә җанлы художник, ә нечкә җанлы кеше тиз җәрәхәтләнүчән, еш кына өметсезлеккә төшүчән була. Ләкин мин үзем Фатихта бу нәрсәне сизмим. Хикмәт нидә соң?.. Хикмәт, минемчә, аның шат табигатьле булуында («Шунда да мин һаман шат булырмын»), уен-көлкене яратуында, рәхәтләнеп көлә белүендә — һәм бу нәрсә художникның нечкә җанын тирән җәрәхәтләнүдән саклый да булса кирәк. Сез аның кайсы гына әсәрен алып укымагыз, нечкә лиризм белән шат юморның, игезәк балалар шикелле, һәр җөмләсендә диярлек янәшә торуын күрерсез.

Фатих — коеп куйган әдип. Яхшы мәгънәдә, киң мәгънәдә әйтәм мин бу сүзне... Тик бу кыска гына язмада мин аның бөтен әдиплек сыйфатларын санап күрсәтүне өстемә ала алмадым — зур эш, авыр эш... Хәтта аның сайрап торган теле турында да әйтмичә узам, чөнки, бердән, Фатих телен барыбыз да беләбез, икенчедән, ул үз телен мактаганны бик үк яратып та бетерми. («Берни булса, тоталар да минем телемне мактарга керешәләр», дип миңа зарланганы да бар.)

Фатих — юлдагы язучы, мәһабәт чал башын текә тотып, һаман алга карап баручы танылган зур әдип. Ихтимал, аның алтмыштан соңгы гомер юлы да шома-такыр гына булмас, әмма озын, бәрәкәтле булыр дип ышанасы килә. Батыр адымнар телим сиңа, дустым!

ӘМИРХАН ЕНИКИ.

*Фатих Хөсни*

# КЕЧКЕ ДОГА

## *Хикәя*

Алдан ук әйтеп керешәм: әзрәге хикәя, әзрәге очерк булып моның. Ничек кенә дисәм дә, мин аны әйтергә тиеш, әйтмичә калдыра алмыйм. Шунсыз ул минем күңелемдә йөри, бүтән яңарак нәрсәләргә урын бирми.

1966 нчы елның җәй башында булса кирәк, сабан туйларында катнашу өчен, без — дүрт татар язучысы — Мамадыш районына киттек. Сабан туе булгач — сабан туе. Йоласын китерделәр, башкалар кыланганны ук кыландылар, арттырып җибәрү дә булмады, калышмадылар да. Минем сөйләргә җыенганым шул тантананың бер көне.

Әйе, бер көнне безне шушы районның Олыяз авылына алып киттеләр. Анда ул көнне Ватан сугышында һәлак булган корбаннар шәрәфенә истәлек-обелиск ачылырга тиеш иде. Киттек. Алай-болай сүз әйтергә кирәк булса дип, арадан беребез речь тә әзерләде. Дөресен әйтергә кирәк, бәйрәм күтәренкелеге белән бергә ук күңелдә моңсулык хисе дә кузгалган — һәйкәл ничек кенә шәп булмасын, кешеләр үзләре исән калып, монда, безнең белән бергә сабан туе ясап йөрсәләр, әлбәттә, күңеллерәк булган булыр иде.

Күрше авыллардан да күп килгәннәр, Казан кунаклары да җитәрлек, районның җитәкче хезмәткәрләре дә шунда — халык бик ишле, авыл уртасындагы мәйдан көнбагыш кыры кебек тирбәлеп тора иде. Һәйкәл әлегә япма астында, әмма күзләр инде анда, җыелган халык тавышсыз-тынсыз гына күзәтә, көтә, кайдадыр трибуна артында оркестрантларның әллә нидә бер трубаларын кычкыртып куйганнары гына ишетелгәләп куя иде.

Менә кызыл материя җәелгән президиум өстәле янына колхозның могтәбәр кешеләре, район агайлары, кунаклардан берничәсе чыгып утырды. Менә шул көнне генә өр-яңа нарат тактадан корыштырган һәм яныннан бер өзлексез чаер исе аңкып торган трибунага формадан киенгән, күкрәкләре сугыш орденнары белән тулган военком менеп басты. Җыелган халык бер чайкалып куйды һәм шулар арасында — ачылачак һәйкәл әйләнәсен, койма өсләрен, автобус кузовларын тутырган, агач ботакларына менеп кунаклаган күп санлы кешеләр арасыннан минем күзем кечерәк кенә гәүдәле, чуар шәлъяулыклы бер әбигә төште. Бу хәтле күп халык арасыннан нишләп нәкъ ул әбине «тотып алганымны» мин хәзер аңлата да алмыйм, ул вакытта сорасалар, ул вакытта да аңлата алмаган булыр идем. Бәлки, шул чуар шәлъяулыгы аркасындадыр, әллә, халык арасында уңайсыз кысылып, ничек булса да күбрәкне ишетеп-күреп калырга тырышып, шул ук вакытта, татар хатын-кызларына хас кыюсызлык белән, ничек тә яңы беләнрәк, авызын томалабрак басып торуы игътибарымны җәлеп иттеме? — Белмим, белмим...

Хәер, ул вакытта бик алай нечкәртеп торырга ирек тә бирмәделәр, военкомның митингны ачык дип игълан итүе булды, мәйданны яңгыратып оркестр уйнап җибәрде.

... Военком сүзен дәвам итте, аның әйтә торган сүзе бетмәгән булган икән һәм ул аны әйтә дә белде. Бәлки, бу шыгрым тулы мәйданга

кычкырыбрак, бугазны киеребрәк әйтергә кирәк булгандыр. Чал чәчле карт сугышчы, сугышта үзен ничек тоткан.лыгын күкрәгендәге орденнары күрсәтеп тора, бәлки, бугазны киеребрәк кычкырырга бу очракта аның хакы да булгандыр, ләкин юк, кычкырмады. Гади генә итеп башлады, моннан егерме биш ел элек кузгалып, безнең җиребез өстеннән гөрселдәп узган ул дәһшәтле вакыйганың — сугыш дигән зилзиләнең безнең халкыбызга китергән зарарларын искә төшерде. Ләкин озак-озак санап тормады, инде безнең ул яралардан котыла баруыбызны әйтте һәм шунда, көтелмәгән хәл, ораторыбызның тавышы кинәт сынып куйды...

— Ләкин бер вакытта да, бер вакытта да онытылмаслык һәм онытырга ярамый да торган, онытырга бирми дә торган яралар да бар, иптәшләр, — диде ул, тавышының йомшара төшкәнен мөмкин чаклы сиздермәскә тырышып. Ул инде мәйданга түгел, үзенә үзе сөйләгән кебек сөйли башлаган иде, — бу мәңге төзәлмәс яра: безнең сугышта башларын салган коралдаш дусларыбыз.

Нәкъ шул минутта, нилектәндер, мин тагы әлеге чуар шәлъяулыклы әбигә күз төшердем. Аның баягы кыюсызлыгы беткән, ничектер алгарак калкып чыккан, ахры, русча сөйләгәнне бик үк аңлап та җитми иде булса кирәк, янәшәсендә басып торучыларның әле берсенә, әле икенчесенә борыла, күрәсең, «нәрсә әйтте?», «нәрсә диде?» кебек сораулар бирә-бирә, үтә кызыксынып сораштыра иде. Мин аңардан шактый ук читтә, аннары тагы күп кеше җыелган җирдә гөжләү дә бар, әбинең күршеләреннән нәрсәне ул хәтле җентекләп сорашканлыгын мин, әлбәттә, ишетмәдем, ләкин чамаладым: аның военком сөйләгәннәрдән ничек тә күбрәкне белеп, аңлап каласы килә иде булса кирәк.

Аннары һәйкәл өстеннән япманы төшерделәр. Алдыбызда өскә таба очлаеп калыккан һәм иң очына кызыл йолдыз беркетелгән конус рәвешендәге зур һәйкәл-обелиск басып калды. Ян-якларына җемелдәгән алтын хәрефләр белән, шушы тирә авыллардан китеп, сугыш кырларында башларын салган геройларның исемлеге язылган һәм, дөресен әйтергә кирәк, кечкенә-кечкенә генә авыллар өчен шактый зур иде бу исемлек. Шунда артымда басып торучы ике кешенең пышылдашып сөйләшкәне колагыма чалынып калды:

— Аның йолдызы төнлә янып торырга тиеш, — диде берсе.

— Ник төнлә генә? Гүпчи янып торырга тиеш ул, — дип, тегесенә каршы төште икенчесе.

Ярым хәрби төстә, хәрби оркестр яңгыравы астында башланып киткән бу һәйкәл ачу тантанасы, ничектер үзеннән-үзе диярлек, колхозның гадәттәге эшләре белән ялганып китте. Трибунада военкомны колхоз председателе алыштырды. Колхозның язгы чәчүдәге уңышлары, алдынгы кешеләре турында сүз китте. Ә бераздан алдынгыларны, берәм-берәм президиум өстәле каршына чакырып чыгарып, бүләкли дә башладылар. Бу турыда алдан сөйләшенү булгандырмы, юктырмы, әмма шунысы бик гыйбрәтле булды: үлгәннәрне олылау өчен дип район үзәгеннән китерелгән оркестр, ничектер бик табигый рәвештә, тереләрне олылау эшенә кушылып китте — бүләккә исеме аталган һәр кешене туш уйнап каршы ала, туш уйнап озатып кала башлады.

Бүләкләнүчеләр күп булды. Бригадирлар, гади колхозчылар, ферма кешеләре, балта осталары, механизаторлар — хезмәтенә күрә хөрмәте дигәндәй, эшләренә карата барысына да өлеш чыкты. Яшьләре дә, картлары да бар. Бер дә назландырып тормыйлар тагы үзләре, председатель әйтә тора, тегеләр оркестр уйнаганга тыз-тыз басып һәм күкрәкне мич капкачыдай киереп, президиум өстәле каршына чыга торалар...

Тик бер кеше генә эшне чак-чак боза язды. Колхоз председателенең:

— Язгы чәчү вакытында, кыр станында безнең тракторчыларыбызны һич тоткарлыксыз тәмле-тәмле ашлар пешереп сыйлап торганы өчен өлкән колхозчыбыз сөекле Мәрвибану апа Хәйретдинова бер күлмәклек штапель белән бүләкләнә, килеп ал, Мәрви апа,— дип игълан итүе булды, оркестр янгыратып уйнап жибәрде, ләкин... Мәрви апа чыкмады. Ул арада халык төркеме эчендә ыгы-зыгы купты, шау-шу китте, председательнең тагын бер әйтүе дә файда итмәде. Игътибар беләнрәк карасам, халык төркеме эченнән әлеге теге чуар шәлъяулыклы апаны чыгарырга маташалар, Мәрвибану Хәйретдинова дигәннәре шул, имеш. Дөресен әйтергә кирәк, беразга әллә ничегрәк булып калды бу тантана. Оркестр уйнап тора бер якта. Председатель хәтле председатель, бәләгенә штапель төргәге салып, басып көтеп тора икенче якта. Мәрви апабызны эткәли-төрткәли президиум өстәле каршына чыгарырга маташалар өченче якта... Ә Мәрви апабыз, яулык почмагы белән авызын каплый биреп, кирегә таба тартылыпмы-тартыла.

— Әнә Гыйльминур чыгып алсын алайса,— диде ул, ахырда кызына ишарәләп. Һәм колхоз председателенә, тавышы житкәнчә кычкырып әйтте — рәхмәтне соңыннан... өенә кереп әйтермен, Фәрди улым. Бу кадәр халык алдына чыгып, ямьсезлегемне күрсәтеп йөрисем юк, ошамаганны...

Тантананы башлагандагы киеренке рәсмилек болай да йомшый төшкән иде инде, Мәрви карчыкның бүләк алырга чыкмый тартышуы, аның тирәсендәгеләрнең төрлечә кыстап, эткәләп-төрткәләп әбине ничек тә президиум алдына чыгарырга маташулары жыелган халыкны бер мәл бөтенләй бушатып, гадәти хәленә кайтарды. Төрле яктан чышпыш сөйләшү, Мәрви карчыкның карышып азаплануын төрлечә юрау китте. Берәүләр моны әбинең мокытлыгы, иске тормыш калдыгы булуы дип аңлатсалар, икенчеләре, моның нәкъ киресен әйтеп, Мәрвине яклыйлар, аның башка вакытта да шулай балалар кебек тартынучан булуын, күзгә чәчрәп керергә яратмавын әйтеп үтәргә ашыгалар иде. Председатель Фәрди дә, бу икенчеләргә кушылып, мәсьәләне тизрәк уен-көлкегә әйләндерергә тырышты булса кирәк, колхоздашларына әйтүдән дә бигрәк, безгә — килгән кунакларга — аңлаткан бер төс белән:

— Шундый инде ул безнең Мәрви апа, фермада эшләгәндә бер чакны шулай сарык бүләк итеп тә, ник бирдек дигән көнгә төштек. Әлек алмыйча, алгач, бүләк сарык итенә кунакка чакырып теңкәгә тиде,— дип көлдерергә маташты.

Һәм гомумән бер мәл иркенләп, тел шартлатып, уен-көлке сөйләшеп алдылар. Шушы ара — буш ара дигәндәй, безнең арттагы берничә яшь-жилкенчәк тагын обелиск башындагы кызыл йолдызга менеп кунаклагандай иттеләр:

— Беләсеңме, нәрсәдән ясалган ул йолдыз? — дип мәсьәләне китереп куйды берсе.

— Рубин,— диде икенчесе, озак баш ватып тормыйча.

— Рубин, капчыгыңны киң тот. Рубинның нәрсә икәнлеген белмисең алайса син,— дип чәчрәп чыкты өченчесе.

Бераз тынлыктан соң, арадан берсе, бәхәскә урын калдырмаска теләгәндәй, өзеп:

— Кремль башнясындагы йолдыз да шундый, сельхозвыставкага барганда Кремльгә ике мәртәбә кердем,— дип, яхшы ук янгыратып, ярып салды.

Әллә бу «Кремльгә ике мәртәбә кергән» егетнең авторитетлы сүзе шулай бик үтемле булды, әллә үз авылларында үз геройларына куйган һәйкәлнең йолдызын Кремль йолдызына тиңләү егетләрнең кәефенә хуш килде, шуннан соң аларның бәхәсе артык ишетелмәде.

Ләкин, дөресен әйтим, мин үзем бу мәсьәлә турында, балалар кебек, кайта-кайта уйландым: чынлап та, нәрсәдән икән соң бу көндез дә болай, кызарып, янып тора торган йолдыз? Чын рубиннан дисән... Күпме хәзер алар, андый һәйкәлләр, безнең авылларыбызда, поселокларыбызда, шәһәрләребездә! Аларның барысына да кайдан чын рубин җиткермәк кирәк?

Моның хикмәтен мин соңыннан, шул көнне кичен, кеше аягы басылгач таптым. Дөресрәге, тапкандай булдым.

Сабан туе уңае белән филармония артистлары да килеп чыккан иде бу авылга. Кичен клубта аларның концерты булды, халык яратып тыңлады. Аннары яшьләр клуб сәхнәсе белән рәттән, ләкин тышкы якта, такта җәеп эшләнгән ачык мәйданчыкта парлап уйнап торган баян көенә тәмам гарык булганчы биеделәр. «Ай-һай ла, тузан туздырасыз!» дип эч пошырып торучы булмады, тузган тузан һавага оча барды. Кайсы туры юлдан туп-туры өенә, кайсылары өйгә кайтканчы кайбер кыйшык тыкрыкларда тукталып үбешә-үбешә, ниһаять, яшьләр дә таралышып беттеләр. Кыек-кыек басып чыгучы һәм капкадан чыгуга хуҗаның күңеле булсын өчен (янәсе, вәт сыйлады!), тавышы булса-булмаса, «Сарман» көенә бер кычкырып җибәрүче кунаклар да инде күзгә чалынмый башлаган иде. Авыл төнен күзәтеп, ялгыз башым аргы очлардан урап кайтышлый, мин тагы, үзем дә рәтләп сизмәстән, көндез кешеләр белән кайнап торган үзәк мәйданга, әлеге теге геройлар истәлегенә ачылган һәйкәл-обелиск янына килеп туктадым. Аның очындагы әлеге кызыл йолдыз, нурын як-якка тигез генә сибеп, тын гына янып тора. Эчендәге лампочкага ут кабызганлыктан һәм, бәлки, әйләнә-тирәдәге кирәкле-кирәксез шау-шу басылганга күрәдер, бу төнге сәгатьләрдә ул, нур чәчү белән бер үк вакытта, ничектер, чакчак кына моңсулык та чәчә кебек иде.

Нилектән икәнен аерып кына әйтә алмыйм, бәлки, көндезге ыгы-зыгыда рәтләп күздән кичерергә өлгермәгән исемлекне ай яктысында иркенләп күздән кичерү һәм, тын калып, бер уйлану өчендер, мин, һәйкәл тирәли куйган рәшәткәне үтеп, эчкә кермәкче булдым.

Ләкин икенче берәү миңа караганда алданрак өлгергән иде инде. Күргәч, аптырабрак калдым. Һәйкәлнең төбенә үк килеп җиргә тезләнгән бер хатын-кыз (башта мин аның тирбәлеп торган җилкәсен генә күрдем,) кулларын авыз каршына ук китереп куйган да бик бирелеп догага чумган һәм аның бу хәер-догасы очсыз-кырыйсыз дәвам итәдер кебек күренә иде. Мин, әлбәттә, тизрәк һәм мөмкин чаклы сиздермәскә тырышып, китү ягын карадым. Ләкин кеше дигәнең шундый догалы минутларда да гел кеше булып кала икән, бераз киткәч, кире борылып, рәшәткәнең каршы ягыннан изге теләкләргә чумган ул хатынга янә күз төшермичә булдыра алмадым. Ул — минем көндезге танышым: биргән бүләкне алмыйча тартышкан әлеге Мәрвибану карчык булып чыкты. «Күрәсең, аның да кеме булса да берәр якыны калгандыр... Көндезге шау-шу белән генә күңеле булмаган, күрәсең», дип уйлап кайттым мин. Кеше күзеннән яшерелеп укылган шул төнге дога мине гаҗәеп бер ачышка китерде: «Тукта әле, егет, тукта, — дидем мин үзем белән үзем сөйләшеп, — шушы яшерен догалардан, анай карчыкларның догаларыннан, яшьләй тол калган китек күңелле хатыннарның кешегә күрсәтмичә түккән күз яшьләреннән янып тормыймы ул йолдызлар? Һәйкәл башларындагы йолдызлар?»

Болай уйлау айнык реализм белән бик үк сыешып җитмидер, әлбәттә. Ләкин, нишләмәк кирәк, мин әнә шулай уйладым ул минутларда һәм шулай уйлау миңа рәхәтлек биргән кебек булды.

*Октябрь, 1967.*

*Геннадий Балакин*

# ЛИДИЯ СӘЙФУЛЛИНА АНТ ИТӘ[1]

1942 елның 24 мартында Воровский урамындагы язучылар клубының күптән ягылмаган ашханәсендә халык бәйрәмдәгечә күп иде. Башкаланың әдәбият әһелләре бирегә күренекле язучыларыбыздан Лидия Николаевна Сәйфуллинаны тәбрикләү өчен җыелдылар. Авыр сугыш еллары булуга да карамастан, Язучылар союзы пленумының махсус карары буенча, аның егерме еллык әдәби бәйрәме үткәрелде. Бик гыйбрәтле хәл бу. Димәк, сугыш чорының бернинди авырлыклары да безнең тормышның табигый агышын туктата алмаган, өзлексез кабатланып торган һава тревогалары, кышкы салкыннар һәм икмәк кытлыгы да совет кешеләрен куркытмаган...

Сугышның әле беренче генә айлары була. Мәскәү урамнарының берсендә Л. Н. Сәйфуллина хәрби чор өчен бик тә хас шундый күренешкә юлыга. Менә хәрби комиссариат йортыннан, ирен фронтка озатып, бер хатын килеп чыга. Үз өстенә кинәт ябырылган авыр хәсрәттән нишләргә белмичә, ул янындагы зур бинаның таш стенасына килеп сыена һәм ачынып елап җибәрә. Шул чак башкаланың зур бинасына сыенган тирән сагышлы, хәлсез кечкенә гәүдәле хатынны постта торучы милиционер күреп ала. Ул әлеге хатын янына килә, ихлас күңелдән кайгысын уртаклаша. Елый-елый шешенеп, хәлсезләнеп беткән хатын, туган абыйсыннан таяныч эзләгән кечкенә кыз шикелле, куллары белән милиционерның муенына сарыла, башын аның күкрәгенә сала. Милиционер аның йомшак чәчләреннән, тетрәп торган җилкәләреннән сыйпый һәм туганнарча гади генә итеп болай ди:

— Еларга кирәкми, сеңелем. Берни эшләр хәл юк. Безгә фашист һөҗүм итте.

Хатын елап кызарынган йөзен күтәрә, кулларын аның җилкәсеннән алып, әкрен генә әйтә:

— Еламыйм... Елый торган вакытмыни? Тормыш, балалар турында кайгыртырга кирәк.

Авыр, рәхимсез сугыш көннәрендә совет кешеләренең бер-берсе турында шулай кайгыртып яшәүләрен Л. Сәйфуллина күп мәртәбәләр күрә. Шундый барлык күренешләр бергә туплана да әдип күңелендә дулкынландыргыч хисләр кузгата, тормыш, яшәү тантанасы булып яңгырый башлый. Югалтулар күңелне никадәр генә әрнетмәсен, ирек сөюче горур халык, Октябрь халкы сагышка да, өметсезлеккә дә бирелми. СССР тормышы тулы көч белән яши бирә[2].

1942 елның исталекле март кичендә, совет язучылары һәм клубка килгән кунаклар аны әдәби эшчәнлегенең 20 еллыгы белән тәбрикләгәндә, Л. Сәйфуллина, бәлки, нәкъ әнә шул турыда уйлагандыр. Әйдә, кичә турында хәбәр итүче игъланнар һәм чакыру билетлары кулдан гына язылган яки машинкада басылган булсыннар. Әйдә, клуб артык салкын булганга, кичәгә килүчеләр чишенә дә алмасыннар, ди. Ләкин боларның берсе дә юбилярга кешеләрнең йөрәк җылысын сизәргә, ә кичәгә килүчеләргә әдәбият фронтының олы көрәшчесенә чиксез ихтирамнарын һәм рәх-

---

[1] Л. Н. Сәйфуллинаның шәхси архивыннан файдалану мөмкинлеге тудырган өчен, автор язучының сеңелесе Зоя Николаевна Шапирога чын күңелдән рәхмәт белдерә.

[2] Л. Н. Сәйфуллина. Тантана итүче тормыш. Очерк. «Крестьянка» журналы. 1943 ел. 10 сан. 16—17 битләр.

мәт хисләрен белдерергә комачаулый алмаган.

Л. Н. Сәйфуллина совет әдәбияты әле формалашып кына килгән бер чорда әдәби иҗат мәйданына килде. Ике халыкның, татар һәм рус халыкларының, уртак кызы кече яшьтән үк гади рус игенчесе гаиләсендә тәрбияләнә һәм рус телен үз ана теледәй белеп, өйрәнеп үсә.

Язучының бабасы Сәйфулла балта эшендә йөреп көн итүче Казан татары була. Мамадыш өязенең Яңа Комазан авылыннан чыккан кеше. Мәгәр аның тормышы авыр фаҗига белән тәмамлана. Мамадышта булган бер янгын вакытында хатыны һәм кызы һәлак була. Бәхетсез Сәйфулла бу авыр кайгыны күтәрә алмый: акылдан яза, озак тормый үлеп тә китә. Аның ятим калган кече улы Мидхәт рус гаиләсендә үсә, шул заман гадәте буенча аны чукындыралар һәм Николай Егорович Сәйфуллин дип йөртә башлыйлар. Казанда укытучылар семинариясен тәмамлагач, ул язучы булырга хыяллана. Авыр тормыш шартлары бу хыялын тормышка ашырырга мөмкинлек бирми, язучылык һөнәрен ул үзенең балаларына васыять итә. Ләкин Николай Егорович Сәйфуллин олы кызы Лидия күренекле язучы булып танылган көннәргә кадәр яши алмады.

Лидия Сәйфуллинаның «Дүрт бүлек», «Закон бозучылар», «Александр Македонский», «Виринея» кебек егерменче еллар башында чыккан повестьлары укучылар һәм тәнкыйтьчеләрне яңа чынбарлыкны дөрес сурәтли алулары белән үзләренә җәлеп иттеләр. Аның беренче әсәрләрен хуплап, «Известия Тат. ЦИКА» газетасы заманында Л. Сәйфуллинага зур өмет баглаган, «бөек революция давылын кыю кабул иткән хәзерге көн»[1]не сурәтләгән әсәрләренә югары бәя биргән иде.

Лидия Сәйфуллина халык арасыннан күтәрелгән һәм үзенең каләме белән халыкка эчкерсез хезмәт итүче яңа төр художник, гражданин әдипләрнең берсе һәм күренеклесе иде. 1931 елда, әдәбият юлындагы башлангыч адымнарын искә төшереп, ул болай яза: «Без Советлар Россиясе әдәбиятына... ирекле рәвештә килдек, эчке бер ышану белән безнең урыныбыз нәкъ менә шунда, дип килдек... Үзебез сайлаган юл өчен без җаваплы. Совет матур әдәбияты сафларында яшәвебез белән үк инде без үз өстебезгә СССРның җаваплы гражданы булу бурычын йөклибез»[2]. Үз өстенә алган шул җаваплылыкка, Ватаныбызга хезмәт итәргә дигән антына Лидия Сәйфуллина бөтен гомере буе турылыклы калды. һәм илебез өстенә фашизм ялары килгәч, үзенең олы яшьтә булуын, сәламәтлеге начарлана башлавын да онытып, ул бөтенхалык сафына, көрәшчеләр фронты сафына басты.

1942 елның февралендә, Кызыл Армиянең 24 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә, Лидия Сәйфуллина сугышчыларга кайнар котлау сүзләре белән мөрәҗәгать итә. Ләкин ул бәйрәм вакытларында сөйләнә торган гади котлау сүзләре генә булмый. Язучы революция Ватаны узган юлны искә төшерә, Кызыл Армия бәйрәмен үз биографиясендәге дулкынландыргыч көннәр белән бәйләнештә карый. Ул — художникның авыр сынау елларында туган халкына биргән тантаналы анты. Без аны әдәбият һәм сәнгать архивында саклануч кульязмалар арасыннан табып алдык[3].

## МИНЕМ АНТЫМ

*Төзелүенә егерме дүрт ел тулу көнендә безнең Кызыл Армиябезне миллионнарча кешеләр тәбрикли... Хисапсыз күп тәбрик авазларына минем дә җанлы, шатлыклы тойгым кушыла. Бу көнне мин күп миллионлы совет халкының бер тере бөртеге кебек яшим, мин — СССР гражданы. Бу минем кешелек язмышымдагы чын бәхет.*

*Яшь вакытымда миңа Советлар иленең Кызыл Армиясе ничек туганын күрү насыйп булды. Башкаладан ерак шәһәр, авылларда, иске Россиянең йөреп булмаслык әшәке юлларында беренче Кызыл Гвардия отрядлары оешты. Бергәләп акларга каршы бару нияте белән, 1918 елның кышында алар берләшә башладылар. Кызыл гвардиячеләрнең сафлары әлегә тигез түгел иде. Өсләрендә империалистик сугыш чорыннан калган шинельләр, сарык тиресеннән тегелгән кыска туннар; аякларында авыр киез итекләр, ертылып, сутелеп беткән иске башмаклар; сыр ган халат һәм бәрән бүрекләр кигән кыргызлар, кулларында сөңге. Сөңгеләр дә, винтовкалар да һәм-*

---

[1] «Известия Тат. ЦИКА» газетасы. 1922 ел. 1 октябрь саны.

[2] Писатели о труде. Рус телендә 1931 ел.

[3] 1363 фонд. 2 тасвирлама. 3 саклану берәмлеге. 7—10 битләр.

*мэсенэ җитми. Төрле милләттән җыелган, тәерче киемле, начар коралланган гаскәр. Ләкин аларның һәрберсе йөрәгендә җиңелмәс корал — җиңүгә ышаныч йөртә. Батырлык аларның калканы иде. Шул отрядның кысрыклавыннан регуляр армияләр тетрәп калды. Менә диген итеп киендерелгән, өйрәтелгән һәм яхшы коралланган гаскәрләр биреште. Безнең ертык киемле, әмма гаделлек рухы белән коралланган кызыл гаскәр җиңеп чыкты. Күптән үзган ул сугыш кырларында безнең күп кеше һәлак булды. Мәңгелек хөрмәт һәм дан аларга!*

*Көрәшкә нинди кыюлык белән кергән булсалар, аларның күбесе шундый ук кыюлык белән үлделәр дә. Мин яраланган разведчик-партизанның күбеккә баткан кечкенә кыргыз атында ничек штабка чабып килүен күрдем. Ул авыр яралы иде, эчәгеләре чыгып, ияргә салынган. Җайдак, хәлсезләнгән кулы белән ишарәләп, аларны урынына кертергә кирәклеген аңлатты. Иптәшләре аның эченә кар куйдылар — партизан сөйләшә башлады. Ашыгыч хәбәрне әйтеп өлгерде һәм үлде. Ерак далада аның исемсез каберен табып та булмас хәзер. Ләкин үлемсез батырлыгын ул үз сыйныфына, үз халкына, үзеннән соң киләчәк буыннарга калдырды. Хәзер, чәчләремә чал кергәч, мин моны яхшы күрәм.*

*Узган егерме дүрт елда безнең илебез, минем Ватаным, моңарчы тиңе булмаган бердәм армия тәзеде. Кызыл Армиядәге һәр кеше — гаскәр башлыгыннан алып иң кече дәрәҗәдәге сугышчыга кадәр — рухлары белән бертуганнар. Алар бетмәс-төкәнмәс ихтыяр көченә ия. Гитлер алып килгән караңгылык безнең тормышыбызны кояштан каплады, кешелек җәмгыятенең бөтен язмышын коточкыч бәла караңгылады. Фронт кырларында булсын, тылда булсын, кайгыдан газапланмаган яки бүтәннәр кичергән газапны уртаклашмаган бер генә минутыбыз да юк безнең.*

*Әмма Кызыл Армия сугышчылары рух төшенкелегенә бирелмиләр. Фронт сводкасы һәр көн аларның «гайрәтләре, батырлыклары, даннары» турында сөйли. Мондый армиянең тылы да зәгыйфь рухлы һәм эшлексез була алмый.*

*Егерме дүрт ел тулу көнендә Кызыл Армияне тәбрикләвем — ул минем антым. Калган гомеремнең бер генә көнен, бер генә сәгатен дә файдасыз яшәмәм дип йөкләмә алам. Кулларым инде винтовка тотарга, станок янында торырга ярамас. Ләкин мин — совет язучысы. Минем коралым бар — ул минем сүзем. Ул бушка яңгырамаска тиеш. Моның өчен мин намусым, тормышым, туган илгә мәхәббәтем белән җавап бирәм. Мин үз халкымның изге нәфрәтен, икенче дөнья сугышында күрсәткән батырлыклардан, дошманны җиңгәннән соңгы якты бәхетен китап битләрендә лаеклы гәүдәләндерү өчен үземнең барлык йөрәк көчемне туплармын. Бу мактаулы максатка омтылу үзе генә дә инде миңа Кызыл Армия белән дуслашу шатлыгы бирә. Минем вәгъдәм йөрәк түреннән килә. Шуңа да ул изге һәм эчкерсез. Мин язган китапларны Кызыл Армия сугышчылары теләп һәм ышанып укысыннар өчен көчемнән килгәнчә барысын да эшләрмен.*

*Мәҗит Рафиков*

# ТӨРКЕМЛЕ РӘСЕМ

Көннең кичке ягы. Офыктагы соргылт зәңгәр рәшә киң болыт пәрдәсенә әверелә, кояш шул пәрдәгә таба иңә бара.

Агалар клуб янына җыелдылар. «Россия» колхозы партоешма секретаре Габделхәй Сәләхов белән Күгәрчен авыл Советы председателе Госман Хәсәнов аларны каршылый тордылар.

Арт почмактан кинобудкага керә торган текә баскыч алдында тар гына капка калдырып, яңа рәшәткә кора башлаганнар. Рәшәткәнең эчке ягында чирәм.

Бу клуб бинасы элек Күгәрчен авылының «өченче мәхәллә» мәчете булган. Таш мәчет. Колхоз оешкач, манарасын егып, икенче кат үстергәннәр дә авыл Советын бу дәрәҗәле таш бинаның өстенә мендереп зурлаганнар. Китапханә белән уку залы да өске катта.

Ә агалар бу таш бинаның мәчет булган чакларны, патша-алпавытлы заманны хәтерлиләр.

Бүген бу өлкән агаларның чырайлары яктырып, хәрәкәтләре җиңеләеп, күз карашлары нурланып киткән. Сөйләшәләр, юкны бар итеп булса да сүз табып сөйләшәләр. Тавышларында күңел күтәренкелеге сизелеп тора.

Менә клубтан озын эскәмияләр алып чыктылар.

— Я, агалар, кем өлкәннәрчә утырып төшә, кем егетләрчә басып кына... Әйдә, тезелешегез.

Район фотографы — җиңел сөякле, җитез егет — бер чүгеп, бер тезләнеп җайланып алды.

— Төшерәм... Тагын бер...

Озакламый бу рәсем Күгәрчен урта мәктәбенең стенасында эленеп торыр. Укучылар үз авылларының ин хөрмәтле өлкән кешеләренә, үзләренең бабаларына горурланып карарлар.

Нинди-нинди юллар алып килде соң әле бу абыйларны бу клуб янына, бу егетнең фотообъективы алдына?..

Колхоз шоферы Шәмгун Вафин белән икәүләп без аларны бу зур авылның күперләреннән, тыкрыкларыннан әйләнә-әйләнә, өйләреннән алып килдек.

Менә алар — эшләпәле-бүрекле агалар. Арада бер-ике кәләпүш тә бар. Иң яше — 1901 елгы Сафа ага Мөхетдинов түшенә медальләрен тезеп таккан, кепкасын егетләрчә кырынрак салып, маңгаена төшереп кигән, туры, ныклы караш белән карап тора. Иң өлкәне — Сиражетдин ага Камалиев, такыясын арткарак чигерә төшеп, маңгае астыннан, күзлек аша җитди бер кыяфәттә карый.

Менә уртада Хәлил ага Ибраһимов утыра. Горурлык та, уйчанлык та бар аның кыяфәтендә. Хәлил аганың 1945 елның 28 маенда солдат килеш Берлинда төшкән рәсеме дә бар — солдат: «Тыңлыйм, иптәш командир!» дигәндәй карап тора... Ә менә 19—20 яшьләрендә Сембер — Бузулук арасында аклар белән авылдан авылга куышып, сугышып йөргән көннәрендә Хәлил ага берәр тапкыр рәсемгә төшкән булса, баш киемендә кызыл йолдызлы бер егетне күргән булыр идек...

Хәлил ага белән янәшә Гыйният ага Гарифуллин җылы, юмарт бер елмаю белән сиңа карап утыра...

Менә ап-ак мыеклы, үткен карашлы, җиңел сөякле Сәйфелмөлек ага Садыйков басып тора. Бала чагында ук, әле Ризаэтдин Заитовның русско-татарская школасына кергәнче, кырык чөйләп, «ташларын» куеп тегермән ясый белгән ул. Хәзер дә



**Рәсемдә Балык Бистәсе районы Күгәрчен авылының гражданнар сугышында катнашкан кешеләреннән бер төркем. Утыралар (сулдан уңга): Ибраһимов Шәвәли, Сафин Җәлалетдин, Хөснетдинов Шакир, Ибраһимов Хәлил, Гарифуллин Гыйният, Әхмәдиев Зәкиҗан, Камалиев Сираҗетдин. Басып торалар: Мингарипов Минзариф, Әхмәтсафин Сафа, Садыйков Сәйфелмөлек, Әхмәдиев Газизҗан, Мөхетдинов Сафа, Гәлиуллин Зиннәт, Хәбибуллин Хәлиулла.**

**Мәхмүт Вәлиев фотосы.**

агачтан сандугач ясап бирерлек оста куллы, галимнәрчә күзәтүчән, тирән фикерле, хикмәтле сүз яратучан, шагыйрь җанлы кеше ул Сәйфелмөлек ага.

Менә Шакир ага Хөснетдинов утыра. «Ә-ә, исәнмесез!» дигән сыманрак карый ул сезгә. Ул 1892 елгы. Сәйфелмөлек аганың тиңдәше. Царицын яклары, Деникин фронтындагы хәлләрне ул хәтерли әле... Кызыл кавалериянең атларын да бик җитез, бик оста дагалаган ул. Ә Бөек Ватан сугышында танклар ремонтлашкан. «Брянск, Беренче Белоруссия, II Балтик буе фронтлары дип язылган аның хәрби билетына...» «Сугышчан хезмәтләр өчен», «Германияне җиңү өчен», «Японияне җиңү өчен» медальләре бар аның. Тик ул аларны никтер такмый килгән... Берничә медаль белән бүләкләнгән... Колхозның оста тимерчесе булган ул Шакир ага, 63 яшенә кадәр тимер суккан.

Бүреген күтәребрәк кигән Сафа ага Әхмәтсафин басмачылар белән сугышып йөргән, Бөек Ватан сугышында гвардия рядовое булып катнашкан. Гомере буе атлар яраткан ул Сафа ага, колхозның атларын тәрбияләгән.

Бу агалар хәзер, әлбәттә, барысы да пенсиядә. Кыр эшләреннән, төзелеш бригадаларыннан, төрле эшләрдән ялга чыкканнар. Рәсемдә утырып-басып торган җирләреннән менә хәзер кузгалып, кайтып җиту белән балтага, кадак-чүкечкә барып ябышырлар, һәркайсысы нәрсәдер эшли, өмәлли башлар сыман.

Мин аларның һәркайсысы белән зур, кытыршы кулларын кысып күрешкәнем бар, сүзләрен тыңлаганда эштән-коралдан туймас бу кулларга карап уйланып утырганым бар.

Мин бу агаларның кайсысының капкасы кайсы якка ачылганын беләм. Бу кешеләрнең һичкайчан кабатланмас тормыш-көрәш юллары миңа Ватаным тарихы, халкым язмышы кебек үк якын.

Аларны бу объектив алдына алып килгән юллар — сукмаклар Күгәрчен авылының нәкъ әлеге патшалы, алпавытлы заманнан, «мең душлы» Күгәрченнең бер ир затына өч кырдан тигән җир өлеше 23 сажин да бер аршын (ягъни 0,64 га чамасы) туры килгән заманнардан, 400 ләп хуҗалыклы Күгәрченнең яртысы сыерсыз, яртысыннан күбесе атсыз чаклардан, авылның якын тирәләрен алпавытлар билләгән заманнардан башланган... Ул заманда бу агаларның үзәкләренә үткән иң яман ачысы — хокуксызлык, җирсезлек булган. Бу рәсемгә төшкән агаларның күбесе патша хезмәтенә дә алынганнар, герман

сугышы газапларын да татыганнар, әмма Ленинның җир турындагы Декреты тормышка ашканчы җирдән өлешсез йөргәннәр.

— Әтигә генә тигән бер имана җиребез бар иде, — ди Зиннәт ага Галиуллин. — Әнигә җир юк, мин 1896 елгы ревизиягә бераз гына туып өлгерми калганмын, әнем дә өлешсез, сеңелне әйтеп торасы да юк...

Мин әтинең олы улы, эшкә бик яшьли җигелдем. Агач сука белән җир сукалагач кул башлары өзелеп төшәрдәй була, чынаяк тәлинкәсен дә күтәрерлек көч калмый, кул калтырый, чәйне ятып эчә идем... Чемаков алпут уртактан чәчтерде. Үзе Казанда торды ул, монда управляющие генә иде... Лихачев алпут та — теге Шумбут спирт заводы хуҗасы — Петербург, Парижларда яшәде, ә эшләрен монда управляющие немец Карл Петрович алып бара иде. Без аңа ялланып үгез белән бәрәңге җире дә сөрдек, бәрәңгесен дә алдык... Алпут Гарталовка да, мунчасында куна ятып, җирен дә сукаладык, урагын да урдык, ашлыгын да суктык. Җире дә, үгезләре дә, атлары да, сбруйлары, атлы молотилкалары да алпавытныкы, без коры хезмәтчеләр генә — пролетариат! Кумәк йөри идек алпавытларга... Уку күп эләкмәде. Нәҗип мулла укытты. «Ярар, аллага гыйбадәт кылырлык булгач, бик җиткән»,— ди иде. Аннан Ризаэтдин абыйның русско-татарская школасына күчтем дә күчүен, эшкә ярый башлагач укып булмады... Чистай ягында байларга ялланып утын кисеп-турап та йөрдек. Шәмсемөхәммәт атлы бер иптәш белән. Кама яры оем-оем утын булыр иде. Безнең кебек ярлы-ябагай байларга, алып-сатарларга ялланып утын кисә...

Күгәрчен авылының үсмерләре алпавыт утарларын бик яшьли таптый башлаганнар. Кайберәүләр шәһәрләргә китеп, тамак, өс-баш ялына татар байларына малайлыкка кергәннәр. Газизҗан ага Әхмәдиев уйнап йөргән җиреннән Чистайга кунакка киткән, кунак булып ятып йоклаган, бакалейщик Мансуровның хезмәтче малае булып уянган... Шакир ага Хөснетдиновны язмыш 12 яшендә пайтәхеткә үк илтеп ташлаган. Ул Петербург байларыннан Һидиятуллин дигән берәүгә малайлыкка барып эләккән... Хәлил ага Ибраһимов, авылдашларына ияреп китеп, Томск сәүдәгәрләре борадәран Фәйзуллиннарда 15 яшендә җимеш сатыша башлаган...

Герман сугышы чыккач, Күгәрчен егетләре — үзләре күбесе җирсез килеш — патша өчен сугышка китәргә тиеш булганнар...

Ә солдатка алганнар. Әйдә, окопта бет ашатсыннар, «ура» кычкырып үлемгә барсыннар, тик алпавыт Лихачевлар, Гарталовлар типтереп яши бирсеннәр...

Февраль революциясеннән соң, исән калган Күгәрчен егетләре бер-бер артлы кайтып төшкәннәр. Пленга эләккәннәре туган авылын соңгарак кайтып күргән.

Октябрь революциясе җиңгәч, Күгәрчен ярлылары иң якындагы алпавыт Чукашев, Чемаков утарларына ашыга. Кемгә алпавытның аты, кемгә — тарантасы, кемгә — капкасы...

1918 елның апрелендә Күгәрченнән ярлылар комитеты комиссиясе, Лаештан — өяз Җир бүлегеннән килгән землемер белән бергә, озын арбага ат җигеп кырга чыгалар. Арбага яңа очлаган казыклар төягәннәр, балта салганнар. Арба башында өч аяклы визирный линейка. Ат янында атлаган землемерның кулында тимер юлчыларныкы шикелле ике флаг: берсе кызыл, берсе ак...

Чабаталы агайлар белән бергә яше егермә белән барган җиңел, җитез генә бер егет Хәлиулла Хәбибуллин атлый. Ул инде сугыш күреп, «дары иснәп» кайткан... Рәсемдә ул, чиккән такыясын киеп, бер кырыйдан гына басып, бәләкәй генә булып төшкән. Гәүдәгә үзе шулай җыйнак, җиңел ул, күгәрчен кауры кебек кенә.

Землемер үзенең өч аяклы визирный линейкасыннан карап күрсәтүенчә, Хәлиулла казыкны уңгарак, я сулгарак күчерә, дөреслэп куйгач аны яңа межага батырып кага да арбадан барып янә казык ала... Буыннан-буынга алпавыт Чукашев, Каменев, Чемаков, Безобразов, князь Грузинскийлар биләп килгән җирләр, Ленин Декреты буенча, яңа межа сузып күгәрченлеләргә, Олы Көл, Кече Көл, һ. б. авыл крестьяннарына шулай бүленә.

— Мин комиссиядә түгел идем, ярдәмче булып кына, казыклар кадап кына йөрдем, — ди Хәлиулла ага. — Халык бик шатланды. Җирләребез артты. Хатын-кыз да өлешкә керде бит. Керәстиян халкы иркен сулап җибәрде.

Ләкин җәйгә чыккач, әлеге алпавытларның яклаучылары — ак чехлар килеп чыгалар, Казанны алалар... Үзләренә гаскәр туплый башлыйлар, хәрби мобилизация уздыралар. Күгәрчен егетләре дә эләгә.

Өяздән җыелган бөтен егетләрне ипи баржасына төяп, Лаештан Самарага җибәрәләр, Совет властена каршы сугыштырмакчы булалар...

Җәйге көн кичкә авыша. Баржаның ян капкалары тыштан бикле, өсте каплаулы, баш өстендә люклары гына бар, өстә мылтыклы солдатлар... Лаештан Кама Тамагына таба алып китәләр... Бара торгач, бер заман, күктә самолет гүләп килә... Кызылларныкы! Бомба ташласа, баржадагы егетләр бетә бит! Баржаны кире боралар. Түбәнге пристаньнан егетләрне кире Лаешка алып китәләр, анда янә баржага төшәргә, Самарага китәргә диләр... Төнгә таба, кабат баржага төяләргә барганда, егетләрнең күбесе тая... Икәүләп-өчәүләп тә, төркем-төркем булып та Коры Елга үзәне буйлап кача-поса кырга чыгалар, урманга кереп хәл җыеп алалар да, Лаешны өстән урап, кайту ягына сыптырталар. Өсләрендә өйдән киеп чыккан әрсез кием, тамак ач. Ике тәүлек кайталар; кайткач, кайсысы ындырда, кайсысы печән кибәне астында, кайсы кайда яшеренеп ята... Лаеш янында ычкына алмаган кайберәүләр соңрак, күбрәк газаплар күреп, кайталар. Шакиров Фатих белән Әзһәров Хәсән аклардан Себердә генә качып, шуннан хәлсезләнеп чак кайтып керәләр. Бу рәсемдәге Хәлиулла ага Хәбибуллин, Гыйният ага Гарифуллин, Зәкиҗан ага Әхмәдиев — шул акларга хезмәт итүдән баш тартып качып кайтучылар исәбеннән. Бу рәсемгә кермәгән Сәйфетдин ага Садыйков та (Сәйфелмөлек аганың энесе ул, Мәскәүдә яши), болар белән бергә качып кайткан.

Күгәрченнең ярлы егетләре арасыннан Кызыл Армиягә үзләре теләп язылучылар да күп булган.

Хәлиулла ага 1919 ел башында авылдашлары Сәйфетдин Садыйков, Мөхәммәтзакир Шакиров, Зәкиҗан Әхмәдиевләр белән Колчакка каршы сугышып йөри. Кулы җәрәхәтләнеп госпитальдә ятып чыккач, бераз вакыт Казанда хәрби объектлар сагында тора, аннан Чабаксар ягында сәнәкчеләр фетнәсен бастыруга катнаша, махсус частьта (ЧОН) хезмәт итә. Ядрин өязендә алар чикмән-чабата киеп, ат эзләп йөргән булып, бер бандага «җыеп алалар»... Хәлиулла ага Псков, Двинск якларында да сугышларга катнаша. Деникин фронтында ул разведчик булып, дүртбиш тапкыр «плен төшеп», дошманнарның гаскәр исәбен, корал көчләрен күзәтеп, үзебезнең якка әһәмиятле мәгълүматлар ташып йөри. Шулай йөргәндә, авылдаш дусты Ямалетдин Билалов белән Калач — Тихорецкая арасындагы бер станциядә үлемнән чак котыла. «Үзләре теләп» аклар ягына чыккан бу ике кызылармеецны деникинчылар штабта танып алалар: «Болар бездә булганнар иде! Мөгаен, коммунистлар алар!..» Китә допрос, китә кыйнау. Сүз ала алмагач, бер байның подвалына төшереп биклиләр дә подвалга су җибәрәләр... Салкын су тездән була, билдән була... Бер офицер узып барышлый гына ишек тишегеннән килеп карый: «Кемнәр буласыз?» — «Татарлар без, Казан ягы, Лаеш өязеннән...» — «Земляки! Мин бит Уракчыдан». (Ә Уракчы — күгәрченлеләрнең волость үзәге.) — «Без бу якка добровольно чыктык, ә безне коммунист диләр...» — «Исән чакта качу ягын карагыз...» Ә подвал чыгарлык түгел, нык, хәл дә беткән... Офицер ике-өч мылтык каешы китереп ташлый... Таң белән үзебезнең якка чыккач, хәлсез бу ике егетне кызыл командирлары чак танып ала.

Хәлиулла ага ял итеп алгач, янә исәнсау сугышка керә (соңыннан тешләре генә коела), ә авылдаш дусты Ямалетдин Билалов шул салкын тиюдән үпкәсе шешеп үлеп кала.

Хәлиулла ага, деникинчыларны диңгезгә бәреп төшердек дигәндә, Таганрогка 8 километр гына калганда, аягы яраланып тылга китә...

— Ватан сугышында да нәкъ шул Көньяк фронтта, Батайск, Ростов тирәләрендә йөрдек, — ди Хәлиулла ага. — Деникин белән сугышып узган таныш җирләр иде. «Бәхет» шул бер үк җирдә булып чыкты: 1943 елның кышында, Ростовка һөҗүм итеп барганда, янә шул ук сул аякка ярчык тиде. Бармак очларын чәрдәкләде... Колхозда балта остасы да, шорник булып та эшләдем, пожарный команда башлыгы булып та тордым. Сугыштан соң, 1955 елга тикле, агротехник идем...

Зиннәт ага Галиуллин рәсемдә Хәлиулла ага янында гына елмаеп тора.

— Герман сугышында, безнең часть камалуда калгач, пленга төштек. Анда күргән газаплар төшеңә кермәсен. Германиядә революция чыккач, пленныйларны алыштырдылар, 1920 елның мартында кайтып төштем. Миңа да җир бирделәр. Әтигә сука сукалаштым. Аннары Кызыл Армиягә алындым. Пермьда поездан төшеп, авылдан-авылга атлар җиктерә-җиктерә киттек. Конный разведкага эләктем. Төнлә авылга

килеп, читтәрәк торган ярлырак өйгә кереп сорашасың: «Авылда аклар бармы, юкмы?..» Булсалар, үзебезнекеләргә хәбәр итәбез дә, рота белән авылның артына чыгып яшеренәбез. Безнекеләр алдан «ура» кычкырып, ата-ата авылга бәреп керә, без тылларыннан күтәрелеп чыгабыз. Аклар, котлары алынып, югалып калалар, плен төшкәннәрен артка озатабыз... Кышын без, разведчиклар, чаңгыга бастык. Чаңгылар яссы, асты — сыер тиресе. Таугa менгәндә артка тайдырмый. Түбән төшкәндә күздән утлар чыга. Аклар торган авылларны камаганда, взвод булса, «Рота!» дип, рота булса, «Полк!» дип команда биреп котларын ала идек...

Уралның олы тавын поезд белән туннельдән үттек... Колчакларны куып узганда, Байкалда боз ята иде әле. Кытай чигендә сугышны бетереп кайтканда бозы юк иде инде... 1921 елның җәендә кайтып төшсәм, әти үлгән, энем үлгән. Авыл Советы миңа бер пот кукуруз оны бирде, өйләндем... Колхозда ат карадым... Ватан сугышында да булдым, 43 нең җәендә Дон буенда ранен булып госпитальдә яттым, Кизел ягы шахталарында каравылда тордым. Кайткач, колхозда ат карадым, сарык көттем...

Яшьләрчә кепка киеп төшкән Сафа ага Мөхетдинов Мелитополь тирәләрендә махночылар белән булган бәрелешләрне күз алдына китерерлек итеп сөйли... Түшендәге медальләренең берсе аңа Бөек Ватан сугышында Кенигсбергны алуда катнашуы өчен бирелгән. Күп фронтларда алга узучы частьларыбыз өчен тимер юллар төзәтү эшендә булган ул.

Минзариф ага Мингарипов та Перекоп районында врангельчеләрне куып атакага баруларын, пулеметтан атып яткан бер ак офицерны ничек йомдыруларын бик җанлы итеп сөйли. Ул да Бөек Ватан сугышында катнашкан.

Гыйният ага Гарифуллин Деникин гаскәрләренә каршы сугышка Царицыннан (Волгоград) ерак түгел Бекетовка янында кергән. «Ак казакларның күп икмәк түләп алган инглиз танклары бар иде, танкка дүртәр пулемет куеп безгә аталар иде»... ди Гыйният ага. 1945 елның бөек җиңү көнен ул Чехословакия җирендә каршылаган солдат.

Ярлы крестьян халкы Совет властен чын-чыннан үз власте итеп кабул иткән, яшь Совет властен дошманнардан саклар өчен бер өйдән икешәр-өчәр бертуганнар бергә күтәрелеп чыккан очраклар да еш булган. Колчак фронтыннан соң, Сәйфетдин Садыйков Бохара, Фиргана, Җидесу якларында басмачыларны куып йөргәндә, аның абыйсы Сәйфелмөлек тә шул ук фронтта булган. Хөснулла ага Сибгатуллин Махно бандаларына, Врангель гаскәрләренә каршы сугышканда, абыйсы Сөнгатулла ага Сибиев Бохараны басмачылардан азат итешеп, Токмак якларына юл тоткан. Разведкада йөргәндә, иптәшләре белән, басмачыларның чалмалы шпионнарын кулга эләктергәләгән. (Фотограф килгәндә бу ике ага өйдә юклар иде.)

Ә Әхмәдиев Сафа картның уллары: 1894 елгы Җәлалетдин ага, 1896 елгы Газизҗан ага, 1898 елгы Зәкиҗан агалар 1918 елның сентябрендә өчесе дә Кызыл Армия сафына басканнар. Менә рәсемдә Җәлалетдин ага (ул Сафин фамилиясендә йөри, энеләре Әхмәдиевләр) горур, тәвәккәл бер кыяфәт белән утыра. Ул, 1918 елның җәендә аклар мобилизациясенә эләккәч, авылдаш иптәше Әдһәм Самаров белән Бишбалтадагы казармадан качып кайткан. 1919 елны Җәлалетдин ага энесе Зәкиҗан белән бер үк фронтта Азин дивизиясендә Колчакка каршы сугышып йөргәннәр. Җәлалетдин ага тиф белән авырып, Камбаркада сафтан калган. Ә энесе Зәкиҗан Аксәет авылына һөҗүм иткәндә яраланып Казан госпиталенә кайтарылган. «Аклар Аксәет мәчете манарасына пулемет куйганнар да безнең цепьләрне кырып кына торалар...» дип сөйли Зәкиҗан ага. Хәлиулла ага Хәбибуллин да шул һөҗүмнәрдә яраланган, Сәйфетдин ага Садыйков та ул Колчак гаскәрләрен эзәрлекләп йөргән карлы, буранлы юлларны, утлы бәрелешләрне яхшы хәтерли. Ә Газизҗан ага махсус эчке сак полкына билгеләнгән, Арчада, Шихранда (хәзерге Канаш) тимер юл станцияләрендә эчке сак хезмәтен башкарган, соңгарак Красноуфимск ягында кулак бандаларын коралсызландыру операцияләрендә катнашкан...

Рәсемдә нечкә генә ак мыек калдырган, какча йөзле ага — Шәвәли Ибраһимов була.

— Пәке идем мин егет чакта, пәке! — ди ул, үткәннәрен хәтерләп. — Скрипкасын да сыздырып уйный идем, җырлап та җибәрә идем. Минем өчен йөрәк майлары сызылган кызлар булды инде, булды... Кызыл Армиядә без авылдаш егет Шиһап Фәтхуллин белән саперный батальонга

элэктек. Казан тирәсендә хәрби ныгытмалар кордык... Чехларны куа-куа Кама, Агыйдел буйлап Уфага барып җиттек. Уфаның тимер юл күперен аклар шартлаткан иде. Поездга утырып Уралга киттек. Сугышсыз чигенделәр... Златоусттан 28 чакрым Кусиновский заводка барып кердек, мин шунда тиф белән авырып калдым... Терелеп кайттым, 16 көн ял иттем, янә алындым. Бу юлы кавалериягә. Мине 2 нче полкның мөселман ячейкасы театральный группага алды, артистларга кием, сәхнә кирәк-ярагы булдырып йөрдем... Аннан мөселман ячейкасына вестовой итеп алдылар...

Бөек Ватан сугышында Шәвәли ага 1942 ел башында фашист гаскәрләрен Мәскәүдән куганда яраланган, ул — Ватан сугышы инвалиды.

— Ул Тәфтиләүләрне үзем уйнап, үзем җырлап биргән чаклар да бар иде...

> Йөгереп бара, йөгереп кайта
> Ударница Мәрзия.
> Дошманнарны сөбереп түкте
> Безнең Кызыл Армия, —

монысын үзем чыгардым, — дип тә куя ул.

Менә шулар инде алар Күгәрченнең гражданнар сугышында катнашкан кешеләре. Бу очеркта аларның кайсысы кайсы дошманнарга каршы сугышкан, кайларда нинди хәрби хезмәт башкарганлыкларын язып бетерү, әлбәттә, мөмкин түгел. Бүген аларны бу клуб янына ил тарихына уелып калган ерак юллар, данлы юллар алып килгән...

Ләкин бу рәсемдә алар барысы да түгел. Сәйфетдин ага Садыйков Мәскәүдә яши, ул бу рәсемдә юк. «...Сарапулны узгач, ачык кырда вагоннардан төшеп, сафка тезелдек. Анда безне дивизия командиры Азин үзе кабул итеп алды, — дип яза Сәйфетдин ага үзенең авылдаш иптәшләре белән Колчак фронтына барулары турында. — Безне 246 нчы укчы социалистик полкка билгеләделәр, шунда ук корал бирделәр. Бекбарда заводы дигән авылда акларның һөҗүмен кире кагып, үзләрен куып киттек... Күз ачкысыз буранда Куеда станциясенә барабыз. Әлмәт дигән авылны азат итеп, төнлә Аксәеткә һөҗүм ясыйбыз... Бу була 1919 елның 27 февраленнән 28 февралена каршы төнге уникеләрдә...»

Менә минем алдымда Сәйфетдин аганың 1919 елның ахырында Казанда 6 нчы запас полкта чагында төшкән рәсеме. Гимнастерка, чалбар, ботинка, обмоткадан. Башында аксыл папаха. Утырып төшкән. Гәүдәгә таза, үткен карашлы егет булган ул. Ә менә аның 1942 елны төшкән рәсеме. Монда да ул солдат. Погоннары юк әле... Берлинны штурмлауда, Праганы азат итүдә дә катнашкан ул...

Рәсемдә ундүрт кеше, ә яшь совет илен дошманнардан сакларга Күгәрченнән йөзләгән кеше күтәрелеп чыккан. Хәмәтхан Моталлапов, Минзакир Садыйков, Миңгали Гарифуллин, Хәмәтхан Мөхәммәтҗановлар Кызыл Гвардиягә үз теләкләре белән барып язылганнар. Хәмәтхан Моталлапов большевик, пулеметчылар командиры булган, Уфаны Колчактан азат иткәндә, яр бакчасында җәрәхәтләнеп, бер аяксыз кайткан. Минзакир Садыйков та Чапаев дивизиясендә сугышкан. Моннан бер-ике ел гына элек үлгән әле ул. Моталлапов Хәмәтханның энесе Гариф, Яруллин Гыйльметдиннәр Пермь ягында Колчак белән сугышканда башларын салганнар. Шәмтиев Харис шул ук Колчак фронтыннан бер кулсыз кайткан. Күпләрнең гомерен сугыш яралары кыскарткан, гражданнар сугышыннан исән кайтканнардан кайберәүләр Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар. Исән булсалар, алар барысы да бу рәсемгә сыярлар иде, безгә истәлекләрен сөйләгән булырлар иде...

Алар безнең бик күпләребезне күрә дә, белә дә алмаганнар, ләкин безнең якты киләчәгебез өчен утка кергәннәр, гомерләрен аямаганнар. Без дә, бик күбебез аларны күрмәгәнбез, ләкин алар, бу рәсемдә булмасалар да, барыбер безнең күңелләрдә яшиләр, яшәячәкләр.

Сүз ахырында шуны өстәп әйтергә кирәк: Хәлиулла ага Хәбибуллин белән Зиннатулла ага Галиуллинны 1917—1922 елларда Совет власте урнаштыру өчен көрәштә үзләрен аеруча күрсәткән кешеләр рәтеннән СССР Верховный Советы Президиумы «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләде.

●

*Галимҗан Латыйп*

## Җыр үткәндә

Шау-гөр килеп иртә таңнан
Уянды кырлар.
Курганнар, үрләр артыннан
Ишетелә җырлар.

Киттеләр аклар кичә кич,
Атларны алып.
Күңелгә гомер җуелмас
Яралар салып.

Шуңамы авыл барына
Сагаеп карый...
Болары тагын атларга
Тимәсә ярый...

Йортта ул сүзне читләтеп
Тарта ул кылны.
Утыртып колак яфрагын
Тыңлый һәр җырны.

Ошаса күңелгә бер җыр,
Эри дә китә.
Кешегә андый вакытта
Бер сүз дә җитә.

Тәгәрәп килә дә җырлар,
Авылга керә.
Бу җырны малай-шалайлар
Беләме!
Белә!

«... Күзгә ачы җилләрдә лә,
Туган-үскән илләргә...»

Куйганнар иде капкага
Кичә нык терәү.
Йөгерә капка ачарга,
Йөгерә берәү.

Иярә аңа малайлар,
Ялт та йолт үкчә.
Шатлыклы хәбәр шул ара
Йортларга күчә.

Югала куркү йөзләрдән:
— Үз икән болар.
Ишетүе шундый күңелле,
Әй, таныш җырлар!

Шлемда кызыл йолдызлар
— Янамы!
— Яна!
Күзләрдән яшьләр ялтырап,
Тамамы!
Тама!

Ләкин бу яшьләр, беләмсез,
Кичәге түгел.
Шатлыгын тыя алмыйча
Чыга ул бүген.

Малайлар шундый түземнәр
Еламадылар.
Аклардан алар берни дә
Сорамадылар.

Ә бүген бөтенләй башка,
Ачылган телләр.
Әйтерсең, алар кичә дә
Уйнаган-көлгән.

— Бир абый, кызыл йолдыз, — дип
Ялына алар.
— Булмаса, атың эчертеп
Кайтсак та ярар.

Бәйрәме безнең урамның,
Һәр кеше көләч.
Тагылган малай-шалайның
Тоймә һәм керәч.

Эленке-салынкы йөрү
Ярамый хәзер.
Алар бит командир кушкан
Һәр эшкә әзер.

Малайлар түшендә йолдыз,
— Купшымы!
— Купшы!
Аларга дөнья рәхәте,
— Шушымы!
— Шушы!

Сөйләде авыл кичә кич
Ниләр булганны:
— Кан белән буяп киттеләр
Аклар урамны.

— Бирмим, — ди Хатмулла атын, —
Мәгез, атыгыз!
Крестьян атсыз нишләсен,
Бармы оятыгыз!..

Ул аннан аклар юлына
Аркылы ятты.
Шомполлар белән суктырып
Киттеләр картны...

Тын гына тыңлый командир,
Ачулы күзләр.
— Хатмулла бабай мескен, ди,
Ул ничек түзгән.

Һәм әйтте:
— Хәлен белергә
Барыгыз алып.
Миң рәхмәт укый әченнән
Аңа бар халык,

Хатмулла бабай шатлыктан
Күтәрде башын.
Яшерде командирдан ул
Җимерелгән кашын.

Янәсе, минем кыяфәт
Ярыйсы әле.
Китмәсен мондый көннәрдә
Дөньяның яме.

— Алсыннар, аты чурт с ним,
Мыскылы яман!
Терелим генә, сугышка
Алсалар барам!

Карчыгы тора аптырап:
— Карт инде син, карт!..
Командир әйтә:
— Күрәмсең, әнә сиңа ат!

Кешнәде ярып Тимеркүк,
Иснәде җирне.
— Иштәмсең, бабай ул сиңа
Сәламен бирде.

Хатмулла бабай моңарга
Әй, каршы торды.
Карчыгы, биргәнне ал, дип,
Тамагын кырды.

— Үз атым, ал бабакаем,
Тартынма бер дә.
Кирәк ул сиңа, бик кирәк,
Сабан сөрергә.

Җыенды иртән походка,
Җыенды гаскәр.
Уйныйлар саратскийны,
Биләр яшьләр.

Сискәнеп китте командир,
Тимеркүк ярып
Кешнәде, күтәрелешеп
Карады халык.

Иярле атка яшь кенә
Малай атланган.
Иреннәр елмая, йөзләр
Балкый — шатланган.

— Бу ни эш! — диде командир. —
Марш кирегә!
Ә малай үйлап та бирми,
Тели белергә.

— Юлга хәзерме чыгасыз!
Иярәм мин дә.
Ышан син миңа, егылмам
Давылда, җилдә.

Мин инде малай түгел лә,
Уналты тулды!
Үземә-үзем ярырга
Тиеш мин юлны.

Рөхсәтсез түгел мин, абый,
Син мине кума!
Бабакай үзе шатланып,
Җыйнады юлга.

Бар, аны хәзер син инде
Ияртми кәра!
Күңелеңдә, димәк, гомерлек
Төене кала.

Уйлана... Хатмулланың да
Хәтере калыр.
Саклар ул авыр бер тойгы,
Каберенә алыр...

Уйнады көмеш быргылар,
Уянды кырлар.
«... Йөгереп китәрдәй булам ла!..»
Киттеләр җырлар...

Иярде җырга күңелләр,
Иярде яшьләр.
Дошманның башы өстендә
Яшеннәр яшьнәр!..

●

*Рафаэль Мостафин*

# УНӨЧЕНЧЕ

*Икенче очерк*

## «Идея ягыннан ышанычлы, мораль яктан тотнаклы...»

**1950** елның 24 апрелендә Кустанай өлкәсенең Боровски сельпосында председатель урынбасары булып эшләүче Мәхмүт Нурмөхәммәт улы Җамалетдиновны кулга алалар. Бу хәл Җамалетдиновның хезмәттәшләре өчен дә, туганнары һәм танышлары өчен дә бик сәер тоела. Чөнки ул эшендә дә, өендә дә, семьясында да тыныч, тыйнак, тәртипле һәм бик төгәл кеше була. Председатель урынбасары итеп билгеләнгәнгә кадәр склад мөдире вазифасын башкара. Анда да бөтен эшен пөхтә алып бара, бер тиенлек әйберсе артык та, ким дә чыкмый. Менә шул гаделлеге өчен аны хөрмәт итәләр һәм, әйбәт эшләвен искә алып, берничә мәртәбә бүләклиләр, премия дә бирәләр. Тикшерү органнарына биргән характеристикасына да: «Тапшырылган эшләрне тырышып башкара, җәмәгать эшләрен үти, идея ягыннан ышанычлы, мораль яктан тотнаклы», дип язалар.

Кыскасы, Җамалетдинов һәр яктан уңган, булдыклы хезмәткәр саналып йөри.

Ләкин, шулай да, кайбер шактый сәер яклары була аның. Әйтик, ул ничектер йомык характерлы кеше була һәм эшеннән соң буш вакытларында беркем белән дә аралашмый. Кунак чакырмый, үзен чакырсалар да барырга яратмый. Эш сәгате бетүгә өенә кайтып китә, хәтта кинога һәм концертларга да бик сирәк йөри. Хатынын да тыеп тора: өйдән чыгып йөрмәскә, кешеләр белән аралашмаска куша. Ихтимал, нервлары какшаган булгангадыр, әгәр кеше күрсә, куркынып, агарынып кала. Аннары үзе артында кем дә булса басып яисә утырып торганны һич яратмый. Хәтта җыелышларда һәм президиум өстәле артында утырырга туры килгән вакытларда да гел арткы рәткә посуны җайлы күрә. Әгәр дә артында берәр кеше утыра икән, минут саен аңа борылып карый һәм, ахыр чиктә, барыбер иң артка күчеп утыра. Хезмәттәшләре аның бу сәер гадәтләрен белсәләр дә әллә ни зур игътибар бирмиләр: сугышның башыннан ахырына тикле диярлек дошман тылында партизанлыкта йөргәннән калган гадәтедер дип кенә уйлыйлар.

Кайберәүләр кебек зуррак урынга ирешергә дә атлыгып тормый Җамалетдинов. Склад мөдиреннән председатель урынбасары итеп күтәрү хакында сүз чыккач та бик күп мәртәбәләр үгетләгәннән соң гына риза була. Сугышта күргәннәре турында сөйләвен үтенеп, пионерлар аны үзләренә чакырган вакытларда да тыйнаклык күрсәтә: минем алай зурлап сөйләрлек батырлык эшләгәнем юк, дип очрашуларга бармый кала.

Кылыч борынлы, кара чәчле, ябыграк озынча йөзле, урта буйлы, тыйнак, әмма зәвык белән киенгән менә шул кеше хәзер кулга алынган һәм тикшерүче каршында утыра. Түгәрәк тимер бөҗралы иске модалы күзлеге аңа интеллигент кыяфәте биреп тора. Тыштан караганда, сәүдә эшчесеннән бигрәк, укытучыга охшаган ул. Гадәттән тыш җитди кыяфәтле булганлыктан, әле егерме тугызда гына булса да, шактый олы яшьтәге кеше кебек күренә.

Җамалетдинов, һич гаепсез кеше кебек, үзен бик тыныч тота. Тикшерүченең сорауларына бер дә ашыкмыйча, артык вакланмыйча, әмма тулы итеп җавап бирә.

Тикшерүче шулай ук ашыкмый. Кулга алынучының үзеннән сорашып, фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын һәм урынын, якын туганнарының фамилияләрен һәм адресларын язып куя. Аннары биографиясен сөйләргә куша.

Җамалетдиновның биографиясендә бер дә алай шикләнерлек нәрсә юк. 1921 елда Кустанай өлкәсенең Семиозерка поселогында туган. Кустанай шәһәрендәге урта мәктәпнең сигез классын тәмамлаган. Шунда комсомол сафына кергән. Аннары нотариаль конторaның секретаре булып эшләгән. 1940 елда армиягә алынган. Беренче көннәреннән алып, Ватан сугышында катнашкан. Яраланган, чолганышта калган һәм партизаннарга кушылган. Алар белән 1944 елга кадәр дошманга каршы сугышып йөргән, аннары безнең армиянең регуляр гаскәрләре сафына күчкән. 1945 елда демобилизацияләнгән һәм шуннан бирле сәүдә эшендә эшли. Өйләнгән. Өченче яшенә чыккан малае бар. Хатыны икенче балага узган.

— Чолганышта ничек калдыгыз? Аннары партизаннарга ни рәвешле юлыктыгыз? Шул хакта тулырак сөйләгез әле!

Җамалетдинов ялт итеп тикшерүчегә карап ала да сүзен дәвам итә.

Сугыш башланганда Балтик буенда булган. Дошманның беренче һөҗүме алар частена туры килгән. Бик тырышып каршылык күрсәтүләренә карамастан, немецларның частьлары Җамалетдиновлар частен флангтан әйләнеп үткән һәм сугышның өченчеме яки дүртенчеме көнендә болар камалышта калган. Шул көннәрдә Җамалетдиновның сул аягы каты яраланган. Аяк сөяге сынган аның. Әмма аны иптәшләре ташлап калдырмаган, үзләре белән күтәреп алып киткәннәр. Урман һәм сазлыклар аша ай ярым чамасы көнчыгышка таба барганнар. Әмма, һәркайда немец патрульләре очрап торганлыктан, алга бару һаман саен кыенлашкан. Шунлыктан сугышчылар икеөч кешелек вак группаларга бүленеп хәрәкәт итәргә карар кылганнар. Ә Җамалетдиновның аягы һаман да ныграк шешә барган. Авыртуына түзә алмыйча кычкыра, саташа ук башлаган. Ахыр чиктә иптәшләре аны кечерәк кенә бер поляк хуторында калдырып китәргә мәҗбүр булганнар.

Йорт хуҗалары бик әйбәт кешеләр булып чыккан: аны бик яхшы караганнар, ашатканнар һәм эчерткәннәр, кирәкле даруларны табып биргәннәр, берничә мәртәбә доктор да алып килгәннәр. Җамалетдинов акрынлап терелә башлаган. Аннары йорт хуҗалары аңа поляк партизаннары отрядына кушылырга ярдәм иткәннәр. Сөйләвенә караганда, 1944 елның җәенә кадәр Җамалетдинов поляк партизаннары отрядында немецларга каршы сугышып йөри. Бик күп мәртәбә сугыш операцияләрендә катнаша, диверсион эшләр башкара, җаваплы заданиеләрне үти. Аннары, руслар группасы белән бергәләп (анда аларның барысын — татарларны да, украиннарны да, белорусларны да, грузиннарны да руслар дип йөрткәннәр), подполковник Золотарев, ягъни партизаннар атап йөрткәнчә Золотарь, җитәкчелегендәге совет партизаннары отрядына кушыла. Бу отрядта Җамалетдинов әллә ни озак тормый. Тиздән фронт Белоруссиягә килеп җитә һәм әлеге отряд Совет Армиясе частьларына кушыла.

Тикшерүче аның сүзен бүлдермичә генә тыңлый һәм сөйләгәннәрен язып бара. Барысы да дөрес, барысы да Җамалетдиновның анкетасына теркәлгәннәргә сүзгә-сүз туры килә. Ә иң мөһиме шул: Җамалетдиновның барлык сүзләре документлар белән раслана. Менә партизан отряды командиры Золотаревның имзасы куелган һәм, бик үк ачык булмаса да, печать белән расланган бер белешмә. Җамалетдиновның, чыннан да, 1944 елның җәй һәм көз айларында Золотарев җитәкчелек иткән отряд белән бергә сугышып йөрүе хакында әйтелгән анда. Менә поляк телендә язылган һәм берничә кеше имзасы белән беркетелгән тагын бер белешмә. Анда шулай ук Җамалетдиновның гадел хезмәт итүе турында әйтелгән. Датасына караганда, белешмә ул поляк отрядыннан киткән көнне бирелгән. Тик шунысы сәеррәк: киткән көне күрсәтел-

гән, ә отрядка кайчан килгәнлеге әйтелмәгән. Тикшерүче шул турыда сорагач, Җамалетдинов җилкәсен сикертеп куя да:

— Немец поездларын шартлаткан чакларда безгә ул хакта белешмә бирмиләр иде, — ди. — Беләсезме, анда бюрократизм белән шөгыльләнеп торырга вакыт булмады. Хәтта сөйгән кызыңның рәсемен йөртергә дә рөхсәт ителми иде. Ә бу белешмәне алырга Золотарь отрядындагы элек махсус бүлектә эшләгән бер кеше акыл бирде. Без, диде, сезнең поляклар белән бергәләп батырларча сугышканыгызны беләбез, әмма алдагы көнегездә, бәлки, документның кирәге чыгар, диде. Шуннан соң без, инде китәргә кузгалгач, кире полякларга килдек тә, шулай-шулай дип мәсьәләне аңлатып бирдек. Алар көлделәр, әмма сораган белешмәне бирделәр. Бер миңа гына түгел, барыбызга да шушылай язды алар. Бик нык оялдык без ул чакта, җир тишегенә кереп китәрдәй булдык. Ләкин соңыннан, 1945 елның маенда тикшерү пунктына эләккәч, теге акыл биргән кешегә бик күп рәхмәтләр укыдык. Югыйсә, үзебезнең гаепсез икәнлегебезне ничек расый алыр идек? — ди.

— Кемнәр соң ул «без»? — ди тикшерүче, Җамалетдиновның сүзен бүлеп.

— Соң мин инде... һәм башкалар...

Болары да дөреслеккә туры килә. Сугыш вакытында фашистик Германия оккупациясенә эләккән барлык совет гражданнары кебек үк, Җамалетдиновның да 1945 елның маенда Львов шәһәре янында тикшерү пункты аша үткәнлеге һәм бернинди дә гаебе табылмаганлыгы турында да белешмә бар аның анкетасында.

Тикшерүче тагын кайбер нәрсәләрне сораша да кинәт:

— Муса Җәлил исемле шагыйрь хакында ишеткәнегез бармы? — дип сорый.

— Муса Җәлилме? — Җамалетдинов уйга калып, кашларын җыера. — Юк... Хәер, бар шикелле. Әйе, искә төште. Белүен белмим мин аны, әмма әсирлектә булган кешеләрдән — татарлардан андый шагыйрь булганлыгы хакында ишеткәнем бар. Сугышка кадәр үк әле Татарстан язучылар союзы председателе булган. «Алтынчәч» операсын язган, шулаймы?

— Аның турынданиләр беләсез?

— Әйбәт сөйләмиләр иде аның турында, — ди Җамалетдинов, көрсенеп. — Үзе теләп әсир төшкән, ә аннары фашистларга хезмәт итә башлаган дип әйттеләр. Аларга татар легионы төзергә ярдәм иткән, фашист газеталарында эшләгән. Аның немец формасын киеп йөрүен дә күргәннәр. Сатлык җан булып чыккан, күрәсең...

Тикшерүче байтак вакыт текәлеп Җамалетдиновка карап тора. Ышанамы ул аңа, әллә юкмы — әйтүе авыр.

— Әйткәннәрегезгә өстисе нәрсәләрегез юкмы?

— Юк.

— Алайса имзагызны куегыз. Менә монда — һәр битнең аскы ягына. Аннары менә монда — азаккы биткә.

Үзе сөйләгән һәр сүзне ятлап калырга теләгәндәй, Җамалетдинов башта беркетмәне бик зур игътибар белән берничә мәртәбә укып чыга. Аннары тикшерүчедән кайбер вак-төяк төзәтмәләр кертүне үтенә. Бары шуннан соң гына боргалап-сыргалап имзасын куя.

## Муса Җәлил шаһитлеге

Хәзер Җамалетдинов кулга алынганга кадәрге хәлләрне күздән кичереп үтик.

1946 елда Татарстан язучылар союзына озын буйлы, киң җилкәле бер кеше килеп керә. Исемен, фамилиясен дә әйтеп тормастан, союзда эшләүче бер хезмәткәрнең өстәленә кызыл кәгазьгә төрелгән төргәк куя да:

— Бу — һәлак булган татар шагыйренең шигырьләре. Бик күп куллар аша, ут һәм тамуг аша, төрмәләр һәм концлагерьлар аша үткән алар. Мин аларны мәрхүмнең үтенече буенча китердем. Миннән бүтән берни дә сорашмагыз, — ди.

Әлеге сәер кеше чыгып киткәч, төргәкне актарып карыйлар. Аннан битләре вак кына гарәп хәрефләре белән язып тутырылган кечкенә блокнот килеп чыга. Дуслары Муса Җәлилнең почеркын шундук танып алалар. Моабит дәфтәренең беренчесе илгә әнә шулай әйләнеп кайта. Тагын бер елдан соң элекке Моабит тоткыны Андрэ Тиммерманс Брюссельдәге Совет илчелегенә Муса Җәлилнең икенче дәфтәрен тапшыра.

Теге беренче дәфтәрне туган илгә кем алып кайтканлыгы байтак вакыттан соң гына ачыклана: Нигъмәт Терегулов диган кеше була ул. Лакин бу хәл ачыклангандa Терегулов үзе үлгән була инде. Шулай итеп, шагыйрьнең әсирлектәге тормышын тулырак ачыкларга ярдәм итәрдәй бик әһәмиятле ул җеп тә өзелеп китә.

Бу мәсьәләдә бердәнбер чыганак булып, Моабит дәфтәре үзе генә кала. Соры катыргы кәгазьдән ясалган ул дәфтәрнең тышлыгына шагыйрь үзенең васыятен язып калдырган.

«...Моны язды татарның билгеле шагыйре Муса Җәлил... 1942 елны сугышка килде һәм әсир төште. Әсирлектә күп газаплар чигеп, кырык үлемнән калып, ахырында Берлинга китерелде. Берлинда сәяси яшерен оешмага катнашуда, совет пропагандасы таратуда гаепләнеп кулга алынды, төрмәгә ябылды. Бәлки аны үлем җәзасына хөкем итәрләр. Ул үләр. Ә аның әсирлектә һәм тоткынлыкта язган 115 шигыре бар. Ул шулар өчен кайгыра. Шуның өчен 115 нең 60 ын гына булса да күчереп калдырырга тырышты. Әгәр бу китап кулыңа төшсә, шигырьләрне яхшылап, дикъкать белән акка күчер, сакла һәм сугыштан соң, Казанга хәбәр итеп, үлгән татар халык шагыйренең шигырьләре итеп дөньяга чыгар. Минем васыятем шул.

Муса Җәлил. 1943. Декабрь.»

Шушы васыятеннән соң, шагыйрь үзе белән бергә хөкем ителгән яшерен оешма членнарының исемлеген китергән һәм: «Болар татар легионын таркатуда, күмәк качу оештыруда гаепләнәләр», — дип язып куйган. Менә ул исемлек:

Гариф Шабаев — бухгалтер.
Муса Җәлил — шагыйрь.
Әхмәт Симаев — журналист.
Абдулла Баттал — Казан.
Курмашев Гайнан —
А. Алиш — язучы.
Фуат Булатов — инженер.
Сәйфелмөлеков —
Хисаметдинов — ветеринария врачы.
Мичурин — юрист.
Әмиров — җырчы.
Шәрипов —

Аннары исемлек астына калын сызык сызылган һәм кыйгачлап, эре хәрефләр белән:

«Хыянәтче — Җәләлетдинов, Үзбәкстаннан [1]», — дип язылган.

Хыянәтченең фамилиясе исемлектә унөченче булганлыктан, аны, шартлы рәвештә, «унөченче» дип атап йөртә башлыйлар. Җәлил шәкертләреннән, ихтимал, исән калган кеше юктыр, алар фашист палачлары тарафыннан үтерелгәндер. Ә хыянәтче... Әллә нинди кабахәтлекләр эшләү бәрабәренә булса да, үзенең пычрак җанын саклап калган, хәтта илгә («Туган илгә» дип әйтәсе дә килми, чөнки хыянәтченең иле юк аның!) кайткан булырга да бик мөмкин.

Менә шул фикердән чыгып, шагыйрьнең дуслары тикшерү органнарына мөрәҗәгать итәләр һәм хыянәтчене эзләүне үтенәләр.

Үзбәкстанда Җамалетдинов фамилияле кеше табылмый. Кустанай өлкәсендә сәүдә эшендә эшләүче Мөхмүт Җамалетдинов диган бер кешене табалар табуын. Әмма аны «унөченче» дип санарга һич тә нигез булмый, чөнки ул, документларына карагандa, сугышның башыннан ахырына кадәр диярлек партизаннар белән бергә дошманга каршы сугышып йөргән. Өстәвенә, заманында фильтрация пунктында да тикшерелгән. Шуларны искә алып, ул кешенең үткәндәге тормышы белән артык төпченеп тормыйлар.

Айлар, еллар үтә. Кайдандыр Җәлилгә яла ягa торган имеш-мимешләр тарала башлый. Фашистларга сатылган икән, җаны-тәне белән аларга турылыклы хезмәт

---

[1] Муса Җәлил хыянәтчене якыннан белмәгән, күрәсең. Шунлыктан аның фамилиясен ялгыш язган. Хәер, төрмә шартларында Мусаның барысын да төгәл итеп белеп бетерә алмавы гаҗәп тә түгел.

иткән икән, дип тә сөйлиләр. Хәтта, Муса әле исән, америкалылар ягына чыккан да, хәзер кайдадыр Көньяк Америкада качып йөри икән дип сөйләүчеләр дә табыла. Тик мондый ялаларның чыганагы озак вакытлар билгесез кала килде. Бары бернәрсә — кемнеңдер шагыйрь исемен пычратырга тырышуы гына ачык иде.

Ялган сүзләр арту белән бергә, Муса Җәлил һәм аның иптәшләренең дошман тылында батырларча яшерен көрәш алып барулары турында да материаллар җыела торды.

Нюрнберг процессы фашизмның кешелеккә каршы алып барган бик күп пычрак җинаятьләрен ачты. Әнә шул әшәке җинаятьләрнең берсе, бөтен халыкара конвенцияләрне бозып, хәрби әсирләрне үз илләренә каршы сугышырга мәҗбүр итү була.

Сугыш башланган көннәрдә үк Гитлер командованиесе яшерен приказ бастырып чыгара. Ул приказ буенча, фашистларга әсир төшкән барлык еврейләр, комиссарлар һәм азиатлар юкка чыгарылырга тиеш була. Татарлар, үзбәкләр, кыргызлар, казакълар, төрекмәннәр, башкортлар һәм башка халыклар «азиатлар» төркеменә кертелә. Ләкин ул приказ, бигрәк тә аның «азиатлар»ны күздә тоткан өлеше, озак яши алмый. Совет Армиясенең каты һөҗүме нәтиҗәсендә бик күп сугышчылары кырыла башлагач, гитлерчылар теге приказларын үзгәртергә мәҗбүр булалар. 1942 ел башында алар хәрби әсирләрдән милли легионнар оештырырга керешәләр. Беренче булып, Урта Азия әсирләреннән Төркстан легионы төзелә. 1942 ел ахырында әзербәйҗан, грузин, әрмән легионнары һәм «Идел — Урал» исеме астында татар легионы оештырыла башлый. Ә рус әсирләреннән иленә хыянәт иткән генерал Власов командалыгында «Рус азатлык армиясе» оештырыла.

Гитлерчылар ул легионнарга зур ышаныч баглыйлар. Шуңа күрә дә алар белән җитәкчелек итүне явыз разведчик, «рус мәсьәләләре буенча белгеч», элек Мәскәүдәге Германия илчелегендә хәрби атташе булып эшләгән җитмеш яшьлек Эрнст фон Кестрингка йөклиләр. Ә «азиатларга рухани» итеп, үзенең бөтен җарияләре белән Иерусалимнан «бөек мөфти» Сәид Мөхәммәт Әмин әл Хөсәенне чакыртып алалар. Легионерларга идеологик «тәрбия» бирү эшенә көнчыгыштагы оккупацияләнгән җирләр министры Альфред Розенберг җитәкчелек итә. Розенбергның көнчыгыш министрлыгы каршында хәрби әсирләрне үгетләү һәм җыйнау буенча эмигрантлар комитеты, шул исәптән «Идел — Урал» комитеты да, төзелә. Ул комитетка элекке Оренбург сәүдәгәре, революциядән соң Төркиягә, аннары Германиягә качып киткән ярым надан, әрсез һәм юньсез Шәфи Алмаз җитәкчелек итә.

Фашистлар командованиесе Идел буенда «ирекле, бәйсез татар дәүләте» төзергә вәгъдә итә. Бу вәгъдә эмигрантлар күңеленә бик хуш килә. Комитетка «Идел — Урал» дигән исем әнә шул һавадагы торнаны күздә тотып бирелә. Дөньяда булмаган ул дәүләтнең җирен «юмарт» фашистлар бик зурдан «билгелиләр»: Иделдән алып Уралга һәм Казаннан алып Астраханьга кадәр җәелә аның чикләре. Татар хәрби әсирләре менә шул идеологик «прәннек»кә омсынып сугышырга һәм үләргә тиеш була. Ә легионга язылырга теләмәүчеләрне фашистлар коточкыч кыенлыкларга дучар итәләр. 1941—1942 елларда гына да йөз меңнәрчә кеше үтерелә.

1943 ел башында Польшадагы Едлино станциясеннән ерак булмаган Радом шәһәрчегендә татар легионының беренче батальоны төзелеп (немец документлары буенча 825 нче), фронтка җибәрелә. Фашистлар ул батальонны зурлап, оркестрлар уйнатып, бик хәтәр речьләр сөйләп озатып калалар. Һәм алар, эшләре уңышлы чыккан тәкъдирдә, менә күрегез, «руслар тарафыннан изелеп килгән» Идел татарлары, «немец туганнары» белән иңгә-иң торып, үзләренең «бәйсезлекләре» өчен ничек яхшы сугышалар, дип бөтен дөньяга акырырга да әзер булалар.

Ләкин, әле фронтка җитмәс борын — Витебск районында ук, алдан эшләнгән план нигезендә, батальон баш күтәрә, немец офицерларын һәм сакчыларын юк итә дә, барлык тупларын, пулеметларын алып, тулысы белән белорус партизаннары ягына чыга. Шулай итеп, баштанаяк коралланган 1200 дән артык кеше фашистлар тоткынлыгыннан азат ителә.

«Ул әшәке азиатларга» ышаныч баглаганы өчен, фон Кестринг соңыннан чәчләрен йолкый-йолкый үз-үзен каһәрләгән дип сөйлиләр.

Әсирләрнең баш күтәрүе легионда көчле яшерен оешма яшәвен ачык раслаучы факт була. Моны фашистлар да яхшы аңлыйлар һәм 1943 елның 10—12 август көн-

нәрендә татар легионының барлык бүлекчәләрендә һәм Берлиндагы «Идел — Урал» комитетында күпләп кулга алулар башлана. Житмеш-сиксән кеше кулга алына. Шуларның уникесен соңыннан төрмәдә җәзалап үтерәләр. Берничә кешене ирекә чыгаралар. Калганнарын, төрлесен-төрле вакытка хөкем итеп, төрмәгә ябалар. Әмма аларның да бик азы гына исән кала.

Сугыштан соң фашистлар архивында табылган материаллардан күренгәнчә, татар легионерлары «иң ышанычсыз», ә «Идел — Урал» легионындагы хәлләр «чын мәгънәсендә катастрофа» дип саналган [1].

Шулай итеп, Гитлер һәм Розенбергның хәрби әсирләрне үз илләренә каршы сугыштырырга ниятләгән идеяләре барып чыкмый.

Еллар үткән саен, фашистик Германиянең нәкъ үзәгендә яшерен оешманың героик көрәш алып барганлыгын раслый торган яңа фактлар арта барды. Муса Җәлил һәм аның иптәшләренең батырлыгы хакындагы материаллар күбәйгән саен, җинаятьченең кабахәтлеге дә күбрәк ачылды.

Сугыштан соң берничә ел үткәч, Җәлил калдырган исемлектә күрсәтелгән кайбер кешеләрнең үтерелмәгәнлеге мәгълүм була. Әйтик, ветеринар врач Рушат Хисаметдинов (Ош шәһәреннән) исән калып туган илгә кайткан. Җәлил җитәкчелек иткән яшерен оешмадагы кайбер хәлләрне ачыклауга аның шактый зур ярдәме тиде.

Р. Хисаметдинов хезмәт иткән часть 1942 елның июнь аенда чолганышка эләгә. Сугышчылар, вак-вак төркемнәргә бүленеп, дошман боҗрасыннан чыгып котылырга карар кылалар. Соңгы патроннарына кадәр атып бетергәч, ач килеш, урман һәм сазлыклар аша, алар көнчыгышка таба юнәләләр. 14 июль таңында Хисаметдиновлар төркеме (алар барлыгы сигез кеше була) дошман патруленә юлыга. Төркемне шундук немец автоматчылары урап ала. Аларның берсе Хисаметдиновны төркемнән читкә сөйрәп чыгара да, автоматын төзәп:

— Комиссарен? — дип кычкыра. Хисаметдиновның петлицаларына төртеп күрсәтә.

— Нейн! — дип кычкыра безнең сугышчыларның берсе. — Ветеринария врачы ул.

Немец автоматын иңенә элә.

Хисаметдинов фашистлар кулына әнә шулай эләгә һәм 1942 елның көзендә аны Демблиндагы хәрби әсирләр лагерена китерәләр. Екатерина заманында ук Висла елгасы буена төзелгән борынгы крепостьта оештырылган ул лагерьны фашистлар бик нык саклыйлар. Крепостьның калын таш стеналары өстенә чәнечкеле тимер чыбык тотылган, ул чыбыклар аша электр тогы үткәрелгән, почмакларына сакчылар өчен каланчалар ясалган, анда пулеметлар куелган. Крепостьның өч ягы Висла суына орынып тора, ә дүртенче ягына тирән канау казылган һәм аңа да су тутырылган.

Ашатыла торган бөтен ризыклары юылмаган бәрәңге кабыгы яисә чөгендер сабагы салып пешерелгән сасы баланда һәм шырпы кабыннан чак кына зуррак эрзац икмәк кисәгеннән генә гыйбарәт булганлыктан, тоткыннар бик нык ябыгалар. Сакал-мыек баскан, айлар буена мунча кермәгән һәм тере скелетка әйләнеп калган әсирләр хәтта крепость ишек алдында үскән үләннәрне дә ашап бетерәләр. Алар арасында тиф һәм дизентерия тарала. Авыруларга берниндн медицина ярдәме күрсәтелми. Көн саен йөзләрчә кеше үлеп тора. Лагерьдагы йөз кешелек «капут-команда» — күмү командасы мәетләрне җирләп барырга чак-чак өлгерә. «Җирләү» дигәне дә чын мәгънәсендә җирләү түгел әле. Кабер-фәлән казып тору юк. Зур һәм тирән итеп казылган чокырга гына тутыралар мәетләрне. Сасый-таркала башламасыннар өчен, көн саен мәетләр өстенә хлор сибеп баралар да соңыннан, чокыр тулгач, аны күмеп куялар.

Менә шундый кыен шартларда Хисаметдинов Гайнан Курмаш белән дуслашып китә. Әгәр Курмашны очратмаган булса, ихтимал, аның гәүдәсен дә капут-команда чокырга илтеп ташлаган булыр иде. Хикмәт шунда, Гайнан Курмаш кухняда эшли. Фашистлар тентеп чыгаруга да карамастан, ничек тә җаен табып, эштән я чи бәрәңге,

---

[1] Немец язучысы Леон Небенцаль бер немец офицерының сугыш чорында язып барган көндәлеген тапкан. Ул көндәлектә «татар легионнарын һич кичекмәстән коралсызландырырга» дигән яшерен приказ барлыгы турында да әйтелә. Приказ 1943 елның унынчы августында, ягъни яшерен оешма членнарын кулга алган көнне, игълан ителгән.

я чегендер яфраклары, яисә маргариннан бушаган кәгазь кисәкләре (ул кәгазьләрне учак өстендә тотсаң, азрак май тамчылары эретеп алырга мөмкин) әләктереп кайта, шул рәвешле Хисаметдиновка ярдәм итә.

Бер көнне Гайнан Курмаш ымлап Хисаметдиновны чакырып китерә дә урта буйлы, каратут йөзле, иске шинель, уңып агарган пилотка, агач башмак кигән һәм бик ябык, хәлсез, күз төпләре шешенеп салынып төшкән кешене күрсәтә.

— Шагыйрь Муса Җәлил бу, — ди Курмаш.

Аннары Казанда яшәгән вакытта Муса белән таныш булганлыгын әйтә. Хисаметдинов үзенең дә шагыйрь белән танышырга теләвен әйткәч, Курмаш Мусаны дәшеп ала. Хисаметдинов үз исемен атагач, Муса да кулын суза:

— Гумеров, — ди ул. Аннары сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куя.

Шул көннән башлап, алар еш кына бергә йөри башлыйлар. Җәлил Хисаметдиновка Казан турында сөйли, шигырьләрен укып күрсәтә. Аның ул шигырьләрен башка әсирләр язып алалар, яттан өйрәнәләр.

Кичләрен әсирләр тоткынлыктан ничек котылу хакында да еш кына сүз кузгаталар. Барысы да, аерым-аерым качарга ярамый һәм мөмкин дә түгел, дигән фикерне яклый. Чөнки лагерь фронт сызыгыннан бик ерак, меңнәрчә километрда. Иртәмесоңмы, фашистлар барыбер тотып алачак. Мисалга ерак барасы түгел: качкыннарны тотып алып кайтып, әледән-әле атып торалар. Димәк, бары оешкан тоста генә уңышка ирешергә мөмкин.

Шулай сөйләшә-серләшә торгач, Муса Җәлил белән Курмаш тирәсенә сыналган, бернинди дә шик тудырмый торган ышанычлы кешеләр группасы — булачак яшерен оешманың үзәге туплана.

Күренекле шагыйрь Салих Батталның энесе Абдулла Баттал үзәкнең ышанычлы члены була. Шат күңелле, зарлануның нәрсә икәнен дә белми торган һәм азрак аксап йөрүче бу кеше Тукай, Такташ, Җәлил шигырьләренең бик күбесен яттан белә һәм аларны еш кына иптәшләренә дә сөйли. Хәтта иң кыен вакытларда да шаян сүз һәм уен-көлке белән иптәшләренең күңелен күтәрә. Шунлыктан тоткыннарның күбесе аның үзен дә шагыйрь дип уйлыйлар.

Җәлил тирәсенә тупланган кешеләрдән Зиннәт Хәсәнов исә үзенең ныклыгы, куркусызлыгы белән аерылып тора. Иптәшләре аны аяусыз, тәвәккәл булганлыгы өчен хөрмәт итәләр. Яшерен оешма карары буенча, бервакыт Хәсәновны немецларга хезмәткә урнаштырмакчы булалар. Ләкин ул байтак вакыт моңа ризалык бирми.

— Холкымны беләсез бит! Ачу ара берәрсенең ипи шүрлегенә менеп төшеп, барыгызны да харап итеп куюым бар, — ди ул.

Шулай да соңыннан музыкаль капеллага «артист» булып урнашырга күндерәләр үзен.

Җәлил фикердәшләренең кайсын гына алып карасак та, йөз кызартырлык түгел. Менә базык гәүдәле, зур йодрыклы, яхшы тавышлы Гарәф Фәхретдинов. Дошман лагерьларыннан өч мәртәбә кача ул. Өченчендә дә фашистлар аны эзләп табып, бик нык кыйныйлар һәм яңадан элекке урынына кайтарып ябалар. Опера театрын гына түгел, хәтта Казанның үзен дә гомерендә бер күргәне булмаса да, Гарәфне немецларга «татар опера театры солисты» дип тәкъдим итәләр... Яки менә кирәген генә сөйләшә торган сабыр холыклы, һәркайда пөхтәлек яратучы, экономист Фуат Сәйфелмөлеков... Үзе әле бик яшь, әмма иптәшләре өчен җанын бирергә әзер торучы Фәрит Солтанбеков... Бик күп укыган, политик яктан зур әзерлекле, һәр мәсьәләне тәнкыйть күзе аша үткәрергә омтылучы юрист Мичурин...

Җәлил — Курмаш группасында шушындый ышанычлы кешеләр унбишләп була. Дөрес, алар әле ант белән дә, устав белән дә бәйләнмәгән. Әмма бер-берләрен ярты сүздән үк аңлыйлар инде.

Җәлил — Курмаш группасы әнә шулай ныгый барган көннәрдә, Демблинга башка лагерьлардан татар, башкорт, чуваш, мари һәм Идел буенда яшәгән бүтән милләт әсирләрен китереп тутыралар. Аннары Берлиннан ниндидер татар эмигрантлары килеп төшә, барактан баракка йөриләр, әсирләрне кызганган булып кыланалар, ярым гарәпчә, ярым татарча нотыклар сөйләп, легионга язылырга өнди башлыйлар. «Монда интегеп үлүдән ни мәгънә бар? — диләр алар. — Без сезне кызганабыз, тормышыгызны саклап калырга телибез. Легионда сезне ризык белән дә, кием белән дә тәэмин итәчәкләр,

барлык шартлар тудырылачак... Сезне фронтка җибәрмәячәкләр, тылда гына эшләтәчәкләр...»

Әсирләрнең күпчелеге бу фашист агитаторларын тыңларга да теләми. Әмма, шулай да, кайбер кешеләргә тәэсире була аларның.

Немецлар лагерьны икегә бүләләр. Бер яртысында әсирләр ачлыктан һәм тиф авыруыннан йөзәрләп-йөзәрләп үлә тора. Ә икенче яртысында — аңысы ярым легион дип атала — көненә өч тапкыр ашаталар, мунча кертәләр, чиста күлмәк-ыштан һәм иске булса да әле шактый нык француз киемнәренә киендерәләр. Ярым легионга күчү мәсьәләсе дә бик ансат була: кул кую да кирәкми, телдән ризалык бирүнең дә хаҗәте юк, телисең икән — тот та күч шул якка. Һәм бу «күргәзмә» агитация тагы үзенекен итә: кайбер әсирләр, иптәшләре күзенә күренмәскә тырышып, кача-поса, тәмле исләр таратып торган поход казаннары ягына юнәлә. Ә анда немецлар аларның хәлләрәкләрен, ныгракларын сайлап алып, Едлинога — татар легионы оештырылып яткан урынга озата торалар.

Әмма әсирләрнең күбесе легионга барырга алай ашкынып тормый. Легион оештыру эше артык озакка сузыла башлагач, немецлар хәтта әлеге формаль рәвештә «үз ихтыярына кую»дан да баш тарталар. Татар һәм башкорт әсирләрен туп-туры легион оештырыла торган җиргә алып киләләр дә барысын да «көнчыгыш ирекләләре» дип игълан итәләр. Бары тик, азрак шарты килсен өчен, кем легионда хезмәт итәргә теләми дип кенә сорыйлар. Теләмибез, диючеләр дә була. Аларны шундук атып үтерәләр.

Беренче (825 нче) батальон әнә шулай оештырыла. Аннары ашыгыч рәвештә икенче батальонны төзергә керешәләр. Җәлилчеләр алдына бу хәлгә карата үз мөнәсәбәтләрен ачыклау мәсьәләсе килеп баса. Үзләре «чиста» калып, иптәшләрен Туган илгә каршы сугышка җибәргәнне карап торыргамы? Әллә, немецларга хезмәт итәргә ризалык биргән булып, легионга барырга да аны эчтән таркату һәм легионерлар кулындагы коралны фашистларның үзләренә каршы юнәлтү өчен көрәшергәме?

Моны хәл итү җиңел булмый.

Демблин лагеренда Муса белән таныш булган фельдшер Н. В. Толкачев бу хакта менә нәрсә сөйли. Лагерь госпиталенең өлкән врачы Аркадий Львович Лев бервакыт яралар бәйли торган бүлмәдә легионерларга мөнәсәбәт мәсьәләсендә Муса Җәлил белән сүз кузгата. Аркадий Львович та, Муса да бер-берен бик яхшы беләләр, шунлыктан ачыктан-ачык сөйләшәләр. Шунда Муса легионга китүгә чын күңеленнән каршы булуын әйтә. Ирекка чыгу өчен бер генә юл бар — ничек булса да, лагерьдан качарга кирәк, ди ул. Ә Аркадий Львович икенче фикерне яклый: очрактан файдаланып, легионга китәргә, шулай итеп, халыкны үлемнән саклап калырга, ди. Аннары аларны, бәлки, үзебезнең якка алып чыгарга да мөмкин булыр. Чыга алмаган тәкъдирдә дә ачлыктан һәм тифтан үлүгә караганда кулга корал тотып үлү мактаулырак һәм ил өчен дә файдалырак булыр, ди. «Командирның солдатларны язмыш кулына ташлап калдыруы — дезертирлыкка тиң!» — ди.

— Дошман мундирын кияргәме? Беркайчан да киячәк түгелмен! — ди Җәлил.

Башта күп әсирләр шулай уйлый.

Яшерен оешма членнарының нинди хәлдә һәм кайчан немецларга «хезмәткә» китәргә карар кылганлыклары бүгенгә кадәр төгәл билгеле түгел әле. 1942 елның ахырында Хисаметдиновны кинәт кенә башка лагерьга күчерәләр һәм ул иптәшләре белән бәйләнешен югалта. Тик соңыннан Едлинога эләгеп, башка татар хәрби әсирләре белән бергә «Идел — Урал» легионы составына кертелгәч кенә, Җәлил һәм аның группасындагы иптәшләрнең гитлерчыларга «хезмәттәшлек» итәргә риза булганлыкларын ишетә. Мусага әсирләр арасында культура-агарту эшләре белән җитәкчелек итүне тапшыралар. Абдулла Алиш «Идел — Урал» газетасы редакциясендә, Әхмәт Симаев радиопропаганда бүлегендә эшли башлый. Яшерен группаның ышанычлы кешеләреннән «Идел — Урал» комитетына эләгүчеләр дә була.

Хисаметдиновны үз һөнәре буенча — ветеринария врачы итеп куялар. Ул музыкантлар белән бер баракта яши башлый. Озак та үтми, Берлин комитетыннан озын буйлы Солтан исемле бер кеше килеп төшә. Комитет легионда музыка капелласы оештыру турында күрсәтмә биргән икән. Музыкантлар, легионда андый капелла төзергә яраклы кешеләр булмавын әйтеп, сукраныша башлыйлар.

— Муса Демблиннан артистлар алып килергә киңәш итә, — ди Солтан.

Хисаметдинов шундук тәшенеп ала: Муса үз тирәсенә ышанычлы кешеләрне тупларга ниятли.

— Демблинда бик озак булдым мин, андагы музыкантларны яхшы беләм,— ди ул.

— Алайса, аларны үзең алып килерсең, — ди Солтан.

Хисаметдинов Демблиннан унөч кеше алып кайта. Аларның берсе дә профессиональ артист булмый. Аның каравы, һәркайсы ышанычлы кешеләр. Капелланың художество җитәкчесе итеп, Берлин комитеты Рушат Хисаметдиновның үзен раслый. Гайнан Курмаш режиссеры итеп билгеләнә.

Лагерьда шактый ирекле йөри алганлыктан, Рушат Хисаметдинов башта качарга да ниятли. Ләкин Курмаш Берлинга барганда Муса Җәлил белән бу хакта сөйләшеп кайткач, качмаска була, чөнки аның бу уен Җәлил хупламый.

— Берәмләп качарга кайчан да өлгереп булыр, — дигән Муса Курмашка. — Хәзер безнең алда җитдирәк бурыч тора — легионны тулысы белән үзебезнекеләр ягына алып чыгарга кирәк. Ил каршындагы бурычыбызны бары шулай гына үти алабыз!

Менә шул бурычны күздә тотып, яшерен оешма членнары беренче батальонга рота һәм взвод командирлары итеп үз кешеләрен куярга тырышалар. Билгеле, яшерен группа башкарган барлык эшләрне Хисаметдинов белмәгән һәм конспирация шартларында белә дә алмаган. Ләкин баш күтәрергә әзерлек алып барылуын сизенгән ул. Менә шуңа күрә дә ул һәм башка «артистлар» Көнчыгыш фронтка озатылган беренче батальоннан түземсезлек белән хәбәр көтәләр. Ниһаять, ул хәбәр килә: кәефләре бик нык кырылган немец офицерларының өзек-өзек сүзләреннән легионерларның, немец сакчыларын юк итеп, Витебск районында бөтен батальоны белән партизаннар ягына чыкканлыгы мәгълүм була. Бу хәбәр шундук бөтен лагерьга тарала. Беренче зур җиңү була бу! Легионерларның күңелләре күтәрелеп китә.

1943 елның май башында музыка капелласы Берлинга экскурсиягә бара. Капелла «артистлар»ын Муса елмаеп каршылый. Бер яктан, дуслар белән очрашуга куанса, икенче яктан, фашистларның теләге барып чыкмауга бик нык шатлана ул. Берлин зоопаркын карап йөргәндә, Муса Хисаметдинов белән Курмашны читкәрәк дәшеп ала. Алар маймыллар читлеге янында тукталып калалар.

— Маймылларга карагыз, — ди аларга Муса, — һәм игътибар белән мине тыңлагыз. Бүгеннән башлап, сез яшерен оешма членнары. Һәр тамчы каныбызны илгә багышлыйбыз, дип ант итегез.

Тегеләр тантаналы ант итәләр.

Муса аларны кыскача гына фронттагы хәлләр белән таныштыра һәм оешма алдында торган төп бурыч — татар легионының бүтән частьларын да үзебезнекеләр ягына чыгарырга әзерләү икәнлеген әйтә. Аннары эшне ничек оештыру мәсьәләсендә киңәшләр бирә. Каршылык группасы, ди ул, зур булмаска тиеш, өч-дүрт, күп дигәндә, биш кешедән дә артмасын. Яшерен оешманың гади членнары башка группалардагы кешеләрне белмәсен, алар бары тик үз җитәкчеләре биргән күрсәтмәләрне генә үтәсеннәр. Кулга алу була калса — шушылай кирәк. Яшерен эшләр капелланың ачык эшләре белән үрелеп барсын: тоткыннар алдында чыгыш ясаган вакытларда, саклык белән генә, немецларга сиздермәслек итеп кенә, илгә турылыклылык һәм ирекне, кулга корал тотып, үзебез яулап алу кирәклеген алга сөргән фикерләр үткәрелергә тиеш.

Кайтып китәр алдыннан Муса Хисаметдинов белән Курмашка ике төргәк листовка бирә. Русча язылган һәм ахырына «IV комитет» дип куелган ул листовкаларда соңгы көннәрдәге Совинформбюросы хәбәрләре һәм легионерларны фашистларга каршы көрәшкә чакырган өндәмә басылган була.

Берлинга барып кайткannan соң Хисаметдинов группасының эше шактый җанланып китә. Шул ук вакытта яшерен эш алып бару да кыенлаша башлый. Чөнки немецлар легионерларга элеккечә ышанмыйлар, шикләнеп карыйлар. Элек легионерларны тизрәк фронтка озату турында гына кайгыртып йөргән фашистлар, хәзер һәр кешене бик җентекләп тикшерәләр. Күзәтү көчәйтелә, кулга алулар башлана.

1943 елның июль ае ахырында Муса Җәлил тагын Едлинога килә һәм яшерен үзәкнең яңа карарын аңлата. Беренче батальон восстаниесеннән соң немецлар татар легионы частьларын фронтка җибәрергә шикләнеп калганнар. Шуңа күрә легионның үз эчендә баш күтәрергә һәм, якында урнашкан әрмән легионы һәм поляк парти-

заннары белән кушылып, һөҗүм итеп килүче Кызыл Армиягә кушылырга кирәк була. Әлбәттә, бик тәвәккәл план бу. Ләкин мондый шартларда әнә шундый зур тәвәккәллек белән генә уңышка ирешергә мөмкин.

Җәлил Едлинога «Шүрәле» исемле яңа музыкаль комедиясен сәхнәгә куйдыру сылтавы белән килә. Моңа ул Берлиннан рөхсәт алган була. Комедиягә репетиция ясаган булып, яшерен оешма членнары баш күтәрергә бик ныклап әзерләнә башлый.

Соңгы киңәшмә августның сигезендәме, тугызындамы үткәрелә. Анда Җәлил, Курмаш, Сәйфелмөлеков һәм Хисаметдинов катнаша. Муса иптәшләренә партизаннар белән элемтә булдырылганлыгын әйтә. Аннары восстание вакытында кем нәрсә эшләргә тиешлекне хәл итәләр. Сәйфелмөлеков группасы легион командованиесен юк итәргә, Хисаметдинов группасы корал һәм атларны кулга төшерергә тиеш. Курмашка лагерь сакчыларын кырып бетерү эше, Фәхретдинов белән Мичуринга элемтәне өзү бурычы йөкләтелә. Баш күтәрү 14 августка билгеләнә.

Ләкин 11 августта иртән иртүк барлык «артистлар»ны ашханәгә чакырталар. Музыка коралларын да алып килергә кушыла, имеш, легион командованиесе комедиянең соңгы репетициясен карамакчы.

Ашханәгә якынлашу белән Хисаметдиновның йөрәге жу итеп китә: ашханә бинасы немец солдатлары белән уратып алынган, һәр тәрәзә каршына кораллы сакчылар куелган була.

Ашханәдә артистларны легионның разведка начальнигы капитан Линкес каршы ала. Авызыннан төкрекләр чәчә-чәчә сүгенеп, ул легионда татар һәм немец халыкларының дошманнары булуы һәм, фюрерның ышаныч белдерүеннән файдаланып, аларның бөек рейхка каршы җимерү эшләре алып баруы турында акырынырга тотына. Аннары күкрәк кесәсеннән исемлек алып, кулга алынучыларны берәмләп сафтан чыгара башлый.

Иң башта Гайнан Курмашны алып китәләр. Аның артыннан Хисаметдиновны. Ашханәнең бер бүлмәсенә алып керүләре була — кемдер бик каты итеп сугып та ега. Аннары баштанаяк чишендерәләр, бик җентекләп тентиләр, бил каешын һәм легионер кнәгәсен алалар да Хисаметдиновның үзен стенага йөзе белән каратып бастырып куялар. Ул күз кырые белән генә Хәсәнов, Батталов, Әмиров, Мичурин һәм башка иптәшләренең дә шундый ук хәлгә төшүләрен күреп кала. Әмма Муса Җәлил анда булмый. Күрәсең, аны аерым алганнардыр.

Сорау алганнан соң тоткыннарга богау салалар һәм көчле сак астында Варшава төрмәсенә озаталар. Ул көнне Едлинода барлыгы утызлап кеше кулга алына.

Төрмәдә аларның барысын да бик каты җәзалыйлар: тимер чыбыклар, резин таяклар белән кыйныйлар. Аңын югалткан тоткыннарны салкын су сибеп аңына китерәләр дә яңадан сорау алалар һәм тагын кыйныйлар.

Хисаметдинов тикшерүчегә берни дә әйтми. Үзен җәзалаган вакытта тик бер генә нәрсә хакында уйлый ул: кем икән сатлык җан?

Берәр ай чамасы вакыттан соң тоткыннарны Берлинга алып киләләр. Ничектер җаен туры китереп, Хисаметдинов Батталдан:

— Безне кем сатканын белмисеңме? — дип сорый.

— Мәхмүт Җамалетдинов, — ди Баттал.

Озынча йөзле Җамалетдинов дигән яшь кенә бер легионерны исенә төшерә Хисаметдинов. Заманында культтзводка кергәли, үзешчән сәнгать түгәрәгенең эше белән кызыксына, сугышка кадәр кичәләрдә үзе дә шигырьләр сөйләгәне булуын әйтә ул. Музыкаль капеллага урнашырга чамалап йөргәндер, күрәсең. Әмма аны капеллага алмыйлар. Аннары Җамалетдинов пропагандист булып эшли. Хисаметдинов шуннан башка аның турында берни белми.

Рушат Хисаметдиновның моннан соңгы язмышы турында зур бер роман язарга мөмкин булыр иде. Германиядә һәм Франциядә төрмәләрдә утыра ул, аннары, ниһаять, җаен табып, кача да француз партизаннарына барып кушыла һәм шулар сафында көрәшеп йөри.

Хисаметдиновның әйтүенә караганда, Җәлил калдырган исемлектәге кешеләрнең тагын берсе — юрист Мичурин да исән булырга тиеш. Легионда пропагандистлар группасына җитәкчелек иткән Мичурин сугышның беренче сәгатьләрендә үк чик буендагы заставада әсир ителгән кеше була. Немецлар аны да яшерен оешма членнары белән

бергә кулга алалар, әмма ике ай тотканнан соң төрмәдән чыгаралар. Шуңа күрә яшерен группаны ул сатмады микән дигән шик тә туа.

Соңыннан ачыкланды: Мичурин, чыннан да, илгә исән әйләнеп кайткан икән. Тикшерүче сораштырганда Мичурин үзенең легионда булуын да, пропагандистлар группасына житәкчелек итүен дә яшерми. Үзенең Муса Җәлил оешмасында торуын да раслый. Ә төрмәдән тиз азат ителүенең сәбәбен фашистларның аны фаш итә торган беркинди дә фактлары булмавы белән аңлата. Җәлилчеләр үзләреннән сорау алганда бик нык торалар, берсе дә иптәшләрен сатмый. Яшерен оешмада торганлыгын расларлык дәлилләре булмагач, гестапочылар Мичуринны төрмәдән азат итәләр. Дөрес, аны элекке эшенә кайтармыйлар, эшче ротага җибәрәләр.

Тикшерүче, Муса Җәлил группасын кем сатканын беләсеңме, дип сорагач:

— Бик яхшы беләм — Мәхмүт Җамалетдинов ул, — дип җавап бирә.

Аннары аңа берничә фоторәсем, шул исәптән Кустанай өлкәсендә яшәүче Мәхмүт Җамалетдинов рәсемен дә күрсәтәләр. Мичурин, һич икеләнмичә, хыянәтчене рәсеменнән танып ала. Кемгә ышанырга соң бу очракта? Элекке «фашистлар пропагандисты»намы? Әллә «батырлыклар эшләгән партизан»гамы?

Мичурин Җамалетдинов белән күзгә-күз очраштыруларын таләп итә.

## Күзгә-күз очрашу

Эшнең болайга ук китәрен Җамалетдинов уена да китерми. Тикшерүче каршында үзен бик тыныч тота, хәтта соңга таба шаяргалап, төрле юк-бар сүзләр дә сөйләшергә тотына. Менә шул чакта Мичуринны дәшеп кертәләр. Җамалетдинов, сүз әйтергә ачкан авызын ябарга да онытып, Мичуринга текәлә.

— Мине монда очратырмын дип көтмәгән идеңмени, кара елан? Инде дөньяда үзеңне белүчеләр юктыр, җепнең очын табалмаслар дип уйлаган идеңме? Кабахәт, сатлык җан! — ди Мичурин, аны күргәч.

Бу хәлдән тәмам коелып төшкән Җамалетдиновның йөзе мәетнекедәй агарып китә һәм ул, бер сүз дә әйтә алмыйча, башын аска ия.

— Йөзеңне читкә борма! — ди Мичурин, ачуын тыя алмыйча кычкырып. — Легионда чакта мин беркайда да югалмыйм дип мактанганың хәтереңдәме? Җавап бир менә хәзер, кара елан!

— Шаһит Мичурин! — ди тикшерүче, аның сүзен бүлеп. — Гаепләнүченең гаебе расланмаган әле, сезнең аны кимсетергә хакыгыз юк. Утырыгыз. Тәртип белән җавап бирегез: каршыгызда утыручы бу кешене таныйсызмы?

— Әйе, мин ул еланны мең кеше арасыннан да таный алам...

— Исегезгә төшерәм: кимсетүсез генә сөйләгез. Әгәр беләсез икән, аның фамилиясен, исемен, атасының исемен әйтеп бирегез, кайда һәм ничек күргәнегезне сөйләгез!

— Җамалетдинов Мәхмүт бу. Атасының исемен хәтерләмим. Мин аны «Идел — Урал» легионында бергә хезмәт иткән вакыттан беләм.

— Гаепләнүче Җамалетдинов, каршыгызда утыручы бу кешене таныйсызмы?

Инде үзен кулга алырга өлгергән Җамалетдинов Мичуринга салкын караш ташлап ала, гамьсез генә булып күренергә тырышып:

— Юк, белмим, — ди.

Мичурин ачуыннан тәмам кызып китә.

— Ничек инде белмисең? — ди ул, тегенең өстенә очып кунардай булып. — Бергәләп шнапс эчкәнне оныттың дамыни? Легионда пропагандист булып эшләгәнеңне дә оныттыңмы? Сине анда әллә ничә кеше күрде бит, алардан сорарга була...

— Үзара ачуланышканыгыз булмадымы? — дип сорый тикшерүче.

— Ул сатлык җан белән нинди уртаклыгым булырга мөмкин! — ди Мичурин, кулын селтәп.

— Мин бу кешене белмим, — ди Җамалетдинов, һаман үз сүзләрен куәтләп.

— Ярый алайса, — ди тикшерүче, беркетмәнен рәсми өлешен тәгаллап. — Хәзер, шаһит Мичурин, шуны сөйләгез: Җамалетдиновны беренче мәртәбә кайда күрдегез һәм аның фашистларда әсирлектәге эше хакынданиләр беләсез?

— Мин аның белән беренче тапкыр 1943 елның маендамы яки июнендәме таныштым, — ди Мичурин.

Беренче батальон үзебезнең якка озатылганнан соң була бу хәл. Ул батальонны әзерләгәндә Мичурин роталарга пропагандистларны үзе сайлап ала. Дөрес, ул сайлаган кешеләрне соңыннан батальон командиры һәм разведка начальнигы раслый, әмма ул формаль раслау гына була. Шулай итеп, Мичурин беренче батальонның барлык роталарына үз кешеләрен урнаштыра.

Ләкин бу юлы аның фикерен сорап тормыйлар. Батальон командиры Мичуринны үзенә чакыртып китерә дә аңа яңа бер пропагандистны — егерме ике яшьлек унтер-офицер Җамалетдиновны тәкъдим итә.

— Монымы? — дип сорый тикшерүче, башын иеп утыручы Мәхмүткә ымлап.

— Әйе, — дип җавап бирә Мичурин.

Шул ук кичне, бер җаен туры китереп, Мичурин бу хакта Курмашка әйтә. Курмаш аңа яңа пропагандист белән сак булырга һәм яшерен оешманың планнарын һич тә сиздермәскә киңәш итә. Шуннан Мичурин Җамалетдиновны күзәткәләп йөри башлый. Гаепкә алырлык бернәрсәсе дә сизелми Мәхмүтнең: һәр эшне тырышып, үз вакытында башкара, юкка-барга бәйләнми. Сугышка кадәр комсомол сафында булганлыгын да яшерми. Башка пропагандистлар белән сөйләшкән вакытларда немецларга тел-теш тидереп алырга да тартынмый һәм, яшерен оешмачылардан аның сүзләрен җөпләүче булмаса да, немец командованиесе биргән сводкаларның дөреслегенә шикләнүе хакында да сөйләштергәли.

Шулай ике ай вакыт үтә.

Июль ахырларындамы яки август башларындамы Гайнан Курмашка культзаводтан бер кешене Берлинга командировкага җибәрергә боерык бирелә. Ничек итеп Берлиннан антифашистик листовкалар алып кайтырга дип, яшерен оешмачылар үзләре дә баш ватып яткан көннәр була бу. Һәм Курмаш, бик теләп, бу эшкә Абдулла Батталны билгели. Батталга Берлинда Абдулла Алиш белән очрашу, аңа баш күтәрүгә әзерлекнең барышы турында үзәккә мәгълүмат бирү һәм берничә мең данә листовка алып кайту бурычы йөкләтелә.

Баттал юлга чыгарга торганда гына батальон командиры аңа тагын бер легионерны — Мәхмүт Җамалетдиновны ияртә.

Алар Берлинда өч-дүрт көн булалар. Баттал яшерен оешманың барлык заданиеләрен үти, татар һәм рус телләрендә гитлерчыларга каршы корал белән баш күтәрергә өндәгән листовкалар да алып кайта. Ул листовкаларны иртәгә баш күтәрәсе диган көнне таратмакчы булалар. Мичурин: «Листовкалар алып кайтуыңны Җамалетдинов сизмәдеме соң?» — дип сорагач, Баттал бер дә исе китмичә:

— Ә мин аның үзенә дә бер төргәк листовка бирдем, — дип җавап бирә.

Эчкерсез, саф күңелле Баттал юлда барганда Җамалетдинов белән ачылып сөйләшеп китә. Шунда, сүз арасында, Мәхмүтнең сугышка кадәрге тормышын һәм комсомол булуын белгәч, очрактан файдаланып, аны үз ягына аударырга уйлый. Дөрес, яшерен оешма булуы хакында аңа берни дә әйтми, оешма әгъзаларыннан берәүнең дә исемен атамый. Әмма, ихтимал, тиздән немецларның эше кыенлашыр дип сиздереп куя.

Берлинга баргач, Җамалетдинов Абдулладан бер адым да калмыйча тагылып йөри. Минем бу шәһәргә беренче генә килүем әле, адашырмын, зинһар, үзеңнән калдырма, ди ул. Моннан барыбер яшереп булмас дип, аннары, аны ышанычлы кешедер дип, Баттал Берлиннан кайтышлый Җамалетдиновка бер төргәк листовка бирә. Төргәктә нәрсә икәнен әйтми, тик тенту-фәлән була калса, аны сиздермичә генә вагон тәрәзәсеннән ташларсың, дип кисәтеп куя...

Яшерен оешмачылар менә шундый кыен хәлгә дучар булалар. Эшләр болайга киткәч, Җамалетдиновны да үзләре белән бер сүздә булган итеп күрсәтмәкче булалар, чөнки, шулай иткәндә, ул да бу эштә катнашкан булып чыга бит. Җамалетдинов листовкаларны алып кайтып биргәч, Курмаш аңа йомышны уңышлы башкарып кайтканы өчен рәхмәт белдерә. Аннары Мәхмүтнең үзенә дә сиксәнләп листовка санап бирә дә аларны матрасы астына яисә мендәре эченә яшереп куярга куша.

— Курыкма, без берничә тапкыр шулай иттек инде, — ди аңа Курмаш.

Мичурин көн буе Җамалетдиновны күзәтеп йөри. Теге үзен бик тыныч тота, бер-

кая да читкә китеп йөрми. Ләкин төнлә, нигәдер, күңеле тынычсызланып уянып киткәч, Мичурин Җамалетдиновның урыны буш икәнлекне күреп ала. Ярты сәгатьләп югалып тора Мәхмүт. Аннары ыңгырашып, әчен тотып кайтып керә. «Иптәшләрне кисәтергә кирәк», — дип уйлый Мичурин, күңеле тагын да ныграк борчыла башлый. Ләкин ул кисәтергә өлгерми кала: иртәгесен барысын да кулга алалар.

Соңыннан Мичуринга мәгълүм булганча, теге чакта үзләрен ашханәгә алып киткәч, баракларда тентү ясала. Листовка табылган кешеләрнең барысын да шундук кулга алалар. Хәвеф-хәтәр булса, берәр иптәшне саклап калдыру нияте белән иптәшләре Мичуринга листовка бирмәгән булалар. Шунлыктан немецлар аңа бәйләнерлек дәлил таба алмыйлар.

Мәхмүт Җамалетдинов та яшерен оешмачылар белән бергә кулга алына. Ләкин тоткыннарны Варшава төрмәсенә алып барганда ул алар арасында булмый инде.

Мичурин Мусаны ничек кулга алуларын күрмәгән. Варшавага тоткыннарны алып барган машинада да булмаган ул. Мичурин Варшава төрмәсендә ике немец сакчысы бик каты кыйнап ятканда гына күргән аны. Дагалы итекләр белән таптый-таптый, автомат түтәләре белән суга-суга кыйнаганда да бөтен битенә кан савып, күгәреп чыккан, авыз-борыныннан кан агып торган Муса фашистларга бер сүз дә эндәшмәгән, бары тик ара-тирә ыңгырашкалап кына куйган. Күрәсең, фашистлар бу төрмәгә аны алданрак алып килгәннәр, һәм башкаларны куркытып, тел яздыру нияте белән шушы «спектакль»нө уйнарга булганнардыр.

Ике ай буена көнөнә берничә мәртәбә сорау ала-ала, һәр сорау алу вакытында бик нык кыйнап, тәмам хәлсезләндереп, ябыктырып бетергәннән соң, ниһаять, Мичуринны төрмәдән чыгаралар. Ул легионга әйләнеп кайткан чакта аның урынына, пропагандистлар группасы җитәкчесе итеп, Җамалетдинов билгеләнгән була. Аз гына шикле кешеләрнең берсен дә немецлар элекке урыннарына кайтармый торган булалар. Ә листовка чыккан кешеләрне үлем җәзасына хөкем итәләр. Урын-җиреннән листовка табылган булса да, нигәдер Җамалетдиновны исән калдырганнар, алай гына да түгел, хәтта зуррак, дәрәҗәлерәк эшкә дә билгеләгәннәр. Шактый сәер тоела бу хәл Мичуринга.

Җамалетдинов үзе дә бик нык үзгәргән була инде. Элекке тыйнаклыгы һәм тәмле теллелегенең эзе дә калмаган. «Көнчыгыш ирекләләре өчен» өченче дәрәҗәле бронза медале тагылган күкрәген киереп, бик горур атлап йөри ул хәзер. Бары тик немецларга гына элеккечә тыйнаклык һәм куштанлык күрсәтә. Шулай да Мичуринның ачыктан-ачык дошмани карашы Җамалетдиновның күңелен борчып торган булса кирәк. Чөнки ул бер нык кына салган көнне Мичуринны чакырып ала да, имеш, исән калуың өчен син гүргә кергәнче миңа рәхмәт укырга тиешсең, әгәр мин яклап алып калмаган булсам, сине дә теге бунтчылар язмышы көтә иде, дип сөйләргә тотына. Яшерен оешманы мин табып бирмәгән булсам, немецлар аларның заговорын мәңге ачачак түгелләр иде, дип тә ычкындыра.

Тиздән, башка легионерлар белән бергә, Мичуринны Франциядә, Ле-Пюи лагерена күчерәләр. Анда бераз торгач, күпчелек легионерлар кебек, ул да, лагерьдан качып, француз партизаннарына кушыла һәм алар сафында сугышның ахырына тикле фашист оккупантларына каршы көрәшеп йөри. Җамалетдинов белән бүтән очрашмый.

Мичурин белән әсирлектә булган, ул сөйләгән сүзләрне раслый алырдай кешеләрнең исем-фамилияләрен язып алганнан һәм, гомумән, үзе кирәк тапкан аерым детальләрне ачыклаганнан соң, тикшерүче Җамалетдиновка мөрәҗәгать итә:

— Шаһит Мичурин әйткән сүзләрне раслыйсызмы?

Җамалетдинов бер агара, бер кызара. Тозакка эләккән бүре сыман боргалана, авыр итеп көрсенеп куя. Аннары, йөзен читкә борып:

— Юк, расламыйм, — ди.

## «Гаебемне таныйм...»

Тикшерү дәвам итә.

Юкка гаепләрен танымый маташа Җамалетдинов. Җинаятьләремне белгән кешеләр инде исән түгелдер дип, юкка гына өметләнә. Тикшерә торгач, Җамалетдиновны белгән-күргән кешеләр тагын табыла. Тикшерүче аларның кайберләрен Мәхмүт белән

күзгә-күз очраштыра, ә кайберләрнең язма рәвештә җибәрелгән шаһадәтнамәләрен укып күрсәтә. Барлык шаһитләр дә Мичурин сөйләгән хәлләрнең дөрес булуын раслыйлар. Алай гына да түгел, хәтта Җамалетдиновны фаш итә торган яңа мәгълүматлар да бирәләр. Шулай итеп, Җамалетдинов тикшерүчегә сөйләгән уйдырма фактлар тулысынча юкка чыгарыла. Ахырдан хыянәтченең җәлилчеләрне сатканнан соңгы язмышы да ачыклана.

Элекке хәрби әсир Н. С. Басаркин Җамалетдиновны күрү белән танып ала һәм бу кеше белән 1943 елда легионда очрашканлыгын сөйләп бирә. Басаркин 829 нчы укчы батальон составындагы дүртенче ротаның өченче взводына эләгә. Унтер-офицер Мәхмүт Җамалетдинов шул взводның командиры һәм шул ук вакытта рота пропагандисты була. Мәхмүт гитлерчыларга бик турылыклы хезмәт итә, политзанятиеләр вакытында Гитлерны һәм фашистлар тәртибен үтереп мактый, кулы астындагы кешеләргә карата үтә каты һәм таләпчән була: юк кына гаепләре өчен дә башта аларны үзе тотып кыйный, аннары гауптвахтага утырта. Легионерлар аның охранка белән бәйләнештә булуын сизенәләр. Бервакыт Җамалетдинов ике әсирнең немец армиясе җиңәчәгенә шикләнеп сөйләшүләрен ишетеп кала. Бу вакыйгадан соң күп тә үтми, теге кешеләр каядыр юкка чыга. Ә фашистларга турылыклылыгы шикле булган икенче берәүне Җамалетдинов штраф батальонына җибәрттерә.

1944 ел башында Җамалетдинов командалык иткән взводны кинәт кенә Краков шәһәренә күчерәләр. Анда легионерлар каравыл хезмәтен башкаралар, складлар саклыйлар. Һөҗүм итеп килүче Кызыл Армия гаскәрләре Краковка якынлаша барган саен, взвод командиры да «әйбәтләнә» һәм йомшара бара. Үз кулы астындагы кешеләргә элеккеге кебек җикеренми, киресенчә, алар алдында ялагайлана башлый. Хәтта «ил каршындагы гаепне аклау» турында да сайраштыргалап куя.

1944 елның җәендә, үз взводындагы унҗиде легионер белән бергә, Җамалетдинов кинәт юкка чыга. Соңыннан аларны партизаннар ягына качып киткән икән дип сөйлиләр. Ләкин Басаркин моның дөреслегенә бик үк ышанып җитми, чөнки бик ансат качып китә Җамалетдиновлар. Немецлар да зур гауга куптарып тормый һәм качкыннарны эзләү дә өстән-өстән генә үткәрелә. Хәтта аларны эзләргә этләр дә чакыртып тормыйлар.

Ләкин элек Җамалетдинов кул астында булган әсирләрдән Ф. И. Наумов һәм И. С. Рәҗәповның әйтүләренә караганда, башта ул, чыннан да, алар белән бергә поляк партизаннары янына качып киткән, аннары Золотарь җитәкчелегендәге совет партизаннары ягына чыккан.

Шулай итеп, Җамалетдиновның партизаннар ягына чыгу вакыты тәмам ачыклана. Үзе бик тырышып расларга тырышканча, 1941 елда түгел, бәлки 1944 ел уртасында була бу хәл.

Менә шушы дәлилләрдән соң да карышып азаплануның мәгънәсе калмый. Җамалетдиновның гаебе тулысы белән расланганлыгын әйтеп, тикшерүче кисәтеп куя һәм аның гаебен азрак йомшарту өчен бары тик бер чара, ул да булса — дөресен түкмичәчми сөйләп бирү чарасы гына калганлыгын әйтә. Ниһаять, ахыр чиктә Җамалетдинов дөресен сөйләргә ризалык бирә.

— Дөресен әйтим, — дип башлый ул, тикшерүче һәр сүзен язарга өлгерсен өчен ашыкмыйча гына, — эшләгән җинаятьләрем өчен җаваплылыктан куркып, тикшерү барышында, биографиямдәге кайбер моментларны чыннан да яшереп калдырдым мин. Хәзер гаебемне тулысынча таныйм һәм бары тик дөресен генә сөйләп бирергә телим. Барысын да нәкъ булганча сөйләп бирергә үзем теләп риза булуымны беркетмәдә күрсәтүне үтенәм...

Моңарчы бик озак дәшми йөрганлегән акларга теләгәндәй, хәзер инде Җамалетдинов чамадан тыш ачылып китә. Тикшерүченең соравын да көтеп тормастан, кирәген дә, кирәкмәсен дә сөйли. Аның сөйләгәннәре, нигездә, түбәндәгеләргә кайтып кала.

Сугыш башланганда ул, чыннан да, Балтик буенда була (бу хәл башка чыганаклар белән дә раслана) һәм аягы яралануы да дөрес (монысын медицина экспертизасы раслый).

Кыскасы, иптәшләре калдырып киткангә кадәрге вакыйгаларның барысын да дөрес сөйли. Ә менә шуннан соңгылары... Беренчедән, иптәшләре аның үзен генә түгел, бәлки үзе шикелле ике-өч яралы сугышчы белән бергә калдыралар. Икенчедән,

поляк хуторында түгел, бәлки Литва җирендәге Паберже дигән урында була бу. Алар шунда бер төн куналар. Ә иртән аларны кулларына автоматлар тоткан Литва полицайлары типкәләп уята. Җамалетдинов фашистларга әсирлеккә әнә шулай эләгә.

Немецлар, гадәттә, авыр яралыларны шунда ук атып калдыралар иисә, хәрби әсирләр лагерена илтеп, шунда газапланып үләргә дучар итә торган булалар. Әмма, әйтерсең, киләчәктә үзләренә турылыклы хезмәтче буласын сизеп, бу юлы Җамалетдиновка карата миһербанлык күрсәтәләр — Тильзит шәһәре тирәсендәге лагерь лазаретына эләгә ул. Лазареттагы әсир совет врачы (Җамалетдинов аның фамилиясен хәтерендә сакламаган) аңа бик зур ярдәм итә: болай да бик кечкенә булган паегын бүлеп ашата, кайдандыр дарулар табып, бик яхшы дәвалый. Шулай итеп, ул врач Җамалетдиновның гомерен генә түгел, аягын да саклап кала.

Дүрт ай ятканнан соң, бөтенләй төзәлеп, Җамалетдинов лазареттан чыга. Аннары аны, башка әсирләр кебек үк, лагерьдан-лагерьга күчереп йөртә башлыйлар.

Әйтүенә караганда, 1943 ел башында аны Едлинога китерәләр һәм көчләп «Идел — Урал» легионына кертәләр. Сигез класс белемле һәм русча яхшы сөйләшүче кеше буларак, аны отделение командиры итеп билгеләләр, аннары, озак та үтми, унтер-офицер дәрәҗәсе бирәләр.

Шушы урынга җиткәч, фикерен тупларга теләгәндәй, Җамалетдинов озак кына тукталып тора.

Тикшерүче:

— Әйдә, сөйләгез, гестапочылар сезне ничек яллады лар? — дигәч, яңадан сүзен дәвам итә.

1943 елның июнь урталарында, кичке сәгать унда штабка чакыртып, рота командиры немец Кох бик нык орышырга тотына аны. Отделениеңдә тәртип юк, легионерлар теләсә кайда буталып йөриләр, киләчәктә дә шулай булса, каты җәзага тартачакмын, дип яный. Аннары Җамалетдиновны гестапочы Миллер квартирасына алып китәләр. Тәрҗемәче аша, Миллер аның Совет армиясендә политрук булу-булмавы хакында төпченергә тотына. Җамалетдинов политрук булмавын әйтә. Ул, чыннан да, политрук булмый. Бу хәл гестапочыны тәмам чыгырыннан чыгара. Аяк тибеп, пистолетын селки-селки акырынырга тотына ул, Мәхмүттән политрук булдым дип әйтерергә тели. Әмма Мәхмүтнең һаман үз сүзендә калуын күреп, аны атарга алып китәргә боера.

Җамалетдиновны лагерьдан 300 метр чамасы читкә алып китәләр дә, кулына көрәк тоттырып, үзенә кабер казырга кушалар. Җамалетдинов тәрҗемәче аркылы, миннән нәрсә таләп итә соң алар, дип сорый. Мин әле бик яшь, кызганыгыз, үтермәгез, дип ялына. Үзара киңәшеп алганнан соң, немецлар аны кире алып кайталар.

Аннары Миллер квартирасында яңадан шул ук хәл кабатлана. Миллер Җамалетдиновның Совет армиясендә политрук булуын танырга куша, ә теге инкарь итә.

Җамалетдиновны тагын атарга алып китәләр, тагын кабер казырга кушалар. Җамалетдинов яңадан үтермәгез дип ялына. Үтермәсәгез мин барысына да риза, ди. Аны тагын Миллер квартирасына алып кайталар.

Бу юлы кайтып кергәндә, Миллер янына татар ак эмигрантлары комитеты «Идел — Урал» җитәкчеләренең берсе Гаяз Исхакый да (Җамалетдинов моңарчы аны Польшада Сувалки лагеренда татарларны легионга керергә өндәп йөргәндә күргән) кереп утырган була.

Исхакый Җамалетдинов белән татарча сөйләшә башлагач, Миллер белән тәрҗемәче бүлмәдән чыгып китәләр.

— Совет Армиясендә политрук булдыңмы син? — дип сорый аннан Исхакый.

— Юк, — ди Җамалетдинов.

— Ышанам, — ди Исхакый, аның белән килешеп. — Син әле бик яшь, шунлыктан политрук була алмагансың. Әмма синең политрук булуың хакында Миллердә ниндидер мәгълүматлар бар икән — сиңа аны тану мәгъкуль булыр.

Ләкин Җамалетдинов танырга теләми. Немецларның барлык политрукларны да шундук атуларын бик яхшы белгән ул.

Шуннан соң Исхакый немецлар белән нидер сөйләшә дә, бу хакта бер сүз дә әйтмәскә кушып, Җамалетдиновны казармасына кайтарып җибәрәләр.

Икенче көнне аны тагын Миллергә чакырталар. Гестапочы янә Җамалетдиновның

тануын талэп итә. Ә теге һич тә таныргә теләми. Шуннан соң Миллер Җамалетдиновны русчалатып сүгә һәм атарга алып китәргә куша. Тагын шул ук хәл — кирәк, кабер казу, исән калдырыгыз дип ялвару һәм Миллер квартирасына кайту.

Миллер янында аны тагын Гаяз Исхакый көтеп ала. Немец аяк тибеп акыра, атам, дип пистолетын селки, ә Исхакый, киресенчә, йомшак кына, ягымлы гына сөйләшә һәм Җамалетдиновны политрук идем дип әйтергә үгетли. Ул төнне дә, Гаяз Исхакый соравы буенча, Җамалетдиновны казармага кайтарып җибәрәләр.

Бу хәл биш төн рәттән дәвам итә.

Алтынчы төнне, Җамалетдинов һаман әле политрук булдым дип әйтергә теләмәгәч, Миллер пистолетын чыгара да атып җибәрә. Ату тавышына Гаяз Исхакый йөгереп керә. Миллер пистолетын икенче мәртәбә, әмма бу юлы Җамалетдиновның нәкъ күкрәгенә атарга төзәп торганда килеп керә ул. Исхакый немецча нидер әйтә һәм Миллер, пистолетын кесәсенә тыгып, ачулы адымнар белән бүлмәдән чыгып китә.

Аннары Исхакый Җамалетдиновның аркасыннан кагып, ярый әле вакытында кереп өлгердем, югыйсә ул сине, һичшиксез, атып үтергән булыр иде, ди. Без икебез дә татарлар, шулай булгач, без бергәрәк булырга, кирәк чакта бер-беребезне бәладән коткарырга тиешбез, ди. Үзенең максаты — рус большевикларыннан азат булган һәм татарлардан гына торган ирекле «Идел — Урал» республикасы төзү икәнлеген әйтә. Легионда әлегә хәтле большевиклар сакланып калган һәм ул дөнья болгаткычлар культвзводка да оя корганнар, ахрысы, ди. Эшне шулар бозды, беренче батальонны большевиклар ягына шулар озатты, ди.

Аннары Гаяз Исхакый Җамалетдиновка фашистларга каршы яшерен эш алып баручы кешеләрне ачыкларга тәкъдим итә.

— Моны ничек итеп эшли алырмын соң мин? — дип сорый Җамалетдинов.

Исхакый янә бер тапкыр аның аркасыннан кагып ала да, синнән күп нәрсә таләп ителми, үзең күргән һәм ишеткәннәрне дөрес итеп сөйләп барсаң — безгә шул бик җиткән, ди. Мин тиздән китәм, ә сине шушы көннәрдә пропагандист итеп билгеләрләр һәм син гестапочы Миллер белән элемтә тотарга тиеш булырсың, ди.

Аннары, бер литр аракы һәм закуска тотып, бүлмәгә Миллер үзе килеп керә. Җамалетдиновны сигарет белән сыйлый, аркасыннан сөя. Җамалетдинов белән Исхакыйга тутырып бирәр стакан аракы бирә, ә үзе стаканның төбенә генә сала. Өчесе чәкештереп эчкәннән соң, Җамалетдиновны казармасына кайтарып җибәрәләр...

Җамалетдинов сөйләгән саен кыза бара. Ничек итеп үзенең түбәнлеккә төшү юлларын шундый теләп сөйли ул, әйтерсең, шуннан ниндидер тәм, ләззәт таба. Үзе сөйли, үзе, ышанамы-юкмы икән дип, әледән-әле тикшерүчегә күз ташлап ала. Ләкин тикшерүченең кыяфәте шундый сабыр, шундый тыныч — аның ни уйлавын һич төшенә алырлык түгел.

— Акрынрак сөйләгез, — ди аңа тикшерүче.

Җамалетдинов тагын сөйләргә керешә.

— Берничә көннән, — ди ул, — миңа медицина тикшерүе үткәрделәр, иске ярам аркасында строевой хезмәткә яраксыз дип таптылар һәм пропагандист итеп куйдылар. Алдан сөйләшү буенча, җиде көннән соң төнге сәгать уникедә Миллер квартирасына бардым. Тәрҗемәче аркылы Миллер культвзводта мине ничек кабул итүләрен сорашты. Гайнан Курмаш сиңа ышаныч белән карыймы, дип сорады. Мин аңа әлегә барысы да әйбәт булуын һәм үземне яхшы каршылауларын әйттем.

Аннары Миллер Җамалетдиновка штаб тирәсендә көндез беркайчан да чуалмаска, үзе янына бары тик төнлә, хаҗәтен үтәргә чыккан булып кына килергә кушкан. Курмаш нәрсә кушса, шуны эшләргә, яшерен оешмага керергә тәкъдим итсәләр һәм берәр төрле задание бирсәләр — аңа да риза булырга киңәш итә. Ун көннән тагын очрашырга булалар.

Әмма, бер атна чамасы үткәч, Җамалетдиновны янә рота командиры чакырта. Ул Кох кабинетына килеп кергәндә Миллер һәм тәрҗемәче дә шунда була. Кох аларның үзләрен генә калдырып чыгып китә.

Миллер Җамалетдиновка тиздән Берлиннан большевикларның күренекле шагыйре, элекке политрук һәм коммунист Муса Җәлил — Гумеров килачәген әйтә. Ул, ди Миллер, зур белемле һәм бик хәйләкәр кеше, ихтимал, культура эше белән шөгыльләнгән булып, рейхка каршы коткы таратадыр.

Шуннан соң Миллер Җамалетдиновка Җәлилнең һәр адымын күзәтеп йөрергә һәм шул хакта һәр көн үзенә хәбәр итеп торырга боерык бирә. Очрашу урыны итеп, Кох кабинетын билгели.

Тиздән Җәлил Едлинога килә. Өстенә граждански кием: эшләпә, көрән костюм, ак күлмәк кигән һәм галстук таккан. Кулында плащ һәм кечкенә генә чемоданы да бар. Аның белән тәбәнәгрәк кенә буйлы, пләшләнә башлаган башлы, монголларныкына охшашрак кысык күзле, эчкечеләрнеке кебек кызыл борынлы, шулай ук граждански киемдәге тагын бер бәндә килә. Җамалетдинов соңыннан белә: дөньяда булмаган «Идел — Урал» дәүләтенең «президенты» Шәфи Алмаз булып чыга ул.

Җәлил легионда озак булмый, нибары өч-дүрт көн генә тора. Музыкаль капелланың эше белән кызыксына, репетицияләрдә катнаша, легионерлар өчен зур үзешчән сәнгать кичәсе оештыра. Мусаның кемнәр белән очрашуын һәм нәрсәләр хакында сөйләшүен Җамалетдинов түкми-чәчми Миллергә җиткерә бара.

Бер айдан соң Җәлил тагын, бу юлы шактый озак вакытка, легионга килә. Җамалетдинов тагын бер адым да калмыйча күзәтеп йөри аны. Бу чорларда Миллер аеруча таләпчән һәм түземсез була башлый. Аяк тибеп, фаш итәрлек дәлилләр табуын сорый ул Мәхмүттән. Дәлил тапмасаң, җаныңны алам, дип яный. «Легионда коткычылар һәм совет агентлары оя корган, ә син шуларны яшереп торасың!» — дип акыра. Җамалетдинов кулыннан килгәнчә тырыша, әмма яшерен оешмачыларның эзенә һич кенә дә төшә алмый. Бары тик Баттал белән бергә Берлинга командировкага барганнан соң гына, ниһаять, ул яшерен оешманың чыннан да яшәп килүен раслый торган реаль дәлилләр табып китерә.

Берлиннан кайтканнан соң беренче төндә үк Җамалетдинов Миллер янына килә дә күргән һәм ишеткәннәренең барысын да сөйләп бирә, үзе белән алып килгән листовкаларны да күрсәтә. Миллер аны разведка начальнигы капитан Линкеска алып бара һәм сөйләгәннәрен тагын бер кат кабатларга куша. Гестапочылар Җамалетдиновның бу хәбәреннән бик канәгать булалар: аны мактыйлар, аракы белән сыйлыйлар һәм иртән, серне ачмас өчен, аны да башкалар белән бергә кулга алачакларын, әмма озак тотмаячакларын әйтәләр, һич тә борчылмаска кушып, казармасына кайтарып җибәрәләр.

Икенче көнне барысы да нәкъ Миллер әйткәнчә эшләнә. Башка яшерен оешма членнары белән бергә, Җамалетдинов та кулга алына һәм батальон гауптвахтасының бер кешелек камерасында төн үткәрә. Ә иртән бер гестапочы аны, җиңел машинага утыртып, Радом шәһәреннән 15—20 километр чамасында урнашкан Едлино лагерена илтеп куя. Едлинода аны Гаяз Исхакый елмаеп каршы ала. Исхакый нидер әйткәч, эсэсчы, машина утыргычы астыннан алып, Җамалетдиновка легионер кнәгәсен һәм бил каешын бирә.

Шуннан соң Җамалетдинов Гаяз Исхакый белән Берлинга китә. Башта Исхакыйның Берлиндагы квартирасында, аннары шәһәр читендәге дачасында яши. Анда ул берни дә эшләмичә ял итә, кинога һәм рестораннарга йөри. Берәр айдан соң Исхакый дачасына легион командиры майор фон Зиккендорф килеп төшә. Немец командаваниесенең заданиесен уңышлы үтәп чыкканлыгы өчен, Җамалетдиновның «Көнчыгыш ирекләләре өчен» өченче дәрәҗә медале белән бүләкләнүен әйтә һәм шундук аның күкрәгенә әлеге медальне тагып та куя. Исхакый да, майор фон Зиккендорфка кушылып, котлау сүзләре әйтә.

Аннары Җамалетдиновны яңадан легионга китерәләр. Кайда болай озак югалып тордың дисәләр, ди аңа Миллер, Варшавада тикшерү төрмәсендә утырдым дип әйтерсең. Җинаятемне таба алмагач, соңыннан азат иттеләр, диярсең, ди.

Легионга кайткач, батальон командиры Җамалетдиновны кулга алынган Мичурин урынына пропагандистлар группасы башлыгы итеп билгели, ә өч-дүрт айдан соң взвод командиры итеп куялар. 1944 ел башында аның взводын Краков шәһәренә каравыл хезмәтенә күчерәләр. Әйтүенә караганда, Җамалетдинов эшләгән хыянәтләре өчен нәк шул көннәрдә үкенә башлый. Үз кул астындагы кешеләргә ярашырга тырыша һәм качып китү чараларын эзли. Аннары бер поляк картыннан партизан отряды урнашкан җирне сорашып белә дә, алгы сызыкны ныгытырга барабыз дигән сылтау астында, үзе белән ышанычлырак дип тапкан унҗиде легионерны ияртеп, башта поляк партизаннары ягына кача, соңыннан белорус партизаннарына кушыла.

# Алдашу нигә кирәк булган соң?

Тикшерүне шунда туктатырга да мөмкин булыр иде. Чөнки Җамалетдиновның гаебе шаһитләр тарафыннан да, гаепләнүченең үзе тарафыннан да тулысынча расланды бит. Җамалетдинов эшләгән кабахәтлекләрнең уннан бере генә дә аны үлем җәзасына хөкем итү өчен җитеп ашкан булыр иде.

Әмма тикшерүче аның эшен ябарга ашыкмый.

Җамалетдинов сөйләгән хикмәтләр, билгеле, реаль һәм инде дәлилләнгән фактларга нигезләнгән, әмма аның сөйләве урыны-урыны белән гадәттән тыш шома, гадәттән тыш дөрес яңгырый. Шуңа сәерсенә тикшерүче. Әлеге гадәттән тыш дөреслек Җамалетдинов эше белән нәкъ менә шушы чакта танышкан язучы Юрий Корольковны да буташтырып җибәргән. «Кырык үлем аша» исемле китапны укыган кешеләр хәтерлидер, анда Җамалетдинов (китапта Ю. Корольков аны Мәхмүт Ягулдин исеме астында сурәтләгән) сөйләгән вакыйгалар бөтенләй диярлек үзгәртелмичә бирелгән.

Әйе, тикшерүче эшне ябарга ашыкмый. Җамалетдинов телгә алган һәр фактны, һәр исемне җентекләп тикшерү башлана. Болай итү хыянәтчене хөкемгә тарту өчен генә түгел, бәлки, барыннан да бигрәк, Муса Җәлил җитәкчелегендәге яшерен оешма башкарган эшләрнең асылын ачыклау өчен кирәк була.

Тикшерүче кабат-кабат чакырып сөйләштерә, сораштыра торгач, Җамалетдиновның хәрби әсирләр лагерьларының исемнәрен буташтыруына, ул лагерьларда үзе кайчан булганлыкны төрле вакытта төрлечә әйтүенә, лагерьлардагы хәлләрне сөйләп бирә алмавына, хәтта үзе белән булган кешеләрнең берсенең дә исемен белмәвенә игътибар итә. Җентекләбрәк тикшерү нәтиҗәсендә Җамалетдиновның, Тильзиттан башка, бер генә лагерьда да булмаганлыгы ачыклана.

Гаебен танып сөйләгән вакытта Җамалетдинов Гаяз Исхакыйны телгә алгач та, тикшерүче үзенең блокнотына ул исемне язып, зур-зур берничә сорау билгесе куя.

Гаяз Исхакый революциягә кадәр татар язучыларының берсе саналып йөри, эсерлар партиясе члены була. Революциядән соң эмиграциягә китә һәм ак эмигрантлар, буржуаз милләтчеләр идеологының берсенә әверелә. Менә шул «эмигрант бабасы» Җамалетдинов кебек вак-төяк агент белән нигә пычранып торсын икән?

Тикшерә торгач, Җамалетдиновның Гаяз Исхакый турында сөйләгәннәре барысы да тикшерүчене бутар өчен генә уйлап чыгарылганлыгы ачыклана.

Моннан тыш, архив документлары нигезендә, легион штабы разведкасында Миллер дигән фамилияле кешенең дә булмавы раслана. Димәк, Гаяз Исхакый катнашкан теге романтик тарих, төнге сынаулар һәм ату белән янаулар барысы да чеп-чи ялган булып чыга [1].

Тикшерү барышында әле «Идел — Урал» легионына кергәнче үк Мәхмүт Җамалетдиновның унтер-офицер чинында булганлыгын һәм «Көнчыгыш иреклеләре өчен» медале тагып йөргәнлеген күргән кешеләр дә табыла. Шулай итеп, Зиккендорфның Исхакый дачасына (ә аның дачасы гомумән булмый!) килүе һәм Җамалетдиновка шунда медаль тапшыруы турындагы хикәя дә баштанаяк буш сүз булып чыга.

Бу ялганлау нигә кирәк булган соң Җамалетдиновка? Берлән, үзен яллаган һәм эшкә җиккән чын хуҗаларының исемнәрен каплап калдырырга, икенчедән, үз биографиясендәге ямьсез фактларны читләтеп үтәргә чамалаган ул.

Лазареттан чыгу белән Җамалетдинов, үзе теләп, фашистлар тарафыннан төзелгән Төркстан легионына язылган, Сум, Харьков өлкәләрендә совет партизаннарына каршы оештырылган җәза отряды экспедицияләрендә катнашкан, талап, яндырып, көчләп йөргән. Нәкъ менә шул хезмәтләре өчен фашистлар аны унтер-офицер чинына күтәргән һәм «Көнчыгыш иреклеләре өчен» медале белән бүләкләгән дә инде.

---

[1] Сүз уңаенда әйтеп китик: Ю. Корольков китабында хыянәтче үзе сөйләгәнчә күрсәтелә. Ш. Маннурның «Муса» романында (анда ул Мәхмүт Ямалтаев исеме белән бирелә) бу мәсьәлә дөрес сурәтләнә.

Тыныч халыкка каршы алып барылган канлы походларның берсендә Җамалетдинов венерик авыру эләктереп кайта һәм госпитальгә керә. Әнә шунда Исхаков фамилияле тәбәнәк кенә, ябык кына бер фельдшер белән (Казагыстан ССРның Кызыл-Урда өлкәсеннән) таныша ул.

Алар үзара дуслашып китәләр, еш кына немецлардан яшереп, медицина спирты да эчәләр. Аннары Исхаков Җамалетдиновны госпитальгә санитар итеп урнаштыра. (Батырлыгы «зур» булса да, яңадан партизаннар пулясы астына китәсе килми тегенең!) Күптәнге гестапо агенты булган әлеге Исхаков аркылы фашистлар Җамалетдиновны үзләренә эшкә яллыйлар. Куркытып та, көйләп-чөйләп тә торырга туры килми аны. Исхаков бу эше өчен күпме түләячәкләрен, җәза отрядында катнашкан кешегә барыбер иленә кайту юлы юклыгын аңлатып бирү белән үк, Җамалетдинов гестапо агентына әйләнеп китә.

Беренче батальонда баш күтәргәннән һәм лагерьда еш кына листовкалар табыла башлаганнан соң, Берлиндагы империя куркынычсызлыгы идарәсе, теләсә ничек итеп булса да, татар легионындагы яшерен оешманы ачуны таләп итә. Менә шул көннәрдә Җамалетдиновның арзанга гына сатылуы фашистлар өчен бик тә әйбәт була.

Исхаков белән бергә аны Едлинога «Идел — Урал» легионына күчерәләр һәм Исхаковны медпунктка фельдшер, Мәхмүтне исә отделение командиры итеп куялар. Гонореясен дәваларга йөргән атлы булып, Җамалетдинов барлык заданиеләрне дә Исхаков аркылы ала. Ә бу эшкә Блок дигән фельдфебель җитәкчелек итә.

Тикшерүчегә Җамалетдинов ул фельдфебельнең тышкы кыяфәтен дә сөйләп бирә. Аның әйтүенә караганда, Блок урта буйлы, пеләш башлы, соры йон каплаган беләген һәрвакыт сызганып йөрүче кеше булган. Сүз арасында Мәхмүткә үзенең Кенигсберг шәһәреннән икәнлеген дә әйткән. Әнә шул билгеләре буенча фикер йөрткәндә, атаклы фашист бүресе, кара эшләр остасы доктор Блок булырга тиеш ул.

Блок — әле Гитлер власть башына менгәнче үк, Кенигсберг шәһәрендәге бер фабрика морҗасы башына свастикалы флаг менгереп кадаган һәм аннан төшешли морҗадагы баскыч басмаларын суырып алып төшкән, шуның белән дан казанган кеше. Баскыч булмаганлыктан, теге флагны байтак вакыт ала алмыйлар. Әнә шуның өчен нацистлар Блокны, Германия өстенә беренче мәртәбә фашист флагын күтәргән кеше буларак, бик нык мактыйлар. Доктор Блок фашистлар разведкасының аеруча мөһим һәм җаваплы заданиеләрен үтәп йөри. Империя куркынычсызлыгы идарәсенең легионга әнә шул атаклы һәм ышанычлы кешене җибәрү факты үзе генә дә Муса Җәлил җитәкчелегендәге яшерен оешманы фаш итүгә нацистларның бик зур әһәмият бирүләре хакында сөйли.

Җәлил, Курмаш һәм яшерен оешманың башка членнарын күзәтү дә әлеге Блок күрсәтмәсе нигезендә башлана. Җамалетдинов һәм Исхаковның күзәтү нәтиҗәләре турындагы хәбәрләрен дә ул үзе тыңлый. Яшерен оешманы фаш иткән төнне дә листовкаларны Блокка Җамалетдинов илтеп бирә.

Үзенең фашистларга сатылу тарихын ялганлап сөйләве белән Җамалетдинов бер атуда ике куян үтермәкче була.

Беренчедән, хуҗаларының «беркайчан да, беркемгә дә гестапо агентларының һәм сотрудникларының чын исемнәрен әйтмәскә», дигән күрсәтмәләрен үти.

Икенчедән, үзен беркатлы мәхлук итеп күрсәтергә һәм гомерен саклап калырга ниятли.

Ә Исхакый дачасындагы тормышы һәм Зиккендорф килүе турындагы икенче уйдырма нигә кирәк булган соң аңа? Азрак бәясен күтәрергә ниятләвен искә алмаганда, шулай ук дөреслекне яшереп калдыру өчен кирәк булган. Тикшерү барышында Җамалетдинов үзе дә, яшерен оешма членнарын сатканлыгы өчен, бик зур сумма акча алуын һәм аннары Австриягә ялга җибәргәнлекләрен әйтә. Тикшереп караганнан соң, бу хәлнең дөреслеге раслана. Ләкин, шулай да, хыянәтче бер бик мөһим моментны яшереп калдырган. Анысы Җамалетдиновның эше ябылганнан һәм ул инде тиешле җәзасын алганнан соң мәгълүм була.

Муса Җәлил яшерен оешмасы члены, культвзвод «артисты» Фәрит Солтанбеков бу хакта менә нәрсә сөйли: легионда кулга алулар башланудан берничә көн элек

кенә Курмаш Солтанбековка Балтик диңгезе буендагы Узидом утравына (легионның ял йорты шунда урнашкан була) барып, концерт куеп кайтырга куша. Аннан кайтышлый Фарит Берлинга кагылырга һәм Абдулла Алиш белән күрешергә тиеш була. Әмма Узидомга килгәч үк, аны кулга алалар һәм Берлинга илтәләр. Ике көн төрмәдә тоталар. Өченче көнне, әйберләрен кулына тоттырып, төрмәнең түбәнге катындагы кетеп тору бүлмәсенә алып кераләр. Солтанбеков килеп кергәндә, ертык гимнастеркадан һәм каешсыз килеш, Җамалетдинов та шунда була. Алар үзара сөйләшеп алалар һәм Солтанбеков легиондагы кулга алулар турында беренче тапкыр Мәхмүттән ишетә.

Аннары аларны машинага утырталар да каядыр (Варшава төрмәсенә булып чыга ул) алып китәләр. Юлда барганда Җамалетдинов кулга алу турында бик тәфтишләп сөйләргә тотына. Солтанбековның үзен ничек кулга алганлыкларын сораша. Сүз арасында гаҗәпсенеп кашларын җыера, немецларны сүккән була һәм, шул рәвешле, акрын-акрын «иптәшләрдән» иректә кемнәр калганлыгын, кемнәр кулга алудан котылуын әйттермәкче була. Әмма Солтанбеков, Курмашның бу кеше белән бик сак эш итәргә кирәк дип кисәтүен хәтерләп, артык җәелеп китми. Арестантларга үзара сөйләшергә гомер рөхсәт итми торган немецларның бу юлы нигәдер бик игътибарсыз кылануларын да сагаерга мәҗбүр итә Солтанбековны. «Белмим», «күрмәдем» дип кенә җавап бирә бара ул тегеңә. Аннары, башым авырта дигән сылтау белән, бөтенләй җавап бирми башлый.

— Син ничек уйлыйсың: безне ни өчен кулга алды икән алар? — ди Җамалетдинов, һаман сагызлануын дәвам итеп.

— Хыянәт иткәнгәдер! — ди аңа Солтанбеков, кискен генә итеп. Күрәсең, нәрсәгә ишарә ясавын аңлагандыр, шуннан соң теге, ниһаять, тынып кала.

Варшава төрмәсенә килеп җиткәч, Солтанбековны конвой белән камерага алып кереп китәләр, ә Җамалетдинов машинада кала. Ихтимал, башка кулга алынган кешеләр янына да шушылай утыртып йөрткәннәрдер аны.

Төрмәгә эләккәннән соң Солтанбеков Гайнан Курмаштан язу ала. Ул кәгазьгә бары тик бер генә сүз — «Мәхмүт» дип язылган һәм аның янына фашист билгесе ясалган була. Хәер, аның сатылган җан икәнлеген Солтанбеков үзе сизенеп өлгерә инде.

Димәк, 11 августтан соң Җамалетдинов чыннан да Берлинда булган. Әмма, үзе әйткәнчә, ялда түгел, бәлки «эштә» йөргән.

Ниһаять, Җамалетдиновның шаһитлегендә тагын бер шикле урын — аның партизаннарга качуы. Тикшерүнең ахырына тикле «гаебемне аз гына булса да аклау өчен» партизаннар янына качып киттем дип расларга тырышып килә ул. Ләкин аның бу сүзләренә ышану кыен. Советлар Союзына кайтса, анда үзен нәрсә көткәнлеген бик яхшы белә Җамалетдинов. Эзен югалту һәм кабахәт җанын саклап калу өчен генә булса да, башка хыянәтчеләр шикелле үк, каядыр Көнбатышка, америкалылар ягына таба сызу ягын карар иде ул.

Ихтимал, гестаподан яңа задание алгандыр Җамалетдинов. Шулай булган тәкъдирдә, аның нигә алай көтмәгәндә Краковка — үзен беркем дә белми торган урынга күчеп китүе аңлашыла. Немец формасы кигән офицерга «поляк картының партизан отряды кайда урнашканлыгын аңлатуына да бик үк ышанып җитәсе килми. Мөгаен, ул мәгълүматларны аңа фашистлар үзләре биргәннәрдер, шулай итеп, хәвефсез-хәтәрсез генә «качарга» мөмкинлек тудыргannардыр. Ихтимал, бары тик безнең гаскәрләрнең зур тизлек белән дошманны кысрыклап килүе аркасында гына Җамалетдинов бүтән җинаятьләр эшләргә өлгерә алмый калгандыр.

Һәрхәлдә, бу мәсьәлә ачык кала әле. Һәм, дәлилләр җитәрлек булмау сәбәпле, бу пункт гаепләү нәтиҗәсенә дә кертелмәгән.

Мене шушы ...ларне күз алдыннан кичергәч, Җамалетдиновның ни өчен шагыйрьнең пакь исемен пычратырга маташуы бик яхшы аңлашыла. Әгәр Җәлилне хыянәтче дип санасалар, ихтимал, Җамалетдиновны беркем дә төпченеп тикшереп тормас иде бит.

1950 елның 16 октябрендә Хәрби трибуналның ябык утырышы үткәрелә. Анда Җамалетдинов эше карала.

Суд тикшерүчеләр тарафыннан әзерләнгән документларны һәм материалларны тикшерә, шаһитләрне тыңлый.

Үзен фаш итүче материалларны кире кага алмаган хыянәтче барлык күрсәтелгән пунктлар буенча да гаебен тулысынча таный. Ул бары тик бер мәсьәләдә генә үз фикерен алга сөрә: мин, ди ул, гаепләү кәгазендә күрсәтелгәнчә 70—80 кешене түгел, бәлки нибары 7—8 кешене генә саттым. Һәм, шул нигездә, судтан үзен исән калдыруларын үтенә [1].

Судта шаһит буларак чыгыш ясаган Мичурин:

— Нинди кешеләрне харап итте бит, эт, нинди кешеләрне! — дип, яшен тыя алмыйча елап җибәрә. — Дөрес, — ди ул, кулга алынучыларның барысын да турыдан-туры Җамалетдинов сатмады. Әмма яшерен оешманың эзенә гестапо бары тик аның хыянәте аркасында гына төште.

Суд киңәшмәгә китә. Аннары шул ук көнчең кичендә хөкем карары укыла. Хыянәтче иң зур җәзага — атарга хөкем ителә. 1951 елның 19 гыйнварында суд карары җиренә җиткерелә.

Җамалетдинов эше буенча үткәрелгән тикшерү аның хыянәтче икәнлеген ачып бирүгә генә кайтып калмады, бәлки Муса Җәлил җитәкчелегендәге яшерен оешма башкарган күп кенә эшләрне белергә дә ярдәм итте. Хыянәтчене хөкем иткәннән соң күп тә үтмәде, шагыйрьнең үлемсез батырлыгы бөтен дөньяга мәгълүм булды.

[1] Әлбәттә, Мәхмүт Җамалетдинов гестапо карамагындагы бердәнбер шымчы булмый. Ул фәкать Радомдагы җиде-сигез яшерен оешма членнарын гына белә. Җәлилчеләрне кулга алулар бер үк вакытта Берлинда, Едлинода, Демблинда һәм башка урыннарда да үткәрелүен искә алсак, Җамалетдиновтан тыш та хыянәтчеләр булгандыр дип уйларга урын кала.

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

*М. Васютин, Җ. Рәхимов*

# ДЕПУТАТ

*Очерк*

Өченче сменаны озатып, икенчесен каршы алган Карабаш төнге йокыга талган. Тик икенче промысел конторасы тәрәзәләренең берсеннән генә ут көлтәсе бәркелә. Ишегенә «СССР Верховный Советы депутаты» дип язылган иң түрдәге бүлмәдә Габделбәр Сәетгәрәев өстәл лампасыннан төшкән яктылыкта дәфтәренә нидер яза.

Ул кичә генә Мәскәүдән, СССР Верховный Советы сессиясеннән кайтып төште. Промыселны гомер күрмәгән кешедәй, бүген көнозын скважиналар янында йөрде. Кичен инде депутатны нефтьчеләр, колхозчылар көтә иде. Мәскәү тәэсирләре, Сессия карарларын уртаклашып йөреп, әле генә ялгыз калуы. Авылдашларының — Зәй-Каратай халкының — өй түбәләре ябу өчен материал сорап язган хатлары буенча тиешле документларны әзерләсә, бүгенгә эше бетә.

Әйе, эше муеннан хәзер нефть остасының. Хәер, депутат итеп сайланганчы да эшсезлектән интекмәде. Киресенчә, тәүлеккә сәгатьләр өстәрдәй булып яшәде. Бүген исә төп хезмәте янына яңа мәшәкатьләр, исәп-хисаплар, йокысыз төннәр өстәлде. Һәр хезмәт иясенең йомышы бар аңарда хәзер. Әле төштән соң гына дистәдән артыграк хат алды. Аларның мәктәпләр, колхозлар, авыл Советлары исеменнән язылганнары да, гади нефтьчеләр, колхозчылар җибәргәннәре дә бар. Берәүләре өй түбәсе ябу өчен материал сорый әнә, икенчеләре авылга су кертү өчен трубалар табуда ярдәмләшүен үтенәләр, өченчеләре тагын әллә нәрсә. Күпме мәсьәләләр хәл итәсе! Аларның кайсыларына күп көч куясы да түгел, кайберләренә исә сабыр итүләрен сорап хат язарга туры килә. Кайсының очына чыгу өчен бер учреждениедән икенчесенә барасың, әллә ниткән холыклы «хуҗалар» белән очрашасың. Сорыйсың, үтенәсең, таләп итәсең. Карабаш эшчеләр поселогын газификацияләү өчен генә күпме көч сарыф итәргә туры килде. Эшнең әле һаман да җайланып киткәне юк. Нибары берничә кварталда гына зәңгәр ялкынга рәхәтләнәләр. Алда исә эшнең тагын да катлаулырагы.

Поселок территориаль яктан Бөгелмә районына керә. Ә андагы предприятиеләрнең күбесе Лениногорск, Әлмәт идарәләренә, трестларына буйсыналар. Хуҗалар житерлек. Тик менә поселоктагы йортларны ремонтлау мәсьәләсе күтәрелгәндә генә кемгә мөрәҗәгать итәргә белмисең.

Шуңа ачынып район Советы башкарма комитетына да, Әлмәткә, «Татнефть» берләшмәсенә дә кат-кат барды Габделбәр. Әмма күңелен тынычландырырлык җавап тапмады. «Иртәгә үк тагын «Татнефть»кә барырга кирәк», — дип уйлады ул һәм эшен бетереп урыныннан кузгалды.

Ә алда уйлануны, хәл итүне көтеп яткан мәсьәләләр никадәр әле. Промыселларны автоматлаштыруны гына ал. Аның белән унунбиш елдан бирле маташалар. Тау-тау эшләр башкарылды. Ә файдасы? Диңгездән бер тамчы. Объектларны автоматлаштыруга ел саен дистәләрчә мең сум акча тотыла. «Менә бу автомат иңмасам», диярлек системалар исә бик аз әле. Бер системаны сынап бетермиләр, икенчесенә тотыналар.

Бу турыда кискен сүз әйтергә, тиешле тәртип кертергә бик вакыт бит инде.

Инде берничә елдан бирле промыселларда пыялаландырылган трубалар куллана башладылар. Эчтән стенасына пыяла ябыштырылган мондый трубаларга парафин утырмый, скважинага кыргыч төшереп азапланасы, өзлексез ремонтлап торасы юк. Ул трубалар төшерелгән скважиналардан иң арзанлы нефть алына. Әмма әнә шуның экономик файдасын «капшап» караган юк бит әле. Андый скважиналар нефть мәйданнарының төрле почмагына чәчелгән. Габделбәрләр участогында да унбишләп бар алар. Барын бер операторга бирәсе иде шуларның, бер үзе хезмәт күрсәтсен иде. Менә шул чак «капшап» булыр иде трубаларның файдасын. Юк шул, кем әйтмешли, берсе мәгърибтә, берсе мәшрикътә аларның. Унбише унбиш оператор кулында. Алардан алынган нефть тә сыек алтынның уртак агымында югалып кала. Пыялаландырылган трубаларны нигә бер тирәдәге скважиналарга куймаска?

Депутат буларак, шулар турында уйлануы бер бүген генә түгел Габделбәрнең. Ялгызы калдымы — шул турыда баш вата...

Культура сарае янындагы таш мәйданда әнә шулай бераз уйланып торды да Габделбәр, бөтенләй башка якка — Карабаш сусаклагычы буена атлады. Күңеле борчулы чакларны бер ялгызы яр өстендә торырга ярата ул.

Әле бая гына таулар арасында шаярып сызгырып йөргән җил тәмам котырган. Менә ул Каравыл тавы белән Тамбикә арасындагы чагылдан ыжгырып килеп төште дә шадраланып торган су өстен болгатты. Ул да булмый, сажень биеклеге дулкыннар бер-берен узып Карабашка таба йөгерешә башладылар. Башта бер җайга гына чабышкан дулкыннар акрынлап ярсый, усаллана баралар, ярга һаман биегрәк күтәреләләр. Ләкин алар, егет-җайдак кулындагы йөгәнле чаптар кебек, ярсыйлар-ярсыйлар да тынып торалар. Аннан яңа көч белән ярга, плотинага ташланалар.

Нефть якларында «Диңгез» дип даны таралган шушы буа, илебез чикләрендәге су бассейннары белән чагыштырганда, фил янындагы тычкан кадәр генә булса да, вакыты-вакыты белән ничек дулый. Ул да шашынган тиле көчкә, гайрәткә ия. Кур ничек кайный, шаулый, ярына сыймыйча каядыр омтыла. Куәт тә бар соң инде үзендә!

Әле 1955 елга кадәр генә теләсә кай җиреннән кичеп чыгарлык елга иде бу Зәй. Нефтьчеләр теләген үтәп, бирегә гидротөзүчеләр, йөзләгән машиналар, земснарядлар, бульдозерлар, экскаваторлар килде. Олы болын белән Чүмәле тау арасында плотина калкып чыкты, күз күреме җитмәс сусаклагыч барлыкка килде.

Җәйге матур көннәрдә Карабаш диңгезе дә тыныч, күндәм. Анда Әлмәт, Лениногорск, Бөгелмә һәм Карабаш нефтьчеләре ял итәләр: су коеналар, балык каптыралар. Ә менә шушындый җил-давыллы көнне якын килмә инде син аңа. Андый чакларны сусаклагыч баш бирмәс аждаһага әверелә, моңарчы яшереп торган дуамаллыгын күрсәтеп ала. Исемнәре дә телгә алынмый торган инеш-елгалар бергә тупланган, әкәмәт зур көчкә ия булалар икән. Бердәмлектә шул хикмәт. Дәрман зур инде ишле суда. Нефтьчеләр Карабаш диңгезенә җыйналган ишле суның бу көченнән файдалана белделәр. Зәй суы куәтле насослар белән җир астына кудырыла, сусаган дивонның сусавын баса, миллиардлаган тонна хәзинәне җир өстенә этеп чыгара. Әйе шул, Исмәгыйл бабай әйтмешли, көчне, куәтне төрлечә кулланып була — аны кая юнәлтәсең бит... Шулчак Габделбәрнең хәтеренә бала чагында булып үткән бер вакыйга килеп төште. Шуңа ялганып, бөтен тормыш юлы күз алдыннан үтте.

...Кайдадыр, көнбатышта, дөньяга ут капкан, кан коела, җәһәннәм кисәве дөрләгән чак иде. Беренче класска укырга керәм дип йорганда, әнисе үлеп китте, йөрәк ярасы йомылып бетмәде, әтисенең сугышта һәлак булу хәбәре килде. Туйганчы ипи ашаган көннәр татлы төш булып калды. Тамагы һич тыңгылык бирмәгән әнә шундый җәйге көннәрнең берсендә дусты Галимҗан Исмәгыйл бабайның кыярын басарга котыртты. Габделбәр андый эшкә маһир түгел иде. Икеләнде, шулай да ризалашты. Тамак дигәнең берни белән дә хисаплашмый икән шул. Ләкин койма төбендә сакта торудан артыгына йөрәге җитмәде аның. Монда эш катлаулы түгел, кеше-кара күренү белән, әче итеп сызгырасың гына. Калганы Галимҗан эше.

Тик киртә буенда торуның да рәте бар икән. Дусы бакчага кереп югалуга күп булса биш минут үткәндер. Әнә куе яфракларны кыштырдатканы да ишетелә инде. Габделбәр исә аяк очына баса-баса аны карый. Шул чак кемдер йомшак кына итеп аның колагыннан эләктереп ала.

— Ә-ә-ә, тишек борын, әйдә әле.

Исмәгыйль карт, колактан авырттырмый да, җибәрми дә тоткан хәлдә, малайны кап-кадан алып кереп китте. Галимҗан качты, ә ул электе. Менә хәзер карт аны эскәмияга йөзтүбән яткырыр, киндер ыштанны күрше кызларын оялтмаслык кына итеп төшерер дә аннан мурда үрергә әзерләп куйган тал чыбыгы чыжлар. Габделбәрнең аркалары эсселе-суыклы булып китте, маңгаена тир бәреп чыкты.

Ләкин вакыйга бөтенләй икенче төс алды. Исмәгыйль карт аны өенә үк кертеп, өстәл артына утыртты һәм алдына эре-эре яшел кыярлар китереп куйды. Аннан өстәл тартмасына тыгылды, аптырап калган малайга зур гына ипи сыныгы китереп тоттырды.

— Аша, — диде ул, аталарча итеп. Аннан үзе дә Габделбәр каршына килеп утырды һәм тәҗрибәле укытучы кебек салмак кына тезә башлады:

— Син, апаем, ярыйсы гына буй җиткереп киләсең, — диде бакчачы. — Беләгеңдә көч, йөрәгеңдә гайрәт арта. Синең кебек чакта әнә шул көч-куәт һич тынгы бирми, тик тотмый. Шундый сәваль туа: шул пырдымсыз егәрлекне кая куярга? Башсызраклар аны теләсә нинди эшкә — яхшымы ул, яманмы — тота башлыйлар. Әйтик, кыйнашалар, кеше әйберенә кул сузалар.

Габделбәр ашаудан тукталып, башын иде. Исмәгыйль карт исә, малайның авырткан җиренә кагылуын сизеп, хатасын төзәтергә ашыкты:

— Тартынмый гына тамагыңны туйдыр син. Кунак иткәндә ашау — урлашу түгел ул. Андый чакта сыйлануның һич ояты юк. Нәрсә сөйли идем әле? Әйе. Гакыллы баш һич алай итмәс, көченә дөрес юл бирер. Укырга форсат юк икән, бүген иң дөрес юл — авылдашларыңа булышу. Колхозда беләгеңә күрә эше табылмый калмас, председатель Вәгыйз абыең белән үзем сөйләшермен. Шулай. Хезмәтнең тире ачы, җимеше татлы була аның. Күңел биреп хезмәт итсәң, тамагың да туяр, ас-башың бөтенәер, үзең кеше буласың. Эш күрсәткән ирне ил онытмас диләр. Вәт...

Бакчачы картның киңәше бик ярады Габделбәргә. Шул вакыйгадан соң «Уңыш» колхозында кулыннан килгәнчә эшләде Габделбәр. Авыл халкының кайгы-шатлыгын уртаклашып яшәде. Зәй-Каратайлылар хезмәтчел халык. Аларның эшчәнлеге аркасында «Уңыш» колхозы авыр сугыш елларында да өшәнмәде, Татарстандагы алдынгы, бай колхозларның берсе булып калды, «миллионер колхоз» дигән аты чыкты. Әнә шул мактаулы, уңган, сер бирмәс колхозчылар сөеп үстерделәр аны. Иң мөһиме — хезмәттән ямь табарга, эшкә күңел куярга өйрәттеләр.

* * *

Габделбәр теше-тырнагы белән җиргә ябышып ятучы авылдашларын, язларын шомырт чәчәкләренә төренеп, купшы таллар арасыннан агып яткан Каратай елгасын, айлы төннәре белән тыныч авыл кичен калдырып армиягә китте. Әйләнеп кайткач, аларның байтагын тапмады. Каратай суы һәм Зәй буендагы бөдрә таллар, тау битләрендәге миләшләр, чытырманлыклар каядыр чигенеп, бу яклар өчен ят булган корыч манараларга, пудра ягынган резервуарларга урын биргәннәр. Тау түбәкләренә тынгысыз буровойлар менеп басканнар. Кичләрен авыл өстендә, ерак басуларда, Зәй күзгесендә йолдызларны көнләштереп, электр лампочкалары җемелди. Урман-кырларны, үзән-каенлыкларны ярып асфальт юллар, югары вольтлы электр линияләре, өстә калган кызыл балчыгы белән «без монда» дип кычкырып ятучы нефтепроводлар үткәрелгән. Зәй буенда яңа калалар, зур-зур поселоклар үсеп чыккан. Машина дигәнең чебен-черкидән дә күбәеп киткән.

Авылда халык бермә-бер ишәйгән. Йортларның берсеннән йомшак рус сөйләме ишетелсә, икенчесендә думбра кыллары чыңлый, татарларга аңлаешлы әзербайҗан сүзләре яңгырап китә.

Авылдашларның да байтагын алыштырып куйганнар диярсең. Элегрәк телләреннән «буразна» белән «ферма» сүзләре төшмәгән Зәй-Каратай егетләре «буровой» да «нефть» дип кенә җибәрәләр. Байтагы инде әнә шул «ду» кубып нефть чыгаручылар белән аралашып та беткәннәр. Эштән кайткач та, мазутлы киемнәрен салмыйча, «мин кем» дигәндәй горурланып йөриләр.

Шулар бары бергә кичәге сержантның күңелен иләсләндереп җибәрделәр. Кунак булып озак йөрмәстән, ул чагында Лениногорск якларында бердәнбер булган промыселның җитәкчеләре янына килде. Шамдәй егетләрнең кирәк чагы иде. Шулай да мондагы абзыйлар, иң элек, килүченең буйсынына түгел, машина чамасын белүенә, электр серләре белән танышлыгына карадылар. Габделбәрнең танкист булуын, электр тирәсендә дә төшеп калганнардан түгеллеген белеп алгач, күтәреп йөртердәй итенделәр...

Писмән, Зәй-Каратай һәм Карабаш яклырында бораулау эшләренең тәмам кызган вакыты. Бораулаучылар скважиналарны берәмләп түгел, дистәләп тапшыралар. Мондый чакта иң әһәмиятлесе — скважиналарны үзләштерү, хәзинә юлларын тизрәк чистартып, аларны илнең кан тамырына тапшыру. Габделбәрне дә скважиналарны үзләштерү бригадасына билгеләделәр. 1952 елның шул көненнән башланды инде егетнең тынгысыз хезмәте. Машиналар да менә алмаган тау башларына җиһазларны күтәреп ташу дисеңме, суы ташыган чагында Зәй аша йөзеп чыгу, яисә шундагы чытырман әрәмәлекләр аша яңа скважиналарга юл салу дисеңме, нефть хәзинәсен һаман юллый алмый скважиналар янында кунып-төнеп яту дисеңме — берсе дә калмады. Аның каравы үзләштерүчеләр үткән юлларда фонтаннар симфониясе көчәя, үсә торды. Хөкүмәтебезнең зур бүләге — «Почет билгесе» орденын шушы елларда алды инде Габделбәр.

Скважиналар, яңгырдан соң калкып чыккан гөмбәләрдәй, күзгә күренеп ишәйделәр. Инде Габделбәр дә, үзләштерү бригадасыннан китеп, күңеле тарткан Зәй буйларында — Карабаш промыселында калды.

Нефтьчеләр аның киң күңелле, эшчән, теләсә кайсы минутта ярдәмгә килүче чын дус икәнен күптән беләләр иде. Шунлыктан егетнең өлкән оператор итеп билгеләнүенә биш куллап куаныштылар.

* * *

«Лениногорскнефть» идарәсендә скважиналарны автоматлаштыруның иң беренче «САТ-1» системасы Габделбәр эшли торган участокта монтажланды. Ләкин идарәнең автоматлаштыру цехы эшне җиренә җиткермәде. Цех тагын да эффектлырак булып күренгән системалар белән мавыгып китте — 1 нче промысел скважиналарын радиодиспетчерлаштыруга һәм катламга су кудыра торган куст-насос станцияләрен автоматлаштыруга бөтен көчен бирде. Карабаш промыселындагы «САТ-1» системасы онытылып калды. Аны эшкә яраксыз, уңышсыз эксперимент, дип ташларга җыенучылар да күренгәли башлады. Чөнки бу система өстәмә мәшәкатьләр тудыра, җәен, азмаз яшенле көннәр булса да идарә итү линиясенең узеллары янып чыга. Аларны төзәтүгә байтак кына көч һәм вакыт таләп итеlә иде.

Әмма Габделбәр белән мастер Пилипенко башка фикердә булдылар. Рационализаторучы-оператор Габдрахман Миңлебаев, нефть осталары Әфләтунов һәм башкалар да автоматларны ходка җибәрү ягында иделәр. Бервакыт, үзара сөйләшеп утырганда, мастер мәсьәләне кабыргасы белән куйды.

— Сезнеңчә ничек, автоматны аякка бастыра алабызмы? — диде ул янындагыларга.

— Теләсәк, булдырабыз, — диде Миңлебаев, — тик моның өчен дүрт-биш кешене бер-ике айга башка эшләрдән азат итәргә кирәк.

— Юк, бу кустарьчылык була, — дип сикереп чыкты Габделбәр.— Эшне кем башлаган, шул ахырына да җиткерергә тиеш. Без аларга булышырбыз.

Мастер да Габделбәр сүзен җөпләде.

— Шулай дөресрәк булыр, — диде ул. — Система автоматлаштыру цехы балансында тора ич. Җитәкчеләр аны безгә чын хуҗаларча тапшырсыннар.

— Ике ел маташтылар инде. Барыбер...— дип сукранды кемдер.

Таралышканда мастер «беразга кал» дип Габделбәр Сәетгәрәевкә ым какты.

— Ә син бу системаны списать итәргә җыенуларын беләсеңме? — диде ул, борчылып. — Юк шул менә. Автоматлаштыру цехы кешеләре бирегә бүтән килмәячәкләр. Нефтепромысел идарәсендәгеләр дә шул фикердә. Безгә цехның партия оешмасына мөрәҗәгать итүдән башка чара калмый. Бәлки, файдасы тияр.

— Алай да ярый, — диде Габделбәр, — ятып калганчы, атып кал.

...Автоматчылар кунакларны ачык йөз белән каршыладылар. Теге яки бу цехта мөһим мәсьәләләр хәл ителгәндә күршеләрдән дә вәкилләр чакыру «Лениногорскнефть» идарәсенең партия-профсоюз оешмаларында гадәткә кереп киткән иде. Шулай да сагаеп калдылар. Бу юлы нефть чыгаручылар чакырусыз һәм көтмәгәндә килеп керделәр бит. Җитмәсә, сүз дә алар промыселына кагылмый, беренче промыселны автоматлаштыру мәсьәләләре тикшерелә.

Габделбәр белән Пилипенко тын гына утырдылар. Мондый шартларда үз фикереңне яклауның никадәр кыен булачагын сизенәләр иде алар. Шулай да бәхәскә әзерләнеп тордылар.

Көн тәртибендәге мәсьәлә тикшерелеп беткәч, цех начальнигы Әхтәм Шәйхуллин, аларга таба борылып:

— Бәлки, кунакларның әйтәсе сүзе бардыр, — дип куйды.

— Бар, — дип урыныннан кузгалды Пилипенко, — һәм сүз зурдан булыр. Сез хәзер генә скважиналарны автоматлаштыруның яңа системасы турында бәхәсләштегез. Ә безнең промыселдагы система турында оныттыгыз. Шуны исегезгә төшерергә иде исәп.

— Кирәге бармы икән? — диде Шәйхуллин. — Иске нәрсә. Без аңа борылып кайтмаска булдык.

— Нефтьчеләр исә башка фикердә, — дип сүзгә кушылды Габделбәр. — Автоматларга тотылган акчаны артыгы белән кайтарып алырга кирәк. Промысел егетләре системаның эшләячәгенә ышаналар. Тик сездән ярдәм булсын.

— Нинди ярдәм? — дип бүлдерде Шәйхуллин.

— Берәр айга өч кеше бирегез, — диде Пилипенко. — Калган ягын үзебез карарбыз.

— Ул кешеләрне каян алырга соң?

— Анысы инде сезнең эш.

Җыелыш кабат кызып китте. Сүзгә яңадан-яңа кешеләр кушылды. Күпчелек бу мәсьәләне башка вакытка, Зәй-Каратайда диспетчерлаштыру эшләре беткәч, карау ягында иделәр. Ләкин промысел вәкилләре үз сүзләрендә нык тордылар. Цех начальнигы бәхәсне тәмамларга ашыкты.

— Яхшы, — диде ул. — Берничә көннән ике кеше барыр.

Системаның яңадан тууы әнә шул шаушулы вакыйгадан соң башланды. Иң элек аңа 40 скважина ялгадылар. Аннан участоктагы скважиналарның барысы да диярлек тоташтырылды. Диспетчерлык пунктының эшен көйләп җибәрделәр. Габделбәрләр, рационаллаштыручы Миңлебаев, Әфләтуновлар системаның эшләү мөмкинлекләрен арттыру турында уйлыйлар иде инде.

Хәзер операторларның куллары бушады. Участок инде яңа скважиналарны өстәмә эшче көчләрдән башка гына кабул итеп ала башлады. Егетләр элеккеге кебек өчәр-дүртәр скважинага түгел, һәрберсе 7—10 скважинага хезмәт күрсәтүгә керештеләр.

Автоматларның җайга салынуын күргәч, промысел җитәкчеләре дә ярдәмнәрен арттырдылар. Ниһаять, 5 нче промыселның мастер Пилипенко участогы Татарстанда беренче булып бер сменалы эшкә күчте.

Төнге сменадан бушаган операторлардан диспетчерлык пункты каршында ремонт группасы оештырылды. Бу — бригаданың төп көченә әверелде. Ремонтчылар скважиналарның туктаусыз эшләвен тәэмин итү белән бергә, линияләрне, җайланмаларны алдан әзерләп тордылар, башка төр перспектив мәсьәләләрне хәл иттеләр. Бу исә нефть чыгаруны киләчәктә тагын да арттыруга китерде. Хезмәтне автоматлаштыру һәм механикалаштыру ягыннан участок республикада беренче урынга чыкты. Аның тәҗрибәсен өйрәнергә күрше Башкортстаннан һәм Куйбышев өлкәсеннән әледән-әле килеп торалар.

Нефть чыгаруда яңалыклар, резервлар эзли-эзли, Габделбәр җитәкчелегендәге коллектив үсә, ныгый барды. Нефтьчеләрнең байтагы, дөньяга шуның өчен генә килгәндәй, операторлык хезмәтенә ансат өйрәнделәр. Кайсылары исә, мәшәкатьле эшнең җаена төшә алмый йөрделәр. Демобилизацияләнгән лейтенант Марат Сәфәров белән шулай булды. Тәмам аптырады аның белән Габделбәр. Теләк тә бар кебек егеттә. Ләкин эшкә күңел куеп җиткерми. Бәлки, эшен ошатып җиткермидер. Мастер белән киңәшеп, Маратка зуррак поручение бирергә булдылар. Электриклар курсына җибәреп укытып кайтардылар да, алты скважинага хуҗа итеп билгеләделәр.

— Монысын булдыра алсаң, унбиш скважина бирербез, — диделәр аңарга.

Иптәшләренең игътибары Сәфәровны үзгәртеп җибәрде. Ул уртак эш өчен янып-көеп йөри башлады. Шулай да тәҗрибәле Габделбәрнең янында булуы һәрчак кирәк аңа.

Бервакыт Марат әлсерәп, арып-талып үзәк культбудкага кайтып егылды. Эш көне тәмамланган чак, инде биродә кемне дә булса очратырмын дип өметләнмәгән иде. Өстенә чиста киемнәрен киеп маташучы Сөетгәрәевне күргәч:

— Мерниклардан нефть акмый, — дип зарланырга тотынды ул. — Өч скважинаны төнлеккә ябып калдырдым.

— Чарасын тапкансың икән, — диде Габделбәр, кашларын җыерып. — Мәшәкатьләнеп тормагансың.

— Сынап карамаган әмәлем калмады инде, — дип акланды Марат, — көнозын шулар янында маташтым.

— Калмады дисең, алайса, — Габделбәр әле генә салып куйган эш киемнәренә үрелде, — барып карыйк әле.

Марат юл буе үзагымны булдыру өчен ниләр эшләве турында сөйләп барды. Газ ташлагычларны тикшерә-тикшерә байтак бардылар алар. Мерниклар янында озак-

озак тукталып, нефть килүен көттеләр. Әмма ул, туңгандай, бер урында тора иде. Төп җибәрү япкычларын ача-ача, алар үз дигәннәренә ирештеләр. Нефть юл алды, мерниклар бушый башлады.

Алар бөтен скважиналарны җибәреп, культбудкага кайтканда төн уртасы җиткән иде инде. Ләкин мәшәкатьле көн моның белән тәмамланмады әле. Карабашка кадәр 15 километрлап араны җәяү тәпиләделәр. Зур эш башкарылды ул көнне. Әмма бу турыда участокта да, промыселда да берәү дә белмәде. Иртән эш башлануга Габделбәр участокта иде инде.

Иптәшләре белән мөнәсәбаттә намуслылык, эшкә чын хуҗаларча иҗади караш коммунист Сәетгәраевнең төп сыйфатларыннан берсе. Нефтьчеләрнең Габделбәргә тиңләшергә тырышулары юкка гына түгел шул. Теге яки бу эшне ансатлаштыруга, җайга салуга багышланган дистәләрчә рационаллаштыру тәкъдимнәре кертте ул. Татарстанда беренче булып нефтьне салкын килеш сусызландыру чарасын да ул уйлап тапты.

Сәетгәраевнең бу эше күпләрне кызыксындырды. Хәзер «Иркеннефть» идарәсенең фәнни-тикшеренү лабораториясе аны тагын да камилләштерү өстендә эшли.

...Инде хәзер Василий Дмитриевич Пилипенконың участок начальнигы булып, ә Габделбәрнең мастерлыкка күтәрелүләренә һәм 5 нче промыселның «Иркеннефть» идарәсенең икенче промыселына әйләнүенә дә байтак вакытлар үтте. Алар коллективы «кара алтын»ны иң күп бирүче буларак, промыселда гына түгел, бөтен Татарстанда дан тота...

...Төн уртасы җитеп кила иде инде. Габделбәр папирос чыгарып кабызды да өенә таба атлады. Әйе, тәүлек узды, ләкин Сәетгәраевнең эше бетеп җитмәгән иде әле. Иртәне нәкъ шуннан, тәмамланмаган эшеннән башлап җибәрергә ниятләде ул. Кичкә таба булган иде ул хәл.

Габделбәр участоктан кайтып, бүлмәсенә керергә өлгермәде, үзен елкән яшьләрдәге бер агай туктатты. Карабаш нефтьчеләренә таныш кеше ул, Әхъдәс Әминов. Габделбәр белгәннән бирле поселокта участок милиционеры булып эшләде. Соңгы вакытта ни сәбәпледер формасын граждански костюмга алыштырган иде.

Кул биреп күрешкәч, бүлмәсенә чакырды аны Габделбәр. Әминов утырды, шактый гына тын торды. Аннан соң гына:

— Эшсез йөрим бит әле, Габделбәр Бариевич, — дип куйды. Аның тавышында ук ниндидер дулкынлану, ачыну сизенгәч, Сәетгәраев иплән кенә сораша башлады.

Әминовның да бала чагы авыр елларга туры килгән. Уку дигән нәрсә юньләп эләкмәгән. Шулай да үзенең тырышлыгы белән шактый гына үсә алган. Дөньяны гөлгә бизәргә, аны бөтен начарлыклардан азат итәргә омтылган аның күңеле. Шул теләк аны милиция эшенә алып килгән. Әмма заманалар үзгәргән саен белемсезлегенең чабудан тартуын ныграк сизенгән ул. Хәзерге чорда милиция работнигы өчен чын педагог булу, марксистик-ленинчыл тәгълиматны тирән белү шарт икәнен тәмам аңлаган. Шуңа газапланып озак йөргән һәм, ниһаять, эштән чыгаруларын сорап гариза биргән. Аның үтенечена каршы килмәгәннәр. Ә хәзер «Иркеннефть» идарәсенең автохуҗалыгына слесарь булып килмәкче икән. Ләкин нияте тормышка ашмаган. Салкын канлы, игътибарсыз начальникка туры килгән Әминов.

Автохуҗалыкка барып, менә шул мәсьәләне хәл итәргә кирәк иде Габделбәргә.

...Ул килгәндә, тынгысыз шоферлар ашкынулы юлларга чыгарга өлгермәгәннәр иде әле. Габделбәр начальник кабинетына узды һәм кыска гына итеп йомышын сөйләп бирде. Чыннан да, үз сүзле кеше икән бу Горбашкин. Башта «лимит юк» та, «фәлән дә төгән» дип сөйләнде, төрле сәбәпләр эзләп маташты. Тик Габделбәрне бик ансат урап уза алмасын аңлагач кына, картасын ачып салды:

— Кирәкми, алмыйм мин аны, — диде ул. — Теге чакны да дүрт-биш шоферны унбиш суткага утыртты. Шуның аркасында гына коллективта хезмәт дисциплинасы түбән булып күренде, премиясез калдык.

Габделбәргә бу кешенең балаларча хөкем йөртүе гаҗәп тоелды.

— Соң ул мәсьәләдә кем гаепле? Милиционермы? Әллә коллективы белән эшләмәгән җитәкчеме? — диде ул, көлемсерәп. Горбашкинга озак кына мораль укырга туры килде. Ләкин тегенең үз туксаны туксан, һаман үзенекен сөйли:

— Алмыйм. Өйдәге бөтен чүпне урамга ташып бетерер.

Горбашкинны автомашинага утыртып, Лениногорскига «Иркеннефть» идарәсенә барырга туры килде. Әминовны эшкә алу турында гаризага резолюция салынгач кына, Карабашка борылды Габделбәр.

Кояш төшлеккә күтәрелгәндә нефть мастерының җитез газигы таныш үзәннәрдән чаба иде инде. Юл уңаена ерак рәтләрнең

берсенә — Үзбәк авылы янына барып чыгарга булды ул.

Зур юлдан читтә, начальство күзе сирәгрәк төшә торган участок бу. Шунлыктан, һәр скважинада диярлек булырга, операторлар белән сөйләшеп, күрсәтмәләр бирергә туры килде.

Инде китәргә генә дигәндә, аны нефтьче-оператор Зәбир Максутов туктатты:

— Яныгызга барырга идем әле, Габделбәр абый, — диде ул, үртәлгән тавыш белән. — Китәм мин моннан. Өлкән оператор яшәргә ирек бирми. Гел бәйләнә, иң кыен эшләргә куша.

Егетнең рәнҗегәне әллә каян сизелеп тора. Чыннан да, нидер булган болар арасында.

Габделбәр Максутовны күптән белә. Промыселда ун елга якын эшли ул. Өченче разрядлы операторга кадәр күтәрелде. Эшнең остасы булып килә. Бу гади авыл малаен нефть чыгару серләренә өйрәтү өчен күпме көч куелган. Биредән китеп кая бара да, кемгә күпме файда китерә. Барын да өр-яңадан башларга кирәк ич. Үзенә дә зыян, җәмгыятькә дә.

Максутовның иңенә кулын салып, әнә шуларны сөйләп бирде Габделбәр. Өлкән операторны кисәтәчәген әйтте, егетне тынычландырып, урынында калырга күндерде.

Автомобиль асфальт юлга чыгып, Карабашка борылгач та, Максутов турында уйланудан тукталмады ул. Китәм, имеш. Күңел ярсулы чакта үлчәмичә әйтелә шул. Ә соңыннан терсәкне тешләп булмый. Бервакыт әле өлкән оператор булып эшләгән чагында, ул үзе дә утырган ботагына балта күтәрмәдемени?

Скважиналарда чисталык өчен көрәшнең иң кызу чокнары иде. Габделбәр иртүк егетләргә эш бүлеп бирде дә юл буендагы ике көпшәле скважинада калды. Җиңнәрен сызганып трап-мерникларны юарга керешә. Шул вакыт, гөнаһ шомлыгына каршы дигәндәй, промыселның өлкән инженеры Нәҗип Байков килеп чыкты.

— Өлкән операторга трап юудан башка эш калмаган икән, — диде ул, әче көлеп. Шуннан китте кызып. Имеш, син оештыра белмисең. Имеш, син өлкән оператор түгел. Промыселдан куарга гына сине!

Инженерның болай котырынуы тикмәгә генә түгел иде. Берничә ай элек уздырылган җыелышларның берсендә үзен Сәетгәрәев тәнкыйтьләп чыкканнан бирле шулай бәйләнә иде ул. Габделбәрнең һәр адымыннан чи эзли, аны кимсетергә маташа. Ул көнге кыланмышы аеруча тәэсир итте Габделбәргә. Шул ук кичне эштән алуларын сорап гариза язды.

Промысел мөдире Николай Николаевич Ким үтенечне өстәл тартмасына салып куйды да Сәетгәрәев янына килеп утырды һәм гадәттәге йомшак, ләкин ышанычлы тавышы белән сөйләп китте. Сәетгәрәевнең үпкәрәнҗүләре бөтенләй юкка чыкты.

Китмәде, калды промыселда Габделбәр һәм зур хатаны ясамый калды. Әйе, әнә шулай анда-монда бәрелми-сугылмый бер урында тир түгеп иҗади эшләве аны — гади игенче улын — дәүләт эшлеклесенә кадәр күтәрде. Аны гынамы?.. Оператор Вәзыйх Арсланов, Наил Шәрифуллин һәм Әнәс Мөхсиновлар инженер дипломнары алдылар, җир асты ремонты мастеры дәрәҗәсенә күтәрелделәр. Гади нефтьче Фәхрислам Ямалетдинов — Габдрахман авыл Советы, Закуан Рәкыйпов — Карабаш поселок Советы депутатлары булып сайландылар. Алар участогында гына дүрт депутат хәзер! Дөньяны ямьгә бизәүче хезмәт булмаса, әнә шулай үсәр идеме соң кешеләр? Эш күрсәткән ирләрне ил онытмый шул.

●



*Мәхмүт Максуд*

# КАЙБЕР ИСТӘЛЕКЛӘР

*Бөек Октябрь социалистик революциясенең җиңүе татар әдәбияты мәйданына яңа яшь талантларны китерде. Һади Такташ, Нәкый Исәнбәт, Муса Җәлил, Гадел Кутуй, Хәсән Туфан кебек язучылар әнә шул вакытта күтәрелде. Алар арасында Мәхмүт Максуд та бар иде. Аның да бөтен тормышы, бөтен әдәби эшчәнлеге, бу юлдагы барлык хезмәте Бөек Октябрь җиңешләре, коммунизм өчен барган бөек көрәш белән бәйләнгән иде.*

*Язучының шәхси архивында аның автобиографиясе саклангән. Гөлсем ханым Максутова-Җиһаншина бу кыйммәтле документны журналга тапшырды. Без аның түбәндә тулы текстын урнаштырабыз.*

* * *

Мин узган гасырның соңгы елында туып, шушы гасырның беренче елында дөньяда тәпи йөри башлаганмын.

Биш-алты яшемдә үк хәреф таныдым. Унынчы яшемдә әти мине үзебезнең Югары Кибәхуҗадан 40 чакрымдагы Кышкар мәдрәсәсенә илтеп куйды.

Шунда мин, бидан-бик бел дип, сарыф укыдым, аннары нәху укыдым. Әнмүзәҗ һәм Шәрхе Габдулланы ятладым. Өч ел бугай, Исагуҗи (манфыйкъ) укыдым, һәм менә хәзер генә, беренче тапкыр буларак, башыма мондый уй килде: суфизм алымнарын үзләштереп, ярсып-ярсып моназара кылышкан 12 яшьлек сабый бала акылыннан язарга тиеш иде бит. Юк, бөтенләй үк язмаганмын. Күрәсең, табигатьнең кушуы буенча, кеше акылсыз түгел, бәлки акыллы булырга тиештер.

Әти «Дин вә мәгыйшәт» журналы белән «Йолдыз» газетасы ала иде. Өебездә һәм авылыбызда вакытлы матбугат шуның белән чикләнә иде. Әдәби әсәрләр бөтенләй юк иде. Бервакыт мин Шыңардан ниндидер бер китап алып кайттым. Ничектер әти аны күрде дә янып торган мичкә ыргытты.

Шулай да ул мине саф мөселман килеш саклап кала алмады. Саурыш авылында җәдит кардәшләребез бар иде, аларда шул елларда Казанда чыга барган яңа әдәбиятның бөтенесе диярлек була иде. Мин бик кече яшьтән, 8—9 дан ук, әдәбият укуга бирелдем, Тукайның күп кенә шигырьләрен белә идем. Фатих Әмирхан әсәрләрен аеруча ярата идем. Галимҗан Ибраһимовның «Табигать балалары»н соклануп, онытылып укыганымны хәтерлим.

1914 елда үзем дә «каләм сыный» башладым. «Җиләк җыйганда» дигән бер хикәя яздым (ярты табак чамасы идедер). Казанга барганда аны Кәримовлар типогра-

фиясенә алып кердем. Көлделәрме, юкмы, хәтерләмим, «Ак юл»га барырга куштылар. Ял көне иде бугай, миңа беренче әсәремне редакциягә тапшырмыйча, Кибәхуҗага кайтып китәргә туры килде.

Әтием, бер әсәремдә әйтелүенчә, «аз һәм үз сүзле, эре һәм кире табигатьле» кеше иде. Ләкин мин кайчакта бераз хәйләгә бирелә идем. Мәсәлән, бервакыт минем яңачарак киенәсем килде. Әти, мин озын җиңле камзул тектерергә уйлаган идем, нишлим икән? — дидем. Ярый, бик яхшы, — диде әти. Ул үзе кыска җиңле камзул кия иде, озын җиңленә бик хуп күрде бугай? Шулай итеп мин беркөнне тегүчедән (безнең авыл — тегүчеләр авылы иде) менә дигән тужурка киеп кайттым. Әти ачуланмады, әмма көлгәнен дә хәтерләмим.

Мәсьәлә тужуркада түгел иде, белемле кеше буласы килә иде. Моны әтигә әйтү мөмкин түгел. Фәннең кайсысыдыр кешене дәһри ясый, ди ул. Хисаптырмы, җәгъраффиядерме, тарихтырмы, — анысын белмим, — дип өсти. Билгеле, ул минем җәдитчә укуыма риза булачак түгел.

Мин өйдән качып китү уена килдем. 1914 елда җәй көне Оренбургка Хөсәения мәдрәсәсенә китәргә җыендым. Ләкин шул вакыт башланган беренче бөтендөнья сугышы минем планнарымны җимерде.

Кышкар мәдрәсәсендә яз көне, белмим ни сәбәпледер, һәр елны бер-ике ай буе Фарсиз уку гадәте бар иде. Ягъни без үлгән кешенең малын бүләргә өйрәнә идек. 1915 елның язында мин әтигә Фарсизны яхшы белүемне сөйләп, Казанга китеп русча укырга рөхсәт алдым. Аңа кадәр дә бер-ике ел үзлегемнән, һади Максудиның «Русстап» дигән дәреслеге буенча укыган идем. Шулай ук Кышкарда русско-татарская школа да бар иде. Мин Габдулла учительгә бераз укырга йөрдемме, әллә йөрү теләге бик көчле булганга күрә, «йөрдем»гә әйләнеп хәтердә калганмы, ачык әйтә алмыйм. һәрхәлдә, мәдрәсәнең үзендә үземнән өлкәнрәк шәкерт Әтнә Абдулдан русча өйрәнгәнемне хәтерлим. Аның үзенең белүе ни дәрәҗәдә булгандыр, һәм ул миңа нинди дәреслекләр буенча укыткандыр, анысын әйтә алмыйм.

1915 елның язында мин Казанда (расход күплеге сәбәпледер) бер-ике айдан артык укымадым. Яңадан авылыбызга кайттым. Ләкин шул елны мин гаҗәп зур бер җиңүгә ирештем. Әти мине Арчадагы ике класслы рус-татар мәктәбенә укырга җибәрде. Дөнья белеме турында әтинең фикере һич тә үзгәрмәгән иде, ләкин мәсьәлә менә нәрсәдә: шунда ике еллык мәктәп бетерсәң, муллалыкка указ алу өчен русчадан имтихан бирәсе калмый. Эше бетеп торсын дип уйлады әти, ул мәктәптә мулла малайлары байтак кына укый иде, һәм учитель Ибраһим абый эшне үзе өчен дә, укучылар өчен дә җайлы итеп юлга салган иде: без аңа аена икешәр сум өстәмә акча түлибез, шуның бәрабәренә ул ике классны бер кыш эчендә тәмам иттерә, ягъни мәктәпне тәмам итү турында яз көне, әлбәттә, кәгазь бирә. Указ алу турында түгел, белем алу турында уйлаганга күрә мин бик яхшы укыдым. Пушкин, Лермонтов, Толстой әсәрләрен элек тәрҗемәдә генә укысам, хәзер инде рус телендә укып ләззәт ала башладым. Яз көне имтихан комиссиясендә Арчаның бик зур ак сакаллы врачы катнашты. Миңа мактау кәгазе бирделәр һәм минем өчен бик кадерле бүләк — Тургеневның «Записки охотника» исемле әсәрен бирделәр. Шуңа күрәдер инде, Тургенев минем иң яраткан язучыларымның берсе булды, әле дә шулай.

Арчадан майда кайтканмындыр. Июньдә инде мин өйдән китәргә җыендым. Урманга утынга барганда күзгә чыбык бәрелгән иде, Арчага, врачка баруны тиеш таптым. Арча базарына баручы яшь крестьян Низами белән сүз куештык. Өйдәгеләргә күрсәтмичә, аңа бер төен әйбер илтеп куйдым. Матур таң беленер алдыннан без юлга чыктык.

Шул китү минем туган өй белән бәхилләшүем булды. Табигый, мин Арчада врачка күренеп йөрмәдем. Малмыж ягына сәфәр иттем. Конфет алып кайтырга дип әни миңа акча биреп җибәргән иде, ул мескен мине көткән, конфет көтеп чәен дә бик озак эчми торган.

Мин кайтмадым, киттем. Балтачка хәтле атта бардым. Тугым төягән арбада биектә тугым эченә утырып бару бик күңелле булды. Аннары күршедәге Сосна авылына шәригем Мәзһар янына кердем. Өйдә туры килмәде. Төенемне анда калдырып, җәяүләп кенә Малмыжга китеп бардым.

Барысын да озын итеп язарга вакытым юк әле. Картая төшкәч, озынрак язарга да ярар. Ә хәзергә эшем күп! Һәм моны мин санаторийда, врач эшләргә рөхсәт итмәгәнгә күрә генә язам.

Малмыжда мин ике ай хәзерләнеп, высше-начальное училищеның өченче классына кердем. Имтихан бирә алмасам, эш харап иде, яшем зур булганга күрә, мине икенче класска алмаячаклар иде. Имтиханны бик яхшы бирдем. Тургеневның бер нәсере буенча (чыпчык турында) сочинение яздым. Арифметика, хәтта геометрия дә уңышлы үтте.

Малмыжда укыган елларымны сагынып искә алам. 15 — 16 дагы яшүсмерләр бик шук булалар бит. Кыш көне читек һәм кәвеш киеп йөргәндә, минем кыяфәтем шактый көлке булгандыр. Ә шулай да миннән берәрсенең көлгәнен һич тә хәтерләмим. Гомумән, милләтчеләр кабарткан тупас милли тойгылар, чит милләтне яратмаулар простой кешеләргә бөтенләй ят нәрсә ул. Моңа мин соңыннан гражданнар сугышы чорында Армиядә һәм аннары Мәскәү университетында укыганда тагы да ныграк ышана төштем.

Малмыжда укытучыларның барысы да мине яраталар иде. Мин аларны әле дә истә тотам. Тарих һәм рус теле укытучысы Вячеслав Иванович Пустовойтовны аерусча тирән бер хөрмәт белән искә алам. Ул миңа укырга китаплар бирә иде. Кайбер сочинениеләремне класста укый иде. Бер көнне ул минем турыда класста: «зародыш будущего писателя», диде. Куандым һәм кызардым.

Февральне дә, Октябрьны да мин, билгеле, бөтенләй политик хәзерлексез килеш каршы алдым. Февральдән соң ярлыларны да, мөгаллимнәрне дә, муллаларны да тырышырга өндәп, шигырь яздым.

1917 елның көзендә без Малмыжда мөселман укучылар союзы төзедек, «Яшьлек көннәре» дигән кулъязма журнал чыгара башладык. Редакторы мин идем. Сәгыйт Фәйзуллин, Габдулла Хәбиб, Нәкый Бәхтияровлар катнашалар иде.

1917 елның җәендә переписьта эшләдем. Тирә-юньдә татар авыллары күп булу сәбәпле, кадерем зур булды. Өс-баш бөтенәйде.

Ике кыш эчендә мин бик күп әдәбият укыдым. Вячеслав Иванович ярдәмендә рус әдәбиятын гына түгел, дөнья классикларын да укый башладым, мәсәлән, Гюгоның кайбер калын романнарын укып чыктым.

Рәхмәт сиңа, хөрмәтле укытучым!

Малмыжда яшәүче педагог һәм язучы Габделхак Динмөхәммәтнең Галимҗан Ибраһимовка тәкъдим итүе буенча, мин 1918 елның июнь башында Мәскәүгә килеп, «Чулпан» редакциясендә сотрудник тәрҗемәче булып эшли башладым. Көн дә «Правда» уку минем политик белем дәрәҗәмне бик тиз күтәрде. Газетада эшләү белән бергә, мин бик актив рәвештә төрле брошюралар да тәрҗемә итә башладым. Шул җәйне минем тәрҗемәдә «Мәүла Хафиз», русчасы «Мулый Гафид персиядская, (легенда, посвященная рабоче-крестьянской Красной Армии, авторы күрсәтелмәгән)» басылып чыкты. Ахырында Якуб Малышевның ике шигыре дә кушылган бу әсәр безнең совет матур әдәбиятыбызда китап итеп чыгарылган беренче тәрҗемәдер дип уйлыйм.

Менә шул вакыттан бирле мин татар совет матбугатында эшлим.

1918 елның ноябрь башында «Чулпан»да үземнең беренче әсәрем — «Бәйрәм җитә» басылып чыкты.

1919 елның февраль башында мин яңадан Малмыжга кайттым, «Ярлылар тавышы» газетасында эшли башладым. Шигырьләр яздым. Комсомолга кердем. Уком члены итеп сайландым һәм май башында, башка комсомолецлар белән бергә, үзем теләп фронтка китеп бардым.

* * *

Биографиямнең дәвамын әсәрләремнән укырга мөмкин, хәзер аерым язып торуны тиеш тапмыйм.

Яза башлавыңа кем сәбәпче булды? дигән сорау биргәлиләр. Минемчә, моның иң дөрес җавабы:

— Тукай сәбәпче булгандыр, Тукай димләүче, өндәүче булгандыр.

Мулла өенә музыка коралы кермәсә дә (хәер, мин кубыз уйнарга өйрәндем, әтидән яшереп тальян гармонь сатып алдым, аны күрше Хупҗамал түтиләргә кертеп куйдым), авыл егетләренең һәм кызларының җырлары, Тукай моңы белән бергә кушылып, минем каныма сеңгән. Демократ, прогрессив татар язучыларының әсәрләре минем яшь йөрәгемдә халыкка хезмәт итү дәртен уятты, акыл җырчысы Пушкин минем юлымны яктыртты. Революциядән соң Ленин комсомолы сүнмәс ялкын дәрләтте.

Тукай, Фатих Әмирхан һәм Галимҗан Ибраһимов минем тел остазым булдылар. Редакциядә беренче тәрҗемәләремне Галимҗан абый карап үткәрде.

Революциянең беренче елларында матбугат кадрларыбыз бик аз иде. Күп кенә язучылар берьюлы төрле жанрда эшләүнең сәбәпләреннән берсе шул булса кирәк.

Кичен шигырь язсаң, көндезен газета өчен хәбәрләр тәрҗемә итәргә туры килә иде. Һәм 1921 елда ук инде мин беренче рецензияләремне дә яза башладым. Барысын бергә җыеп әйткәндә, мин унсигез елдан артыграк нәшрият һәм газета-журнал редакцияләрендә эшләдем. Редактор исә, теләдеме-теләмәдеме, тәнкыйтьче дә була. Гомумән, совет язучысының, бигрәк тә коммунист язучының, тәнкыйтьче булмавы, ягъни әдәби тормышның теге яки бу мәсьәләсе һәм аерым әсәрләр турында үз фикерен матбугатта әйтмәве мөмкин түгел. Миңа да тәнкыйть өлкәсендә беркадәр эшләргә туры килде.

Шулай да жанрларның чиратлашуында дип әйтимме, үзенә бертөрле законлылык бар кебек һәм турыдан-туры тормыш таләпләре чагыладыр кебек. 1919 — 20 елларда мин комсомол ялкыны белән шигырьләр яздым. Күп еллар шигырь язмый торганнан соң, 1936—37 елларда Мәскәүдәге Студия өчен (Муса Җәлил тапшыруы буенча) «Фауст» һәм «Евгений Онегин» либреттоларын тәрҗемә иттем. Шул ук елларда Гейненың «Германия»сен дә тәрҗемә иттем. Аннары 1939—1940 елның көзендә-кышында, Көнбатыш Белоруссияне азат итү походында дивизия газетасында эшләгәндә, яңадан шигырьләр яза башладым. Газета өчен материал җыю теләге белән полктан полкка җәяү йөрергә туры килә иде. Буш вакыт күп. Ләкин юлда барган килеш (бигрәк тә инде буранлы көннәрдә) бернәрсә дә язып булмый. Менә шуннан инде зиһендә берәмләпикешәрләп шигырь строфалары төзелә башлый. Дөрес, рус телендәге солдат газетасына татарча шигырьләрнең кирәге юк, ләкин үземне, кайда гына булсам да, «Совет әдәбияты» журналының бер авторы дип исәпләргә гадәтләнгәнмен. Менә шулай итеп мин Казанга «Кара төнне җиңгән кояш турында»ны җибәрдем. Мусаның Союзда председатель вакыты иде. Ул, бер дә иренмичә, миңа бик озын һәм бик җылы хат язды. Һәм әсәр журналда басылып чыкты.

Бөек Ватан сугышыннан соң мин бигрәк тә очерклар жанрында эшләдем. Мәскәүнең 800 еллыгына багышлап балалар өчен шигырь белән озын хикәя яздым, шулай ук тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлегемне активлаштырдым.

Пушкин һәм Лермонтов бездә сугышка кадәр үк инде шактый күп тәрҗемә ителгән булсалар да, шагыйрьләребез ни өчендер, Некрасовка бик аз мөрәҗәгать иткәннәр иде, бөтен байлык 700 юллар чамасындагы кечкенә генә бер китаптан гыйбарәт иде. Некрасов иҗатын, беренче буларак, азмы-күпме киң күләмдә татар укучыларына җиткерү шәрәфе миңа насыйп булды. Некрасов әсәрләреннән мин бөтенесе 14 мең юлдан артыграк тәрҗемә бирдем.

Кайбер иптәшләр минем шигырь язуымны да, шигырь тәрҗемә итүемне дә килешмәгәнрәк бер эшкә санамакчы булалар. Ләкин мин моны җитди дип әйтә алмыйм. Әгәр мин үземнең шигырьләрем белән укучыларны коммунизм идеяләре рухында тәрбияләү максатына азмы-күпме хезмәт итә алам икән, бу начармыни? 1943 елда миңа дошманнан азат ителгән Украина җирендә снайпер Әхтәмов белән очрашырга туры килде. Мин аңа «Совет сугышчысы» газетасының берничә номерын бирдем. Әхтәмов минем имзасыз басылган һәм өч кенә куплеттан торган «Разведчик җыры»н үзенең куен дәфтәренә күчереп алды. Сугышчының куен дәфтәре кадерле була. Минем өчен зур мөкафәт иде бу. Кайбер шигырьләремне (мәс. «Сөю турында бер сөйләшү», «Диңгез җиле», «Чәчәкләр нәрсә сөйләде», «Күгәрчен») шигъри яктан һич тә зәгыйфь дип уйламыйм. Һәм талантлы шагыйрьләребездән дә бу турыда бик җылы сүзләр ишеткәнем бар. Быел мин очраклы рәвештә бер фактны белдем. Мина

таныш булмаган композитор Шәмсетдинов 1918 елда язган бер шигыремне («Кызарып-кызарып кояш баткан чакта») музыкага салган. Тыңлаучылар яраталар, ди.

Шигырь тәрҗемәсе мәсьәләсе тагы да ачыграк. Әгәр мин татар шигырь теленең хәзерге таләпләре югарылыгында тәрҗемә бирә алам икән, бүтән шагыйрьләребезнең тәрҗемә хезмәтенә минем хезмәтемне дә өстәү культурабызның үсеше өчен файдасыз эшмени? 1947 елда бугай, нәшрият өчен язган бер рецензиясендә, Сибгат Хәким Некрасовның «Кырык тартмачылар»ын Муса Җәлил яхшы тәрҗемә иткән, дип әйткән иде. Сибгат кебек шагыйрьнең минем тәрҗемәне Мусаныкы дип кабул итүе нәрсә турындадыр сөйли булса кирәк. Гомумән Сибгат Хәким минем байтак тәрҗемәләремне редакцияләде һәм һәрвакыт яхшы карашта булды.

Бу турыда язу ваклык түгелме соң?

Түгел. Сүз бездә әле принципиаль характерда булмаган фикер йөртүләрнең һәм «хөкем чыгарулар»ның бетеп җитмәгән булуы турында бара. Хезмәтең турында җылы сүз ишетергә теләү һәркем өчен дә табигый бер нәрсә. Мин бик ачы тәнкыйтьтән дә курыкмыйм, ләкин ул нигезле булырга, аргументлы булырга тиеш.

Тәрҗемәгә «җиңел кәсеп» итеп караганым юк. Җиңел гонорар эзләгән кеше «Кола Брюньон» кебек, тәрҗемә өчен чамадан тыш авыр бер әсәргә якын да бармас. «Фауст»ны да мин бик җиңел генә эшләмәдем. Минем немецча белүем бик шәптән түгел бит. Еш кына сүзлеккә мөрәҗәгать итеп булса да, оригиналына тиешенчә төшенеп эшләдем. Шуның өстенә Холодновский һәм Брюсов тәрҗемәләрен өйрәндем, башка тәрҗемәләргә дә күз салдым.

Проза тәрҗемәсенә дә өстән генә карамыйм. Аңлашылмаган урыннар очрый икән, мин моны аңлап җиткерә алмыйм, дип әйтүдән курыкмыйм. Тәрҗемә ителә торган әсәрнең үзендә дә каршылыклы яки аңлаешсыз моментлар булырга мөмкин. Андый очракларны да ачыкларга тырышам. Мәсәлән, миңа Ажаев һәм Семушкинның үзләре белән сөйләшергә туры килде. «Ана»ны тәрҗемә иткәндә Горький музеенда консультация алдым. «Сугыш һәм тынычлык»ны тәрҗемә иткәндә Гослитиздат редакторыннан һәм Толстой музееның гыйльми секретареннан ярдәм алдым, шулай ук кайбер принципиаль мәсьәләләр һәм аерым моментлар турында академик басма редакторларыннан карт текстолог Родионов белән сөйләштем. Шагыйрь Антокольскийның да, мәрхүм Пришвинның да аерым мәсьәләләрдә миңа ярдәм күрсәткәннәре бар.

Тәрҗемәләремдә кимчелекләр бик аз булыр дип уйларлык дәрәҗәдә акылсыз кеше түгелмен. Ләкин кайбер иптәшләрнең барлык кимчелекләрне (һәм шул җөмләдән бәхәсле моментларны да, хәтта уйдырма кимчелекләрне дә) ашыгу нәтиҗәсе дип кенә аңлатырга теләүләренә кайчакта күңел рәнҗи. Дөрес, мин сугыштан соңгы елларда бик күп тәрҗемә иттем, ләкин бездә күп эшләгән өчен түгел, бәлки аз эшләгән өчен яки начар эшләгән өчен генә шелтәләргә мөмкин.

Һәрбер совет язучысы кебек, мин дә үземне бәхетле кеше саныйм. Биографиямнән зарланыр хәлем юк. Тормышка хәзерләнүемне Кышкар мәдрәсәсе шәкерте сыйфатында башлаган булсам, соңыннан яшьлек елларымда Мәскәүнең данлыклы университетында коммунист галимнәрдән белем алу бәхетенә ирештем. Үз гомеремдә ике тапкыр Ленинның сөйләгәнен тыңладым. Мәскәүнең партия оешмасы мине тәрбияләде, социализм һәм коммунизм төзү өчен көрәшче итеп чыныктырды. 1918 елда беренче тапкыр Мәскәүгә килгәч, бернichә ай татар эшчеләренең — наборщикларның гомуми торагында яшәдем. Икенче тапкыр мин Мәскәүгә 1921 елның январенда, Комсомол Үзәк Комитетының чакыруы буенча, «Яшь эшче» газетасында эшләргә килдем. Шул вакыттан бирле Мәскәүдә яшим. Һәм 1941 елда сугыш башланганга кадәр Мәскәүнең һәм Мәскәү өлкәсенең татар эшчеләре арасында (ә 1931, 1932, 1933 елларда өлкәдәге рус авылларында да) партиянең Мәскәү комитетының агитаторы, пропагандисты булып эшләдем.

Язучы буларак та мин үземнең азмы-күпме хезмәтемне агитаторлык, пропагандистлык хезмәте дип кенә аңлыйм һәм шуны үзем өчен горурлык саныйм.

Әле эшкә ашырылуны көткән иҗат планнарым байтак бар. Алар минем хыялымда, берсен-берсе этешеп-төртешеп, чиратта алдынрак урын алырга ашыгалар кебек.

Ләкин язмышның көтелмәгән шаяруларын беркем дә алдан белеп бетерә алмаган. Һәрхәлдә, мин якын еллар эчендә планнарымның кайберләрен тормышка ашыру мөмкин булыр дип өмет итәм.

Коммунизм төзүнең җидееллык грандиоз планы язучыны яшәртә, яңа көч бирә, күбрәк һәм яхшырак эшләргә ашкындыра.

*1958 ел, ноябрь.*

# БӘХЕТ БИРГӘН ҖИРЕМ...

Халык тормышын тирәнрәк аңлыйсың килсә, аның җырларын өйрән, диләр. Чыннан да, халкыбыз тормышының иң әһәмиятле сәхифәләре борынборыннан җырларда теркәлә килгән. Җырларда халыкның рухи байлыгы, аның моңзарлары, сагыш-шатлыклары, алай гына да түгел, бөтен бер тарихы чагыла. Ил өстенә кайгы килеп, яуга барганда да, җиңү көне килеп, чиксез шатланганда да кешеләр җырны юлдаш иткән.

Әнә шуңа да композиторларыбыз халыкның бай музыкаль фольклорына, гасырлар буена иҗат итә килгән гүзәл җырларына аерым бер хөрмәт һәм игътибар белән карыйлар: аны өйрәнәләр, тагын да баета һәм тулыландыралар. С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, З. Хәбибуллин кебек композиторларыбыз белән бергә, бу эшкә Александр Сергеевич Ключарев та күп көч куйды. Аның татар халык җырларын җыю, өйрәнү һәм эшкәртү юлындагы хезмәтләре тәкъдир итүгә һәм хөрмәткә лаек. Композитор буларак та, Александр Сергеевичның иң күркәм сыйфатлары нәкъ менә җыр жанрында аеруча калку һәм тулы ачылды. Республикабызның музыка сәнгатен Ключарев иҗатыннан, аның аһәңле җырларыннан башка күз алдына китерү кыен булыр иде.

Шикләнмичә әйтергә мөмкин: А. Ключарев иҗатына уңай тәэсир ясаган вакыйгаларның берсе һәм әһәмиятлесе Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле оештырылу булды. Тиз бер ара эчендә яшь композитор ансамбль белән тыгыз элемтәгә керде, коллектив өчен бик күп халык җырларын эшкәртте, үзе яңа көйләр язды. Еллар узган саен бу дуслык һаман ныгый, тирәнәя барды. Ансамбль өчен Ключарев кебек күп көч куеп һәм тырышып эшләгән композиторларыбыз, ихтимал, бернечә генәдер.

Композиторның иҗат эшчәнлеге утызынчы еллардан башлана. Аннан бирле никадәр әсәр язылган. А. Ключарев тарафыннан иҗат ителгән җырларның гына саны да йөзгә якын. Ул җырларда гүзәл замандашыбыз, аның кайнар дәрт белән тасвирланган эчкерсез хисләре, тормышыбызның иң әһәмиятле вакыйгалары чагыла, аларда бик күп тема һәм проблемалар күтәрелә.

Партиягә багышланган җырларында Ключарев музыка дөньясындагы гимн традицияләрен уңышлы дәвам итә. Салмак темп һәм тантаналы яңгыраш аларга үзгә бер төс, яңа бер аһәң бирә. Менә М. Садри сүзләренә язылган «Синең белән көчлебез» исемле җыр. Биредә композитор юлбашчыга ода җырлау белән генә чикләнми. Ул, барыннан да бигрәк, Ленинның гадилеге һәм кешелеклелеге, тирән акыл иясе булуы турында сөйләргә тели. Һәм композитор үз максатына ирешкән дә.

Туган илгә, Татарстанга багышланган көйләр А. Ключарев иҗатында аерым урын алып тора. Шундый көйләрнең берсе — «Туган җирем — Татарстан» исемлесе — республика радиосының чакыру сигналына әверелеп, көн саен Советлар Союзының бөтен почмакларына тарала:

> Кая гына китеп,
> Кайларга бармадым,
> Сагынып кайттым Иделем
> таңнарын...

Барыбызга да таныш бу шигъри юлларда туган илгә булган олы мәхәббәт хисләре дә, аерылу моңсулыгы, кавышу шатлыгы да яңгырый. «Туган җирем — Татарстан» бер Ключарев иҗатында гына түгел, ә бөтен татар музыка сәнгатендә иң танылган, иң популяр җырларның берсе, дияргә була.

М. Хөсәен сүзләренә язылган «Яңа Казан» маршы турында да шул ук сүзләрне әйтергә мөмкин. Ул башкалабызның музыкаль эмблемасына әверелде.

Дөньяда иң күп таралган җырлар, әлбәттә, мәхәббәт хакында, яшьлек турында. Алар Ключарев иҗатында да аз түгел. Бу темага багышлап язган җырларында композитор дәртле, тормыш сөючән яшьлекне раслый, мәхәббәткә дан җырлый. Әмма урынына, текстның эчтәлегенә карап, ул көйләрнең аһәңе, яңгырашы һаман үзгәрә, төрләнә бара. Шагыйрь М. Садри тарафыннан иҗат ителгән «Яз җыры»ның сүзләре гади генә.

Зөя суын эчеп үстек бергә,
Саубуллаштык Идел ярында,
Саубуллаштык алтын көз көнендә,
Сайрар кошлар киткән чагында,
Сайрар кошлар киткән чагында...

Композитор язган көй дә җырда сөйләнгән вакыйгаларга хуш килеп тора. Ниндидер уйчанлык, җылы, йомшак һәм моңсу авазлар өстенлек итә бу көйдә. Инде «Мулланур Вахитов», «Давыл алдында» кебек татар халкының алдынгы улларына, бөек вакыйгалар эчендә кайнаган батыр йөрәкле революционерларга багышланган көйләрдә композиторның тавышы тагын да көрәя төшә, көй пафослы, югары яңгырашлы була бара.

А. С. Ключаревның татар музыкасын башка милләтләрнең музыкаль казанышлары исәбенә баетуда да өлеше аз түгел. «Бохара-Урал», «Җайдак казакъ кызына» исемле җырларда без композиторның үзбәк һәм казакъ халык музыкасы элементларына мөрәҗәгать итүен тоябыз. «Хезмәт сөюче яшьлек»тә исә рус халык җырларына хас интонацияләр өстенлек итә. Әмма ни генә булмасын, Ключарев иҗатының нигезендә татар халык көе, татар моңы ята.

Александр Сергеевич үзен киң диапазонлы, бай палитралы композитор итеп танытты. Еш кына бер үк җырда ул төрле жанр элементларын янәшә куллана. Әгәр «Синең белән көчле без», «Туган җирем — Татарстан», «Идел җыры», «Безнең дуслык» җырларында җиңел көй һәм эпиклык берләштерелсә, «Идел дулкыннары», «Сәлам сиңа, Куба» җырларында эпиклык белән борынгы Венеция җырларына хас көй агышы — баркарола өстенлек итә. Төрле алымнарны бергә кулланып, музыка сәнгате традицияләреннән кыю файдалану Ключарев җырларына яңа һәм матур бизәкләр, үзенчәлекле аһәң өсти.

Композитор үз җырларында төрле музыка коралларына да зур урын бирә. Курай, гармун яки скрипка авазлары көйгә көтелмәгән бизәкләр, яңа борылышлар өсти, аны баетып, тулыландырып җибәрә. Бу — композиторның бик күп әсәрләренә хас үзенчәлек. Ул ритмикада да, гармониядә дә, авазлар чиратлашуында да татар музыкасының бай мөмкинлекләреннән иркен файдалана. Образ төзүдә фортепьяно партиясе дә зур роль уйный. Ключаревта ул музыкаль картиналарны аңларга булыша. Җырда нинди дә булса елга турында сөйләнсә, аккомпанемент су чайкалган, дулкыннар йөгерешкән авазлар чыгара. «Кама буйлары» җырындагы пароход гудогы, «Яңа ел белән»дәге курантлар чыңы картинаны тагын да ачыграк күзалларга ярдәм итә. «Яңа Казан» дигән бәйрәм җырының фортепьяно партиясендә демонстрациягә чыккан халык ыгы-зыгысын тойгандай буласың. Болар барысы да композитор тарафыннан уңыш белән, җентекләп һәм яратып эшләнгәннәр. Ключарев фортепьяноның бөтен мөмкинлекләрен белеп эш итә.

Ниһаять, композитор үзен музыкаль кереш остасы итеп тә танытты. Аның инструменталь керешләре гаять образлылар. Ләкин җырны, төп образны күмеп китмиләр. Киресенчә, ачарга, тулыландырырга ярдәм итәләр. Ключарев җырларының кереш өлешләре еш кына җырның бөтен рухын билгели һәм күңелдә эмоциональ атмосфера тудыра. Кайчакта җырның төзелеше башкачарак була: кереш өлеш белән кульминация тәңгәл киләләр. Шуңа иң тәэсирле һәм хәтердә калучан өзек җырның икенче бер өлешендә инде таныш кебек яңгырый. Ләкин бу шулай тоела гына. Чынлыкта исә кульминацион интонация икенче тапкыр кабатланганда гына бөтен тулылыгы белән яңгырый.

Татар халкының гына түгел, ә күп милләтле совет халкының массовый җыр жанрына зур өлеш керткән талантлы композитор Александр Сергеевич Ключарев иҗатының гомуми сыйфатлары әнә шулар.

Яраткан композиторыбыз 60 ның өске ягына чыкты. Ләкин ул хәзер дә актив иҗат итә. Аның киләчәктә тә безне берсеннән берсе матуррак җырлар белән куандырачагына ышанып калабыз.

З. СӘЙДӘШЕВА.

Альберт Фәтхи

# МӘГЪРИФӘТ ТӨБӘКЛӘРЕ ҺӘМ ӘДӘБИ БАГЛАНЫШЛАР

Һәркайсыбызга мәгълүм булганча, татар халкы Идел буе, Урал, Көнбатыш Себернең төрле почмакларына таралып, башка халыклар белән аралаш урнашкан хәлдә яши. Бу хәл, әлбәттә, культурабызның үсеш тарихына, әдәби-мәгънәви мирасыбызның күләме һәм сыйфатына да зур йогынты ясаган, тирән эзен салган. Ерак-ераклардан агып килгән елгаларның бер җиргә коюыннан диңгез хасыйл булган шикелле, төрле төбәкләрдә туып-үскән иҗат ияләренең эшчәнлеге бергә кушылуы, бер үзәк тирәсенә иҗтимагый берләшүе, тупланууыннан зур бер иҗтимагый куәт һәм шул куәтнең иҗат җимеше булган рухи хәзинә барлыкка килгән. Әгәр без язучыларның туып-үсү һәм тору, эре әсәрләрнең язылу-басылу урыннарын географик картада нокталар белән билгеләп чыксак, татар әдәбиятының картасы — әдәби карта хасыйл булыр иде. Бу картага күз төшергәндә төбәкләрнең төрлелеге аермачык күренә. Татар әдипләренең иң күпчелеге Казан һәм аның тирәләре белән бәйләнгән. Мөхәммәдъяр, Мәрҗани, Курсави, Насыйри, Тукай, Галиәсгар Камалларга — татар әдәбият күгендәге иң якты йолдызларга бишек булган җир бу. Иделнең урта агымындагы, уң як ярдагы төрле җирләрдә яшәүче мишәрләр арасыннан күтәрелгән Г. Кандалый, М. Акъегет, Г. Коләхметов, Ш. Камал, К. Тинчурин, Һ. Такташ, Г. Кутуй кебек зур иҗат ияләренең дә әдәбиятыбыз үсешендәге рольләре һәркемгә мәгълүм. Ока суы буендагы Касыйм татарлары XVII гасыр башында әдәбиятыбызга «Җәмигъ-эт-тәварих» исемле тарихи әсәр биргәннәр. Казаннан көнчыгышка таба барганда, Уфа, Оренбург, Уральск, Троицк, Чиләбе кебек шәһәрләргә килеп чыгабыз. Бу туфракта туган әсәрләребез тагын да күп. Бигрәк тә XVIII гасыр урталарыннан башлап, бу төбәктән дистәләрчә шагыйрьләр, әдипләр чыккан, анда йөзләрчә әсәрләр язылган. Исмәгыйль Бикмөхәммәт угылы, Әбелмәних һәм Һибәтулла Каргали, Мөхәммәтгали Чокрый, Әхмәт Уразаев-Кормаши, Акмулла, Дәрдмәнд, Мәҗит Гафури, Сәгыйт Рәмиев, Риза Фәхретдин, Фатыйх Кәрими кебек әдип, шагыйрьләрнең тормышы һәм эшчәнлеге шушы як белән бәйләнгән. XIX гасыр азагы, XX гасыр башында гомумтатар әдәбиятына һәм иҗтимагый фикер хәрәкәтенә билгеле бер өлеш керткән эшлеклеләр Астрахань һәм Себер татарлары арасыннан да чыккан.

Әдәбият — иҗтимагый-тарихи күренеш. Ул халык тарихы белән аерылгысыз рәвештә бәйләнгән. Татар әдәбияты әсәрләренең һәм аларны иҗат итүче әдипләрнең төрле төбәкләргә баглы булулары да халык тарихы белән бәйләнгән, һәм әлеге әсәрләрнең иҗат тарихын, мотивларын һәм үзенчәлекләрен аңлау өчен әнә шул халык тарихын азмы-күпме төпченү кирәк. Бу — фән өчен зарури бер нәрсә. Чөнки аңсыз әдәби әсәрне — конкрет бер тарихи-иҗтимагый продуктны тану юк, таныган хәлдә дә бик сай, тар, беренче нәүбәттәге яктан түгел, ниндидер икенче, өченче чираттагы бер яктан гына тану була. Әдәбиятыбыз тарихы буенча соңгы елларда чыккан китаплар, аянычка каршы, менә шушы тар тануга бик күп мисал бирәләр. «Борынгы татар әдәбияты» китабында, мәсәлән, «Җәмигъ-эт-тәварих» әсәре хакында да, «Исмәгыйль сәяхәте» турында да кыска һәм аз сөйләнгән дип әйтеп булмый. Әсәрләрнең төзелеше, теле хакында төгәлме-түгелме күзәтүләр бар. Әмма аларның нинди мохит җимешләре булуы, нәкъ менә шул мохитның бу әсәрләрнең фикри-иҗтимагый йөзен билгеләве

хакында күңел өчен генә булса да бернәрсә дә әйтелмәгән. Димәк, иң әһәмиятле нәрсә игътибардан читтә калган. Әсәрне конкрет тарихи җирлегеннән аерып алып, бары бер генә яктан — әдәби факт итеп кенә карау XIX һәм XX йөз татар әдәбиятына багышланган башка күп кенә хезмәтләрдә дә сизелә. Моннан исә аерым бер күренеш — төбәк тарихы түгел, гомумән, татар әдәбияты тарихы гына зыян күрә.

Болар бөтенесе безнең әдәбият тарихы фәненең тикшеренү методларында, мирасның принципиаль мәсьәләләрен хәл итүдә җитди кимчелекләр булудан килә. Шуңа күрә күп гасырлык әдәби мирасыбызның социаль мәгънәсе ачылып җитми. Әдәбиятыбызның, халык тарихына бәйләнешле рәвештә, үсә, төрләнә, байый килүе, киң иҗтимагый йогынтылы зур көчкә әверелү процессы, бу процессның катлаулы динамикасы, аны хәрәкәткә китерүче һәм тоткарлап килүче көчләрнең нисбәте әлегә хәтле тиешенчә танылып-беленеп беткәне юк.

Бәхеткә каршы, безнең тарих фәненең беренче этабында бу өлкәдә бик күп аның документланган материал туплап калдырылган. Шиһабетдин Мәрҗани һәм аның эшен дәвам иттерүче Ризаэтдин Фәхретдин үзләренең «Мостафад-ел-әхбар» һәм «Асар» исемле биографик-библиографик энциклопедияләрендә, тарихи шәхесләргә характеристика биргәндә, территориаль һәм хронологик төгәллеккә, документальлеккә җитди игътибар итәләр. Бу китапларда тарихи конкретлык принцип буларак гамәлгә ашырыла, шулай ук этник моментлар да игътибарга алынып, «мишәр таифәсе», типтәр, ханкирмәнле (Касыйм татары), Астрахань татары рәвешендә күрсәтеп барыла. Беренчел чыганаклардан — борынгы кулъязмалардан алынган оригиналь текст һәм фактларны эченә алганлыктан, Ш. Мәрҗани һәм Р. Фәхретдиннең бу хезмәтләре мирасыбызның һичкайчан искерми, мәгънәсен югалтмый торган алтын фондын тәшкил итәләр. Р. Фәхретдин үзенең остазы — Мәрҗанинең кулы җитмәгән Оренбург тирәсе әдәбиятын аеруча җентекләп тикшерде, нәтиҗәдә «Сәгыйт» (1897), «Исмәгыйл сәяхәте» (1903) китаплары дөньяга чыкты. Патша хөкүмәтенең рәсми политикасы алга сөргән тенденциоз карашлар йогынтысына бирелмәгән рус галимнәре дә татар язма культурасын өйрәнүгә зур өлеш керттеләр. Аерым төбәкләр буенча Октябрьга кадәр түбәндәге галимнәрнең хезмәтләре чыкты:

Казан арты һәм Тау ягы язма культурасы (Ш. Мәрҗани, Х. Әмирхан, К. Насыйри, Р. Фәхретдин, Г. Әхмәрев, Н. Березин, К. Фукс һ. б.).

Касыйм татарларының язма культурасы (В. Вельяминов-Зернов, Х. Фәезханов, Н. Березин һ. б.).

Урал татарларының язма культурасы (С. Күкләшев, Р. Фәхретдин, Р. Игнатьев һ. б.).

Себер татарларының язма культурасы (Р. Фәхретдин, Н. Катанов һ. б.).

Совет чорында мирасны тану буенча гаять әһәмиятле казанышларга ирешелде. Бигрәк тә 20 нче елларда, Казандагы иҗтимагый фән белгечләренең башында Галимҗан Ибраһимов торган вакытларда, гомумтатар иҗтимагый-культура хәрәкәтләре, әдәбияты, матбугаты буенча зур хезмәтләр иҗат ителде. Боларда, татар халкының барлык төбәкләре бербөтен итеп алып каралган хәлдә, аерым төбәкләрнең дә материалы конкрет рәвештә тикшерелеп, үзенчәлекләре белән ачып бирелде һәм, нәтиҗәдә, төпле фәнни гомумиләштерүләр ясалды. Октябрьга хәтле үк бу мәсьәлә белән махсус кызыксынган Г. Ибраһимов татар әдәби мирасын төбәкләп тикшерү принцибының фәнни эшләнүендә, нигезгә куелуында гаять зур роль уйнады. Ул үзенең «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» исемле китабында (1925) төбәкләп өйрәнү принцибын эзлекле төстә гамәлгә ашырды. Гали Рәхим, Габдерахман Сәгъди, Сәет Вахидиләр, мирасны тикшергәндә шушы юлдан барып, фән тарихында җуелмас эз калдырдылар.

Аерым төбәкләрнең әдәбияты буенча да кызыклы гына тикшеренүләр булгалады. Әдәбият галиме, тәнкыйтьче Заһит Шәркый Оренбург төбәге татар әдәбияты һәм иҗтимагый хәрәкәтләре буенча аерым китаплар чыгарды [1]. Сәйфи Кудаш үзенең «Хәтердә калган минутлар» һәм «Яшьлек эзләре буйлап» исемле мемуар әсәрләрендә Урал татарларының 1910 еллардагы әдәбият-сәнгать тормышын җанлы итеп тасвирлап бирде,

[1] Оренбург краенда татар әдәбияты тарихы. Оренбург. 1928 ел; Оренбургта революция көннәре. Оренбург. 1926 ел.

боларның бер яктан Казан ягы белән, икенче яктан казакъ даласы белән бәйләнешләрын ача торган бай фактик материал теркәде.

Димәк, татар әдәбияты тарихын аерым төбәкләр буенча өйрәнү өчен шактый бай материал тупланган. Әмма бу бай мирасны махсус фәнни тикшерү тәҗрибәсе әле зур түгел. Язма әдәбиятны тикшерү буенча эш шулай тора. Әмма халык мирасының башка тармакларын өйрәнә торган белгечләрнең бу өлкәдәге уңышлары зуррак һәм, һичшиксез, әдәбиятчыларга үрнәк булырлык. Татар тарихчылары, этнографлар, фольклорчылар һәм тел галимнәре бөтен территориаль-этник комплексны иңли торган әһәмиятле хезмәтләр бирделәр[1]. Телче-диалектологлар, татар сөйләм теленең җирле диалектларын өйрәнеп, диалектологик сүзлекләр һәм фәнни очерклар чыгардылар. Хәзерге көндә алар, үзләре туплаган бай фактик материалны карталарга салып, диалектологик атлас төзеп яталар. Шуңа күрә территориаль принципны гамәлгә ашыру ягыннан алар бүгенге көндә безнең фәннең иң алдынгы сафында баралар дисәк, бер дә ялгыш булмас төсле. Алар башкара торган эш халык тарихы өчен әһәмиятле материал булачак.

Аерым төбәкләр буенча махсус тикшеренүләрнең татар халкының төрле халыклар белән бәйләнешләрен ачу өчен дә әһәмияте әйтеп бетергесез зур.

Безнең әдәбият фәнендә бу өлкәдә күп еллардан бирле филология фәннәре докторы Мөхәммәт Гайнуллин кызыклы хезмәтләр биреп килә[2]. Ләкин, безнеңчә, галимнең тикшеренү ысулында кимчелек күзгә ташлана: әдәби бәйләнешләрне халыкларның реаль тарихи-иҗтимагый мөнәсәбәтләре җирлегенә куеп карау җитми. Нәтиҗәдә, әдәби мөнәсәбәтләр бөтен тирәнлеге һәм реальлеге белән ачылып бетми кала.

Без бу мәкаләдә Урал татарларының язма культурасы һәм китап әдәбиятына караган кайбер тарихи-әдәби мәсьәләләргә тукталырга уйлыйбыз. Әһәмияте белән Казан ягыннан кала икенче дәрәҗәдәге, аерым дәверләрдә хәтта төп йорт — Казан һәм Казан арты культурасына җитди йогынты ясаган, аны баеткан төбәк ул. Бу төбәкнең килеп чыгуы, ягъни татарларның бу төбәккә төпләнү һәм әзлекле рәвештә иҗтимагый үсә килү тарихы белән бәйләнештә караганда гына Урал татарларының гомумтатар культура хәзинәсенә керткән хосуси өлеше һәм аның специфик үзенчәлекләре ачылырга мөмкин.

## Идел буеннан Уралга таба...

Һәркемгә мәгълүм булганча, татар һәм башкорт халыклары нәсел-ыруглары белән бик якыннар. Шуңа күрә тел галимнәре, төрки телләрне нәсел-ыруг ягыннан төркемләгәндә, боларның икесен дә кыпчак-болгар төркемчәсенә кертеп йөртәләр. Бу ике тел, бер-берсенә бик якын булуы белән, башка кыпчаклардан (казакъ, каракалпак, нугай, кумыклар) һәм башка болгарлардан (чувашлардан) да аерылып тора, практик тормышта исә тәрҗемәсез-нисез аңлашу тәэмин ителә. Бу якынлык телдә генә түгел, билгеле бер дәрәҗәдә фольклор һәм гадәт-йолаларда да күзәтелә. Әмма менә бу табигый стихияләрдәге берлек, кардәшлекне, уртаклыкны иҗтимагый күренеш булган

[1] Р. И. Нафигов. Формирование и развитие передовой татарской общественно-политической мысли. Рус телендә. Казан. 1964 ел. 11—12 битләр; Н. И. Воробьев. Этнические группы татар Среднего Поволжья и Приуралья. Итоговая научная сессия Казанского института языка, литературы и истории АН СССР за 1963 год (краткое содержание докладов). Рус телендә. Казан. 1964 ел. 44—48 битләр; Н. И. Воробьев. Поволжские татары. Народы Европейской части СССР. Рус телендә. II том. Мәскәү. «Наука» нәшрияты. 1964 ел. 634—636 битләр; М. Нигъмәтҗанов. Ерак чыганаклар. «Совет әдәбияты» журналы. 1965 ел. I сан. 134—140 битләр; Ф. С. Фасеев. Краткий грамматический справочник татарского языка. «Татарско-русский словарь». Мәскәү. «Советская энциклопедия» нәшрияты. 1966 ел. 809—811 битләр.

[2] М. Гайнуллин. Вопросы изучения взаимосвязи и взаимообогащения литератур народов Поволжья, Урала и Казахстана. Итоговая научная сессия Казанского института языка, литературы и истории АН СССР за 1963 год (краткое содержание докладов). Рус телендә. 1964 ел. 13—20 битләр. М. Гайнуллинның шушы тема буенча төрле фәнни басмаларда һәм «Татарстан коммунисты», «Совет әдәбияты», «Дружба народов» кебек журналларда басылган мәкаләләре бар. Кыскалык өчен без монда аларның исемен атап тормыйбыз. Журнал мәкаләсенең күләме сыйдырмаганлыктан, башка очракларда да без тәфсилле библиография бирүдән баш тартырга мәҗбүрбез, бары тик иң кирәклеләре генә күрсәтеп барылыр.

мәгърифәт, китап әдәбияты һәм язма әдәби телгә карата механик рәвештә күчереп карарга ярамый. Сөйләшү телендәге уртаклык йогынтыдан түгел, тумыштан, нәселдән килсә, мәгърифәт һәм язма әдәбиятның торышы исә һәр халыкның үзенә генә хас иҗтимагый үсеш, иҗтимагый эшчәнлек дәрәҗәсе белән билгеләнә. Башка факторлар — территориаль якынлык, политик язмышта бердәмлек булу, иҗтимагый-экономик мөнәсәбәтләр туры килгәндә генә, әлеге табигый якынлык иҗтимагый якынлык булып реальләшә ала. Хәтта үзе үк моңа актив йогынты ясый, тизләтә торган фактор ролен уйнарга мөмкин. Татар һәм башкорт халыкларының җиде-сигез гасырлык тарихы — табигый якынлыкның иҗтимагый якынлык булып реальләшү юнәлешендә үсә килү тарихы ул.

XVI гасырның урталарына кадәрге дәверне болгар-татар һәм башкортларның иҗтимагый-культура багланышларының борынгы баскычы итеп карарга була. Аянычка каршы, бу чордан язма истәлекләр дә, фольклор материаллары да аз сакланган. Бер дәүләт составында яшәгәнлектән, башкортларның, бигрәк тә көнбатыштагыларының, ыруг аристократиясенә бу дәвердә үк Болгар һәм Казан кебек мәгърифәт үзәкләренең тәэсире зур булган. Әмма әле бу заманда ике халыкның иҗтимагый якынаюына ирек бирми торган тенденцияләр дә үзен сиздереп торган. Башкорт ыруглары арасында Казан ягыннан килгән феодаль изүгә, авыр ясаклар түләтүгә каршы күтәрелүләр булып торган [1]. Башкорт халык иҗатында, социаль психологиясендә үз мөстәкыйльлеге өчен көрәш мотивлары көчле булган. Мәсәлән, бу «Җик-Мәргән» эпик хикәясендә гәүдәләнә, мондый мотивлар көнбатыш башкортларның шәҗәрәләрендә дә очрый.

XVI гасыр уртасын һәр ике халык иҗтимагый һәм культура үсеше икесенеке ике төрле булган хәлдә каршы ала. Аларның Россия дәүләте составына керүләре дә үзгә формада бара. Казан ханлыгы Мәскәү дәүләте кул астына кереп, илдә татарларны экономик кысрыклау, дини җәберләүләр башлангач, татар халкы, төркем-төркем булып, үзенең төп ватанын ташлап, башка җирләргә, көнчыгышка таба күчеп утырырга, башкорт туганнары арасына сыенырга мәҗбүр була [2]. Баштарак, ак патшаның «киң күңеллелеге» аркасында, башкорт ыругларына зур-зур итеп җирләр бүлеп бирелеп, документлар белән беркетеп куелганлыктан, җир мәсьәләләрендә дә иркенлек сизелә һәм күчеп килгән татарларны кабул итүдә әллә ни каршылык булмый. Әмма колониаль властьларның йогынтысы торган саен көчәя бара, җирле, төп халыкның хокукы кысылу күчеп килүчеләргә дә, татар һәм башкортларның иҗтимагый-экономик мөнәсәбәтләренә дә эз салмый калмый. «Кара сакалың кая барсаң да калмый» торган булып чыга. Колониаль властьлар «качак» татарларны (документларда алар шулай исемләнә) кабул итмәскә, куып җибәрергә указлар чыгаралар. Чөнки аларны, меңәрләп-меңәрләп качу аркасында, Казан ягында хөкүмәткә ясак түләүчеләрнең саны бик тә кимүе борчый. Шулай да татарларның күбесе төпләнеп кала. Моның исә татарлар өчен генә түгел, җирле башкортлар өчен дә йогынтысы була. Элегрәк башкорт ыруглары, күчмә тормышта көн итеп, мал асрау белән генә шөгыльләнсәләр, хәзер инде

[1] Р. Кузеев, Б. Юлдашбаев. 400 ел рус халкы белән бергә. Башкорт телендә. Уфа. 1957 ел. 21 һәм 26—27 битләр.

[2] Башкортстанга татарларның кайчан һәм ничек килеп чыгуы, төпләнеп китүе фәндә әле тиешенчә өйрәнелмәгән. Кайбер галимнәр мондагы татарларны XII—XIV гасырларда килеп төпләнгән болгарларның варисы итеп карыйлар. (Г. В. Юсупов. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. Рус телендә. Мәскәү. СССР Фәннәр академиясе нәшрияты. 1960 ел. 131—132 битләр; Вопросы диалектологии тюркских языков. Материалы второго регионального совещания по диалектологии тюркских языков. Рус телендә. Казан. 1960 ел. 169—173 битләр.) Бу караш бик бәхәсле. Безнеңчә, татарның феодаль түрәләре, мәсәлән, тарханнар башкорт арасында XVI гасыр урталарына хәтле үк берән-сәрән яшәгән. Әмма киң катлау татар массасының авылы-авылы белән күченүләре, төпләнеп китүләре соңрак башланган. Бүгенге көндә Башкортстанда булган татар авылларының күпчелегенең тарихы XVI гасыр урталарыннан да борынгыга китми. Бу мәсьәләне татар (типтәр), мишәр һәм башкорт шәҗәрәләре, авыл халкының үз тарихы хакындагы риваятьләре, эпиграфик истәлекләр һәм архив документлары буенча конкрет өйрәнү бик файдалы булыр иде. Бу хакта Р. Фәхретдиннең «Асар»ында һәм XIX—XX гасырда чыккан күп кенә татар китапларында, вакытлы матбугат битләрендә бай гына документаль фактик материал теркәлгән. Уфада татар телендә чыга торган «Кызыл таң» газетасы бу турыда даими рәвештә материаллар биреп бара.

алар утрак тормышка күчә башлыйлар, игенчелек белән шөгыльләнергә тотыналар[1]. Хуҗалыктагы менә бу җитди үзгәрешләр нәтиҗәсендә, көнбатыш башкортлары арасында патриархаль-ыруглык гадәт-йолалары зәгыйфьләнү, кимүгә таба юл ала, рухи тормышка да яңа сыйфатлар керә бара. Татарның башкорт һәм Башкортстан белән мөнәсәбәте Казан ягының ясаклы крестьяннар катлавы белән генә түгел, өстен, изүче сыйныфлар — «йомышлы татар»лардан булган мирзалар аша да гамәлгә ашырыла[2]. Мирзалар, Мәскәү колониаль властеның агенты буларак, башкорт белән идарә итү, администрация «йомыш»ларын үтиләр, тылмач, писарь, шымчы, гаскәри отряд башлыклары булып эшлиләр, иткән хезмәтләренә күрә, зур титул, байлык һәм җир казаналар. Мондый кешеләрне, «башкорт илкәйләрен утка тотып яурының алтынлаган», ягъни иненә генераллыкның алтын погонын таккан гаскәри Тәфкилев ише кан эчкеч түрәләрне, башкорт халкы үзенең җырында да ләгънәтләде. Димәк, милли-колониаль политика гамәлгә ашырылган шартларда, татарларның сыйныф-сословие һәм этника ягыннан төрлелегенә бәйле рәвештә, Башкортстанга килеп чыгу мотивлары да, төпләнеп китү, административ-сословие ягыннан теркәлү формаларында да төрлелек бар. Башкортстанга мишәрләрнең күпчелеге патша хөкүмәте тарафыннан XVII гасырның урталарында Иделнең уң ягы — Тау ягындагы төрле төбәкләрдән китерелә һәм, күз-колак булу, шымчылык итү, коралды кузгалышлар була калганда тизрәк бастыру өчен, башкорт авыллары арасына утыртыла. Бервакыт патша хөкүмәте башкорт старшиналары янына секретарь итеп мәҗбүри рәвештә мишәрләрне куя, чөнки соңгыларына, язу-сызу эшләре белән бергә, шымчылык итү бурычлары да йөкләтелә[3].

Менә монда инде патша хөкүмәтенең өч этник төркемнең (башкорт, Казан татар, мишәр) үзгәлегеннән, үзгәрәк тарих кичерүеннән, иҗтимагый психологияләрендәге аерымлыклардан үзенең политикасы өчен файдалануы, берсен икенчесенә каршы котыртуы күренә. Ике бертуган халыкның — татарның һәм башкортның үзара мөнәсәбәтләренә, якынаюына һәм туганлашуына каршы төрлечә тоткарлык ясала. Мәсәлән, 1736 елның февралендә чыгарылган Указ буенча, башкорт белән татарның бер-берсе белән никахка керүенә каршы киртә корыла, яшьләр губернатор рөхсәте белән генә, бер яхшы ат биргән очракта гына гаилә кора алган[4].

Өч этник төркем арасында төрле яклап иң күп зыян күргәне, иң изелгәне Казан татарлары булган. Иҗтимагый шартлар аларны хәтта үзенең төп этнонимын (этник исемен) югалткан формада төпләнергә, башка атама белән рәсми теркәлергә мәҗбүр итә. «Типтәр» дигән административ-сословие термины белән йөртелгән катлауларга күчеп килгән халыклар, башлыча Казан татарлары белән бергә чуваш, мари, удмурт, мордвалар һәм өлешчә башкортлар, мишәрләр дә кереп китә, һәм монда барган этник процесслар нәтиҗәсендә, XIX гасыр урталарыннан башлап инде «типтәр» дигән атама Башкортстан татарларын гына билгеләрә[5]. Безнең XIX һәм XX гасыр язма әдәбиятында да һәм Урал татарларының үзендә дә бу атама әнә шул соңгы мәгънәсендә кулланыла.

---

[1] Башкорт АССР тарихы буенча очерклар. I том. I кисәк. Рус телендә. Уфа. 1957 ел. 273 бит; Р. Г. Кузеев. Очерки исторической этнографии башкир. ч. I. Рус телендә. Уфа. 1957 ел. 22 бит.

[2] Г. Газиз. Татар тарихы. Мәскәү. 1925 ел. 255—256 битләр.

[3] Мишәрләрнең кайдан һәм нинди максат белән күчерелүе хакында түбәндәге хезмәтләрдән укырга мөмкин: Ф. Вәлиев. Борынгы бабаларыбыз кемнәр? «Казан утлары» журналы. 1967 ел. 2 сан. 136 бит; А. П. Чулошников. Восстание 1755 года в Башкирии. Рус телендә. Мәскәү. СССР Фәннәр академиясе басмасы; Материалы по истории Башкирской АССР. т. V. Рус телендә. Мәскәү. 1960 ел. 574—577 битләр (күп томлы бу басма алда «МИБ» рәвешендә кыскартылып, томы һәм битләре генә күрсәтеп барылачак).

[4] А. П. Чулошников, исеме аталган китап, 26 бит.

[5] А. Ш. Афлетунов. Языковые особенности татар западной и юго-западной части БАССР. Итоговая конференция КГУ им. В. И. Ульянова-Ленина за 1960 год. (Краткое содержание докладов.) Рус телендә. Казан. КДУ нәшрияты. 1961 ел. 42—43 битләр.

Җирле булу омтылышы Казан татарларының бер өлешен «башкорт» дип язылырга да мәҗбүр иткән [1].

Татар белән башкортны бер-берсеннән аерып тотар һәм үзара ызгыштырыр өчен, патша хөкүмәте нинди генә чаралар куллануга да карамастан, уртак тарихи-иҗтимагый язмыш, бер үк политик режимда көн кичерү аларны торган саен якынайтты, тигезәйтте, бердәм иҗтимагый омтылышлы итте. Безне, әлбәттә, бу иҗтимагый шартларның рухи культурага ясаган йогынтысы кызыксындыра. Көнбатыш башкорт ыругларының утрак тормышка күчүе мәгърифәт, язма әдәбият белән шөгыльләнергә уңайлы шартлар тудыра. Казан ягыннан зур әдәби-мәгънәви байлык алып килгән татар укымышлылары — абызлар башкортлар арасында төрле юнәлештә мәгърифәт эшчәнлеге җәелдереп җибәрәләр. «Татарларның килеп утыруы башкортлар арасында грамоталылыкның үсүенә йогынты ясады» [2], — дип тәкъдир итәләр хәзерге тарихчылар бу эшчәнлекне. «Башлап безнең кызларны хат язарга, «Йосыф-Зөләйха» әсәрен укып, егетләргә «китапча» гашыйк булырга бигрәк тә әнә шул Казан өйрәтте», — ди башкорт галиме Әхнәф Харисов [3]. XVII гасырларда ук татар абызлары, авылдан-авылга күчеп йөреп, башкорт балаларына әлифба танытканнар, аларны белем дөньясына тартканнар [4]. Менә мондый укый-яза белгән кешеләрнең күбәя торуы исә, үз нәүбәтендә, борынгы әсәрләрнең яңа күчермәләрен эшләтү, элгәреге мирасны киңрәк тарату өчен дә, замандаш вакыйгаларны гәүдәләндерә торган яңа әсәрләр иҗат итәрлек каләм ияләренең тууы өчен дә киңрәк мөмкинлекләр биргән.

Дөрес, башкорт феодаль аристократиясенең элегрәк тә, XVI гасыр урталарына хәтле үк, аерым төр язма әсәрләре, мәсәлән, шәҗәрәләре булган [5]. Әмма башкортларда мәгърифәтнең, язма культураның шактый киң җәелеп, тотрыклы бер төс ала башлавы XVII гасырның II яртысы, XVIII гасырның I яртысы белән бәйле. XVIII гасырның I чирегендә инде Башкорстанда мәдрәсәләр ачыла башлый [6]. XVIII гасырның II яртысында исә башкортлар арасыннан әдипләр һәм шагыйрьләр дә күтәрелеп чыга. (Мәндеш Котыш улы, Таҗетдин Ялчыгол һ. б.)

Борынгы язма культура, китап әдәбияты тарихы — документаль фән ул. Бары тик язма хатирә генә бу өлкәдә чыганак була ала. XVII—XVIII гасыр татар-башкорт әдәби багланышлары да, тарихта булган бер хәл икән, конкрет хатирәләр белән расланырга тиеш — шул вакытта гына без тарихи хакыйкатьне таный алабыз. Аянычка каршы, бу дәвергә караган язма истәлекләр, ягъни турыдан-туры шул төбәктә күчерелгән китаплар, иҗат ителгән әсәрләр бик аз сакланган, тарих өчен берән-сәрән фактлар гына торып калган. Шулардан берсен күрсәтеп китүне кирәк саныйбыз. Бу — 1600 елда Гәйнә ягында күчерелгән «Төхфәи мәрдан» кульъязмасы. Нибары 50—60 ел элек кенә ханлык башкаласы — шәһре Казанда иҗат ителгән киеренке рухлы бу әсәрне нинди язмыш Көнбатыш Урал урманнары арасына китереп ташлаган соң? Китапны күчерүченең «Кәминә» кушаматын йөртүе дә очраклы гына түгелдер (кәминә — кимсетелгән, түбәнсетелгән дигән сүз). Чын-чынлап уйландыра торган факт бу. Гәйнә ягы язма культурасындагы башка төр әсәрләр дә безгә бу китапның халык белән

---

[1] С. Бикбулатов. Башкирские восстания и татары. «Вестник научного общества татароведения». Рус телендә. 9—10 саннар. 1930 ел. 70 бит; Н. Г. Гурвич. Справочная книжка Уфимской губернии. Рус телендә. Уфа. 1883 ел. 371—372 битләр; Җ. Алмаз. Башкортстан Дүртиле һәм Илеш районнары татарларының сөйләшенә карата. Татар теле һәм диалектологиясе мәсьәләләре (Казан дәүләт университеты. Гыйльми язмалар. 119 том. VI китап). Казан. 1959 ел. 155—157 битләр. Башкортстандагы төрле этник төркемнәрнең бик тә катлаулы иҗтимагый-экономик һәм этник мөнәсәбәтләрен тикшерү безнең төп бурычыбыз түгел, бу — тарихчы һәм этнографларның эше. Әмма бу тарихны белү Урал татарларының язма культурасын, фольклорын, диалектын өйрәнүчеләр өчен дә кирәк. Шактый күп, бай документаль материалның инде бастырылган булуы тикшеренүченең эшен шактый җиңеләйтәчәк.

[2] Башкорт АССР тарихы буенча очерклар. I том. I кисәк. Уфа. 1956 ел. 139 һәм 285 битләр.

[3] Ә. Харисов. Башкорт халкының әдәби мирасы. XVIII—XIX гасырлар. Башкорт телендә. Уфа. 1965 ел. 16 бит.

[4] МИБ. I том. 169, 292, 294 битләр; III том. 493—494 битләр.

[5] Ә. Харисов, исеме аталган китап, 209—210 битләр.

[6] Шунда ук, 160 бит; Башкортстан АССР тарихы буенча очерклар. I том. I кисәк. Уфа. 1956 ел. 285 бит.

бергә үткән юлын ачыкларга ярдәм итә. Бу ялгыз бер факт. Без белми торган, хәтта белә алмаслык хәлгә килгән, әмма кайчандыр чынбарлыкта булган шушындый фактлар күпмедер?!

Татар абызларының башкорт арасына яңалыклар китерүенә, халыкның иҗтимагый психологиясендә дә үзенчәлекле мотивлар хасил булуына колониаль идарә әһелләре игътибар итми калмаган. Чөнки алар монда үзләре үткәрә торган политикага хуш килми, бик үк ярап бетми торган тенденцияләр сизгәннәр һәм аның йогынтысын чикләү, тоткарлау, көчсезләндерү өчен мөмкин булганның бөтенесен эшләгәннәр. Үзләренең сыйнфый ихтыяҗларыннан чыгып, алар татар һәм башкорт халыкларының әдәбият-мәгърифәт бәйләнешләрен бер яклы, бер-берсенә йогынтысын гел тискәре генә итеп күрсәтергә тырышканнар. Шул чорның тарихи документларында бу хакта кызыклы мәгълүматлар бар. Уфа вице-губернаторы П. Д. Аксаков 1743 елда башкорт халкының иҗтимагый хәленә бәя бирә торган бер язмасында, Казан татарлары аркасында, башкортлар арасында грамоталы кешеләр күбәюен әйтә һәм үзенең сыйнфый-тенденциоз позициясеннән торып булса да, грамоталы кешеләрнең иҗтимагый психологиясендә дә үзгәрешләр килеп чыгуын объектив рәвештә таный[1].

Менә мондый карашлар башка төрләргә практик чара күрү өчен кулланмага әверелгән. Һәм ике халык арасында уртак рухлы әдәби әсәрләрнең — кулъязма китапларның таралуын тоткарлау өчен төрле киртәләр корылган. Менә шуның бер факты: 1737 елда көнчыгыш Башкортстанда (Себер юлында) хөкүмәт эшләре белән йөргәндә, полковник Тәфкилев бер башкорт кулында «Чингизнамә» исемле татарча тарихи әсәрнең кулъязмасын күрә. Бу кулъязманың азагында китерелгән вакыйгънамәнең әле яңа гына булып үткән замана хәлләре — башкорт яулары турында хәбәр бирүе Тәфкилевне бөтенләй куркуга төшерә. Ул, янында йөрүче йомышлы татар — тәрҗемәче Арслан Бикмәт углыннан (Бәйматевтән) текстның русчага тәрҗемәсен эшләттереп ала да, бу әсәрнең зарарлы, үзе әйтмешли, «котккы сала торган ялган» («возмутительный пасквиль») булуын билгеләп, 1737 елның 4 ноябрендә хөкүмәт сенатына рапорт язып җибәрә һәм бу китапны күчерүче Мостафа Котлугъ-Әхмәт углын (Тәфкилев аны «вор» дип кенә атый) тизрәк эзләп табып кулга алырга һәм җәза бирдерергә тәкъдим итә. Шунысы кызык, әлеге татарча кулъязманың да дүрт кәгазе (8 битлек текст) умырып алынып, документ буларак рапортка теркәлеп җибәрелә. Архивта кулъязма оригинал да, русчага тәрҗемә дә һәм рапорт та бергә сакланып калганнар[2]. Һәм алар инде бүгенге көндә, татар әдәбияты әсәрләренең хөкүмәт кешеләре тарафыннан күптәннән бирле эзәрлекләнеп килүен раслый торган документлар буларак, бик тә әһәмиятлеләр.

Үз дәверенең фикер иярләре буларак, татар һәм башкорт абызларының халыкка йогынтысы аз булмаган һәм аларның иҗтимагый эшчәнлеге белән бәйле башка әһәмиятле фактлар да бар. Билгеле булганча, XVII гасыр һәм XVIII гасырның I яртысындагы Башкортстан һәм Татарстан тарихына феодаль-колониаль изелүгә каршы халык хәрәкәтләре, тарихка «башкорт болалары» исеме белән кергән восстаниеләр хас. Башкортлар белән бергә, бу кузгалышларда татарлар (типтәрләр, мишәрләр) да катнашкан һәм менә шушы зур вакыйгаларда аларның дуслыгы ныгыган, иҗтимагый психологиядә дә элеккерәк дәверләргә хас этник йомыклык, чикләнүчәнлектән арынып, гомуми сыйфатлар формалаша барган. Татар абызларының бу кораллы яуларда актив катнашуы тарихи документлар буенча ачык күренә: халыкны җәлеп итәр өчен яуга күтәрелү мотивларын нигезләп, төшендереп бирә торган өндәмәләр иҗат итү, аның нөсхәләрен күбәйтү һәм киңрәк территориягә тарату эшен абызлар алып бара. Яулар басылып, халык күңелендә генә калган вакыйгаларны тарих итеп китапка язма рәвештә теркәп калдыру, вәкаигънамәләр (хроникалар) иҗат итү дә, башлыча, татар абызларының эше. Югарыда телгә алынган Тәфкилев сенатка җибәргән вәкаигънамә ике халыкның да — башкортның да, татарның да бер булып көрәшү фактларының иң әһәмиятлеләрен ачып бирә. Бу әсәр фәндә XIX йөз башыннан, Ибраһим Хәлфин бастырганнан бирле, билгеле. 1735—1741 елгы Акай Күсүм улы җитәкчелегендәге баш-

---

[1] Документның оригиналында менә болай әйтелгән: «Токмо кто грамотен, тот и хитрее к наживе обманами, которых уже ныне грамотей больше развелось от казанских татар...» (МИБ. III том, 527 бит.)

[2] БАУДА. Хөкүмәт сенаты фонды. 1164 эш. 895, 900—905 кәгазьләр.

корт восстаниесе турындагы вакыйгънамә дә кызыклы [1]. Батырша Алеев тарафыннан 1755 елның июлендә төзелеп халыкка таратылган зур хитапнамә-программа безгә бу чор укымышлыларының иҗтимагый аңы, тарихка мөнәсәбәте турында күп нәрсә сөйли [2]. Хәер, мишәр һәм Казан татар абызларының үзенчәлекле роль уйнавын колониаль властьлар да бик яхшы сизгән һәм, бу кузгалышларның чыганагын корытыр өчен, 1740—1750 еллардан башлап кискен чаралар күргән [3]. Шул сәбәпле, күтәрелешләр заманының күп тарихи һәм әдәби әсәрләре безнең көннәргә хәтле килеп җитә алмаган.

XVII—XVIII гасырларда Башкортстан мәгърифәтендә һәм администрация эшендә язма татар теленең функциясенә килгәндә, шуны әйтергә кирәк: тел үзенең характеры белән сыйнфый күренеш булмаганлыктан, шушы ук тел капма-каршы ике сыйныфка да — хезмәт ияләренә дә, эксплуататорларга да бердәй хезмәт итте. Башкорт һәм татарны изүчеләргә каршы кулына корал алырга өндәгән хитапнамәләр дә татарча иде, икенче, каршы яктан, хөкүмәт, патша гаскәре ягыннан җибәрелгән кәгазьләр дә, патшага күндәм, тугры булырга үгетләгән һәм төрле вәгъдәләр белән юмалаган язулар да татар мирзалары һәм йомышлы абызлар тарафыннан языла иде.

Җыеп кына әйткәндә, башкорт һәм Урал татарларының XVII—XVIII гасырның беренче яртысындагы үзара бәйләнешләре бик кызу рәвештә иҗтимагый якынаю юлы белән бару һәм бу юлга корылган тоткарлыкларның зарарлы йогынтысын киметә килү белән характерлы. Моннан соңгы баскыч шуның тагын да көчәйгән дәвамы гына булды.

## Җаек даласы—халыклар капкасы

Бу чорның иң беренче һәм әһәмиятле факты — 1745 елда Оренбург шәһәре янында, Сакмар суы буенда Сәгыйт (Каргалы) бистәсе нигезләнү. Монда, үзләренең ихтыяры белән, Казан тирәсендәге татар сәүдәгәрләреннән зур бер төркем күчеп килә һәм төпләнеп китә. Алар тиз арада Казагыстан, Урта Азия (Бохара, Хива), Көнчыгыш илләре белән иҗтимагый-экономик мөнәсәбәтләр сферасына тартылалар [4]. Идел буендагы Мәкәрҗә ярминкәсе татар сәүдәгәрләренең товар-акча мөнәсәбәтләрендә һәм капитал туплауда нинди роль уйнаган булса, Оренбургның алмашу базары һәм Эрбет ярминкәсе дә шундый ук роль уйный. XVIII йөз азагында Оренбург шәһәрендә сәүдә эшен, башлыча, Сәгыйт бистәсе татарлары алып бара һәм аларның саны башка милләт сәүдәгәрләреннән, атап әйткәндә, руслардан 6 тапкыр күбрәк була [5]. Бу дәвердә Идел — Урал буеның үзенең төрле төбәкләрен, шәһәрләрен, авылларын тоташтыра торган эчке экономик бәйләнешләр тагын да көчәеп китә. Чит илләр белән бәйләнеш исә татарның аерым катлаулары эшчәнлегенең географик һәм этник сферасын тагын да киңәйтеп җибәрә. Элегрәк татарлар бары башкортлар, руслар, чувашлар, удмуртлар, марилар, мордвалар белән генә бәйләнгән булсалар, хәзер инде алар казакъ, үзбәк, таҗик, каракалпак, төркмән, кыргыз, уйгурлар белән иҗтимагый-экономик бәйләнешләрга керәләр. Россиянең көньяк-көнчыгыш чикләре киңәюгә нисбәтле рәвештә, Казан ягы татарларының аерым катлаулары Казагыстан һәм бераз соңрак Урта Азиядәге шәһәр һәм авылларга күчеп утыралар, төпләнеп калалар. Уральск, Чиләбе, Троицк, Кызылҗар (Петропавловск), Семипалатинск шәһәрләрендә татар бистәләре барлыкка килә. Мәгълүм булганча, бу процесс XX гасыр башларынача дәвам итте. Татар әдәбиятының әлеге халыклар әдәбияты белән мөнәсәбәтләре дә — татарның бу халыклар белән реаль мөнәсәбәтләренә нигезләнгән, шул процессның нәтиҗәсе буларак туган бер күренеш.

«Җаек даласы — халыклар капкасы» дигәнебез менә шушы вакыйгалар белән конкретлаштырыла. Әлбәттә, алда әйткән бу иҗтимагый процесс бик катлаулы формада

---

[1] Тексты «История Татарии в документах и материалах» (Мәскәү. 1937 ел. 402—406 битләр) исемле китапта басылган.

[2] А. П. Чулошников, шул ук китап, 39 һәм 55 бит.

[3] Шунда ук, 36 бит.

[4] Г. Гобәйдуллин. Татарларда сыйныфлар тарихы. Казан. 1925 ел. 50—54 битләр; Г. Газиз. Татар тарихы. Мәскәү. 1925 ел. 227 бит.

[5] Н. Г. Аполлова. Особенности возникновения и развития городов Оренбургского края в XVIII в. «Города феодальной России». Сборник памяти Н. В. Устюгова. Рус телендә. Мәскәү. 1966 ел. 461 бит.

барган, чөнки татарның башка халыклар белән мөнәсәбәтләренең көчәеп китүе, экономика һәм культурасының үсеп китүе хөкүмәт һәм идарә кешеләренә бу юлга төрле киртәләр, тоткарлыклар корырга мәҗбүр иткән. Алар хәтта, бераз соңлабрак булса да, Сагыйт бистәсе татарларының иҗтимагый эшчәнлегенә тоткарлык ясарга тырышып караганнар[1]... Әйе, тарих шома гына бармаган. Бу тарихи-иҗтимагый мәсьәләләрне тикшерүне тарихчыларга калдырып, бу хәлләрнең язма әдәбиятта ничек чагылуына күз төшереп китик.

Казан ягы мәгърифәтенең тотрыклы традицияләрен үзе белән алып килгән Сагыйт бистәсе тиз арада бик көчәеп китә һәм бөтен Идел — Урал буена, шул исәптән Казанның үзенә дә, теге яки бу дәрәҗәдә йогынты ясый торган бер төбәккә әйләнә. Сагыйт бистәсе сәүдәгәрләре Исмәгыйл Бикмөхәммәт улының 1751 елларда Һиндстан һәм Гарәбстанга сәяхәтен тасвирлаган документаль-әдәби очеркы[2], Гобәйдулла Әмировның Һиндстанга сәяхәт көндәлекләре (татарча оригиналы әлегәчә табылганы юк) әдәбиятның дөньяви, заманча эчтәлек белән байый килүен күрсәтә торган беренче әсәрләр булып торалар. Элегрәк әдәбият дөньясында башлыча руханилар эш алып барган булса, инде феодаль түрәләр дә, сәүдәгәрләр дә кулларына каләм алалар, әдәби сүз аша үзләренең карашларын үткәрәләр. Мәсәлән, бу чор шагыйрьләре арасында безгә шигырьләре белән генә түгел, җәмгыятьтә кылган эшләре белән дә мәгълүм булган мишәр старшинасы Габделмәннан Мөслимов шәхесе бик кызыклы. Ул үзенең шигырьләрендә түбән катлауларның иҗтимагый хәрәкәтләренә мөнәсәбәтен белдергән[3]. XVIII гасырның соңгы чиреге, XIX йөзнең I яртысында Урал төбәгендә яңа әдипләр, шагыйрьләр күтәрелә һәм җанланып киткән эчке иҗтимагый-экономик мөнәсәбәтләр боларның әсәрләрен Идел — Урал буендагы бөтен төбәкләрнең әдәби байлыгына әвереләдерә, аштарак кульъязма китаплар, соңрак Казан басмалары аша татар һәм башкортлар арасында популярлык казануына китерә. Төп чыгышлары белән Казан ягы татарларыннан булган[4], Сагыйт бистәсе мохитында яшәгән Әбелмәних Каргали, Һибәтулла Салихов кебек шагыйрьләр әнә шундый язмышка очрады. Төпченә китсәк, без бу төбәктә иҗат ителеп тә, Казан ягы мәгърифәте һәм әдәбиятында зур әһәмият казанган тагын башка төр әсәрләр, күп фактлар саный алыр идек. Мәсәлән, тарихи материаллар «Шәраит-ел-иман» исемле беренче татар әлифбасының да, укымышлылар фольклорын — хикәяләрне эченә алган әдәби җыентыкның да шушы Каргалы бистәсе мохитында төзелүе турында мәгълүмат бирәләр.

Менә бу әдәби фактларның тарихи мәгънәсе бар: алар Идел — Урал буенда оригиналь әдәбиятның процесс булып, көчле агым белән үсә баруын күрсәтәләр. Бераз алгарак китеп әйтсәк, шушы процесс, XIX йөзнең 60 елларыннан яңа баскычка үрләп, яңа дәвер сыйфатлары алып, 1905 елга хәтле килә. Янсә ачыграк итеп әйткәндә, без монда Оренбургта чыккан татарча пролетариат, большевиклар газетасы — «Урал»га хәтле китергән иҗтимагый-фикри, әдәби үсешнең озын һәм катлаулы юлына керәбез.

Безне монда башлыча бу процессның баштагы чоры кызыксындыра. Хәзерге көндә инде XVIII йөз азагы, XIX гасырның I яртысындагы әдәбиятның төп вәкилләре дә, характерлы әсәрләре дә билгеле. Дөрес, әле бездә әдәбиятны киң мәгънәсендә аңлап, төрле фәнни-популяр һәм практик әсәрләрне дә бергә алып өйрәнү җитми. Бу дәвер

---

[1] Башкирия в русской литературе. Рус телендә. I том. Уфа. 1961 ел. 393—394, 446 бит.

[2] Соңгы вакытта бу сәяхәтнең документлары басылып чыкты: Русско-индийские отношения в XVIII веке. Мәскәү. «Наука» нәшрияты. 1965 ел. 342—343 битләр. 180 документ.

[3] М. Гали. Пугачев хәрәкәте турында кайбер әдәби материаллар. «Совет әдәбияты» журналы. 1948 ел. 9 сан. 104—107 битләр; Борынгы татар әдәбияты. Казан. 426—427 битләр.

[4] Язучыларның биография фактларын тикшергәндә, язма документларны тиешенчә файдаланмый торган кайбер авторлар, мәсәлән, Оренбург ягын өйрәнүче М. С. Лоссиевский үзенең «Былое Башкирии и башкир по легендам, преданиям и хроникам» исемле хезмәтендә боларның милләтен «башкорт» дип билгеләнгән. Хәлбуки, бу дөрес түгел, Әбелмәнихның атасы Казан артындагы Мәңгәр авылыннан күчеп килгән (кара: Р. Фәхретдин. Асар. I җилд. II җөзьә. Оренбург. 1901 ел. 42—43 бит; Сәгыйт. Казан. 1897 ел. 7 бит; Ш. Мәрҗани. Мостафад-ел-әхбар. II кыйсем. Казан. 1900 ел. 127 бит). Һибәтулланың әтисе Чистай өязе Такталы авылыннан күчеп килгән (Асар. II җилд. XIV җөзьә. Оренбург. 1907 ел. 444 бит; Сәгыйть. 22 бит).

татар авторларының тарих, фәлсәфә, хокук гыйлеме, география, математика, астрономия, медицина кебек фәннәргә караган әсәрләре кузгатылмаган килеш ята. Шуңа күрә моннан соңгы дәвернең иң эре эшлекләләре булган Мәрҗани һәм Насыйриларның эшчәнлеген тикшергәндә дә аларның үз халкыбызның мәгърифәт һәм гыйлем туфрагында элгәредә үк борын төрткән традицияләрне үстереп җибәрүләре бөтен тулылыгы белән ачылмый кала. Монысы киләчәк эше. Әмма инде без таррак, гадәттә сәнгатьчә, күркәм сүз һөнәре мәгънәсендә аңлана торган әдәбиятны өйрәнүдә соңгы елларда уңышларга ирешеп киләбез. Бүгенге көндә фән дөньясы бу әдәбиятның билгеле бер заман, халык, җәмгыять белән бәйләнмәгән булуы турындагы ялгыш карашлардан арынып килә. Хәер, фәннең үткән этапларындагычарак фикер йөртүләр анда-санда әле бүген дә кабатланып куярга мөмкин, әмма андый хәлне китереп чыгара торган бер генә сәбәп — әдәбиятның үзен, текстларны чынлап торып тикшермәү булыр.

Г. Кандалый, Утыз Имәни кебек заманча иң алдынгыларына кагылып та тормастан, һибәтулла Каргали, Әбелмәних Каргали, Шәмсетдин Зәки кебек суфи шагыйрьләрне дә без Россия гражданлыгыннан мәхрүм итә алмыйбыз. Алар, дөньяга гомуми карашлары белән суфи булган хәлдә дә, конкрет бер халыкның — татарның тормышы турында, аның да нәкъ менә үзләренә замандаш дәвере хакында хөкем йөртәләр, шушы халык җәмгыятенең бөтен катлауларының — «гавам»ының да (масса), «голамә»сенең дә (укымышлылар), баеның да холкын-фигылен тикшерәләр, төрле күренешләргә, хәлләргә үз мөнәсәбәтләрен белдерәләр. һибәтулла Каргали үзенең остазы Дәүләтшаһ Гаделшаһ углына (1831 елда үлгән) багышланган мәрсиясендә замана хәлләрен тасвирлый, суфи әхлагына каршы тел озайтуга хәтле барып җиткән бер «фетнәче» авызыннан «Бу фетнә заманыдыр, бу дар, — көффар мәкамыдыр, тыярга юк дорыр имкян» дигән сүзләрне әйттерә икән, инде бу үзе генә дә шагыйрьнең кайсы ил гражданлыгында булуын билгертеп тора.

Бу дәвер әдәбияты тормышны реаль детальләр белән гәүдәләндерүгә җитди игътибар бирә. Мәсәлән, Утыз Имәни татар авылы тормышын җанлы итеп тасвирлап бирә: җыеннар, хатыннарның каба-орчык күтәреп утырмага йөрүләре, аулак өйдә урын аш пешерүләр, кубыз уйнау, биюләр, байларның баллы чәй мәҗлесләре, ишек төбеннән уза алмый торган фәкыйрьнең туны тишек булудан көлүләре, күрше рус авылыннан килгән Гришка белән төне буе әңгәмәләшүләр — менә бу конкрет детальләр бөтенесе дә безгә чынбарлыкны танып белергә ярдәм итә. «Игенчеләр гошер бирмәс, ганиләр ашка өндәмәс, фәкыйрьләр өмәгә килмәс...», — ди әлеге мәрсиясендә һибәтулла. Ярлыларны тамак ялына эшләтү — өмәләр үткәрү шулай ук элекке татар авылының үзенчәлекле бер күренеше. Димәк, татар суфиларын замана, җәмгыять хәлләре белән бәйләнеше булмаган, ниндидер бер суфичылык сахраларында гизеп йөри торган дәрвишләр генә итеп күз алдына китерергә һичбер нигез юк.

Бу дәвер татар язучыларның географик мохитлары да, иҗтимагый мохитны күз алдына китерүләре дә шактый киң. Исмәгыйл Бикмөхәммәт улы кебек һиндстан, Гарәбстанда да йөргән, Утыз Имәни һәм Әбелмәних кебек Урта Азия, Әфганстанда да булганнарының карашында географик киңлек булуы табигый. Г. Кандалый да үз авылы янсә үзе укыган мәдрәсәләр мохиты белән генә калмый. Ул үз халкының иҗтимагый мохитын бөтен киңлеге белән, аның эре-эре экономик һәм административ пунктлары белән конкрет рәвештә күрә.

Иҗтимагый аңның икенче бер мөһим моменты — халык тарихына мөнәсәбәт, бүгенге заманны гына түгел, үткәнне дә күз алдына китерергә тырышу. XVIII гасырның II яртысында татар укымышлылары арасында җирле тарих, мирас белән кызыксыну көчәйгән, бу темага күп кенә әсәрләр язылган. Суфичыл карашлы булу гына, мәсәлән, Таҗетдин Ялчыголга тарихи әсәр язуга комачаулык итмәгән, Болгар, Казан шәһәрләренең тарихын, анда күренекле кешеләр торуын «Тарихнамәи болгар» исемле әсәрендә (1805 ел) тасвирлаган.

Бу чор әдипләренең иҗтимагый карашлары киңәю телгә дә тәэсирсез калмаган: яңа, заманча күренешләр китереп чыгарган. Алар, татарның традицион китап әдәби теленең күп сыйфатларын саклаган хәлдә, халыкның җанлы сөйләшү теленә хас көнкүреш сүзләреннән (каба, орчык, утырма, урын аш, өмә шикелләләр) иркен файдаланалар.

«Тематикасының төрлелеге, идея позициясенең каршылыклы булуы, әсәрләрендә дидактика һәм реализм алымнарының бергә аралашуы белән Утыз Имәни урта гасырчылыктан яңа гасырга күчү чоры шагыйре булып күз алдына килә. Аның әсәрләрендә бер яктан, XV—XVII йөзләр әдәбияты өчен характерлы алымнар кулланылса, икенче яктан, XIX, хәтта XX йөз башы әдәбияты өчен үзлекле булган алым һәм мотивлар да очрый. Димәк, Утыз Имәни иҗаты татар әдәбияты тарихында билгеле бер этапны гәүдәләндерүче әдәби мирас булып тора»[1], — дип яза шагыйрь иҗатын җентекләп тикшерүче Үлмәс Беляева. Бу сүзләр, минемчә, шул дәвер әдәбиятының башка вәкилләренә карата да кулланыла ала һәм халыкның бөтен бер гасырлык мәгърифәт, әдәбият тормышы, иҗаты урта гасырлыктан яңа заманга күчү чоры итеп характерлана ала.

# Мирас һәм аның варислары

Урал татарлары әдәбиятының җирле спецификасын өйрәнү мәсьәләсенең безнең әдәбият фәнендә бөтенләй куелганы юк дияргә була. Бу җирле үзенчәлекләрнең шактый зур өлешенең татарларның башкортлар белән аралашуы нәтиҗәсендә килеп чыккан булуын искә алсак, әлеге мираска башкорт халкының ни күләмдә өлеш кертүе һаман ачыкланмаган килеш кала килә. Аерым фактларга күз төшереп карагандa, шушы ике халыкның бәйләнешләрен чагылдырган чыганакларга — әдәби текстларга фәнчә мөнәсәбәт җитеп бетмәү күренә.

Безнең халык авыз иҗатында «Рус-француз сугышы бәете» исемле бер тарихи әсәр бар. Исеменнән үк сүзнең нәрсә турында баруы аңлашылып тора. «Урамнарын тутырса да французлар Мәскәүнең, унике типтәр бетерде французның гаскәрен», — диелә анда. Икенче бер строфасында: «Французлар монда килгәч, таныдылар үзләрен, унда — башкорт, сулда — типтәр, таба алмыйлар эзләрен», — диелә. Без моны бәетнең кульъязма нөсхәсе буенча укыйбыз[2]. Ә менә СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият, тарих институты әзерләп бастырган «Бәетләр» җыентыгында (Казан. 1960 ел. 67—68 бит) «башкорт», «типтәр» сүзе кергән строфаларның берсен дә күрмибез. Оригиналдагы шундый биш строфаның бишесе дә һичнинди искәртүсез-нисез төшереп калдырылган. Без баштa китергән строфадагы «типтәр» сүзе «солдат» белән алыштырылган. Шулай итеп Башкортстан татарларының — «типтәр»ләрнең башкортлар белән бергә ил дошманнарына каршы көрәш документы танымаслык хәлгә китерелгән. Реаль тарихны, бабаларыбызның хәтта француз генералларын да таң калдырган батырлыгын гәүдәләндергән бу текстның иң үзенчәлекле урыннарын бу рәвешле «редакцияләү»не, әлбәттә, һичнәрсә белән дә аклап булмый.

Билгеле булганча, башкорт арасында туып-үскән янсә торган татар язучылары үз әсәрләрендә башкорт халык иҗатын киң файдаланганнар. М. Гафури, Ф. Вәлиев, С. Сөнчәләй кебек күп язучыларның шундый әсәрләре бар. Ф. Вәлиевның 1916 елгы «Аң» журналында «Җик-Мәргән» (халык хикәясе) исеме белән басылган әсәренең сюжеты татар әдәбияты һәм сәнгатендә билгеле бер резонанс алды. Татар фольклор материаллары белән бергә, М. Җәлил бу сюжетны «Алтынчәч» драматик поэмасында файдаланды.

Язучыларның кайсы халыкның фольклорыннан булса да иҗади файдаланулары, әлбәттә, аклана — бу әдәбиятны баета гына. Әмма менә борынгы әдәбият тарихчыларының бу хикәяне XV—XVI гасыр татар әдәбияты һәм фольклорының бер әсәре итеп тәкъдим итүләре[3] һич тә акланмый. Бу бары башкорт халкы арасында гына туа һәм тарала ала торган сюжет, анда аның үзенчәлекле тормыш-көнкүреше, аңы, гадәтйолалары гәүдәләнгән. Эпосның мотивлары башкорт халкының башка төр әсәрләре, мәсәлән, шәҗәрәләре белән дә документаль рәвештә раслана. М. Гафуриның шул ук «Борынгы татар әдәбияты»на кертелгән эпик хикәясе дә, минемчә, болгарларның монголларга каршы көрәшен түгел, бәлки бераз соңгырак дәвернең — башкортларның нугай хакимнәренә каршы көрәшен гәүдәләндерә. Әлбәттә, М. Гафури хикәясе дә,

---

1963 ел. 559 бит.
[1] Борынгы татар әдәбияты. Казан. Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханә.
[2] Казан дәүләт университеты. 340 сан. т. (2821).
Көнчыгыш кульъязмалар бүлеге. 1963 ел. 349—353 битләр.
[3] Борынгы татар әдәбияты. Казан.

Ф. Вәлиев хикәясе дә, мотивларының каян алынуына карамастан, XX йөз башы татар әдәбиятының әсәрләре булып торалар һәм әдәби-тарихи фән дә аларны үз урынына куеп, шул дәвер эчендә генә өйрәнә ала. Әдәбиятыбызның XV—XVI гасырдагы хәлен өйрәнүгә килгәндә исә, анда, соңгы заман әкиятләре белән тутырмаган хәлдә дә, болай да әсәрләр җитәрлек, бары тик булган хәтлесенең мәгънәсен таба белергә генә кирәк.

Татар әдәбиятының башкорт халкы белән бәйләнешын өйрәнүнең кайбер моментларын карап үтик.

Татар әдәбиятының үсешенә өлеш керткән әдипләр, шагыйрьләр арасында нәселеыругы белән башкорт булганнары бар. Мондый хәл бигрәк тә XVIII гасырның II яртысында башлана һәм Октябрь революциясенә кадәр дәвам итеп килде. Башкорт милли әдәби теле 1917—1924 елларда гына төзелде һәм шул арада башкортча китап, газета, журналлар күренә башлады. Аңа хәтле башкорт халкы татар әдәбияты белән яшәде, җәмгыятьтәге язма тел ихтыяҗын да татар теле үтәп килде. Мәктәп һәм мәдрәсәләрдә дә, татарлар белән бергә, татар телендә укыдылар. Башкортлар арасында бу гадәти бер хәл итеп кабул ителде. Моның тарихи-иҗтимагый сәбәпләре бар иде: «Бер яктан, гомуми милли үзаңның, үзеңне милләт итеп тану хисенең җитлекмәгән булуы һәм шуның өстенә, икенче яктан, татарча сөйләү, шулай ук әдәби теленең башкорт теленә якын, хәтта бөтен башкортларның өчтән бер өлешеннән дә күбрәге өчен асылда туган тел булуы башкорт шәкертләрендә, гомумән интеллигенция санында йөрүчеләрдә татар мәдрәсә һәм мәктәпләрендәге укыту политикасы җитди ризасызлык тудырмады», — дип яза бу хакта Ә. Харисов [1].

Совет дәверендә милләт булып формалашкан, милли әдәбиятын төзегән башкорт халкы үзенең әдәби үткәненә ничек карарга тиеш? Аның мирасы бармы? Бу хакта соңгы ярты гасыр эчендә кайбер фикерләр әйтелгәләде [2]. Бигрәк тә 20 елларда башкорт милли әдәбиятының беренче буын вәкилләре бу мәсьәләгә игътибар бирделәр. Күренекле башкорт филологы Сәгыйт Мирасов XVII—XIX гасыр татар-башкорт язма әдәбиятының сыйнфый асылы хакында аеруча кызыклы тикшеренүләр ясады. Әмма вульгар социологик, догматик карашлар хакимлек иткәнлектән, башкорт халкы гадәттә Октябрьга кадәр язусыз, әдәбиятсыз булган халыклар исәбеннән, иҗтимагый үсеше белән примитив дәрәҗәдәге халыклар белән беррәттән йөртелде. Хәлбуки, бу дөрес түгел иде. Алда ук әйтелгәнчә, башкортлар язулы һәм әдәбиятлы иде, татар телендәге әдәбиятка өлеш керткән үз вәкилләре дә бар иде һәм татар телендәге әдәбиятны башкорт халкы тулысынча үз әдәбияты итеп таный иде.

Соңгы елларда башкорт халкының әдәби мирасы белән кызыксыну көчәйде. «Башкорт халкының әдәби мирасы» төшенчәсенә галимнәр, гадәттә, Уралда булган татарча әдәбиятның кайбер өлешләрен, бигрәк тә нәсел-нәсәбе белән башкорт булган әдипләрен алалар һәм, әлбәттә, моның «уртак мирас» булуын, ягъни шул ук әдәбиятка татар халкының да варис булуын икърар итәләр.

Башкорт галимнәренең генеалогик моментларга, Урал төбәге әдәбиятының тематикасы, мотивлары, тел-стилендәге кайбер үзенчәлекләргә, бигрәк тә бу үзенчәлекләрнең башкорт этникасының стихиясе белән бәйләнгәннәренә игътибар юнәлтүләре дә әһәмиятле һәм бу, дөрес нигездә алып барылганда, фәнне яңа күзәтүләр белән баетырга мөмкин. Әмма кайбер хезмәтләрдә башкортка гына хас булмаган һәм генетик яктан да башкорт белән генә бәйләнмәгән элементларны да башкортныкы итеп күрсәтергә тырышу тенденциясе сизелә. Мәсәлән, Ә. Харисов татар шигыренең остасы Дәрдмәнд шигырендәге «шоңкар», «шоңкар чөю» кебек сүз һәм тәгъбирләрне башкорт теле стихиясеннән килә дип исәпли. «Шоңкар» — төрки телләр арасында бигрәк тә башкорт теле өчен хас сүз, ә «шоңкар чөю» дип әйтүне фәкать башкорт авызыннан гына ишетергә мөмкин», — ди ул һәм мисаллар китерә (42 бит). Чынбарлыкта исә бу тәгъбир татар телендә дә бар һәм бик борынгы заманнан бирле килә. «Толпардан

[1] Ә. Харисов, исеме аталган китап, 45 бит.

[2] Башкирская литература. «Литературная энциклопедия». Рус телендә. I том. Мәскәү. 1929 ел. 373—376 нчы багана. Башкирская АССР. Литература. «Большая Советская энциклопедия». Рус телендә. 2 басма, IV том. Мәскәү. 1950 ел. 354—355 битләр; Башкортстанда революциягә тиклем әдәби башлангыстар. «Башкорт совет әдәбияты». Уфа. 1955 ел; «Краткая литературная энциклопедия». I том. Мәскәү. 1962 ел. 480 багана.

тояк калыр, шоңкардан кыяк калыр»; «Ике шоңкар талашса, бер каргага жим төшәр», — дип, татар мәкальләрендә[1] күп мәртәбәләр кабатланыла. Татар халкы һәм аның бабалары гомер буе утрак тормышта көн итсәләр дә, аларга сунарчылык ят булмаган. Болгар, Казан кебек хезмәт бүленеше бик алга киткән киң бер дәүләттә, бер почмагында таш йортлар салып, фән, әдәбият белән шөгыльләнсәләр, икенче бер төбәгендә, шоңкар чөеп, сунарчылык иткәннәр. Язма истәлекләр шуны раслый. Борынгы бер язма дастанда да бу сүз очрый[2]. 1522 елда Нократ татарлары арасында язылган эпиграфик истәлектә безем өметләр «мәгәр шоңкар булып очты»[3] рәвешендә очравы инде бу сүзнең, бик озак кулланып, чарланып җитүе, күчерелмә мәгънәле тәгъбир — тел бизәгенә әверелүен күрсәтә. Халык авыз иҗатында мәкаль һәм дастаннарда бу сүз гадәттә «толпар» сүзе белән рифмалашып йөри. Дәрдмәнднең дә боларны нәкъ әнә шул формада куллануы шагыйрьнең татар халык иҗаты хәзинәсеннән иркен файдалануы турында гына сөйли. Бу сүз һәм тәгъбирне Уралдагы татар әдибенең теленә башкорт теленең йогынтысы итеп карау өчен бернинди нигез юк. Ә. Харисов «башкорт сүзләре» дип китергән исемлектәге (42 бит) һәр сүзнең татар телендә дә булуын, аның сигез-ун гасыр буе язылып килгән китаплары эчендә дә очравын, эпитафик ташларына да уелган булуын, һәм, ниһаять, Уралдан ерак җирләрдәге татарларның сөйләшү телендә дә кулланылуын югарыдагыча документаль рәвештә күрсәтеп торырга бу урында ихтыяҗ юктыр дип беләм. Әлбәттә, без татар әдипләре язган әсәрләрдә башкорт теле элементлары бөтенләй юк, була алмый дип әйтергә җыенмыйбыз. Андый элементларның булуы бәхәссез. Сүз боларны чын-чынлап төпченеп, төгәл фәнни ысуллар белән тикшерү кирәклеге турында бара.

Башкорт әдәби мирасын тикшерүчеләрнең генеалогиясе, нәсел-нәсәбе белән башкорт булган язучыларның этник психологиясенә игътибар итүләре дә аларның гаять әһәмиятле, иң нечкә, специфик моментны танып белүгә таба юнәлеш алуларын күрсәтә. Ә. Харисов Башкортстанның көнбатыш төбәгендәге башкортлар һәм алар арасыннан чыккан әдипләр хакында менә болай ди: «Монда шунысы бик кызык һәм мөһим: көнкүреш, тел һәм культураларының уртаклыгына карамастан, бу регионндагы татарлар үзләренең татар халкына, ә башкортлар башкорт халкына караулары белән горурланып булганнар. Хәтта әсәрләрендә халык телләкләреннән аерылган, күбесенчә «теге дөнья» уе белән яшәгән Таҗетдин Ялчыголов һәм Гали Чокрый сымак суфи язучылар да үзләрендә башкортлык тойгысын горур саклаганнар» (40 бит). Әйе, Т. Ялчыгол башкортның Әйле ыруыннан. Ә. Харисов аны «халык телләкләреннән аерылган, күбесенчә «теге дөнья» уе белән яшәгән, дип характерлый. Безнеңчә, болай әйтү бик үк төгәл түгел. Тарихи шәхесне, әдипне үзе яшәгән иҗтимагый шартка куеп, шул заман җәмгыятенең төрле катлауларының ихтыяҗлары белән бәйләнештә караганда гына аның иҗатының, әсәрләренең мәгънәсе ачыла ала. Бу — тарихи фәннәрнең элементар таләбе, тарихи конкретлык принцибы. Гали бер башкорт кызы Газизәнең үтенүе буенча әсәр язган, бик катлаулы әхлакый категорияләрне үсмер кызлар да аңларлык телдә төшендереп биргән, XIX гасыр башкорт һәм татар мәгърифәтендә үзенең тарихи миссиясен намус белән үтәгән бу әдипне болай гына «теге дөнья» — «ахирәт» үлчәве белән генә үлчәү мираска вульгар социологик мөнәсәбәттән башка нәрсә түгел. Монысы — бер момент. Безне монда бигрәк тә икенче момент — әдипнең этник психологиясе кызыксындыра. Билгеле булганча, әдип хакында аның әсәрләре буенча хөкем йөртәләр. Социаль психологиянең бер тармагы булган этник психология дә һәр әдипнең әсәрләрендә гәүдәләнә. Без алдарак Т. Ялчыголның «Тарихнамэи болгар» исемле әсәр язуын телгә алган идек. Әдип аны халык телендә йөргән төрле легендалар һәм борынгы китапларда очрый торган кайбер мәгълүматлар буенча язган. Ул үзенең нәсел-нәсәп шәҗәрәсен, «башкорт» булуын белә. Әмма шулай да ул үзенең бәйләнешләрен Болгар, Бүләр, Кашан һәм Казандагы күренекле кешеләр белән бәйли һәм менә бу болгарлар, ягъни татарлар, белән бәйләү тенденциоз төс ала. Иҗтимагый-

[1] Н. Исәнбәт. Татар халык мәкальләре. I том. Казан. 1959 ел. 82 бит; «Совет әдәбияты» журналы. 1951 ел. 5 сан. 81 бит.

[2] Әхвәле Чингиз хан вә Аксак Тимер. И. Хәлфин басмасы. Казан 1819 ел. 32, 55 бит.

[3] Г. В. Юсупов. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. Рус телендә. Мәскәү. 1960 ел. 61 таблица.

этник психологиядәге «болгарлык» Мәрҗани һәм Насыйриларның замандашы һәм фикердәше Мөхәммәтгали Чокрый иҗатының йөзен билгели торган лейтмотивка әверелә. Ә. Харисовның аны да «теге дөнья» уе белән яшәгән дип бәяләве шагыйрьнең әсәрләреннән танылa торган чынлыкка бөтенләй туры килми. Әлбәттә, Гали Чокрый да үзенең нәсел-нәсәп шәҗәрәсен, Табын ыруына һәм бу ыругның кайсы буынына каравын яхшы белә. Әмма ул бөтен әсәрләрен үзенең замандашларына «болгар», ягъни татар, мәгърифәт эшлеклеләренә багышлый, аларның халыкны агарту өчен эшләүләрен мактый. Болгар шәһәрен ул мәгърифәт, гыйлемнең башы итеп карый, мондагы тормышка зыян китергән чит ил баскакларын, замандаш дошманга мөрәҗәгать иткәндәй, ярсулы рух белән сүгә, ачына. Шагыйрь борынгы Болгар белән генә түгел, бәлки Казан шәһәре һәм үзенең замандашлары — төрле кәсеп ияләре белән горурлана. «Җиһан халкы мәдех саздыр!» — «дөнья халкы алдында мактаулы», — ди ул Казан һәм аның халкы турында. Димәк, Ә. Харисовның Чокрый хакында «башкортлык тойгысын горур саклаган» дию генә тулы характеристика түгел. Шагыйрьнең әсәрләре бөтен иҗаты аша кызыл җеп булып үткән социаль-этник психологиясен бары «болгарлык» (шагыйрь хәтта үзенең нисебен дә «Болгари» дип йөрткән), ягъни «татарлык», дип кенә билгеләргә була.

Көнбатыш башкортлар арасыннан чыккан бу әдипләрнең «болгарлыгы» каян килә соң? Борынгы китаплар арасына чумган, халыктан ерагайган берән-сәрән укымышлының гына хыялы түгелме соң бу? Түгел. Бу тарихи-иҗтимагый зарурлыктан килеп чыккан. Тарих фәне бу әдипләр яши торган иҗтимагый мохитны менә ничек аңлата: «Башкортстанның көнбатыш районнарындагы башкортлар күп гасырлар буе тел һәм культуралары бик якын булган татарлар белән тыгыз мөнәсәбәтләрдә булдылар. Татарларның озак дәвам иткән һәм торган саен көчәя барган йогынтысы нәтиҗәсендә башкортларның күпчелеге инде XIX гасыр урталарына татар телен һәм татар культурасының күп элементларын кабул иткән иде»[1]. Заманында бу мәсьәләгә Галимҗан Ибраһимов та игътибар итеп, «тарихи агымның зарури нәтиҗәсе» булган бу объектив процессны тәэмин иткән политик, социаль-экономик һәм культура факторларына тарихи-материалистик анализ ясаган иде. «Моңа кем дә булса хезмәт итмәде, бәлки адәм теләкләренә илтифатсыз бара торган тарихи агымның зарури нәтиҗәседер. Хәзерге әдәбият — бу фактор түгел, бу сәбәп түгел, бәлки хәяттагы табигый куәтнең адәм теленә, сүзгә керүе генәдер», — дигән иде әдип 1915 елда.

Алда әйтелгәннәрдән кыскача нәтиҗә ясыйк. Урал төбәгендәге татарча әдәбиятның, һичшиксез, башкортка нисбәтле специфик моментлары бар. Әмма әлегә ул үзенең фәнчә танып белүчесен, төрле яктан төпченә-төпченә тикшерүчесен көтеп ята. Моны тикшерү һәр ике халыкка да — татарга да, башкортка да үзенең тарихи мирасын тану өчен кирәк, һәм бу аларга менә дигән итеп уртаклашып эшләр өчен киң бер мәйдан булып тора. Аяныычка каршы, кайбер галимнәрнең хезмәтләре, атап әйткәндә Ә. Харисовның китабы, бу изге теманы тагы да эшләүгә зур файда китерерлек хезмәт булмады. Шуңа күрә аның фактларсыз, дәлилсез чыгарылган хөкемнәре коры дәгъва, декларация төсен ала.

## «Уртак» дию белән генә түгел...

Менә бу үзенчәлекле нокта — специфик момент дигәнебез — асылда зур бер гомумилекнең бер өлешенә генә мөнәсәбәт дигән сүз бит әле. Бу зур гомумилек — татар халкының күп гасырлык әдәби мирасы. Урал төбәгендәге татарча әдәбият — аның килеп чыгышы белән татар булганы да, башкорт булганы да әнә шул гомумилекнең бер җирле хосусый күренеше генә булып тора. Хосуси күренеш гомумигә мөнәсәбәтсез генә тикшерелә алмый. «Мөнәсәбәт» дигән төшенчәне урын-ара мәгънәсендә конкретлаштырганда без Урал төбәгенең Казан төбәге белән бәйләнешләрын, заман мәгънәсендә конкретлаштырганда исә тарихның билгеле бер дәверенең үткәнгесе, әлгәрегесе (ретроспектива) белән яки аның дәвамы, нәтиҗәсе, соңы (перспектива)

[1] Башкиры. Народы Европейской части СССР. Рус телендә. II том. Мәскәү, «Наука» нәшрияты. 1964 ел, 684 бит.

белән бәйләнешләрен аңлыйбыз. Әдәби күренешләрне менә шушы өч заманлы тарихи чынбарлык эчендә җанлы бер нәрсә итеп караганда гына берәр төрле хикмәт, мәгънә чыгарып була.

Инде без Ә. Харисов китабында менә бу гомумигә мөнәсәбәтнең ничек булуы турында бер-ике сүз әйтеп китмәкче булабыз. Хәер, моның күп якларын инде алда китерелгән конкрет фактлардан ук белеп була. Хосусый күренешләрдә фән принципларыннан тайпылу — гомумине аңлауга да зыян китерү дигән сүз. Башкорт фольклорына караган икенче бүлекне исәпкә алмаганда, Ә. Харисов китабының язма әдәбиятка караган 300 битлек өлеше менә шуның ачык мисалы. Урал төбәгендәге татарча әдәбиятка башкорт халкының да варислыгын, димәк, уртак мирас булуын билгеләүдә гомумине хосусый белән бәйләп карый алмау бик ачык күренә. Автор болай ди:[1] «Башкортстандагы иске кульязма һәм басма әдәби комарткыларның[2] бер мөһим үзенчәлеге шунда, алар башкорт культурасына карау белән бергә күп ягы белән татар культурасына да керә. Шуңа күрә аларны бары тик башкорт яки, киресенчә, татар милке итеп кенә күрергә тырышу тарихи дөреслек белән бөтенләй исәпләшмәү булыр иде. Монда теге яки бу поэтик күренешнең ике халык культурасы өчен уртак булуын тану гына җитми әле. Әнә шул у р т а к л ы к н ы ң х а р а к т е р ы н, а н ы ң а й ы ш ы н[3] а ч ы к к ү р ә б е л е р г ә д ә к и р ә к. Чынлап та, Шәмсетдин Зәки — уртаклыкның бер күренеше, ә Мәҗит Гафури — бөтенләй башка күренеш. Гафури үзенең әсәрләрендә башкорт белән татар ярлыларының зарлы тормышын, үз заманының прогрессив идеяләрен ихлас чагылдырганы өчен ике халыкның уртак һәм бердәй якын язучысы. Димәк, Гафури үзенең иҗаты белән ике якны да — башкортны да, татарны да — берьюлы зәвыкландыра, рухи канәгатьләндерә алганы өчен уртак әдип. Шәмсетдин Зәки исә, әлек аны күпме генә Урал — Волга буйларының Фөзулие дип йөртмәсеннәр, асылда бер якка да була алмаганы өчен, үзен бер халыкның да күңел җырчысы итеп күрсәтә алмаган өчен иске поэзиядә «уртак» күренеш. Мондый «уртаклык» билгеле, бертуган ике халык тормышын, гомумән, реаль дөньяны аңлаудан һәм аны чагылдырудан килми, ә шагыйрьнең иҗади аморфлыгыннан, үзара аралашып яшәгән башкорт белән татарга аларның иҗтимагый тормышыннан, иҗтимагый фикер һәм теләкләреннән чыгып түгел, бәлки дин уртаклыгыннан чыгып, «гомуми мөселманлык» позициясеннән торып караудан килә» (5 бит). «XIX гасырда Волга — Урал буе «төрки»ендә таралган әдәбиятта да башкортларның өлеше бар. Монда да күп нәрсә уртак — ике әдәбиятның да мирасына карый. «Өлеш»не билгеләгәндә, уртаклыкны күрсәткәндә, монда да к ү р е н е ш л ә р г ә ү з с ы й ф а т л а р ы н н а н ч ы г ы п я к ы н к и л е р г ә, а л а р г а т а р и х и күзлектән карарга кирәк...» (39 бит).

Менә монда ике нәрсәне аерырга кирәк: 1) мәсьәләнең принципиаль теоретик куелышы, фәнни критерий билгеләү; 2) шушы мәсьәләнең конкрет әдәби фактларда, күренешләрдә (Т. Ялчыгол, Ш. Зәки, Г. Чокрый, М. Гафури, Ш. Бабич) конкрет хәл ителеше, ничек тикшерелүе.

Ә. Харисов үзенең гыйльми максатын билгеләгәндә фәнни терминнарны («уртаклыкның характеры», «аның асылы», «әдәби күренешләрнең үз сыйфатлары», «аларга тарихи күзлектән карау») дөрес билгели. Әмма шунысы кызык, ул боларның беренчесенә һәм иң әһәмиятлесенә — «уртаклыкның характеры» — игътибарны юнәлтми, аны ташлап калдыра. Дөресрәге, шуны бөтенләй икенче нәрсә — «әдәби күренешләрнең сыйфаты» төшенчәсе белән алмаштырып, соңгысын исбатлауның бердәнбер аргументына әверелдерә һәм китапның буеннан-буена тикшерү практикасында да бары шуның буенча гына бара.

«Уртаклыкның характеры» дигән әйбер, минем аңлавымча, тарихи-иҗтимагый төшенчә. Ягъни ике халыкның (башкортның һәм татарның) ничек итеп иҗтимагый якынаюының, икесенең дә өлеше кергән әдәби байлыклар иҗат итәрлек хәлгә килү тарихын ачу дигән сүз, бердәм иҗтимагый-культура коллективында кайсы этниканың активрак булуын, кайсысының социаль-этник психологиясенең чагылуы һәм әдәбиятның әнә шул социаль психологиянең үсүенә хезмәт итүен ачу дигән сүз. Монда инде һәр

---

[1] Ә. Харисов китабыннан өземтә, специфик башкорт сүзен саклаган хәлдә, татарча китерелә. Китерелгән өземтәләрдә курсив безнеке.

[2] К о м а р т к ы — истәлек.

[3] А й ы ш — асыл, төп сыйфат.

ике этниканың — татарның да, башкортның да иҗтимагый үсешен, эшчәнлеген аерып, конкрет-тарихи күз алдына китерә алу, боларны якын иткән тарихи хәлләрне политик, социаль-экономик, сыйнфый моментлары белән күрә белү таләп итеэ. Моның өчен XVIII гасырның урталарына кадәрге дәверне, ягъни ретроспектив моментны яхшы белү кирәк. Хәлбуки, бу — Ә. Харисов китабында юк. 40—41 биттәге 20—30 юллы аңлатма идиллия характерында гына, конкрет тарих түгел[1]. Автор хәзерге Башкортстан туфрагында «адым саен... укый белсәң, канлы көрәш, яулар пичәте», дәвер эзләре ята дисә дә (25 бит), конкрет эше, фактлар, документлар белән шул эзләрне күрсәтеп бирә алмаган. «Кыйссаи Йосыф» ише Болгар — Казан ягыннан Уралга килгән әдәбият турында сөйләгәндә дә Ә. Харисов үз фикерләрен документ белән дәлилләргә, бу әсәрләрнең башкорт арасында эшләнгән кайсы гасыр күчермәләре булу хакында мәгълүмат бирергә тиеш иде.

«Бохарадан кәрван килә» дигән бүлектә Уралның Урта Азия белән экономик-культура бәйләнешләре тәфсилле һәм кызыклы итеп тасвирланса да (155—158 бит), бу мөнәсәбәтне алып баручылар башлыча Казан татарлары булуы, Уралда башланып киткән мәгърифәт, әдәбият тормышының да йогынтылы көчләре татарлар булуы бөтенләй диярлек ачылмый кала.

Инде «әдәби күренешләрнең сыйфаты» дигән төшенчәне алыйк. Бу да әдәби-тарихи төшенчә. Гадәттә беренче — тарихи-иҗтимагый нигезне таныганнан соң гына әдәби әсәрне эчтәлек һәм форма ягыннан дөрес өйрәнеп була. Теләсә нинди төр танып белү дә тарихи моментны үз эченә алганлыктан, бу ике төшенчә гадәттә бер-берсе белән органик рәвештә бәйләнгән. Ягъни төп игътибар әдәби әсәрнең фикерен һәм тел-стилен тануга, тикшерүгә генә юнәлтелгән хәлдә дә — әгәр бу тану алдан уйлап куелган, кайдандыр алынган уйдырма караш өчен мисал эзләү, иллюстрацияләү юлы белән түгел, бәлки фактлар җыелмасын тарихи конкрет, фәнни объектив тикшерү юлы белән хәл ителә торган булса — үзеннән-үзе әдәбиятның тарихи-иҗтимагый нигезен аңлау ихтыяҗын китереп чыгарыр иде. Шулай итеп, димәк, беренче нокта да игътибардан төшмәс иде. Ә. Харисовның XIX гасырның I яртысындагы Урал төбәгенә карата (текстларның эченә кереп тормыйча гына) бары тик вульгар карашлардан гына чыгуы аны үзеннән-үзе кайсы халыкның иҗтимагый продукты булуы, кемнең үсүенә хезмәт итүе кебек мәсьәләләргә якын да китермәгән. Урал төбәгендәге «әдәбиятның сыйфаты»н тану өчен, аны Казан ягы әдәбияты (Г. Утыз Имәни, Г. Курсави, Г. Кандалый һ. б.) белән бәйләнештә карау кирәк иде. Хәер, Урал төбәгендәге әдәбият та бөтен вәкилләре (Исмәгыйль Бикмөхәммәт угылы, Габделмәннан Мөслимов) һәм бөтен төр әсәрләре белән файдаланылмаган. Башлыча нәзым белән язылган әсәрләргә генә күзәтү ясалган. Әмма аннан, тарих белән исәпләшмичә, еш кына шигърилек таләп итү сизелгәләп китә. Урал төбәгенеке генә булмаган, авторлары да, иҗат итәлү вакытлары да бик үк билгеле булмаган аноним поэзия белән мавыгу да төп темадан һәм үзенчәлекле мәсьәләләрдән ерагайта гына. «Илаһи әйләмә мохтаҗ, шу дүрт адәм капусына» (219 бит), «Күңелдән кидәрер өч нәснә кайгу» (226 бит) кебек Г. Утыз Имәни шигырьләренең аноним әсәрләр исәбенә кертелүе, бу әсәрләрнең байтагысының инде күптән бастырылган, фәндә билгеле булуларының исәпкә алынмавында да текстология мәсьәләләренә игътибарсызлык күренә.

Тикшерү ысулындагы кимчелекләрнең нинди аяныч хәлгә китерүен Ә. Харисовның сөземтәләреннән аермачык күрәбез: «XVIII—XIX гасырларда поэзия башкорт җәмгыятенең көзгесе, идеологиянең системалы бер күренеше булып үсү төсен алмаган иде әле. Дөньяви шигырьләр языла, укыла, тыңлана һәм кульъязма рәвештә тарала килгән. Әмма аларның авторлары «шагыйрь» дигән исемне дәгъва итмәгәннәр, билгесез булып кала килгәннәр. Авторларны шигырь язарга дәртләндергән нәрсә дә, күпчелектә, иҗтимагый үсештә үз-үзеңне тою һәм танудан, үзең вәкиле булган башкортларны яки татарларны үз тарихы, үз язмышы белән аерым халык итеп тою һәм шуның белән горурланудан килмәгән. Шуңа күрә шагыйрьләр — исемнәре мәгълүм булмаганнары да, мәгълүм булганнары да — гадәттә гомуми мөселманлык рухында (берәүләр дини

[1] Без бу мәкаләнең I бүлегендә әлеге катлаулы тарихның кайбер якларына туктадык, киләчәктә бу юнәлештә җентекләүле тикшеренүләр булыр дип уйларга кирәк.

юнәлештә, икенчеләр дөньяви юнәлештә) кешелекнең мәңгелек темаларына — мәхәббәт, әхлак, яшәү һәм үлем мәсьәләләренә багышлап шигырьләр язганнар» (238 бит).

Бу сөземтә Ә. Харисовның үзе тапкан һәм әсәрендә файдаланылган бик тар даирәле материал — интим һәм дидактик шигырьләр өчен генә дөрес. Шулай итеп, XVIII гасырның урталарына хәтле Башкортстанда булган иҗтимагый эчтәлекле әдәбият бөтенләй игътибардан читтә кала. Ә. Харисов бу чорда «Башкортстанда берсен икенчесе алмаштырып, әдәби эстафета каләмен кулдан-кулга тапшыра килгән язучылар булмады» дип (15, 25—26 битләр) катгый хөкем чыгара. Мондый әдәби эстафетаның һәм «үз язмышы булган халык» итеп тою, көрәш рухы белән сугарылган әдәбиятның булганлыгы, аның патша түрәләре тарафыннан даими рәвештә эзәрлекләнеп торуы, шуңа күрә әсәрләрнең кульязмалары да аз саклануы яки бөтенләй сакланмавын белер өчен укучыга үзе эзләнеп табарга гына кала (бу хакта без журналның 5 нче санындагы мәкаләдә һәм монысының баштагы бүлегендә азмы-күпме мәгълүмат бирәбез).

Ә. Харисовның XIX йөз татар-башкорт поэзиясенең идея-тематик даирәсе, сәнгатьчә үзенчәлекләре хакында йомгагы да (378—380 бит) әдәби фактлар җыелмасыннан чыгарыла торган тарихи дөреслеккә туры килми. Авторның әлгәрегә татар әдәби теленә карашы тагын да сәеррәк. Ул болай яза: «Шикайәтләр «төркичә», соңрак татарча язылган» (37 бит). «Һәрбер язма комарткы әдәби тел күренеше була алмый әле. Моның өчен югарылыгына «күтәрелгән», әдәби «иләктән» үткәрелгән булуы шарт. Мәсәлән, татар теленең кульязма текстлары моннан берничә гасыр элек барлыкка килгән, әмма татарга аңлаешлы татар әдәби телендәге тәүге китаплар XIX гасырның икенче яртысында гына күренә башлый» (34 бит). «Таҗетдин Ялчыголов белән Әбелмәних Каргали язган әсәрләрнең телләре башкорт та, татар да тиз генә аңламый торган тел, чамадан тыш гарәпләштерелгән «төрки» (40 бит).

Боларның бөтенесендә дә бер фикер үткәрелә: Идел — Урал буе «төрки» теленә хәзерге татар теленең дә, башкорт теленең дә мөнәсәбәте бер үк төрле, тигез икән (янәсе, ул бүгенге көндә икесенә дә... аңлашылмый, «төрки тел» бер нәрсә, «татар теле» исә бөтенләй икенче нәрсә, гүя ки «төрки тел»дән «татар теле»нә эзлекле күчеш булмаган). Монда язма әдәби телгә үзгәреп, үсеп, баеп тора торган иҗтимагый-тарихи бер күренеш итеп карау җитми. Хәлбуки, бу язма тел татар халкының иҗтимагый үсеш ихтыяҗлары нәтиҗәсендә туды. Шундый ук ихтыяҗлар нәтиҗәсендә үсә килде, хәтта аерым шартларда ул бик тә катлауланырга, башка телләр (гарәп, фарсы, төрек, үзбәк) белән мөнәсәбәткә керергә, алар йогынтысына бирелергә мәҗбүр булды. Монысы да тарихи зарурилык, иҗтимагый үсеш ихтыяҗы сәбәпле иде. Һәм, ниһаять, заманы, шарты килү белән үзенең күп гасырлык үсешенең логик нәтиҗәсен дә бирде: яңа сыйфат эверелешенә кереп, халыкның яңа иҗтимагый үсеш этабының теленә эверелде — безнең хәзерге татар әдәби теле әнә шундый диалектик үсеш нәтиҗәсе ул. Идел буе «төрки»се — билгеле бер дәвердә татар халкы сөйләшкән телнең лингвистик хасиятьләрен чагылдыра. Әмма ул, культуралашкан, язма әдәби тел буларак, берничә төрле стиль үзенчәлекләре алып, шушы ук халыкның (һәм бары тик аныкының гына!) катлаулы иҗтимагый-тарихи мөнәсәбәтләрен, халыкның иҗтимагый үсеш, аң-белем дәрәҗәсен дә чагылдыра. Шуның белән ул кинрәк социаль мәгънәгә ия һәм нииндидер анадан тума, бишектәге хәлендә калмаган, һәм бу телнең борынгы хатирәләрен тикшергәндә дә әнә шундый тарихи-иҗтимагый аң белән карый белергә кирәк. Автор менә шушы «төрки тел»гә башкортның да мөнәсәбәте татарныкы шикелле үк булуын, уртаклыкны «исбатлый». Һәм шушы телнең XIX гасыр урталарына хәтле Башкортстанда да кулланылуын күздә тотып, андагы иҗтимагый функциясенең татарлар белән бәйләнешле булуын инкарь итәргә тырыша һәм татар теленең Башкортстандагы функциясен бары XIX гасыр урталарыннан гына башлый. Китапның буеннан-буена бары тик «төрки тел» дигән терминның гына кулланылуы да һичничек тә акланмый. Бу исем билгеле бер халык телен белдерми, бәлки «роман теле», «славян теле» дигән шикелле бер төркем телләр ыругының нәсел-нәсәп атамасы буларак йөртелгән һәм, башка ыругдан булган телләр (мәсәлән, гарәп, фарсы) белән бутамас өчен, шушы гомуми терминны үз язма телләренә карата үзбәкләр дә, төрекләр дә һәм татарлар да кулланган. Бу мөстәкыйль өч халык, өч регионның язма теле лексик-грамматик нормалары, диалекталь нигезләре белән катгый аерылып торуына карамастан, һәркайсының үзенә генә хас исеме булмау, борынгы заманда, әлбәттә, принципиаль әһәмияткә ия булма-

ган. Әмма хәзерге көндә башкача: фәндә борынгы телнең исемен дә шул телнең иҗатчысы, иясе һәм варисы булган халыкның исеме белән миллиләштереп алу кабул ителгән. Әйтик, XIII—XIX гасыр Идел буе «төрки тел»ен гадәттә фәндә «борынгы татар теле» дип алалар [1].

Китапта Ә. Харисовның әнә шул Идел буе «төрки»се хакында бердәм, төпле фикере юклыгы күренә. Бер урында Идел — Уралның үзенә генә хас язма теле булуы хакында әйтелсә (21 бит), икенче урында Идел — Урал буена язма телнең бары Урта Азиядән генә китерелүе хакында сөйләнә (50 бит). Болар бит бер-берсен юкка чыгара торган ике фикер. Һәм фәндә инде аның соңгысының дөрес түгел дип ташланганына да берничә дистә ел гомер үтте.

1905 елга кадәрге татар әдәбиятының тарихи-иҗтимагый мәгънәсе, сәнгатьлелек дәрәҗәсе чамалы гына булуы хакында фикерләр әлегрәк тә аз әйтелмәде. Әдәбиятның халык, җәмгыять, замана белән бәйләнмәгәнлеге, «мөселманлык» рухында гына булуы, язма әдәби телнең дә татарның үз иҗаты гына булмыйча, кайдандыр эшләнеп китерелүе, корама гына булуын билгеләү кайчандыр гадәткә кереп киткән иде. Һәм мондый нигилистик караш, төрле объектив тарихи-иҗтимагый һәм субъектив сәбәпләр аркасында, аклана да иде. Әле ул вакытта чын мирас тарих тузаны астына күмелгән хәлдә ята иде. Шуңа күрә татар әдәбияты һәм әдәбият белеменең зур авторитетларының (Г. Тукай, Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди, Г. Рәхим һ. б.) әсәрләрендә дә инде бүгенге көн өчен әһәмиятен югалткан, тарихи дөреслеккә туры килми торган кайбер ялгыш фикерләр булуы безне дә бер дә гаҗәпсендерми. Ә. Харисов исә үз китабында еш кына аларның менә шундый бүгенге көн өчен искергән фикерләрен файдалана, аларның әсәрләреннән өзекләр китереп, үз карашын үткәрер, куәтләр өчен бер чара, дәлил итә (мисал өчен 21—22, 29 битләрдә Г. Тукай фикерләрен ничек аңлау һәм аңлатуны карагыз). Мирасны тану һәм халыкка кайтаруда зур уңышлар дәвере булган соңгы 10 ел эчендә чыккан хезмәтләр тиешенчә файдаланылмаган.

Ә. Харисовның 1905 елга кадәрге татар поэзиясенә һәм татар әдәби теленә карашының дөрес түгеллеге инде безнең матбугатта азмы-күпме тәнкыйть ителде [2]. Әйе, мондый төпле, дәлилле тәнкыйтьләр дә бик кирәк һәм алда һәр мәсьәлә буенча тагын да тәфсиллерәкләре булыр дип өмет итәбез. Әмма бу китапка икенче төрлерәк; авторның тикшеренү методларындагы кимчелекләр, аның мәгълүм концепцияләрне нинди алымнар белән иллюстрацияләве ягыннан тәнкыйть күп өлеш кызыклырак һәм файдалырак булачак.

Вульгар концепциянең нинди арсеналдан алынуы ягыннан бигрәк тә, мәсәлән, XIX гасырның I яртысындагы Казан татар китапчылыгына күзәтү кызыклы (205—206 бит). Ә. Харисов бу китапларның «иң зур өлеше кешене дин сөреме белән исәңгерәтүгә, аны дөньядан биздерүгә исәп тоткан», — дип нәтиҗә ясый (205 бит). Безне, нәтиҗәдән бигрәк, бу хәлнең сәбәпләрен ничек аңлату кызыксындыра. Ә. Харисов моның ике төрле сәбәбен ачып бирә: беренчесе — татар байлары һәм руханиларының «грамотасыз халыкны эксплуатацияләү һәм башын каңгырату өчен басма сүздән намуссыз файдаланучылар» булуы. Ә. Харисов бу хөкемне Казан китапчылыгына күзәтү характерындагы мәкалә белән чыккан профессор В. Д. Смирновтан ала. Аннан берничә цитата китерә һәм азакта «бик дөрес әйткән» дип үз бәясен кушып куя. Икенчесе — татарлар арасында «кульъязма китап кына — чын китап ул» дигән караш булуы, басма китапка кырын караулары, аннан йөз чөерүләре, һәм, шул сәбәпле, күп кенә әсәрләрнең бары тик кульъязма хәлендә генә йөрүләре, басмага үтмәүләре (199, 205 бит). Бу фикер дә В. Д. Смирновтан алынган.

Татар китапчылары арасында чын-чынлап үз халкын дөньяви, заманача мәгърифәтле итәргә тырышучылар аз булмаган. Әмма аларга 50—60 ел буе башлыча дини китаплар гына бастырып ятырга туры килгән икән, без моны татар китапчыларының

---

[1] Бу турыда тәфсиллерәк мәгълүматны түбәндәге хезмәтләрдән алырга мөмкин: Хорезми. Мухаббатname. Мәскәү. 1961. Ә. Нәҗип язган сүз башы. 7—10 һәм 16—21 битләр; Н. А. Баскаков. Тюркские языки. Мәскәү. 1960 ел. 160—161 битләр; Ә. Нәҗип. Татар әдәбиятының һәм әдәби теленең кайбер онытылган язма истәлекләре турында. «Совет әдәбияты» журналы. 1957 ел. 12 сан. 87 бит. Шул ук елгы 4 сан. 94—95 битләр.

[2] Шакир Абилов. Борынгы татар әдәбиятын өйрәнүнең өлгергән проблемалары. «Казан утлары» журналы. 1966 ел. 6 сан. 136—137 битләр. Хатип Госман. Татар поэзиясе тарихында Тукайның урыны. Шунда ук, 1966 ел. 10 сан. 112—123 битләр.

сыйнфый максатлары белән генә түгел, бәлки алар өстеннән хакимлек итеп торган, йогынтылырак көч булган патша монархиясе тәртипләре, аның катгый цензурасы белән аңлатабыз. Димәк, әлеге ике сәбәп тә нигезле түгел. Әйтелгән сүзнең мәгънәсендә әйтүчесенең иҗтимагый йөзе чагылу мәгълүм бер хәл. Әлеге сүзләрне әйтүче В. Д. Смирнов кем соң ул? Петербург университетының Көнчыгыш факультетында Төркия тарихы һәм әдәбияты буенча профессор. Төрки халыкларның телләрен, әдәбиятын, тормышын гыйльми нечкәлек белән белүен ул Петербург цензура комитетында татар китабы буенча цензор булып торганда тулысынча файдаланган, дөньяви эчтәлекле, заманы өчен әһәмиятле бер генә иҗтимагый фикерне дә үткәрмәгән, сөзеп, кызыл белән сызып торган. Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдин, Ф. Халиди, Т. Яхин кебек татар авторларының китаплары да бу язмыштан читтә калмаган[1]. 20—30 ел буе татарча китап өлкәсендәге алга омтылышлы фикерләрне буып ятучы В. Д. Смирновка Казан татар китапчылыгына «фәнни» күзәтү-очерк язып чыгу ни өчен кирәк булган соң? Рус җәмәгатьчелегендә татарлар хакында ялгыш фикер тудыру, патша хөкүмәтеннән һәм аның цензурасыннан гаепне төшереп, бөтенесен бары бичара татар китапчыларына гына аударып калдыру өчен эшләнгән бу. Аның цензор буларак эшчәнлеге милли-колониаль изүне мөһим бер өлкәдә практик гамәлгә ашыруы булса, «фәнни очерк» белән чыгуы исә әнә шул изүгә теория юлы белән хезмәт итү була. Бу очерк чын, академик фән белән бернинди уртаклыгы булмаган официоз, апологетик «фәннең» сыйнфый асылын һәм фальсификация методларын өйрәнү өчен генә әһәмиятле.

Ә. Харисов менә шушындый типтагы берничә автордан өземтәләр алып файдалана да, «бик дөрес әйткән», «без моңа кушылабыз» дип үзенең мөнәсәбәтен белдереп куя (мисал өчен карагыз: проф. М. В. Флоринскийдан файдалану, 28 бит; татар халкының музыкага, имештер, сәләтсез булуы хакындагы уйдырма караш тарафдары С. Г. Рыбаков фикерләрен файдалану, 58 бит).

Дөрес, Ә. Харисов китабында кызыклы һәм әһәмиятле генә сәхифәләр дә юк түгел. Бу бигрәк тә татар гыйльми мирасындагы кайбер казанышлардан файдалана белүдә күренә. Мәсәлән, Мәрҗани һәм Фәхретдин әдәбиятны мәгърифәт йортлары — мәдрәсәләр белән бәйләнештә карыйлар иде. Ә. Харисов та мәдрәсәләр тарихына кагыла, мәдрәсәдәге кульъязма китапчылыкка киң туктала. Р. Фәхретдиннең «Асар»ындагы фактлар нигезендә ул бик кызыклы очерклар язган. Гәрчә аның күзәтүләре сай, өстән-өстән генә булса да, әлегә мондыйларының да булмаганлыгын искә алганда, әһәмияте юк түгел. Күренекле әдип, публицист, тарихчы һәм фикер иясе Р. Фәхретдин мирасын тәкъдир итү буенча да Харисовның эше игътибарга лаеклы.

Татар гыйльми мирасыннан иҗади рәвештә файдалана белү китапның икенче бер моментында да ачык күренә. Бу — татар халкы арасында Урта һәм Кече Азиядән алып кайтылган, әмма тора-бара үзебезнеке шикелле булып үзләшеп киткән төрки әдәбият әсәрләренә мөнәсәбәт мәсьәләсе. Боларны татар халкы вәкилләре иҗат итмәгән, әмма аерым тарихи-иҗтимагый шартларда читтән үзләштерү һәм сайлап алу үзе генә дә бер иҗат төсен алырга, читтән кергән әсәрләр билгеле бер дәвернең әдәби зәвыгын, фикер дәрәҗәсен чагылдыра торган, халык тарихының аерылгысыз бер элементына әверелгән бер байлык тәшкил итәргә мөмкин. Заманында Г. Ибраһимов та бу мәсьәләгә мөнәсәбәтен белдереп, болай дигән иде: «Дәхи бар башка туфракта туып та үз әдәби малыбыз кабиленнән[2] булып киткән әсәрләр. Боларның бер груһы[3] — Рабгузи, Бакыргани, Ясәви кебек — чыгытайдан[4], бер груһы — «Мөхәммәдия», «Сәед-Баттал» кебек — госманлылардан[5] безгә керде. Болар бездә гаммәнең[6] кыйммәтле җан азыгы — үзләшкән әсәрләр булганга, әлбәттә шул вакытның тарихын тулы белү өчен бездә өйрәнелергә, дәреслеккә кереергә, әдәбият тарихыбызда кайдан килүләре әйтелеп тикшерелергә тиешләр» («Безнең юл» журналы. 1922 ел. 2 сан. 44—45 битләр). Әдәбиятыбыз тарихын шушы принцип буенча беренче тикшерү-

---

[1] Бу турыдагы фактларны кара: Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапхана кульъязмаларының тасвирламасы. V чыгарылыш. Казан. 1960 ел. 21, 40—41, 50, 52—51 битләр; Шул ук, Х чыгарылыш. Казан. 1962 ел. 22, 43—44 битләр.

[2] Кабиленнән — категориясеннән.

[3] Груһ — төркем.

[4] Чыгытай — борынгы үзбәк теле.

[5] Госманлы — төрекләр.

[6] Гаммә — масса.

челәр Гали Рәхим һәм Газиз Гобәйдуллин булды. Алар бу стабиль репертуардагы әсәрләргә генетик классификация ясап, һәр әсәргә аерым-аерым характеристика бирделәр[1]. Шунысын да әйтеп китик, соңгы елларда бу принцип башка тугандаш халыкларның әдәбият тарихы фәнендә дә кулланыла. Мәсәлән, үзбәк галимнәре үзләренең әдәби мирас хәзинәсенә атаклы әзербәйҗан шагыйре Фөзулины да кертәләр[2]. Димәк, Ә. Харисов китабының «Классик Көнчыгыштан кергән әдәби комарткылар» дип аталган бүлеге безгә әдәби мирасның кызыклы бер почмагына якты төшерә.

Әмма мондый бер-ике уңай сыйфат кына Ә. Харисов китабының тулаем кимчелеген каплап кала алмый. Ул татар телендәге Урал әдәбиятының специфик күренешләрен тикшерүдә дә рациональ тәҗрибә бирми, тагын да зуррак, киңрәк гомумилеккә — гомумтатар әдәби мирасына карашы да тамырыннан ялгыш булып тора.

Шуның белән Ә. Харисов башкорт халкының да әдәби үткәнен бозып күрсәтә һәм, нәтиҗәдә, башкорт укучысы тарихи дөреслекне танудан мәхрүм хәлдә кала. Иҗтимагый йөзе ниндидер абстракт «мөселман», «төрки» итеп кенә тәкъдим ителгән әдәби мирасны башкорт укучысының үзенеке итеп кабул итмәве һәм мондый китапның чыгуына ризасызлык белдерүе мөмкин.

Мирасны фәнни хәл итүнең икенче яклап та әһәмияте бар. Уралдагы язма әдәбият мирасына мөнәсәбәт ул китапханә яисә архив тузаны кунып беткән, гасырлар буе хәрәкәтсез яткан, иясе билгесез борынгы кулъязмаларга мөнәсәбәт кенә түгел. Бу — әнә шуларның төп иҗатчысы, иясе һәм варисы булган, бабалары иҗат иткән рухи байлыкны саклап һәм үстереп килә торган татар халкына да мөнәсәбәт. Аның өчен мираста «өлеш билгеләү» мәсьәләсе тормый, чөнки ул моны инде күптән эшләгән, аны чын-чынлап фәнчә тикшерү эшенә дә моннан йөз ел элек үк тотынып, эзлекле рәвештә аны танып, бәяләп, үзенең үсеше өчен кирәк күләмдә файдаланып килә. Гасырлар буе Уралда гомер сөреп килгән, бүгенге көндә дә шунда яши торган татарлар бу төбәктә иҗат ителгән әдәби хәзинәнең тере варислары булып торалар. 1959 елгы халык исәбе алу мәгълүматлары буенча, Башкортстанда 768,6 мең татар яши — бу БАССРдагы бөтен халыкның 23%ын тәшкил итә. Шуның өстенә 348,7 мең башкорт, ягъни башкортларның гомуми санының 35% ы туган теле итеп татар телен исәпли һәм татар телендәге әдәбиятны үз туган әдәбияты итеп күрә[3]. Әлеге әдәби мирасның иҗтимагый йөзен дөрес аңлатмау, бозып тәкъдим итү, бертуган, игезәк ике халыкның бер-берсенә мөнәсәбәтләренә ялгыш тон бирүе мөмкин, туганлык, дуслыкка файда итмәве мөмкин. Шагыйрь әйтмешли, «Өфе белән Казан арасы — ике дус кул сузган арасы» гына бер җирдә мирасны өйрәнүдә Башкортстан белән Татарстан арасында ике төрлелек булырга тиеш түгел, киресенчә, уртак мирасны чын-чынлап уртаклашып өйрәнергә тиешбез.

* * *

Җыеп кына әйткәндә, татар мәгърифәтен, әдәбиятын төбәкләр буенча конкрет тарихи өйрәнүнең гаять зур фәнни әһәмияте бар. Мондый тикшеренүләрне төпле нигезгә кую өчен эшлисе эшләр күп: Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдин, Г. Ибраһимовларның гыйльми мирасын иҗади рәвештә файдаланырга, билгесез яткан язма истәлекләр исәбенә чыганаклар базасын киңәйтергә, баетырга, тикшеренүләрне төрле яклап, күпкырлы итеп алып барырга кирәк. Киләчәктә эшләнәчәк мондый хезмәтләр гомумтатар әдәби мирасын тануга җитди өлеш булып керерләр дип ышанасы килә.

---

[1] Татар әдәбияты тарихы. I җилд. 2 бүлек. Казан. 1923.
[2] Үзбәк адабиети. Түрт томлик. IV том. II китап. Үзбәк телендә. Ташкент. 1960 ел. 9—110 бит.
[3] Ә. Харисов, күрсәтелгән китап, 35 бит; Народы Европейской части СССР. Рус телендә. II том. Мәскәү. 1964 ел. 684 бит.

*Тәлгат Галиуллин*

# ПОЭМАНЫҢ БАРЫР ЮЛЛАРЫ

Иҗтимагый тормыш шартлары үзгәрүгә, халыкның сәнгатьчә фикерләве, рухи таләпләре үсүгә бәйле рәвештә, илленче елларның урталарыннан поэма жанрында да «яңарыш» чоры башланды. Эпик поэзиянең моңарчы онытылып торган төрләре яңадан активлашып китте, милли традицияләргә игътибар үсте; яңа эчтәлек, кешенең рухи дөньясына тирәнрәк үтеп керергә омтылу поэманың тасвир чараларын бермә-бер баетып җибәрде.

Соңгы унъеллыкта поэма жанры нигездә төп ике юнәлештә үсте. Беренчедән, язмышлар бәрелешенә, вакыйганың эзлекле үсешенә нигезләнгән традицион поэма, мәгълүм үзгәрешләр кичереп, алга таба үсешен дәвам итте. Икенчедән, поэма жанрында субъектив башлангыч бик нык көчәйде. Матбугат битләрендә шәхеснең уй-кичерешләрен сурәтләүгә багышланган һәм еш кына лирик монологлардан торган, иркен композицияле лирик-фәлсәфи поэмалар күренә башлады. Стильләр төрлелегенә омтылу, әзер схемалардан качарга тырышу, поэманың яңа мөмкинлекләрен эзләү матур бер традициягә әйләнде.

Поэманың үсеш юлын гадиләштереп, туры сызык рәвешендә күз алдына китерергә ярамый, әлбәттә.

Соңгы елларда поэма жанры үткән юл шактый сикелтәле булды. Капма-каршы тенденцияләр, төрле характердагы эзләнүләр, әдәбиятның башка жанрлары белән аралашып китү очраклары әнә шул турыда сөйли.

* * *

Лирик поэма илленче елның урталарында зур бәхәсләр уятты. Аны кайнар яклаучылар да, бөтенләй инкарь итеп чыгучылар да булды. Бу кылыч чакыштыруларның әле бүген дә тукталганы юк. Әмма хәзер бер нәрсә ачык: соңгы еллар татар поэзиясен С. Хәкимнең «Язьгыз, җир улллары», «Үрләр аша...», И. Юзеевның «Тынлык белән сөйләшү», Р. Әхмәтҗановның «Йолдызстан», Ш. Галиевнең «Әткәйгә хат» шикелле лирик-фәлсәфи поэмаларыннан башка күз алдына китереп булмаячак.

Поэма жанрында шәхси-лирик башлангычның көчәеп китүен һәм акрынлап алгы сызыкка чыгуын очраклы бер хәл, дип кенә аңлатып булмый. Ул татар поэзиясендә һәм бөтен совет әдәбиятында барган катлаулы эчке үзгәрешләрнең табигый чагылышы иде. Совет демократиясенең тагын да чәчәк атуы, Ленинча тәртипләрнең яңадан гамәлгә керүе лирик поэзиянең үсеп китүенә нык ярдәм итте: хискә чикләнмәгән ирек бирелде. Лирика үзенең игътибарын кеше күңеленә юнәлтте, шәхеснең рухи камилләшүен, чәчәк атуын сурәтләде. Чынбарлыкны тасвирлау алымнары күп мәртәбә катлауланды, төрләнде. Иҗади активлык рухы өлкән шагыйрьләр поэзиясендә дә, яшьләр иҗатында да ачык сизелде. Х. Туфан лирикасы яңа сыйфатларга баеп үсеп китте. С. Хәким үзенең фикергә һәм хискә бай иң уңышлы лирик парчаларын нәкъ шул елларда иҗат итте. И. Юзеев, Ш. Галиев, Г. Афзал, Ә. Баянов, Х. Камалов шикелле сәләтле

яшьләр тавышы да татар укучыларына лирика дулкынында килде.

Ләкин бу әле — поэмаларга булган ихтыяҗ кимеде, зур полотнолы әсәрләр иҗат итү мәсьәләсе көн тәртибеннән төште, дигән сүз түгел. Шагыйрьләр, эпик поэзиянең мөмкинлекләрен киңәйтергә омтылып, яңа сукмаклар эзләүне дәвам иттеләр. Матбугат битләрендә шигырьгә бик якын торган беренче лирик поэмалар күренде. Ш. Галиевнең «Әткәйгә хат», И. Юзеевның «Әнкәй», М. Шабаевның бераз соңрак язылган «Сине эзлим» кебек поэмаларында лирик шигырь белән уртаклык бик ачык сизелә. Аларда төгәлләнгән вакыйга да, катлаулы характерлар да юк диярлек. Бу әсәрләрнең үзәгендә лирик настроениенең алышынуы, кичерешнең эзлекле үсеше, шәхеснең уйланулары ята.

Илленче елларның икенче яртысыннан лирик поэзиядә яңа сыйфатлар төсмерләнә башлый. Чынбарлыкны эмоциональ буяулар аша гына сурәтләү хәзер инде шагыйрьләрне канәгатьләндереп бетерми. Илдә, дөньяда барган хәлләрне акыл көче белән дә аңларга тырышу тенденциясе көчәя. Бу исә фикер поэзиясенең үсешенә, интеллектуаль башлангычның көчәюенә алып килә. Сюжетлы шигырьләр күбәя, лирик характер эпик төсмерләр алып үсеп китә. Дәлилгә С. Хәкимнең «Хәйрулла», «Мари карты Филипп», «Имәт», «Артиллерист Гыйльфан», «Усал диләр мине» кебек шигырьләрен китерергә мөмкин. Мондый «объективлашкан» образлы әсәрләр Х. Туфан, Ә. Давыдов, Г. Хуҗиев, Ш. Галиев, И. Юзеевлар иҗатында да шактый.

Чорның олы проблемаларына, масштаблырак вакыйгаларына таба борылу лирика белән поэма арасында торган «синтетик» жанрлар үсешенә алып килде. Баллада, кечкенә поэма, шигъри цикллар күбәйде. С. Хәким «Суд залында», Ә. Давыдов «Себер трактында квартал», Х. Камалов «Туган җирдә» исемле, Ш. Маннур нефтьчеләр тормышына багышланган шигъри цикллар иҗат иттеләр. Х. Туфан һ. Такташ истәлегенә багышланган шигырьләр бәйләмен төгәлләде.

Тематик уртаклык, идея-эстетик һәм интонацион якынлык, кичерешнең эзлекле үсеше бер циклга кергән аерым әсәрләрне бер бөтен шигъри тукыма итеп кабул итәргә мөмкинлек бирә. Тәнкыйтьче Н. Юзиев С. Хәкимнең «Суд залында» әсәрләрен цикл итеп карауны хуплап бетерми. Шигъри бәйләмгә артык кырыс таләпләр белән килгәндә, тәнкыйтьче белән килешергә дә мөмкиндер. Ләкин С. Хәкимнең лирик поэзия формаларын киңәйтеп җибәрергә, жанр киртәләрен аударырга һәм аңлы рәвештә цикл тудырырга омтылуы — игътибарга лаек күренеш иде. Шигъри бәйләмнәр, балладалар, сюжетлы озын шигырьләр лирик поэзия белән поэма арасында күпер ролен үтәделәр. Бер мәлне лирик һәм эпик поэзия арасындагы чик, жанр формаларына хас үзенчәлекләр югалып калды. Баллада белән кыска поэма, шигъри цикл белән поэма арасындагы чикләрне билгеләү шактый кыенлашты. Шигъри жанрларны өйрәнүгә зур көч куйган әдәбият галиме Н. Юзиев, мәсәлән, С. Хәкимнең «Сары капкалы йорт» әсәрен бер урында баллада, икенче урында кыска поэмалар рәтендә карый. Э. Межелайтисның «Кеше», М. Кәримнең «Европа — Азия» шикелле кеше язмышы, аның уй-кичерешләре аша дәверне сурәтләгән әсәрләрен бер очракта поэма, икенче җирдә шигырьләр циклы дип атыйлар.

Лирик поэзиянең интенсив үсеше поэма жанрына торгынлыктан чыгарга булышты. һ. Такташның «Алсу», «Мокамай» поэмаларыннан соң тукталып торган кыска поэма жанры яңа шартларда кабат терелде. Ш. Галиев «Хупҗамал», М. Шабаев «Конрад», «Ди татарише фрау», «Шәймәт карт», Э. Мөэминова «Ефәк яулыгым», И. Юзеев «Язылмаган поэма» кебек үзенчәлекле әсәрләр яздылар.

Кыска поэма, вакыйганың үзен сурәтләүдән бигрәк, үзәккә кешене куя. Шәхес үз тормышының иң хәтәр, борылыш моментларында алына һәм кискен, ачык буяулар белән сурәтләнә. И. Юзеев үзенең «Язылмаган поэма»сында, вак детальләрдән, тәфсилле хикәяләү алымнарыннан баш тартып, эре романтик сызыклар, киеренке хис аша татар халкының батыр улы, шагыйрь Хәйретдин Мөҗәйнең соңгы минутларын гәүдәләндерә. М. Шабаевның «Шәймәт карт» поэмасында кеше рухы һәм тормыш күренешләре күңел көрлеге, уйнаклап торган юмор, көлү аша тасвирлана. Мәгънәсез, буш сүзләрдән качарга тырышу, фикер тыгызлыгына омтылу — бүгенге поэманың бер әһәмиятле үзенчәлеге. «Кешенең язмышын ачкан, аның психологик портретын ачык буяуларда күз алдына бастырган кечкенә күләмле эпик форма гомумән поэзиядә

активлашып бара»[1], — дип, Н. Юзиев бик дөрес яза.

Лирик поэма да бер урында тукталып калмады, акрынлап иҗтимагый эчтәлеккә, әһәмиятлерәк вакыйгаларга таба борылды, сәнгать, әдәбиятның башка төрләрә ирешкән казанышларны үзенә «сеңдерергә» омтылды. «Чорлар чатында» поэмасында Ә. Давыдов публицистика тәҗрибәсенә мөрәҗәгать итте, Р. Әхмәтҗанов фәнни фикерләү алымнарын игътибар белән өйрәнде, И. Юзеев, кеше күңеленең матурлыгын, рухи катлаулылыгын тирәнрәк ачып салу нияте белән, поэмага шартлы символлар, аллегорик образлар алып керде. С. Хәкимнең «Үрләр аша...» поэмасында баллада жанрының шифалы тәэсире ачык сизелә. Ватан сугышы герое Янар Ярулланың психологик портретын иҗат иткәндә, шагыйрь баллада жанрына хас тасвир чараларыннан шактый иркен һәм оста файдалана.

Дөрес, лирик поэма элек-электән килә торган традицион сыйфатларын да югалтып бетерми. Элеккечә үк ул — күләме буенча зур түгел, вакыйганы эзлекле тәртиптә ачып бирергә омтылмый, әһәмиятсез детальләрне, гади көнкүреш ваклыкларын сурәткә кертми, лирик-шәхси башлангыч поэманың төп эчке хасияте булып кала бирә. Әмма лиризмның чыганагы һәм функциясе үзгәрә. Хәзер ул, барыннан да бигрәк, авторның үз шәхесе белән бәйләнгән, шагыйрьнең олы дөнья белән актив мөнәсәбәткә керүе нәтиҗәсе буларак барлыкка килә. Кеше һәм чор язмышы турындагы сөйләмдә шигъри киңлек белән лиризм үзара аралашып китәләр. «Әнкәй» поэмасы И. Юзеев өчен дә, гомумән, лирик поэма өчен дә үтелгән чорга әйләнеп кала. Кайчандыр ачыш саналган «лирик поэма» термины үзе дә, жанрның салават күперсдәй төсләр байлыгын чагылдырудан бигрәк, традиция буенча гына сөйрәлеп йөрүче шартлы атамага әйләнә. Метафорик, фәлсәфи, публицистик, гиперболик һәм башка терминнар белән аталучы поэмалар күбәя. Ә. Давыдовның «Чорлар чатында» әсәрен, мәсәлән, нигездә лирик поэма алымнарына таянып язылган булуына карамастан, фәлсәфи-публицистик поэма дип йөртәләр. Бу — тәнкыйть капризы гына түгел. Бу әсәрдә шәхес кичерешләрен сурәтләүдән бигрәк, заман һәм чынбарлык турында уйланулар, шигъырьнең төп идеясен, әйтергә теләгән фикерен раслап килүче төрле күренешләр, публицистик чигенешләр әһәмиятле. «Тыныч мәхәббәт», «Яңгырлы таң», «Ферма кызы» поэмаларында башлаган эзләнүләрен дәвам итеп, шагыйрь публицистика белән художестволы образ арасындагы уртак ноктаны табарга, тормыш, яшәеш законнарына тагын да тирәнрәк үтеп керергә омтыла.

Поэма: «Беләсеңме, тормыш нәрсә ул?»; «Беләсеңме, бәхет ул нәрсә?» кебек сорауларга җавап эзләү рәвешендә язылган. Болар яңа сораулар түгел, билгеле. Әмма һәр чор ул сорауларга үзенчә җавап бирә. Егерменче гасырның икенче яртысында бәхет төшенчәсе дә, тормыш төшенчәсе дә бик нык үзгәрде. Дөньяда иминлек, тигезлек, дуслык юк икән, кеше чын мәгънәсендә бәхетле була алмый, ди шагыйрь. Бәхет турындагы фәлсәфә авторны иҗтимагый-политик мәсьәләләр турындагы уйлануларга алып килә. Поэманың аһәңе, сурәт алымнары да үзгәрә. Музыкальлек, гармония публицистик интонациягә, фикер энергиясенә юл бирә.

Кыскасы, «Чорлар чатында» поэмасы — лирик поэма тукымасында барган үзгәрешләрне чагылдыруы ягыннан да, күтәргән мәсьәләләре буенча да алтмышынчы еллар башы өчен ачыш иде. Әмма ул сезон җимеше булып калды, акрынлап онытылды. Төп сәбәп — авторның образлы тәкъбирләрдән, ачык һәм төсле буяулардан баш тартып, иҗтимагый хәлләргә иярүендә, аларны санап чыгу юлына басуында булса кирәк. Авторның вакыйгаларга һәм күренешләргә шәхси бәясе җитеп бетми. Шагыйрьнең тормыш, бәхет турындагы фәлсәфи сорауларга җавабы да, тулылыгы һәм яңалыгы ноктасыннан караганда, бәхәс уятырга мөмкин. Яшь шагыйрь өчен бу поэма, һичшиксез, шигъри ачыш булыр иде. Ләкин тәҗрибәле һәм колачлы шагыйрьдән олырак һәм яңарак фикер ишетәсе килә икән, бу да — табигый нәрсә.

«Чорлар чатында» поэмасы белән бер үк вакытта һәм, бигрәк тә аңардан соң, «эрепләндерелгән» образлы, ачык буяулы, иркен сулышлы поэмалар еш күренә башлады. Ә. Баянов, Р. Әхмәтҗанов, И. Юзеев, Ш. Галиев, М. Шабаевлар җиң сызганып лирик поэманың мөмкинлекләрен киңәйтү эшенә керештеләр. Дөрес, аларның эзләнүләре һәр очракта да уңышлы булмады.

---

[1] Н. Юзиев. Традицияләр яңарганда. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1966 ел. 169 бит.

Төрле стиль юнәлешләрен бергә кушарга омтылу шигъри индивидуальлекнең югалуына китерде, вак әйберләр турында зур фәлсәфә куерту декларативлыкка, фикер сайлыгына этәрде. Бу яктан Р. Әхмәтҗановның «Йолдызстан» поэмасы аеруча характерлы. Ул яшьләр иҗатына хас уңышларны да, кимчелекле якларны да күрсәтерлек мисал була ала.

Поэма космосны яулау романтикасын җырлауга, чордашларыбызга хас әхлакый үзгәрешләрне күрсәтүгә багышланган. «Йолдызстан»га романтик күтәренкелек, патетика һәм эмоциональлек хас. Шагыйрь, символик образлар, шартлы-романтик сурәтләр аша, чорны иңләргә, йолдызстанга үтеп керергә, замандашы турында матур һәм калку фикерләр әйтергә тырыша. Төрле яссылыкта яткан төшенчәләр, төрле тарихи чор вакыйгалары, ассоциатив метафора ярдәмендә, бер төенгә җыелалар. Галилей, Брунолар батырлыгы турындагы сөйләм бүгенге кешеләр язмышы хакындагы уйлануларга алып килә. «Кызу атылып янган йолдыз сыман, Коперниклар янган бу юлда», ди шагыйрь. Тора-бара ул сурәт киңәя, бүгенгә тоташа, «йолдыз булып атылып янам икән, нуры булып сиңа кайтырмын», дигән романтик төсмерле яңа метафора тууга җирлек әзерли.

«Йолдызстан» поэмасының шигъри тукымасында, ачык булып, ике стиль агымы сизелеп тора. Беренче агым шагыйрьнең үзенчәлекле ачышлары белән бәйле. Ул авторның заман, кеше турындагы уйлануларын, самими, эмоциональ хисләрен укучыга ачык һәм төгәл итеп әйтеп бирергә булыша. Икенче стилистик агым китап романтикасына барып тоташа. Автор, бер төркем яшь рус шагыйрьләре үрнәгендә, поэмасын аңлы рәвештә катлауландыра, эстетик ээлеклелектән баш тартып, фикерен ассоциацияләр болыты, «ертык» образлар өермәсе астында күмеп калдыра. Шул урыннарда фәлсәфи тирәнлек күпсүзлелек белән алмашына, синтетик фикерләүне абстракт гыйбарәләр ташкыны күмеп китү куркынычы туа, поэзиянең йолдызстаны — кеше йөрәге арткы планга күчә. Нигездә уңышлы язылган бу поэманың укучы тарафыннан төрлечә кабул ителүе дә, бәлки, нәкъ менә шул агымнар төрлелеге, аларны берләштерә алмау белән аңлатыладыр да...

Р. Әхмәтҗанов, үзенә якын интонацияне эзләп, Такташ поэзиясенә, Ф. Бурнаш, И. Йосфи, Ш. Фидаи кебек шагыйрьләрнең романтик ачышларына, фольклор сурәтләренә мөрәҗәгать итә, А. Вознесенскийның эксперименталь лабораториясенә ишек кага.

Шигъри горизонтын киңәйтергә омтылуы — куанычлы хәл, билгеле. Ләкин шагыйрьнең тәҗрибәләр чоры озаккарак сузылды шикелле.

«Чорлар аша» һәм «Йолдызстан» кебек әсәрләрдән күренгәнчә, лирик поэма шәхеснең интим хисләрен сурәтләү яисә шагыйрьнең үзе хакында уйлануларын күрсәтү белән генә чикләнми икән. Аны аерым бүлекләре арасында бернинди бәйләнеш булмаган, кирәк икән теләсә күпме һәм теләсә нинди юнәлештә кыскартырга да, сузарга да ярый торган поэманың җиңеләйтелгән төре дип күз алдына китерергә ярамый. Кичерешләрнең эзлекле үсеше, фикер логикасы, эстетик тәгәлләнгәнлек, сөйләмнең буеннан-буена сузылган эчке идеясе булмаганда, әсәр поэма санала алмый, лирик шигырьләр бәйләме булып кына кала. Шул яктан караганда С. Сөләйманованың «Язылмаган җырлар» әсәре, мәхәббәт хисен, сагыну сагышын шактый матур чагылдырган өлешләре булса да, поэма булу дәрәҗәсенә күтәрелә алмаган, лирик шигырьләр циклы, җырлар бәйләме булып калган. Бер генә кылдан торган уен коралы катлаулы көйләрне башкара алмый. Ә поэма бары тик катлаулы көйләрне генә уйнарга тиеш. Ахыр чиктә, хәзерге лирик поэма конкрет образлардан да, вакыйга сюжетыннан да баш тартмый. Ул үзенә төрле яссылыкта яткан гаять күләмле күренешләрне һәм хәлләрне, әһәмиятле вакыйгаларны бик җиңел сыйдыра ала.

Лирик поэманың яңа сыйфатларга баюы, шигъри эпоска тартымлык күрсәтүе С. Хәким әсәрләрендә бик ачык төсмерләнә. С. Хәким эпик поэзиядә күптәннән эшләп килә. «Бакчачылар» поэмасында шагыйрь төп игътибарын кеше язмышын сурәтләүгә, характер тудыруга юнәлткән иде. «Дала җыры» поэмасында ул масштаблы вакыйгаларны, ил йөрәгендә тирән эз калдырган хәлләрне иңләргә, аларны калку сурәтләрдә чагылдырырга омтылыш ясады. Шул ике юнәлештә эзләнүләр алып бару белән бергә, С. Хәким лирик эпос традицияләренә дә мөрәҗәгать итте. «Ленин фәрманы белән», «Үрләр аша...» һәм кайбер башка поэмалары әнә шул турыда сөйли.

«Үрләр аша...» поэмасы төзүчеләрнең фидакарь хезмәтен данлауга, халыклар арасындагы дуслыкны җырлауга багышланган. Әмма шагыйрь «вакыйга һәм факт» дәреслеген күрсәтү белән генә канәгатьләнми, поэманың офыгын бик нык киңәйтә, иҗтимагый-фәлсәфи нигезен тирәнәйтә. Әсәр, язгы чәчәк шикелле, һаман ачыла, тармаклана бара, хис төрле тирбәлешүзгәрешләр аша үтә, фикер киңәя, полифоник төсмер ала бара. Поэманың ишектәрәзәләрен чынбарлыкка һәм тарихка таба борып куеп, шагыйрь фикер агышына төрле юнәлеш бирә, сөйләмнең тонын һаман җанландыра тора. Әсәрнең умыртка баганасын авторның тормыш һәм кеше турындагы уйланулары тәшкил итә. Торбалар салып Халидә бара, ул ераккарак киткән, Көнбатышка атлаган саен, уйлануларның яңгырашы үзгәрә, кискен интонация беренче планга чыга. Берсен-берсе кысрыклап килгән әврмәле хисләр лирик геройны үткәнгә, зур тарихи вакыйгаларга алып кереп китә. Поэмадагы лирик-эмоциональ башлангыч драматизм белән алмашына, тойгыга, лирик хисләргә урын җитми башлый...

Батырлык һәм үлемсезлек турындагы уйлар туган ил, халык һәм аның характеры турындагы тирән фәлсәфи фикерләргә алып килә:

Халкым минем, болай бер карауга
Бик тынычсың, син бик юашсың.
Кирәк чакта трассалар өчен
Син айкыйсың тирән су астын...

Бу фикерләр гомуми дә, абстракт та түгел. Шагыйрь аларны Ярулла һәм Халидә тормышы мисалында раслый.

Шагыйрь Халидәнең бары татар милләтенең купчелегенә хас иң гомуми, җыелма сыйфатларын гына ача, башка үзенчәлекләре укучы хыялы белән тутырыла. Гомумиләштерелгән образларга, романтик сурәтләүгә таянып, дәресрәге, аларны реалистик сәнгать таләпләренә буйсындырып, автор беркет очышы биеклегеннән җир шарына караш ташлый, тарихны бүгенге чынбарлык итеп тоярга мәҗбүр итә. Шагыйрьнең уйланулары, эмоциональ кичерешләре, үткәнгә сәяхәтләре тар вакыйгачикләрен җимереп чыгалар һәм «Үрләр аша...» поэмасын лирик-фәлсәфи әсәрләр рәтенә кертергә мөмкинлек бирәләр.

Поэманың кайбер җитешсезлекләре турында матбугатта әйтелде инде. Яңа вариантында да әсәр «таплардан» азат түгел. Кайбер иптәшләрнең киңәшен тотып, фабула канвасын дәвам иттерергә омтылу, вакыйганы, проза әсәрләрендәге шикелле, ахырына чаклы илтеп җиткерергә тырышу поэмага зур яңалык өстәмәгән. Киресенчә, әсәрнең иҗтимагый-фәлсәфи ягын, чор һәм тарих турында уйланулар өлешен кочәйтергә кирәк иде шикелле. Әмма ничек кенә булмасын, «Үрләр аша...» поэмасы — татар поэзиясенең яңа уңышы. Ул егерменче йөз лирик эпосының камил формаларын эзләүнең, аерым кеше язмышы белән тарихи чор арасындагы бәйләнешләрне яңача күрсәтергә омтылуның нәтиҗәле адымы булды.

* * *

Бай традициясе, ерак гасырлардан килә торган олы тәҗрибәсе булган эпик поэма каршына тормыш тагын да катлаулырак таләпләр куйды. Шуның белән бергә, «сюжетлы» поэманың яңа сыйфатларга баюы гаять зур каршылыклар һәм әчке көрәш аша барды. Сугыштан соңгы поэманың аерым үзенчәлекләрен турыдантуры кабатлау, вакыйганы сүзгә-сүз сөйләп чыгу белән мавыгу, эпик поэзиянең үсешен гаять авырлаштырды. Моны шагыйрьләр үзләре дә ачык төшенделәр. Чорга хас форма эзләү өзлексез дәвам итте. Эпик поэма әдәбиятның башка төрләре ясаган ачышларга, бигрәк тә роман, повесть, новелла ачышларына мөрәҗәгать итте. С. Батталның «Олы юл буйлап» повестеның яңа варианты, «Чирмешән буйларында» исемле шигъри романы, Ш. Маннурның «Җир-әнкәнең сылу кызы» исемле тезмә повесте, Ә. Давыдовның «Су-юлы», «Уяну» поэма-новеллалары, Н. Арслановның «Егет яуда сынала» дигән поэмахикәясе һәм шундый характердагы башка әсәрләр басылып чыкты. Сүз дә юк, эпик поэзиянең тормышны иңләбрәк сурәтләргә омтылуы игътибарга лаеклы күренеш иде. Әмма бер ачыш икенче урында югалтуга да алып килде. Ниндидер «гибрид» жанр барлыкка килде, эпик поэзиядән романтик рух югалды, аны югары сәнгать төре иткән күп кенә башка үзенчәлекләр нык тоссезләнде яки бөтенләй диярлек юкка чыкты. Ш. Маннурның «Җир-әнкәнең сылу кызы» шигъри повесте, оста ювелир кулы белән эшләнгән һәм йөрәккә үтеп керерлек аерым урыннары булуга карамастан, киң тормыш күренешләрен тасвирлау ноктасыннан караганда да, характерларны

тормышчан, ышандырырлык итеп сурәтләү ягыннан да шул ук темага багышланган проза әсәрләренә нык оттыра. Үткән ел С. Батталның «Чирмешән буйларында» исемле шигъри романы дөньяга чыкты. Роман төп ике сыйфаты белән күңелне җәлеп итә. Беренчедән, С. Баттал хәтергә сеңәрлек характерлар тудыруга ирешкән. Икенчедән, революция алды еллары татар тормышы, өермәле чор турында, үзенчә, «Батталча» оста итеп сөйләп бирә алган.

Шул кадәресен дә әйтергә кирәк: роман тигез язылмаган. Кайбер урыннарда әсәргә лирик киеренкелек, табигыйлек җитми. Әсәр революция алды еллары «татар тормышының экциклопедиясе» дәрәҗәсенә күтәрелсен өчен (роман дип аталган, безнең аңа шундый таләпне куярга хакыбыз бардыр), романны әһәмиятсез һәм чырайсыз күренешләрдән тазартырга, «олы юл буйлап» кыюрак атларга кирәк булгандыр шикелле. Прозада һәм драматургиядә күптән күренгән образлар, тешне камаштырып бетергән ситуацияләр (мәсәлән, мулла маҗаралары) белән артык мавыгу, ясалма күренешләр хакына булса да укучыны көлдерергә тырышу да әсәргә ямь өстәми.

Эпик поэманың проза алымнарына мөрәҗәгать итүе бер безнең әдәбият өчен генә хас үзенчәлек түгел. Илленче елларда, мәсәлән, рус поэзиясендә дә күп санда тезмә романнар, повестьлар язылды. Е. Долматовскийның «Добровольцы», В. Саяновның «Колобовы» шикелле проза принципларына ияреп язылган шигъри романнары, хаклы рәвештә, тәнкыйтькә очрады. Әлбәттә, поэма-роман, поэма-повесть, поэма-хикәя язуга гомумән каршы килеп булмый. Әдәбият тарихы бу юлда да гүзәл ачышларны белә. Әмма һәр жанрның үз эчке законнары бар. Башка жанрларның казанышларын «күчереп утырту» һәр очракта да уңышлы чыкмый.

Проза жанры үзенчәлекләре белән мавыгу вак детальләр, әһәмиятсез эпизодлар белән тулы озын-озын әсәрләр кубәюгә китерде. Бу нәрсә Г. Хуҗиев, Ә. Давыдов, Ш. Мөдәррис, С. Баттал шикелле тәҗрибәле, өлкән шагыйрьләр иҗатында да, Ә. Баянов, М. Шабаев кебек яшьрәк буын авторлар иҗат иткән әсәрләрдә дә сизелә.

Фәлсәфи нигезнең йомшаклыгы, киң гомумиләштерүләрдән, вакыйгаларны куертыбрак сурәтләүдән баш тарту К. Фәсәховның «Пәрәвез», Х. Камаловның «Яну», А. Сәләхетдинов белән К. Фәсәховның «Мишә җыры» поэмаларына байтак зыян китергән. «Мишә җыры»нда тормыш материалы ничек бар, шул килеш әсәргә кертеп утыртылган. Чынбарлыкны туры сызык буенча гына сурәтләү әсәргә натуралистик детальләр һәм артык гадиләштерелгән ситуацияләр алып кергән, кешенең суда чагылган шәүләсен хәтерләткән схематик образлар туугa сәбәпче булган.

Заман темасына багышланган, әхлак, яңа тормыш төзү мәсьәләләрен күтәргән эпик поэмалар идея-эстетик яңгырашлары, форма өлкәсендәге ачышлары буенча, тарихи-революцион, биографик, гражданнар һәм Ватан сугышлары темасына багышланган әсәрләр белән берничек тә ярыша алмыйлар. Җанлы хисләре, тере уйлары, матур хыяллары белән сурәтләнгән чордашыбыз образы укучы белән бик сирәк, сагындырып кына очраша. Тематик чикләнгәнлек, вакыйга һәм традиция колы булу, характер тудыру алымнарында схематизм яшьләр иҗат иткән поэмаларда аеруча нык күзгә ташлана. Поэмаларыбызның тематик яктан сайлыгы турында тәнкыйть фикере әледән-әле әйтелеп тора. «Вакыйгага нигезләнгән поэмаларда гаҗәп бертөрлелек күзгә ташлана, — дип яза З. Мәҗитов. — М. Шабаевның «Кына көле», Х. Камаловның «Зәй буенда», А. Сәләхетдиновның «Үкенү», Ә. Баяновның «Челтәр аша» поэмалары әнә шундый»[1]. Болар бары тик бер әдәби ел эчендә «ясалган» әсәрләр. Бу күңелсез исемлекне тагын да арттырып булыр иде. Югарыда искә алынган поэмаларда мәңге «картаймый» һәм һәркемне дулкынландыра, уйландыра торган әхлак, мәхәббәт мәсьәләләре күтәрелә. Темага җитди һәм яңача килгәндә, алар, Һ. Такташ, М. Җәлил поэмалары шикелле, зур әдәби вакыйга дәрәҗәсенә күтәрелә алырлар иде, әлбәттә. Кызганычка каршы, бу әсәрләргә теманы яңача хәл итү, чынбарлыкны үзенчә күрү һәм яңалык җитми. Тормышның фаҗигале якларын гына җыеп, аны мелодраматик юнәлештә үстерү, шигъри зәвыгы түбән укучыга җайлашып, аның эмоциясе белән шаяру, кирәксә-кирәкмәсә буяуларны куерту, күз яше чыгарырга тырышу әлеге әсәрләрдә шигъриятне күмеп китә, поэма озын һәм күңелсез рифмалашкан юлларга әйләнә. Ул әсәрләрнең фабуласы да мелодраматизмның классик схемасын-

---

[1] «Совет әдәбияты» журналы. 5 сан. 1964 ел. 139 бит.

нан ерак китмәгән. Мәсәлән, «Кына гөле»н алыйк. Анда Рәшидә белән Галимҗан бер-берсен ошатып йөриләр. Шагыйрьнең төрле могҗизалар ясарга сәләтле «илһам таягы» Галимҗанны юлдан алып ташлый. Рәшидә яратмаган кешесенә тормышка чыга. Мәхәббәт җимерелә. Башка поэмаларның үзәгендә дә шушындый ук фабула дияргә була.

Шулай итеп, төрле сәбәпләр аркасында, күләмле эпик поэма беркадәр югалып калды, үзенең элеккеге абруен саклый алмады. Ләкин бөтен поэзиядә зур сыйфат үзгәреше барган бер вакытта характер поэмасы да үткәндәге казанышларны «җанландыру», күптән үтелгән үрләргә яңадан әйләнеп кайту белән генә чикләнмәде. Тәҗрибәләр, эзләнүләр булып торды, һәм алар төрле юнәлештә алып барылды. Бу, барыннан да бигрәк, поэмаларның тематикасында, эчтәлегендә күренде. Яңа эчтәлек исә тасвир чараларын баетуны, булганнарын барлап чыгуны таләп итте. Халкыбызның героик үткәненә, тарихи-революцион вакыйгаларга багышланган поэмалар күбәйде. Бу юлда С. Хәким, Г. Хуҗиев, Ш. Мөдәррис шикелле өлкән буын шагыйрьләр үрнәк күрсәттеләр. Р. Әхмәтҗанов, М. Шабаев, Х. Камалов, Ә. Баяновлар иҗатында яшь кешенең дөньяга карашы, характеры формалашу, әхлак, яңа тормыш төзү мәсьәләләренә игътибар үсте.

Эпик поэма өлкәсендә күренгән бәрлык яңалыкларга тукталу мөмкин түгел, әлбәттә. Биредә поэманың турыдан-туры жанр үзенчәлегенә, эчке хасиятенә караган бер тенденция турында гына әйтеп үтәсе килә.

Без эпик поэмаларның беришесендә романтизм тенденцияләренең, лирик-шәхси алымның көчәеп китүен күз алдында тотабыз. Лиризмның эпик поэма тукымасына үтеп керүе образлы фикер тыгызлыгы белән вакыйга тирәнлеген, кеше язмышы белән чор хакыйкатен бергә иңләп бирү юнәлешендә яңа мөмкинлекләр ачты. Сәләтле шагыйрьләр үткәндәге ачышларны кабатлаган поэмалар белән бәхәскә керделәр һәм шигырь, лирик поэма ачышларына сукмак салдылар. Әлбәттә, лирик тасвир чараларына йөз тотуны шигырь сыйфатларына механик күчерүгә генә кайтарып калдыру беркатлылык булыр иде. Халкыбызның героик үткәне, шәхеснең яшьлеге, мәхәббәте турында сөйләгәндә, психологик анализ, рухи дөньяны сурәтләү алымнарын да читләтеп үтеп булмый. Ахыр чиктә, романтик-лирик башлангычның көчәеп китүенә карап кына, эпик поэма үзенең эчке хасиятен, традицион билгеләрен югалтмады. Шулай да, әдәби юнәлешләр, стильләр, жанр төрләре арасында аралашу соңгы еллар поэмасының төп бер үзенчәлеге булып тора. Безнеңчә, хәзерге лирик поэма белән эпик поэма арасында, илленче еллар уртасындагы шикелле, үтеп булмаслык чик, кытай стенасы юк инде.

Эпик поэмада субъектив башлангычның тирәнәкләнеп китүе милли традицияләргә, шул исәптән халык иҗаты гәүһәрләренә, игътибарны арттырды. С. Хәким, Г. Хуҗиев, Ш. Мөдәррис, И. Юзеевлар халык җырларының әлегәчә күрелмәгән матурлыкларын, яңа эстетик мөмкинлекләрен ачтылар. С. Хәким «Ленин фәрманы белән», Ш. Мөдәррис «Үлемсезлек» поэмалары белән, җыр алымнары ярдәмендә, жанрның формасын баетып җибәрделәр, яңа тасвир чараларына ишек ачтылар. «Үлемсезлек» һәм «Ленин фәрманы белән» поэмалары, интонацияләре һәм стиль үзенчәлекләре арасында аерма зур булуга карамастан, бер ноктада керешеп китәләр. Икесендә дә бүлекләр җыр дип аталган. Ни өчен соң шигырьләр утызынчы еллар поэмасында ук киң кулланылган традициягә кабат яңарталар? Безнеңчә, бу алымга мөрәҗәгать итүнең төп сәбәбе — теманың үзенчәлекле булуында һәм аны яңача чишәргә омтылуда. Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышлары көрәшчеләренең батырлыгы, җырның тылсымлы канатында, үлемсезлеккә гасырларга китәргә тиеш. Мондый фаҗигале һәм героик вакыйгалар, искиткеч кешеләр турында гадәти рәвештә генә сөйләү мөмкин түгел, алар хакында акыннар шикелле җырлап кына була. Беренче карашка әһәмиятсез генә күренгән яңалык поэмаларның яңгырашын үзгәртеп җибәрә, азатлык өчен көрәшнең драматизмын күрсәтү, геройларның психологиясенә тирәнрәк үтеп керү һәм эпик сурәтне лирик поэзия, фольклор казанышлары белән бизәкләп бару өчен зур мөмкинлекләр ача. Шагыйрьләрне җыр жанрының киң таралган булуы һәм гаять сыйдырышлы мәгънәсе җәлеп итә. Поэманың тышкы формасына гына караган үзгәреш, ахыр чиктә әсәрнең эмоциональ рухына, яңгырашына тәэсир итә, сурәтнең офыгын киңәйтә һәм тел-стиль алымнарын төрлеләндерүгә мөмкинлек бирә.

Ә. Баянов та «Сез аңларсыз мине» поэмасының астына тикмәгә генә «истәлек-

ләр дәфтәреннән» дип язмаган. Шагыйрь шәхси башлангычны ассызымлап үтәргә, укучының игътибарын әсәрнең үзенчәлегенә юнәлтергә тели.

Соңгы еллар поэмасында шагыйрьнең үз шәхесенә, үз язмышына игътибар үсте. Еш кына шагыйрь үзенең тормыш юлына мөрәҗәгать итә, үзен җәмгыятьнең бер индивиды, материянең җанлы кыйпылчыгы буларак тикшерә, шәхси биографиясе аша чор хакыйкатен сурәтли. Бу юлда В. Луговскойның егерме дүрт поэмадан торган «Гасыр уртасында» китабы зур ачыш булды. Шәхси аша гомумине чагылдырырга омтылу тенденциясе С. Хәким, И. Юзеев, Ә. Давыдов, Ш. Мөдәррисләр иҗатына да хас. «Сез аңларсыз мине» поэмасында табигатьнең матурлыгын, тормышның ямен, тәмен аңлый белә торган малайга чынбарлык үзенең кайгы-хәсрәтләрен, «ачы даруларын» кызганмыйча татыта. Авырлыклар аның характерын чыныктыралар, кешелек сыйфатларын тагын да үстереп җибәрәләр. Иң хәтәр минутларда да ул кешеләргә ышанычын югалтмый. Менә әсәрнең иң драматик моментларыннан берсе... Сугыш вакыты. Ачлык. Көтмәгәндә өй талана, «чөйләр моң кала». Бала шунда да анасын юатырлык сүзләр таба:

Урлагандыр кирәк булганга,
Бездән ул күп, бик күп ярлырактыр,
Гафу итик, әни, елама.

Поэманың оста кул белән эшләнгән матур урыннары аз түгел. Уңышлары яктылыгында җитешсезлекләре дә ачыграк күренә. Тәнкыйтьтә әйтелгәнчә, соңга таба әсәрнең драматизмы, ышандыру көче кими төшә. Шәхес культы чорын сурәтләгәндә, «тамды минем тик бер тамчы яшем» дип, геройны үз чорыннан акыллырак итәргә тырышу — ышандырмый һәм бу темага язылган әсәрләргә яңалык өстәми. Нәкъ шул урыннарда кичерешнең киеренкелеге кими, лирик-эмоциональ ташкын сүрелә. Поэманың күләм буенча биләгән мәйданы да вакыйга киңлегенә һәм фикер тыгызлыгына җавап бирми. Һ. Такташ үзенең «Мокамай» поэмасында ике яшь кешенең рухи һәм драматик биографиясен бик аз мәйданга сыйдыра алган. Шулай да, Мокамай, типик образ булып, халык күңеленә мәңгегә сеңде. Ә. Баянов тудырган лирик геройның киләчәге исә оптимистик тойгы уятмый.

* * *

Киләчәктә поэма жанры нинди рәк юнәлештә үсеп китәр соң? Бу сорауга җавап бирүе кыен. Лирик поэманың да, соңгы елларда яңадан терелеп, җанланып киткән лирик эпосның да, эпик һәм «миниатюр» поэмаларның да иҗат мөмкинлекләре зур. Поэманың барлык төрләрен дә гаять бай һәм катлаулы чынбарлык үзе тудыра. Хәзерге поэзиядә В. Белинскийның классик билгеләмәсенә тәңгәл килгән яисә әһәмиятле вакыйгаларны сурәтләгән, тормыш күренешләрен идеаль моментында тотып алган әсәрләр белән беррәттән, гади көнкүреш хәлләренә корылган, фольклор сюжеты нигезендә язылган, бер интим кичереш үсешен сурәтләгән поэмалар да, сатирик, новеллистик, гиперболик әсәрләр дә язылып тора. Даими рәвештә камилләшә баруы гына поэманың «үзгәреш кичерми» торган «төп законы» дип дөрес әйтәләр.

Күптән түгел «Казан утлары» журналында И. Юзеевның «Тынлык белән сөйләшү» исемле яңа поэмасы басылып чыкты. Яңгырашы белән дә, композициясе буенча да әсәр үзенең күп санлы кардәшләреннән аерылып тора. И. Юзеев поэманың онытылып торган төрен иҗатка кайтара, жанрның үсеш юлларын киңәйтеп җибәрә. Автор, шартлы-романтик алымнарны реалистик сәнгать казанышлары белән синтезлап, тезмә белән чәчмә юлларны аралаштыра бара, сәнгать белән тормыш арасындагы тәңгәллекне яңача, киңрәк аңлап, бөтен кешелекне борчыган проблемалар турында үз сүзен әйтә.

«Тынлык белән сөйләшү» сугышка һәм явызлыкка каршы язылган поэма. И. Юзеев безнең әдәбиятта күп тапкырлар яктыртылган бу теманы ачуда тапталган юлдан китми. Ул шартлы, аллегорик образларны «эшкә җигә». Шагыйрьнең кыю каләме тынлыкны «йокысыннан уята», аны кеше язмышы һәм чор турындагы әңгәмәгә катнашып китәргә мәҗбүр итә. Поэмада индивидуальләштерелгән образлар да, реаль ситуацияләр дә юк шикелле. Ләкин тирәнрәк карасаң, аның безнең әдәбиятта киң таралган бик күп урта кул поэмалардан тормышчанрак әсәр икәнен күрәсең. Автор, романтик поэзиянең, импрессионизмның иң яхшы казанышларына таянып, шартлы символлар аша тормышның һәм тарихның гади күзгә күренми торган катламнарына үтеп керә.

Поэманың бик үзенчәлекле һәм тирән фәлсәфи нигезе бар. Шагыйрь кешелек тарихын, шәхесне революцион гуманизм позициясеннән торып сурәтли. Ул дөньяның киләчәгенә шикләнеп караучылар белән бәхәскә керә. Поэмада гамьсезлек белән гуманизм, киләчәктән куркып яшәү идеясе белән актив революцион көчләр арасында кискен көрәш бара... Ахыр чиктә сәламәт башлангыч җиңеп чыга. Ул дөньядагы җәбер-золым турында фикер йөртә башлый һәм зур югалтулар, корбаннар аша булса да, көрәш юлына баса. «Сак йоклагыз, туганнар», дип үзенең кардәшләрен уятырга, чаң сугарга юлга чыга.

И. Юзеев поэманың иҗат мөмкинлекләрен киңәйтү юнәлешендәге эзләнүләрен буш урында алып бармый, әлбәттә. Ул татар поэзиясенең иң гүзәл казанышларына таянып эш итә. Шагыйрь һ. Такташ, М. Җәлил ачышларына киң таянган. Драматизм белән фәлсәфи киңлекнең, лиризм белән шартлылыкның синтезына омтылып, автор «Җир уллары трагедиясе», «Алтынчәч» әсәрләренең, Ә. Фәйзи поэмаларының ачышларын үзәккә ала, шулар аша совет поэзиясенең соңгы еллардагы кыю эзләнүләренә таба юл тота.

Авторның фантазиясенә, хыял көченә чикләнмәгән мөмкинлекләр ачкан реалистик шартлылык, төрле яссылыкларда яткан күренешләр арасында якынлык күрергә мөмкинлек биргән романтик аллегория, символика хәзерге поэмада яңадан тиешле урынын алды. Мәсәлән, якын арада гына Литва шагыйре Ю. Марцинкявичюсның проблемасы буенча да, яңгырашы белән дә И. Юзеев поэмасына якын торган «Стена» исемле әсәре рус телендә басылып чыкты. Укучы беренче юллардан ук явыз көчләрне символлаштырган фантастик диназавр янсә стена шикелле аллегорик образлар ташкынына килеп эләгә. Ләкин үзенең яңгырашы, фәлсәфи тирәнлеге һәм эстетик кыюлыгы белән поэма тормышчан һәм актуаль әсәр булып кабул ителә. Шагыйрь яхшылык белән явызлык, гуманизм белән вәхшилек арасындагы каршылыклар көрәшен үзенчә, яңача гәүдәләндерүгә ирешкән.

Поэма чынбарлыктагы гомумирәк һәм әһәмиятлерәк вакыйгалар турында сөйләргә, шагыйрьнең башка жанрларда, бигрәк тә лирик поэзиядә алып барган эзләнүләренә, уйлануларына нәтиҗә ясарга тиеш. А. Блок, В. Маяковский, А. Твардовский, һ. Такташ, Ф. Кәрим, М. Җәлил, Ә. Фәйзи поэмалары менә шул сыйфатлары белән үлмәс әсәрләр рәтенә керделәр. Хәзер безнең, С. Хәкимнең «Үрләр аша...», И. Юзеевның «Тынлык белән сөйләшү» шикелле, поэзия үсешенә билгеле бер йомгак ясап, яңа, тапталмаган юллар ачкан әсәрләребез аз түгел. Эпик поэзиядә сискәндерә, уйландыра торган урыннар күп. Дөрес, сан буенча поэма, җылы яңгырдан соң күтәрелгән гөмбә шикелле, бик тиз үсә. Ләкин сыйфат үсеше бүгенге эстетик таләпләрдән калыша. Эпик поэзиянең уңышлы үрнәкләре жанрның «серенә төшенеп» язылган әсәрләр белән янәшәдә шагыйрьләр үзләре «поэма» дип куйган, «илһам мичендән» пешеп җитмичә алынган тезмә әсәрләр арасында аерма җир белән күк арасын хәтерләтә. Бу хәл шагыйрьләрнең үз һөнәрләренә җавапсыз караулары, газета-журналларның, нәшриятларның талымсыз булулары, тәнкыйтькә «эстетик усаллык» җитмәү белән аңлатыла. Шулай да мәкаләне кара буяулар, төшенке хис белән тәмамлау дөрес булмас иде. Эпик поэзия үзенең тарихи юлында бик күп каршылыкларны үтте. Гасырлар сынавын үткән тормышчан һәм үзенчәлекле жанр буларак, поэма социалистик реализм методының иң гүзәл ачышларына таянып, укучысын яңа күркәм ачышлары белән шатландырыр дип ышанасы килә.

●

КИТАП КҮЗӘТҮ

# ГАДЕЛЛЕК ҖЫРЧЫСЫ МӨХӘММӘДЪЯР

**Офыкта янгын — кызарып кояш байый. Шәфәкъ нурларыннан чал сакаллар, җыерчыклы йөзләр алсуланып кабына. Ләкин күзләр моңлы, төпсез. Күзләр түгел, әйтерсең лә, хәсрәт чоңгылы алар...**

**Кан төсле кызарып баеган кояшка карап, шагыйрь уйга талган. Аның да гомер кояшы баеп бара. Ләкин үз язмышы турында түгел аның уйлары. Мәдрәсәләр, таш-пулат-сарайлардан китүе, галим-голәмә, шагыйрь-шогара мәҗлесләреннән аерылуы өчен пошынмый ул. Каберстан тынлыгына килеп, мөҗавир, ягъни зират күзәтчесе, булып калуы өчен дә көенми шагыйрь. Аның хәсрәте башка: төбенә җитмәслек тирән, күтәрә алмаслык авыр. Бер гомер йолдызы сүнү белән бетә торган шәхси хәсрәт түгел, ә ил-улус өстенә төшкән зур, олы кайгы.**

**Илнең мазасы киткән. Яу артыннан яу. Туган җирдә әле кылычлар чыңлый, әле сөңгеләр сыка. Сугышта кулга төшерелгән маллар, әсир иткән яшь ирләр, куып китергән кәнизәк кызлар да улус-мәмләкәт тәнендәге җәрәхәтне каплый алмый. Тәхет тирәсендә гел ызгышлар; аннары җыйнаулашып баскынга чабулар. Үзләре яуга китәләр китүен, ләкин сугыш, вәйранчылык иярттеп кайталар. Раббем, боларның чиге булырмы, ниһаять!..**

**Ләкин шагыйрь үзен борчуга, йөрәген утка салган әйберләр турында, фикер иясе хәким кебек, читтәнрәк торып уйлана. Югарыда утырган казый сыман, хөкемен дә өстән торып чыгара. Халык, ил, дәүләт язмышын ул үзе яшәгән конкрет шартлардан гына чыгып түгел, бәлки ерак узган тарихлар фонында — олы тәҗрибә манарасыннан карап күңелдән кичерә. Шуңа да бер хакыйкатькә көннән-көн якынрак килә бара: әйе, халык, улус-мәмләкәт өстенә төшкән җәфалар өчен дәүләт башында торган ил агалары, хөкүмәт башлыклары гаепле! Әгәр тәхет тирәсендәге низагларга сарыф иткән көч-гайрәтләренең бер өлешен генә булса да ил кайгысына биреп гаделлек белән хөкем йөртсәләр, бу вәйраннарга, бу һәлакәтләргә зәмин калыр идемени!..**

**Шагыйрьнең күзләре ерак офыкка текәлгән. Бары шунда гына күкнең чите якты, зәңгәр сыман. Моңлы күзләр дә үз идеалларын баеп баручы кояш артыннан — ерак тарихның зәңгәр томаннарыннан эзли. Күз алдына ерактан хәбәрләр илтүче китаплар килеп баса. Колакларда исә риваять сөйләүче равиләрнең тавышы яңгырый. Шул хәбәрләргә караганда, кешеләр гел җәбер-золымда гына яшәмәгәннәр икән. Мәсәлән, Һарун әр-Рәшид яки анда Нушируан Гадил заманнарында.**

Бер мәлик бар ирде, аңла, и җәван[1],
Аты ирде үзенең Нушинрәван[2],
Кем җиһанда гадиле мәшһүр ирер,
Мәдхе[3] аның барча телләрдә йөрер.

---

[1] Җәван — егет.

[2] Нушируан (яисә Нушинрәван, Анушируан) — борынгы Иран падишасы, идеаллаштырылган образ.

[3] Мәдех — мактау, яхшылыгын сөйләү.

Шулай, гаделлек белән идарә итүчеләр дә булган икән. Үзе генә гадел булып калмаган, Нуширван әнә хәтта вәзирләреннән дә мәшвәрәт кылу — киңәш белән эш итүне, гадел хөкем йөртүне таләп иткән. Ә безнең Болгар-Казан иленең кояшы баеп бара...

...Тәбәнәк өстәл янында тезләрен бөгеп утырган шагыйрьнең моңсу күзләре кинәт серле нурлар белән балкып, кабынып киткәндәй була. Кулындагы каурый каләм дә, очарга җыенган кош кебек, бер талпынып ала. Аннары ак кәгазь буйлап гизә башлый. Берара туктап кала, шунда ук, җилпенеп-җилпенеп, тагын кузгала.

Очар ирде нагаһан бер анча каз...
Пала салды карчыгасын ул заман,
Казны типте карчыгасы, и җәван!..

Лачыннан котылырга теләп киек каз кача. Фикерләр дә шулай. Шагыйрь кулындагы каурый каләм күптәннән әйтелә алмый йөргән ул фикерләрне, сүзләрне «тотып» кәгазьгә төшерә.

Гадел берлә ил камуг булыр әман[1],
Калмаз илдә фетнә вә золым һаман...
Бер сәгать гадел кыйлмак яхшырак,
Кем гыйбадәт алтмыш елдан озаграк.
Гадел берлә бу җиһан мәгъмүр ирер[2],
Гадел берлә уш җиһан пор нур ирер[3].

Әйе, ил өстеннән кайгы-хәсрәт китсен, сугыш-низаглар бетеп, халык тыныч яшәсен өчен, гаделлек кирәк. Бер сәгатьлек гаделлек тә алтмыш ел аллага табынудан саваплырак. Гыйбадәтең үзең өчен булса, гаделлегең бөтен ил өчен кирәк:

Гадел кыйлса падишаһ бер дәм, ишет...
Барчага тигәр өлеш андин тәмам,
Кыйлыр аның илә рәхәт хасс-у-гамм[4].

Гомер-гомергә ил җилкәсен кимергән золым астында сыкраган, җәбер-җәфа чүпләндә сусаган шагыйрь, тамчы гаделлеккә зар булган гражданин әнә шулай бер минутлык гаделлек турында хыял итә... Әмма бөтен дөньяда, шул исәптән Болгар-Казан илендә дә, җәбер-золым, фетнә, низаглар хөкем сөрә. Табигатьнең генә түгел, кешенең дә кояшы баеп бара. Улус-мәмләкәт күгенең дә офыгы кызарган.

Ил өстенә төшкән бәла-җәфалардан ничек котылырга! Шагыйрь фикеренчә, бер генә юл бар: үгет-нәсихәт һәм вәгазь юлы белән ил агаларын туры юлга, гаделлеккә, гаделлеккә һәм тагын гаделлеккә өндәргә. Әгәр барлык акыл ияләре, җөмләдән шагыйрьләр дә шул юлга басып, тәрбия эшенә тотынсалар, ихтимал, гаделлек җиңәр иде. Кызганычка каршы, алар шан-шәрәфкә кызыгалар, майлы калҗаларга сатылалар, тәхет тирәсендә тәлинкә ялап, җәнҗаллар оештырып, гомер түздыралар. Ханнары да шулар сүзен сөйли, шулар коткысына ияртә. Туры сүзгә исә юл бирмиләр, хак сүзләрне тотып җәзалыйлар, хәтта:

Нәчәләр сүзләмәен сүз гөлене кистеләр,
Сүзләгәнне күрә белмәй тән тишеп кан эчтеләр!

Нишләргә! Бәлки, аңарга да дәшмәскәдер, бәла-казалардан аулаграк булыргадыр! Шагыйрь икеләнә. Сүзне вөҗдан ала:

Диде: «И ахмак, нәсихәт кыл кабул,
Бу табигать хакына кылма фозул[5].»

---

[1] Әман булу — имин булу.
[2] Мәгъмүр — төзек.
[3] Пор нур — нур белән тулы.
[4] Хасс-у-гамм — байлар һәм ярлылар, ягъни халыкның барлык катламнары.
[5] Фозул кылу — кысылу, тыю.

Сүзләгел сән бернәчә шәкәр сачып,
Бу табигать милкенең агзын ачып.
Бу эшидә йөрәкеңи даглагыл[1],
Мәрданәләрдик[2] билеңне бәглагыл.

Күрәсез, вөждан туры сөйләргә, хакыйкать өчен көрәш юлына басарга боера. Гражданин шагыйрь өчен исә вөждан сүзе — закон. Һәм хан-солтаннарга нәсихәт әйтү, аларны туры юлга, гаделлеккә өндәү кебек хәтәр, авыр эш өчен ул билен баглый, шул эштә ярдәм сорап, ходасына ялвара:

Сүзләмәктә сән йөземи ак кыйл, —
Сүзләреми ил күңлигә йомшак кыйл!

Ил күңеле... Илгә исә иминлек кирәк. Татары белән ары өчен дә, чирмеше һәм урысы өчен дә сугыш, җәбер-золым түгел — тыныч тормыш кирәк. Шулай икән, нәрсәгә дип, берең тәкбирләр әйтеп, икенчең тәреләр күтәреп, бер-береңә ташланырга! Дин-иманның ни катнашы бар соң! Ни өчен мөселманнар «кяфирлар» өстенә ыргылырга, христианнар исә «басурманнар» бугазына ябышырга тиеш! Бәла-каза, бәхетсезлекләр дини үзгәлектән килми бит:

Кефер берлә мәмләкәт булмас хараб.
Бәлки:
Золым берлә булыр ил хәле яман.

Менә шулай әкрен-әкрен капшанып һәм кармаланып шагыйрь олы хакыйкатькә таба килә. Килә генә, барып ук җитми әле. Шулай да, патшалар политикасын поплар яклаган, ханнарныкына исә мөфти-казыйлар фатиха биргән бер чорда, дини түземсезлекне дәүләт политикасы югарылыгына күтәреп, шуны «илаһи калкан» иткән бер заманда «дин бары вөждан иреге, кешенең ш ә х с и эше» дип ачык итеп, кистереп әйтү гаҗәеп зур батырлык иде. Һәм мондый батырлыкны бары гражданин шагыйрь генә эшли ала иде. (Патшаларның эшчәнлеген түгел, бәлки аларның дөньяда булуларын гына да «гаделлек тантанасы» дип дәгъва иткән шагыйрьләр әз идемени!!) Улусмәмләкәтнең иминлеген, барлык халыкның рәхәт тормышын кайгырта белер өчен дә олы йөрәкле патриот, ялкынлы гуманист булырга кирәк. Ә безнең алдагы шагыйрь исә кайгыртып кына калмый, гаделлеккә дан җырлый, шул идеяне кыю һәм эзлекле рәвештә пропагандалый. Изге эшләре өчен кяфир Нуширванны ул мөселман татар патшаларына үрнәк итеп куя. Я, бу кыюлык түгелме!

Китерелгән шушы фактларга гына таянып та, шагыйрьнең иҗтимагый-мораль йөзен билгеләргә мөмкин булыр иде. Ләкин, моннан чыгып, аны «кызартырга» кирәкми, билгеле.

Ярлы илгә рәхим-шәфкать кыйлгайсыз —

кебек аерым шигырь юлларына таянып, авторны сыйнфый аңы чарланган демократ ясап кую ашыгычлык булыр. Әсәрләрендә даими рәвештә ханнарны телгә алганы, поэмаларының берсен хан исеменә багышлаганы өчен, аны «сарай җырчысы» дип игълан итү дә мәгънәсезлек булыр иде. Безнең алда — иң элек г о м у м ә н ил, дәүләт, б а р л ы к җәмгыять ихтыяҗлары турында кайгыртучы шагыйрь. Ул «хасс-у-гамм» (өстен һәм түбән катламнар) турында абстракт кына сөйләми, бәлки:

Барча тынсын дөньяда юксыл вә бай, —

дип, үзенең төп программасын да ачык әйтә. Фикерләрен тагы да үстерә төшеп, үзе хыял иткән гадел җәмгыятьне менә болайрак сурәтли:

... Көчлек көчсезгә тигермәс зыян.
Бүре берлә куй бергә су эчәр,
Үрдәк белән карчыга бергә очар.

[1] Й ө р ә к н е д а г л а у — йөрәкне яндыру (ягъни янып иҗат итү).
[2] М ә р д а н ә л ә р д и к — батырларча, егетләр кебек.

Көрәшсез, ул — гамәлдәге тормыштан ризасыз шагыйрь, утопист шагыйрь, барлык катламнар дус яши торган бәхетле, гадел җәмгыять турында кайгырган гуманист шагыйрь.

Аның исеме — Мөхәммәдъяр. Ул XVI йөзнең беренче яртысында Казан шәһәрендә иҗат иткән. Билгеле тарихи эволюцияләр, көчле иҗтимагый регресслар кичереп, сугыш-ызгыш, җәбер-җәфа чүленә әверелгән Казан улусында гаделлеккә зар-интизар булып аһ иткән бөек гуманист. Үз иле өчен генә түгел, бәлки барлык кешеләр өчен дә иминлеккә сусаган ул. Үзе гомер кичергән конкрет мохитның гаделсезлегеннән сыкранса да, яхшы үрнәк өчен Мөхәммәдъяр гомум кешелек тарихына мөрәҗәгать иткән.

Дөрес, болай эшләүнең башка сәбәпләре дә бар иде. Беренчедән, идеалларын узган тарихларның зәңгәр томаннарыннан эзләү — барлык утопистлар өчен дә хас күренеш. Икенчедән, хыялый тәкъдимнәрне хыялый «фактлар» (легендар «гадел» патшалар үрнәге) белән раслау реаль тормышка карата объектив скептиклыкның да бер галәмәте иде. Башкачарак итеп әйткәндә, гаделсез реаль тормышны кире кагулары һәм аның урынына борынгының «сәгадәтле» дәверләрен тәкъдим кылулары белән утопистлар үзләренең бөеклекләрен дә, көчсезлекләрен дә бер фокуска җыялар. Көчлелек — инкарь, көчсезлек — икърар. Нәрсәне теләмәгәннәрен ачык беләләр, ләкин ни теләгәннәрен тәгаен әйтә алмыйлар. Бу — утопистларның барсы өчен дә хас, уртак сыйфат. Социаль утопиянең иң югары ноктасы саналган Роберт Оуэн, Сен-Симон кебек шәхесләрнең эшчәнлекләрендә дә реальлекне кире кагу, гаделсез тормышны фаш итү көчле. Яңаны төзү мәсьәләсенә килгәндә исә алар да хыялый утраулар, «гадел» патшалардан бик үк ерак китә алмадылар. Ләкин туачак һәм туып формалашкан, изелгән халыклар кулында кодрәтле көрәш коралына әверелгән марксизм тәгълиматының нигез чыганакларының берсе шул социаль утопия идеяләре булуын игътибарга алсак, без XVII — XVIII гасырлардагы утопистлар истәлеге алдында ихтирам белән тез чүгәргә тиешбез. Мөхәммәдъяр исә алардан да элегрәк яшәгән һәм Казан ханлыгы дип аталган, исеме дә сүгену сүзе дәрәҗәсенә төшерелгән бер өлкәдә ялкынланып, нәфрәтләнеп, татлы хыялларга бирелеп иҗат иткән.

Гел кире яктан телгә алынып килгән Казан ханлыгында шундый олы идеяләрнең дөрләп кабынуы кайберәүләр өчен, бәлкем, ят тоелыр. Әмма кешелек тарихындагы социаль утопия идеяләре үсеше күгендә якты йолдыз булып янган Мөхәммәдъяр исә очраклы рәвештә ялгыш кабынган, ялгыз кабынган факел булмаган. Гуманизм идеяләренең орлыкларын ул бай шәрык әдәбияты традицияләреннән алган һәм аларны үзе яшәгән мохитка яраклаштырып, үстереп биргән. Димәк, мәсьәләнең әһәмияте XVI гасырда Мөхәммәдъяр исемле бер олы гуманистның яшәве белән генә чикләнми. Кешелек культурасының гүзәл бер чәчәге булган шәрык әдәбиятының алдынгы идеяләре Казан ханлыгы туфрагында да дөрләп үсәр өчен бәрәкәтле җирлек тапкан икән. Бу — хикмәтнең бер ягы. Икенче ягы исә социаль утопия идеяләренең Казан ханлыгы шартларында гадәттән тыш актуальләшеп китүендә, үзенең җырчы көрәшчесен дә дөньяга тудыруында. Мөхәммәдъяр нәкъ менә шундый социаль тигезлек, гомум гаделлек турында янып җырлаган трибун шагыйрь, гражданин һәм фикер иясе.

...Аның ялкынлы шигъри юлларын кат-кат укыйм. Уйланам, тагын укыйм. Сокланам, шул ук вакытта гаҗәпләнеп тә куям: гомум кешелек, социаль тигезлек кайгысы белән янып яшәгән бу гаҗәеп авторның әсәрләре ни өчен шушы елларга хәтле өйрәнелмичә, киң катлау укучыларга тәкъдим ителмичә ятты икән! Җавап эзләмим. Чөнки минем өчен хәзер Мөхәммәдъяр поэмаларының басылып чыккан булуы әһәмиятлерәк. Әйе «Төхфәи мәрдән» һәм «Нуры Содур» поэмалары, бик соң булса да, аерым китап рәвешендә басылып чыктылар[1] һәм аларны укып чыгу белән мин күңелдән югарыда сөйләгәннәрне кичердем. Кичердем генә түгел, шулай аңладым. Хәтта халык, ил белән бергә шагыйрь кичергән фаҗигане күз алдына китереп, аны үз җилкәмдә тойган кебек булдым. Гаделсезлек сахрасында бер тамчы суга зар булып,

---

[1] Мөхәммәдъяр. Төхфәи мәрдән. Нуры содур. Поэмалар. Текстларны Ш. Абилов әзерләгән, редакторы проф. Х. Госман. Казан. 1966 ел.

кулын күккә сузган хәсрәтле карт шагыйрьне дә, баеп барган кояшны да күзләрем белән кичергәндәй булдым.

Биредә, әлбәттә, мин үземнең шәхси тойгыларымны, яңа китапны укып чыгу белән туган хисләремне сөйлим. Фикерләремнең кайберләре белән килешмәүчеләр дә табылыр. Бу бик ихтимал. Чөнки без Мөхәммәдъяр мирасын әле җитәрлек дәрәҗәдә яхшылап өйрәнмәдек. Ләкин Мөхәммәдъяр иҗатының төп сыйфатын билгеләгәндә, икеләнмичә бер нәрсәне әйтә алам: безнең алда кешеләр бәхете өчен көенеп, гомум гаделлеккә дан җырлаган бөек гуманист, чын патриот. Бу сүзләремдә арттыру күрмим. Чөнки мин Мөхәммәдъяр эшчәнлеген бүгенге бизмәннәр белән үлчәмим, бәлки ул яшәгән караңгы XVI гасыр фонында карыйм. Һәм аның олы йөрәгенең ялкынын тоеп, бөеклегенең мәһабәтлеген күрәм. Шул ук вакытта бу ялкынның көчен, бөеклекнең күләмен бер татар дөньясы белән генә дә чикләргә теләмим. Юк, чөнки Мөхәммәдъяр—гомумкешелек әдәбияты күгендә дә үз урынын алырлык олуг шагыйрь. Ә ни өчен соң без моңарчы аның турында начар белеп яшәдек! Бу инде бөтенләй икенче мәсьәлә. Монда шагыйрьнең берничди катнашы юк. Шулай ук өйрәнелми ятуга карап, Мөхәммәдъяр йолдызы да сүнмәгән. Киресенчә, безнең белемебез күгендә бер ут кабынмый яткан...

Мөхәммәдъярның гуманизм җырчысы булуы шагыйрьнең безгә килеп җиткән әсәрләрендә ярылып ята. Аның вак-вак хикәя-иллюстрацияләрдән, лирик чигенешләр һәм уйлануларлан оештырылган поэмаларындагы һәрнәрсә бер максатка — актив рәвештә гаделлекне яклауга буйсындырылган. Хушнавә белән башка сарай шагыйрьләре арасында булган диспутта да, шартлы рәвештә «Заһид хикәясе» дип аталган мәсәләдә дә, игелекле кыз һәм явыз ата хикәясендә дә, сәхавәт-юмартлык, хәя, вафа турында җырлаганда да шагыйрь шул бер төп фикерне уздыра. Болай әйтүдән шагыйрь иҗатын тарайтып карау дип уйланмасын. Чөнки, игътибар итсәң, юмартлык белән турылык та, рәхимлелек белән о я т л ы л ы к та нигездә олы гаделлеккә кайтып кала. Мәсәлән, гадел булмаган кешедә оят буламы соң!

Тагын бер характерлы деталь. Мөхәммәдъяр, шул замандагы шәрык поэзиясе традициясенә буйсынып, изге сугыш — газават турында бер бүлекчә яза. Мәгәр безнең өчен «изге сугышны» шагыйрьнең ничек аңлавы әһәмиятлерәк. Безнең җырчы, башка мөселман шагыйрьләре кебек, гел «кяфир» һәм «мөэмин» сугышлары турында лаф ормый. Бәлки, традицион теманы да үзенең олы максатына буйсындыра: саф дини дошманлык мәсьәләләреннән югары күтәрелеп, газаватка социаль-этик мәгънә бирә, «халыкка зыян кыйлган» явыз елан-чаяннарны үтерергә өнди. Бу инде — соңгы дәвер шәрык-мөселман поэзиясендә дә сирәк очрый торган яңа сыйфат.

Мөхәммәдъярны вәгазьче, дидактик шагыйрь генә дип уйлау тирән ялгышу булыр иде, әлбәттә. Аның гражданлык бурычы, гуманизмы шагыйрьнең төп игътибарын рациональ һәм этик мотивларга юнәлтергә мәҗбүр итсә дә, әсәрләрен ул гаҗәп матур тел, тулы канлы поэтик образлар белән яза алган. Шулай ук халык телендәге хикмәтле мәкальләрдән, образлы әйтемнәрдән дә бик оста файдаланган. Вакыты-вакыты белән безнең алда чын-чынлап ялкынланып, тилереп җырлый торган илһам иясе. Бу сыйфат лирик чигенешләрдә, шагыйрьнең эчке монологларында калку булып чагыла. Һәм шул юлларны укыгач, аның интим әсәрләре нинди кодрәтле лирик хис белән яңгырады икән! — дигән сорау туа. Киләчәктә, ихтимал, без андый шигырьләрне табу һәм укып ләззәтләнү бәхетенә ирешербез. Ә хәзергә Мөхәммәдъярның бары ике поэмасы гына чагыштырмача тулы килеш басылып чыкты. Бу да зур казаныш.

Ләкин поэмаларның кайбер урыннарында акланмаган кыскартулар үзләрен нык сиздерделәр. Мәсәлән, шагыйрьнең Сафа-Гәрәйгә мөрәҗәгать иткән сүзләрен өтекләп бирүнең хаклыгын мин берничек тә аңламадым. Бәлки, киресенчә, шагыйрь фәлсәфәсенең ярлылануын сиздем. Ханга мөрәҗәгать итү, аңар үз әсәрен багышлау бу әле ханчылык идеясен уздыру дигән сүз түгел ләбаса! Чынлыкта исә бу яшерен полемиканың бер төре.

Кызганычка каршы, поэмадагы иң мәгънәле, матур шигъри юллар төшеп калган, авторның ил-дәүләт турындагы олы кайгысы, тирән фәлсәфәсе дә бик нык зәгыйфьләндерелгән. Әйтерсең лә, безнең заман укучылары ханнар, аллалар исемен укып юлдан язарлык, зәгыйфь, ышанычсыз, гуяки шулай эшләп, әдәби мирасның «кимчелеген бетерәбез»... Чынлыкта исә мондый примитив алымнар белән без (галимнәр һәм

редакторлар] үз дәрәҗәбезне генә төшерәбез: катлаулырак мәсьәләләрне аңлаудан, киң катлам укучыларга аңлатудан качабыз. Бары шул гына.

Әлбәттә, мондый кимчелекләрдә китапны төзүче, текстларны матбугатка әзерләүче Ш. Абиловны гына гаепләү хаксызлык булыр иде. Биредә редакция белән редколлегия дә, эчке рецензентлар да өлешсез кала алмыйлар. Профессиональ сер булса да, бер нәрсәне ачык әйтик: бездә матбугатка чыгасы берәр китапны тикшергән вакытта: «бу мәсьәләне ачыкларга»; «монысын нигезләп аңлатырга»; «тегесенә дөрес бәя бирергә» диясе урында, күбрәк очракта «бу җирен кыскартырга», «монысын төшереп калдырырга» кебек «җиңел» тәкъдимнәрне ешрак ишетергә туры килә. Шулай йолкынган, таланган китаплар дөньяга чыга.

Шакир Абиловның конкрет хезмәтенә килсәк, ул нигездә уңай тәэсир калдыра. Дөрес, матбугатка беренче мәртәбә буларак әзерләнгән бу китапта да төгәлсезлекләр, техник һәм гыйльми җитешсезлекләр байтак [транскрипциядәге кытыршылыклар, сүзләрне ялгыш аңлату h. б.]. Кереш мәкалә дә сүлпәнрәк язылган. Ләкин мин аларга бу юлы игътибар итмәскә булдым. Чөнки гыйльми төгәллек дигән нәрсәгә зур тәҗрибә нәтиҗәсендә генә ирешелә. Безнең текстология өлкәсендәге тәҗрибәбез исә әлегә бик сай. Бәлки, Мөхәммәдъяр әсәрләренең аерым китап булып чыгуы бу юлда белемебезне арттырыр, безгә киләчәктә ничегрәк эшләргә кирәклеген ачыграк күрсәтер. Бер Мөхәммәдъяр иҗатын өйрәнүгә генә кайтып калмый бу, әлбәттә. Ә аның әсәрләре исә тагы да яхшырак сыйфат белән, янә дә тулырак хәлендә киң катлам укучылар өчен басылырга тиеш. Китапның берничә ай эчендә бөтенләй сатылып бетүе моңа яхшы дәлил. Әмма шагыйрьнең барлык мәгълүм әсәрләреннән югары сыйфатлы академик басма әзерләү мәсьәләсенә килсәк, бу инде көн кадагында торган актуаль бурычларның берсе.

М. ГОСМАНОВ.

# КӨЛҮ—ҮТКЕН КОРАЛ

Нићаять, татар язучыларының сатира һәм юмор әсәрләре аерым китап булып басылып чыкты[1]. Шундый бер китапның кирәклеге хакында сүз күптән бара иде. Әмма җыентыкта сатирабыз тарихы, көлү һәм аның теориясе, һич югында бүгенге татар сатирасының торышы турында гына булса да кыскача кереш мәкалә урнаштырылмаган. Аның хәтта нинди максат белән чыгарылуы турында да берни дә әйтелмәгән. Кирәк иде.

Җыентыкта тупланган әсәрләр белән танышып чыккач, төзүчеләр алдына шактый кыен бурыч куелганлыгын чамаларга мөмкин. Аңа төрле чорда иҗат иткән 66 авторның 137 исемдәге сатира-юмор әсәре һәм халык мәзәкләре урнаштырылган. Авторлар, күрәсең, татар сатира тарихыннан үрнәк әсәрләр сайлап аерым китап чыгарырга теләгәннәр. Димәк, бу җыентык сатира-юмор әдәбиятыбызның якты көзгесе, эталоны булырга тиеш иде. Чынлыкта исә мәсьәләнең бу ягы башкачарак хәл кылынган. Җыентыкны дөньяга чыгаручылар «һәр автордан ике-өч әсәр булсын» дигән принциптан чыгып эш иткәннәр кебек. Шуның нәтиҗәсе буларак, сатира һәм юмор өлкәсендә әле тәҗрибә генә ясаучы авторларга да киң урын бирелгән. Ш. Бабич кебек көлү осталарының әсәрләре исә бөтенләй читтә калган. Җыелган материалны чорларга бүлеп урнаштыру, жанрлар ягыннан классификацияләү мәсьәләләренә игътибар бирү дә файдалы булыр иде. Ләкин бу эш тә эшләнмәгән.

Инде тупланган кадәресенең идея-тематик ягына, аерым әсәрләрнең сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсенә күз салыйк. Социаль-политик сатира үрнәкләре бөтенләй читтә калган, тормыш-көнкүреш мәсьәләләренә багышланган сатира-юмор әсәрләренә җиңелчә мәзәк дип карау тенденциясе сизелеп тора. Бездә еш кына көлү төшенчәсен сатира белән алмаштыралар, сатираны тәнкыйтькә якынлаштыралар. Тәнкыйть сүзе исә «чыбыркылау», «кыйдерүгә» дә кайтып кала. Ләкин сәнгатьчә оста эшләнгәндә, кеше пси-

[1] Юмор һәм сатира. Казан, 1966 ел.

хологиясен белеп, этика, эстетика закончалыкларын тоеп язылганда гына сатира-юмор әсәрләре укучының таләпчән зәвыгын канәгатьләндерә ала. Шул шартлар үтәлмәгән икән, тема актуальлеге дә, форма яңалыгы да көлү әсәрен уңышсызлыктан коткара алмый. Көлдерми торган әсәрләрне без бу җыентыктан да байтак таба алабыз. Мисалга Б. Рәхмәтнең «Көн дә иртәгә», Ә. Ерикәйнең «Исе китми», Г. Латыйпның «Кешесенә карата» кебек шигырьләрен күрсәтергә мөмкин.

Көлү әсәренең көче, билгеле, авторның көлә белүендә. Ә нәрсә соң ул көлү! Көлү ничек, кайчан барлыкка килә! Аның нинди закончалыклары бар! Атаклы рус тәнкыйтьчеләре һәм сатириклары көлү белән көлү арасында зур аерма күргәннәр һәм ике төрле көлү яшәвен күрсәткәннәр. Аның берсен алар буш, мәгънәсез көлү дип атыйлар, ә икенчесен, нигезендә искелек белән яңалыкның диалектик көрәше яткан комик каршылыклысын, югары көлү дип йөртәләр. Сатираның да, юморның да һәм башка көлү төсмерләренең дә нигезендә көлке каршылык ята, аларның барсында да теге яки бу дәрәҗәдә искелекнең яңалыкка каршы көрәше гәүдәләнә. Искелекнең мәгънәсез каршылыгы безнең күңелдә үзенчәлекле эмоциональ тәнкыйть формасы — көлү уята. Монысы барлык көлү әсәрләренең дә нигезендә яткан уртак сыйфат. Ә соң сатира белән юморның аермасы нидә!

Билгеле, сатира белән юмор арасына кискен чик сызу җиңел эш түгел. Монда бер яктан икенче якка дәвамлы күчеш процессы бара. Шулай да, сатира һәм юмор әсәрләре турында сүз барганда, күренекле әдәбият галиме Ю. Б. Боревның түбәндәге фикерләре белән килешми булмый:

«Сатира, — ди ул, — алдынгы политик, эстетик һәм әхлакый идеалларга туры килмәүче һәрнәрсәне аяусыз фаш итүче, аларның тулысынча тормышка ашу юлында торучы һәрнәрсәдән нәфрәтле көлү. Сатира көлә торган күренешне тулысынча инкарь итә һәм аңа ул күренештән читтә торучы идеалны каршы куя. Юмор исә үз объектында идеалга туры килерлек кайбер уңай якларны күрми кала алмый».[1]

[1] Ю. Б. Борев. Основные эстетические категории. Рус телендә. Мәскәү. 1960 ел. 243 бит.

Димәк, көлә торган объектның иҗтимагый зыянына карап, авторлар көлүнең төрле төсмерләрен кулланалар икән. Шул ноктадан торып якын килгәндә, бездә эш ничегрәк тора соң! Әйткәнебезчә, татар әдәбиятындагы социал-политик сатира үрнәкләре бу китапка аз кертелгән: Г. Тукайның «Китмибез»е, М. Гафуриның «Сахибе кәрамәте», һ. Такташның «Нәни рәзбойнигы». Октябрь революциясеннән соңгы чордан социаль-политик сатира әсәрләре бөтенләй юк. Кайберәүләр бу мәсьәләгә карата да икеләнү белдерәләрдер, бәлки. Янәсе, социализм әдәбиятында андый сатирага җирлек бармы икән!.. Хәлбуки, җир йөзендә сыйныфлар көрәше — социаль-политик көрәш дәвам итә. Бөтендөнья күләмендәге прогрессив көчләрнең реакцион көчләргә каршы көрәшендә Советлар иленең тоткан урыны һәм ул көрәшнең экономика, идеология өлкәсендә төрле формаларда баруы ачык бер хакыйкать. Бу исә социаль-политик сатирага эш әле күп булуы турында сөйли. Алай гына да түгел, дөньяның һәр почмагында халыкларның капитал коллыгыннан котыла баруы, аларның социаль казанышлары һәм шул юлдагы көрәшләре — эпохабызның иң характерлы үзенчәлеге. Сизгер һәм тәҗрибәле авторлар заманыбызның бу җитди һәм актуаль мәсьәләләренә үзләренең әсәрләрен багышлаганнар. Мисал өчен бу китапка керми калган берничә әсәргә игътибар итик. Ш. Мөдәррииснең «Янки базары яхут яңадан-яңа Кисекбаш», «Дагессонның көндәлеге», «Ревизор», «Сыңар колак вакыйгасы» һәм Ә. Исхакның «Мещан базары яхут киселгән тел», «Татар бае нилэр күрми яхут Кабан күле тиз кибәрме», «Колонизатор зары» кебек әсәрләре әнә шундыйлар. Күрәсез, бөтендөнья күләмендәге конфликтларны иңләгән социаль-политик сатира үрнәкләре бездә дә бар икән. Һәм алар монда саналган әсәрләр белән генә дә чикләнмиләр.

Китапта дингә каршы язылган сатира әсәрләреннән матур гына үрнәкләр бар. Ф. Әмирханның «Хәзрәт үгетләргә килде», Г. Газизнең «Чалбар», Ш. Камалның «Сәмруг кош», И. Рәмиевнең «Сәбитский намаз», Х. Туфанның «Козырь туз», Ә. Исхакның «Динсез дуртюллыклар», Ф. Хөсниның «Бал мичкәсе бушады» кебек әсәрләрен күрсәтергә мөмкин.

Җыентыкка кергән әсәрләрнең иң күбесе — тормыш-көнкүреш темаларына караган сатира-юмор үрнәкләре. Алар

саранлык, ваклык, икейөзлелек, мин-минлек, азгынлык, әшнәлек, бюрократлык, ялагайлык, битарафлык, кирелек, күз буяу, куркаклык һәм башка шундый тискәре күренешләрне фаш итүгә багышланганнар. Мондый әсәрләр арасында «Сәмигулла абзый» (Ф. Әмирхан), «Исерек» (Г. Газиз), «Язмаган ризык» (Ә. Фәйзи), «Сәдака» (М. Әмир), «Әзер хикәя» (Ә. Еники), «Гөлҗамал апа чәй эчерә...» (Г. Галиев), «Тактика» (А. Расих), «Мин ничек өлкән инженер булдым» (С. Сабиров), «Бүләк» (А. Гыйләҗев) кебек үзенчәлекле кыска хикәяләр бар. Шул ук вакытта тормыш-көнкүреш мәсьәләләренә багышланган сатира-юмор әсәрләре арасына ялгыш кертелгән хикәяләр дә күзгә ташлана. Г. Бәшировның «Мыек Шәмсетдин», Г. Минскийның «Четерекле сорау», К. Фәсәховның «Уртач Сәйфуллин», Х. Сарьянның «Хәерсез» кебек әсәрләренә игътибар итегез. Сүз аларның яхшылыгы, начарлыгы яки сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәләре турында бармый. Хикмәт аларның көлү әсәре булу-булмавында. Без беләбез: халык тапкыр, зирәк, мәзәкчән ул. Аның бу сыйфаты, һичшиксез, төрле жанр әсәрләрендә чагыла. Әмма тукымасында көлү элементы очраган һәр әсәр сатира-юмор әсәре булып бетми. Көлү әсәрләренең специфик үзенчәлеге, аларга куела торган махсус таләпләр бар. Шуңа күрә югарыда исемнәре саналган әсәрләрнең кайберләрен без тукымаларында көлү элементы чагылып киткән гади хикәяләр дип, ә икенчеләрен уңышсыз көлү үрнәкләре дип бәяләү ягында торабыз. Тормыш-көнкүреш мәсьәләләренә багышланган әсәрләрдә тема бертөрлелеге һәм кабатлаулар нык сизелә. Шушы бер китапта җиде әсәр исерек кеше, унбер хикәя һәм шигырь көлке хәлгә калган гашыйклар, алты әсәр иркә бала, унөч әсәр уңайсыз хәлгә калган карт кешеләр турында. Билгеле, алар арасында бик әйбәтләре дә бар. Теманы төрле алымнар ярдәмендә чишәргә омтылу да үзен нык сиздерә. Әмма ике су тамчысыдай бер-берсенә ошаганнары да байтак. Бу исә авторларыбызның бер телгә кергән җитешсезлек тирәсендә таптану, вакланулары турыкда сөйли.

Бу мәкаләдә без укучы игътибарын күбрәк китапның һәм аңа кергән әсәрләрен җитешсез якларына юнәлтүне кирәк таптык. Моның үз сәбәпләре бар. Сатира-юмор әдәбиятыбыз күптәннән аксап, өстерәлебрәк килә. Партиябезнең XX һәм XXII съездларыннан соң сатира күге болытлардан арынды, жанрга киң мөмкинлекләр ачылды. Әмма татар язучылары бу юлдан һаман да кыюсыз атлыйлар, көлүнең мөмкинлекләренә, көченә икеләнеп, шикләнеп карау бетеп җиткәне юк. Татарстан китап нәшрияты чыгарган әлеге китапта да шул нәрсә күзгә ташлана.

Әмма ни генә булмасын, җыентыкның чыгуын сатира һәм юмор файдасына зур бер эш дип санарга кирәк. Бу матур башлангыч киләчәктә дәвам ителер, татар әдәбияты тарихыннан төрле характердагы һәм төрле чор сатира-юмор әсәрләре сайланып, көлү үрнәкләренең яңа, фундаменталь җыентыклары төзелер дип ышанасы килә.

Н. ХАНЗАФАРОВ.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

*Әбрар Кәримуллин*

# КУЛЪЯЗМА МИРАСЫБЫЗНЫҢ КАЙБЕР МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

**Нинди кулъязмаларны татар халкының язма мирасы дип карый алабыз? Аларның үзенчәлекләре нидән гыйбарәт? Кулъязма мирасыбызның күпме өлеше безнең көннәргә кадәр килеп җиткән? Язма әсәрләрне туплау, саклау һәм өйрәнү өлкәсендә нәрсәләр эшләнгән,ниләр эшлисебез бар?.. Бу мәкаләдә шул сорауларның кайберләренә генә булса да тукталып үтәсе, җавап табасы килә. Кайберләренә генә дибез. Чөнки кулъязма мирасыбызга караган мәсьәләләр бик күп. Аларны санап кына чыгу өчен дә озак вакыт, күп урын кирәк булыр иде. Сүзне кулъязма әсәрләрнең ничек саклану мәсьәләсеннән башлыйк.**

**Билгеле булганча, инде XI—XIII йөзләрдә үк Болгар дәүләте Европадагы иң алдынгы илләрдән саналган. Биредә мәһабәт сарайлар төзегәннәр, Европада беренче буларак чуен койганнар. Болгарда мәктәп-мәдрәсәләр булган, сынлы сәнгать осталары, галимнәр, шагыйрьләр яшәгән, кулъязма китаплар язылган. Әмма Болгар галимнәре Ногманның «Болгар тарихы», Борһанетдин Болгариның медицина буенча язган хезмәте, Сәмәркандинең «Әдәб»е, башка әдип һәм галимнәрнең кулъязмалары түгел, хәтта күчермәләре дә безгә килеп җитмәгән. Ярый әле: кайбер Болгар галимнәренең исемнәре һәм аерым хезмәтләре гарәп сәяхәтчеләре тарафыннан теркәлеп калган. Югыйсә аларны да белмәгән булыр идек [1]. Аксак Тимер, Болгар шәһәрен алгач, үзенә хезмәт итүдән баш тарткан өчен генә 36 галимне үтерткән [2]. Аңа хезмәт итәргә ризалык биргәннәре дә аз булмагандыр...**

**Ни өчен соң Болгар мәдәнияте, болгар китаплары безнең көннәргә хәтле килеп җитмәгән?**

**Моны кайбер кешеләр шул чорларда булып торган сугышлар, янгыннар белән аңлаталар. Дөрес, янгыннар, сугышлар аркасында да бик күп язма мирас мәңгегә юкка чыккан. Ләкин бу рәвешле генә аңлату тулы булмас иде. Төп сәбәп — язманың материалында. Безнең бабаларыбыз IX йөздә үк язу өчен күбрәк кәгазь кулланганнар. Кәгазьнең гомере исә бик чикле. Агачтан ясалган кәгазь 100 елга түзә, чүпрәк-мамыктан ясалганы — 400—500 ел. Болгар чорындагы кулъязма китапларның уттан-судан имин калганнары да җитәрлек булгандыр. Аларның язмышы кәгазь гомеренә бәйле. Әнә бит төрки руник язмалар шактый күп сакланган [3]. Моннан 1500 еллар элек язылганнары да безнең көннәргә хәтле килеп җиткән. Чөнки таш кыялардагы руник язмаларны вакыт та, табигать стихиясе дә җимерә, юкка чыгара алмаган. Нык материалдагы язмалар Болгар дәүләте чорыннан да байтак калган. Мәсәлән, кабер ташлары, металлдан, сөяктән ясалган бизәнү әйберләрендәге, алтын-көмеш акчалардагы язмалар. Шундый ук истәлекләрнең Казан ханлыгы дәверенә караганнары да, XVII—XVIII йөзләрдән сакланып калганнары да күп кенә.**

---

[1] Д. А. Хвольсон. Известия о хазарах, буртасах, булгарах, мадьярах, славянах и руссах... Спб. Рус телендә. 1869 ел. 87 бит.

[2] Материалы по истории Татарии. Вып. 1. Рус телендә. Казан. 1948 ел. 208 бит.

[3] С. Е. Малов. Памятники древнетюркской письменности. Рус телендә. 1951 ел. 451 бит; С. Е. Малов. Енисейская письменность тюрков. Рус телендә. 1952 ел. 116 бит; И. А. Батманов и А. Г. Кунаа. Памятники древнетюркской письменности. Рус телендә. Кызыл. 1962—1965; Г. Рәхим һәм Г. Газиз. Татар әдәбияты тарихы өчен материаллар җыю юлында бер тәҗрибә. Казан. 1923 ел. 175 бит; Х. Курбатов. Идел буе болгарларында гарәп язуына кадәр булган алфавит. «Совет әдәбияты» журналы. 1957 ел. 10 сан. 112—117 битләр; М. И. Артамонов. Надписи на баклажанах Новочеркасского музея и на камнях Маяцкого городища. «Сов. археология». т. XIX. 1954 ел. Рус телендә. 266—268 битләр.

Язма мирасыбызның кәгазьдәге өлеше ничек сакланган, күпмесе безнең көннәргә килеп җиткән? Әлегә бу сорауга тулы җавап биреп булмый. Моның өчен, илебез китапханәләрендә сакланган меңнәрчә әсәрләрне өйрәнү-тикшерүдән тыш, чит илләрдәге барлык шәрык кулъязмалары белән танышып чыгу, шуның өстенә халык кулында сакланып калган кулъязмаларны белү кирәк булыр иде.

Болгар китаплары сакланып калмасалар да, ул чорда иҗат ителгән әсәрләрнең кайбер күчермәләре әле дә исәннәр. «Кыйссаи Йосыф», «Кисек баш», «Бәдәвам» кебек әсәрләр шул чордан калган. Болар янына, Бакырганиның «Ахырзаман китабы», Рабгузиның «Кыйссаи әнбия»се, Әхмәд Ясәвинең «Хикмәтләр»е кебек, болгар-татарлар арасында киң таралган аерым әсәрләрне китереп кушарга мөмкин.

Алтын Урда чоры татар әдәбияты истәлекләреннән дә безнең көннәргә хәтле сакланып калганнары бар. «Нәһҗел фәрадис», «Гөлстан бит төрки», Котбинең «Хөсрәү вә Ширин»е, Хисам Кәтибнең «Җөм-җөмә солтан»ы, Хәрәзминың «Мәхәббәтнамә»се шундыйлардан[1]. Татарстан дәүләт музеенда 1532 елда, ягъни моннан 436 ел элек, язылган Сәхип Гәрәй хан ярлыгы саклана. 1964 елда Пермь өлкәсендә шагыйрь Мөхәммәдъярның «Нуры сыдур» исемле поэмасының күчерелмәсе табылды. Ул 1600 елда, моннан 368 ел элек күчерелгән. Казан ханлыгы чорыннан Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихи Болгари», XVII йөз галиме Кадыйр Галинең «Җамигъ әт-тәварих» исемле хезмәтләренең күчермәләре, шагыйрь Утыз Имәни әсәрләре, XVIII—XIX йөзләрдә язылган күп санлы кулъязмалар сакланып калган. Исән калган язма мирасыбыз әдәби һәм тарихи әсәрләр белән генә чикләнми, әлбәттә. Алар арасында халык авыз иҗаты әсәрләре, сүзлекләр, календарьлар, шәҗәрәләр, сәяхәтнамәләр, медицина, математика, ботаника, космогония, формаль логика, астрономия, фәлсәфә, сәнгать тарихы, поэтика, этика буенча язылган хезмәтләрнең күчермәләре күп. Шулай ук дини эчтәлекләре, пәйгамбәрләр тарихына караганнары да җитәрлек.

Татар кулъязмаларының күпчелеге, һичшиксез, илебез китапханәләрендә саклана. Казан университеты китапханәсендә генә дә аларның саны 12 мең чамасы. Ленинград университеты, Азия һәм Африка халыклары институтының Ленинград бүлеге китапханәләрендә дә татар кулъязмалары шактый күп тупланган. Мирасыбызның бер өлеше Уфа, Саратов, Ташкент, Одесса, Киев, Харьков, Львов, Ереван, Алма-Ата, Душанбе, Вильнюс, Кишинев китапханәләренең шәрык кулъязмалары бүлегендә очрый. Алар чит ил китапханәләрендә дә байтак. Австрия фәннәр академиясе, Голландиянең Лейден университеты, Англиянең Британия музее китапханәләрендә, Венгрия, Польша, Франция, Төркия һәм Румыниядә татар кулъязмалары саклануы турында матбугат битләрендә хәбәрләр басылды. Татар кулъязмаларының башка илләр китапханәләре һәм архивларында да булуы билгеле. Мирасыбызның байтак өлеше, мәсәлән, Чехословакия[2], Италия[3], Кытай[4], Болгария[5], АКШ[6], Швеция[7], Бельгия[8], Финляндия[9] һәм башка

---

[1] Э. Наджип. Кипчакско-огузский литературный язык мавлюкского Египта XIV века. Автореферат. Рус телендә. Мәскәү. 1965 ел. 38—39 битләр.

[2] Arabishe, türkische und persishe Handschriften der Universitätsbibliothek in Bratislava. Bratislava, 1961. 550 S.

[3] V. Nallino. V manuscritti arabi, persi., sersi., seriaci et turchi della Bibliotek National. e della Rome Academia della sienze di Torino. Torino, 1900. — E. Tissernat. J catalogni stampati dei manoscritti orientali della Biblioteca Vaticana dal '700 ad oggi. — Orientalia NS, t. 5, 1936. pp. 102—108.

[4] Э. Наджип. Тюркоязычные рукописи в Пекине. «Народы Азии и Африки» журналы. 1965 ел. 3 сан. 133—138 битләр.

[5] А. Шишманов. Собрание восточных рукописей в Софии. «Записки восточ. отд. имп. русского археологического общества». Рус телендә. 23 том. 1915 ел. 61—76 битләр.

[6] C. D. Mathews. Manuscripts and Mamlük inscription in the Lansing collection *in* the Denver Public Library. — Journal of the American Oriental society, t. 60, 1940, pp. 370—382. — M. Ahmed Simsar. Oriental manuscripts of the John Frederic Lewis collection in the. Free library of Lhiladelpnia. Philadelpnia, 1937. XIX, 248 p.

[7] K. V. Zetterstéen. Die arabischen, persischen und türkischen Handschriften der Uneverstätsbibliothek zu Uppsala verzeichnett und beschriefen. — Monde Oriental, t. 22, 1922, S. I—XVIII, 1—498; t. 29, 1935, S. I—X, 1—180.

[8] W. Heffening. Eie Jslamischen Handschriften Universitäts — Bibliothek Löwen. — Museon, t. 50, 1937, S. 85—100.

[9] J. Aro. Die arabischen, persischen und türkischen Handschriften der Universitäts—bibliothek zu Helsinki. — Studio Orientalio, t. 23, vol. 4, s. 1—84.

илләрнең китапханәләрендә, бу илләрдәге кайбер ориенталистларның шәхси фондларында сакланып килә. Бу исемлекне дәвам итәргә мөмкин булыр иде. Ләкин китерелгән кадәресе дә кулъязмаларыбызның күп булуын һәм киң таралуын расларга җитә кебек.

Илебез китапханәләрендә татар кулъязмаларының ничек туплануын артык аңлатып торуның кирәге юк. Алар, нигездә, Россия галимнәре, татар халкының үз вәкилләре тарафыннан җыеп тапшырылганнар. Чит илләргә исә алар төрле юллар белән таралган. Бер өлешен IX—XVIII йөзләрдә Европа илләренә күчеп киткән болгарлар, кыпчаклар үзләре белән алып чыкканнар дип карарга мөмкин. Кыпчаклар арасында миссионерлык эше алып барган чиркәү әһелләре, төрле сәбәпләр белән Россиягә килеп чыккан чит ил сәяхәтчеләре, биредә яшәгән әсирләр дә көнчыгыш кулъязмалары белән кызыксынганнар[1]. Польшадагы татар кулъязмаларының бер өлеше, мәсәлән, Россиядә сөргендә булган поляклар тарафыннан алып кайтылган[2].

Кулъязма китапларның теле мәсьәләсе бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән. Ә бу, үз чиратында, шактый күңелсез хәлләргә дә китергәли. Шәрык халыклары, шул исәптән болгарлар да, алдынгы гарәп культурасы, аның графикасын үзләштереп, кабул итеп кенә калмаганнар, телен дә бик әйбәт өйрәнгән булганнар[3]. Гарәп теле шәрыкның «латины» саналган. Татарның әлек барлык диярлек фәнни, дини әсәрләре шул телдә язылган. Соңга таба поэзия өлкәсендә фарсы теле дә киң кулланыла башлый. Шуңа күрә татар кулъязмалары арасында фарсы, бигрәк тә гарәп телендә язылганнары аерата күп очрый.

Буржуаз ориенталистлар язма әсәрнең кайсы халыкныкы булуын аның теленә карап кына билгеләделәр һәм билгеләп киләләр. Кызганычка каршы, бу формаль теориягә иярүчеләр совет ориенталистлары арасында да күренгәли. Моннан берничә ел элек СССР Фәннәр академиясе «Персидские и таджикские рукописи института народов Азии Академии наук СССР» исемле бер хезмәт чыгарды. Биредә Институтның Ленинград бүлегендә саклаучы фарсы телендәге кулъязмаларының тасвирламасы басылган. Исеменнән үк күренгәнчә, андагы кулъязмаларның барысы да таҗик һәм фарсы халыкларының язма мирасы итеп бирелгән. Хәлбуки, тасвирламага кергән 4680 кулъязманың 568 данәсе татарлар тарафыннан язылган яки күчерелгән, аларның шәхси китапханәләреннән җыеп алынган. Аларны Идел буе татарлары арасыннан И. Готвальд, Х. Френ, А. Казембек, В. Акчурин, М. Зарипов, А. Самойлович һәм башка кешеләр, төрле вакытларда җыеп алып, Фәннәр академиясенә тапшырган. Шундый ук хәлне әлеге Институтның башка хезмәтләрендә дә очратып була. «Каталог арабских рукописей института народов Азии» сериясе белән чыгарыла торган кулъязмалар тасвирламасының беренче һәм икенче чыгарылышларында татарлар[4] тарафыннан язылган, алар арасыннан җыйнап алынган матур әдәбият, география буенча хезмәтләр, сәяхәтнамәләр дә, гарәп телендә язылган булуларыннан чыгып кына, гарәп әдәби мирасы дип аталган[5]!

Әгәр кулъязмаларның хуҗасын билгеләүдә мондый формаль теориягә таянып эш итә башласак, Казан университетының фәнни китапханәсендә саклаучы гарәп, фарсы телләрендәге 8000 гә якын язмаларның барысын да гарәп, фарсы халыклары мирасы дип карарга тиеш булабыз түгелме соң? Бу теориянең тагын бер зыяны шунда: мондый караш халкыбызның гарәп, фарсы телләрендә язылган мирасына салкын карауга,

---

[1] С. К. Булич. Очерки истории языкознания в России. Т. I. Спб. Рус телендә. 1904 ел. 202 бит.

[2] J. D. Pearson. Oriental and Asian bibliography. London, 1966, pp. 69—85.

[3] 922 елда Багдад хәлифәтенең илчесе Болгарга килгәч, Алмаз хан бу илче алып килгән хатны тәрҗемәсез укый. (П. Савельев. Мухамеданская нумизматика в отношении к России. Спб. Рус телендә. 1847 ел. 21 бит.)

[4] А. Б. Халидов. Вып. 1. Художественная литература. Рус телендә. 1962 ел; А. И. Михайлова. Вып. 2. Географические рукописи. Рус телендә. 1961 ел.

[5] Дөрес, барлык галимнәр дә мондый җиңел, объектив ук булмаган алымнар белән эш итмиләр, билгеле. Әйтик, шул ук институт галиме А. М. Мугинов үзенең «Описание уйгурских рукописей института народов Азии» дигән китабында борынгы төрки, уйгур, гарәп, фарсы, татар телләрендәге кулъязмаларның тасвирламасын китергән һәм аларны уйгур язма мирасы дип атаган. Ни өчен? Чөнки алар барысы да уйгурлар арасыннан җыелган, алар тарафыннан язылган яки күчереп алынган һәм уйгур халкына хезмәт иткән.

культура тарихыбызны ярлыландыруга, аларны тиешенчә өйрәнмәүгә китерә. Татар әдәбияты тарихында бары тик төрки телләрдә язылган кулъязмаларны гына өйрәнүнең төп сәбәбе менә шушыннан килә дә инде.

Татар кулъязмаларының теле гаять катлаулы. Күреп үткәнчә, аларның күбесе гарәп, фарсы телләрендә язылган. Хәтта кайбер «татарча» язылганнарының да татарчалыгын, С. Кукляшев әйтмешли, җөмлә ахырында очраучы ярдәмче фигыльләрдән генә билгеләп була. Әйтик, әсәрнең авторы Урта Азиядә укыган булса, ул күбрәк чыгытай, Анатолиядә укыган булса — госманлы элементларын куллана. Хәтта Казан губернасының кайсы мәдрәсәсендә тәрбияләнүенә карап та авторларның телләре бер берсеннән нык аерылган. Шуңа күрә кулъязмаларыбызның тел чуарлыгын һәрвакыт истә тотарга кирәк. Аерым әсәрләрнең теге яки бу телдә язылуларыннан, госманлы яки чыгтай телләренә якын булуларыннан чыгып кына бу безнең кулъязма түгел дип мөһер сугарга ярамый.

Язма мирасыбызны барлаганда, татар кулъязмаларына гына хас башка үзенчәлекләр дә искә алынырга тиеш. Беренчедән, күп очракларда татар кулъязмаларының исеме күрсәтелмәгән була. Шуннан чыгып, бер үк әсәрне төрле исемнәр белән йөртү очраклары күренә. Кол Галинең әдәбият тарихында шактый киң өйрәнелгән «Йосыф кыйссасы» да төрле вариантларда язылып йөри: «Йосыф китабы», «Йосыф кыйссасы» һ. б. Икенчедән, татар кулъязмаларында еш кына әсәрнең авторы, язылу елы һәм урыны күрсәтелми. Авторы күрсәтелгән очракларда да, исеменә карап кына аның кайсы халык вәкиле булуын һәрвакыт дөрес билгеләп булмый. Билгеле булганча, борынгы заманнарда ук татарлар арасыннан чит илләргә барып укучылар, сәяхәтчеләр шактый булган. Биографияләрендәге шушы моментларны күрсәтү өчен, алар исем-фамилияләренә үзләре укыган, сәяхәттә булган шәһәрләр, илләрнең исемнәрен дә кушып йөрткәннәр. Татар авторлары арасындагы Хәрәзми, Бохараи, Дагстани, Сәмарканди, Багдади, Мисыри, Һинди, Дәһләви кебек фамилияләр әнә шуннан килә.

Кулъязма мирасыбыз турында сөйләгәндә, аны туплау, саклау, шулай ук өйрәнү турында да бер-ике сүз әйтми үтү мөмкин түгел. Яхшымы, яманмы, — бу өлкәдә элекке чорларда шактый зур эш башкарылган. Күп кулъязмалар китапханәләргә тупланган. Моның өчен рәхмәттән башка сүз юк. Соңгы елларда Казан университеты тарафыннан оештырылган археография экспедициясе, шулай ук университетның фольклор, диалектология экспедицияләре Рязань, Пермь, Оренбург, Астрахань, Ульяновск, Горький өлкәләрендә, Чувашстан һәм Башкортстанда яшәүче татарлар арасында сакланган йөзләгән кулъязмаларны табып алып кайтты. Бу эш белән СССР Фәннәр академиясе Казан тел, әдәбият һәм тарих институтының диалектология, фольклор һәм этнография экспедицияләре дә шөгыльләнә башлады. Ләкин университет та, институт та бу эш белән системалы рәвештә шөгыльләнә алмыйлар. Хәтта алар кулъязмалар җыю эшен киң күләмдә, актив алып барсалар да, илебезнең һәм Европа, һәм Азия өлешләрендә шактый киң таралган татар авылларын айкап чыгу өчен дистәләгән еллар кирәк булыр иде. Гарәп язуын укырлык буын бетеп бара. Шунлыктан бу графика белән язылган кулъязма китапларның кадере дә шактый кимеде. Ә бу, үз чиратында, халык кулында сакланып калган кулъязмаларның тизрәк югалуына китерә. Шуның өчен дә кулъязма мирасыбызны туплау актуаль мәсьәләгә әйләнде. Аларны саклап калу өчен җәмәгатьчелекнең актив ярдәме кирәк. Бу эштә халык белән иң якын элемтәдә яшәүче авыл интеллигенциясе, бигрәк тә укытучылар, зур ярдәм күрсәтә алалар.

Мирасны җыю кем эше?—дип сораулары бар. Бу барыбызның да намус эше. Ләкин, ничек кенә булмасын, аның оештыручысы, бер үзәге булырга тиеш. Җитәкче булу, оештыру Казан тел, әдәбият һәм тарих институты җилкәсенә төшәргә тиештер, билгеле.

Хәзер басма китап заманы. Ләкин бүгенге көндә дә кулъязма әсәрләр туып тора. Язучыларыбыз, галимнәребезнең кулъязмаларын җыйнарга хәзер үк керешсәк, начар булмас иде. Дөрес, Тел, әдәбият һәм тарих институты бу өлкәдә шактый зур эш алып бара. Ләкин барысын да эшли дисәк, бик үк дөрес булмас. Хәзергә кадәр хәтле Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, М. Фәйзи, М. Җәлил кебек классикларыбызның кулъязмалары, алар иҗатына бәйле материалларның бер өлеше әле һаман да аерым кулларда сакланып килә.

Дәүләт һәм фән учреждениеләренә тупланган байлыкның саклану мәсьәләсенә дә игътибарны арттырырга кирәк кебек. Дөрес, Казан университеты китапханәсендәге кульязмалар тулысынча документаль каталогларга кертелгәннәр, аерым папкаларга салынып, тимер ишекләр ясалган бүлмәләрдә, шкаф эчләрендә саклананалар. Ләкин кәгазь гомере бик чикле бит. Шуның өчен кульязмаларның борынгыларының, кәгазьләре картайганнарының фото-микрокопияләрен ясатырга, кәгазьләрен химик юллар белән ныгытып, реставрацияләп, оригиналларының гомерен озайту эшенә керешергә кирәк. Ә бу юнәлештә бездә бер нәрсә дә эшләнми диярлек.

Татарстан дәүләт музеенда саклануы кульязмаларыбызның язмышы аеруча борчый. Саклану шартлары тиешле таләпләргә җавап бирми. Биредә кульязмаларның бер өлеше хәтта дәүләт учетына да кертелмәгән. Аерым кульязмаларның югалу очраклары да билгеле.

Кульязмаларыбызның тасвирламаларын басып чыгару да көн тәртибенә баскан мәсьәләләрнең берсе. 1950 елларның уртасында Казан университеты, бу эшкә шактый актив керешеп, анда саклануы 12 меңләп кульязманың 500 енең тасвирламаларын да чыгарган иде. Ләкин шуннан соң бу китапханәнең безне яңа тасвирламалар белән куандырганы юк. Ә бит инде безгә Казаннан тыш саклануы кульязмаларыбызның тасвирламаларын да хәзерләргә вакыт җитте. Мондый тасвирламаларсыз мирасыбызны белү, тиешенчә өйрәнү, шулай ук әдәбият, культура һәм халкыбызның тарихын тирән яктырту авыр булачак.

Биредә язма мирасыбызның тарихи, теоретик, практик мәсьәләләренең бәхәсле моментларына да кагылып үтелде. Мәкаләнең төп максаты да шул: моңа хәтле күләгәдә калып килгән кульязма мирас мәсьәләләрен, бу өлкәдә яшәп килүче бәхәсле моментларны, җитешсезлекләрне күрсәтү иде. Кульязма китапларның язма ысуллары, стильләре, сәнгатьчә бизәлеше, аларның язылу, җыелу тарихлары кебек специфик сораулар биредә каралмады. Алары турында палеографлар, сәнгать белгечләре үз фикерләрен әйтерләр.

Кульязма мирасыбыз — халкыбызның байлыгы, культурабызның хәзинәсе, энҗеләре. Аларга булган карашны үзгәртәсе иде.

# Укучылар иҗаты

## Тайгада

Чыкты ай, күктә йолдызлар.
Сибелә нур күлләргә.
Безне тайга матурлыкка
Тели, ахры, күмәргә.

Ай астында, мүк өстендә
Урманчылар тезелгән.
Учак пыскый, төтеннән
Черки кача безелдәп.

Һәрбер кичнең гадәте бу —
Сүз башлана бүген дә:
Мин, — ди күрше, — бер аюны
Бистем уч төбемдә.

Кистем агач, аумый гына —
Каршы яктан терәгән...
Йонлач хуҗа минем белән
Шаярырга теләгән...

Табыла шаян сүзләргә
Аннан уздыручысы.
Ышанабыз кайчагында,
Юанычыбыз — шушы...

Тына урман, тына юллар,
Тына ылыс бөртеге.
Яктыра учак аланда,
Бу — тайганың бер төне.

## Кара урман

«Кара да гына урман», — дип җырлыйлар, —
Кара түгел, яшел икән бит.
Урман уртасында бер моңлысы
Яшерен генә яшен түккән бит.

Моңлысын да, шаянын да җырның
Туры килде тыңлап үсәргә...
Кайсысының тылсымнары икән
Әйләндерә урман кисәргә.

Урманчылар тайга кочагында
Яңа җырлар җырлап тынмыйлар.
Ак төннәрдә манси егетләре
«Кара урман» көен тыңлыйлар.

Кирәк микән шаулы урманнарда
Моңлап җыру тальян гармунын! —
Көчем арта сыман анда тойгач
Моң сөюче дуслар барлыгын.

Уйныйм көйләр,
Дуслар гына түгел,
Тыңлый аны яшел урманнар...
Элек кенә тормыш һәм заманнар
Кара урман кебек булганнар.

*Гази КАМАЛОВ.*

# *Безнең интервью*



## ӘДИПНЕҢ УҢЫШЫ

*Ибраһим Зиннәт улы Нуруллин күп санлы тәнкыйть мәкаләләре, «Тукай эстетикасы», «Образлар дөньясында», «Ш. Камал иҗаты», «XX йөз башы татар әдәбияты» исемле фәнни хезмәтләре һәм «Тукай Петербургта», «Поэт из деревни Кырлай» (Мәскәүдә «Детгиз» нәшриятында русча басылган), «Тукай турында хикәяләр» исемле әдәби әсәрләре белән киң катлам укучыларга инде күптән таныш. Соңгы елларда ул яңа зур фәнни хезмәт — «Татар әдәбиятында критик реализмның формалашуы һәм үсеше» дигән темага докторлык диссертациясе язды. Ә 1967 елның икенче яртысында шул хезмәтен уңышлы яклап, филология фәннәре докторы дигән фәнни дәрәҗә алуга иреште.*

*Шул уңай белән редакция И. Нуруллинга берничә сорау бирде. Түбәндә докторның ул сорауларга биргән җавапларын урнаштырабыз.*

*РЕДАКЦИЯ.*

**СОРАУ. Ибраһим ага, кыскача гына булса да, үзегезнең автобиографиягезне сөйләсәгез иде?**

**ҖАВАП.** Бу очракта гадәти автобиография кирәк булмас дип беләм. Бит каләм иясенең биографиясе гадәттә аның иҗатына нисбәтән генә киндидер әһәмияткә ия. Шуңа күрә мине әдәбиятка китергән һәм хезмәтемә билгеле бер юнәлеш биргән кайбер фактларга гына тукталып китмәкче булам.

Мин әдәбиятка буразнадан килдем дип мактана алмыйм. Минем әти, авыл укытучысы булып, Ш. Камалның Каюмы тибындарак бер кеше иде.

Чаллыда үткәрелгән бу елымны киләчәк язмышымны билгеләгән бер эпизод итеп саныйм: мин ул елда, район китапханәсендәге татар китапларын укып бетерүдән тыш, С. М. Киров үлеменә багышланган беренче «шигыремне» язган идем.

Аннары тагын авыл мәктәбе. Куйбышевта чыгып килгән «Колхозчы» газетасы тәэсирендә бер төркем укучыларның (мин дә шул исәптә) язарга кызынып йөрүләре. Моннан соң Казан, әдәби җомгаларга йөрү, тере язучыларны күрү.

Аннары Бөек Ватан сугышы. Солдат капчыгында — Свирский, Такташ, Гариф Галиев, борынгы грек философлары турындагы китап. Госпитальдә бер ел: роман артыннан роман уку, Белинский һәм Писарев хезмәтләрен өйрәнү, шигырьләр язу.

Аннары тагын авыл. Фатих Хөсни кулыннан кичеп дөнья күргән беренче хикәя.

Укуымны дәвам иттерү нияте белән Казанга кайткач, минем алда уку йорты сайлау проблемасы тормады: университет каршында татар бүлеге минем өчен ачылган диярсең! Ул арада тагын берничә хикәям басылса да, тәнкыйть һәм фән белән кызыксыну көчәя барды. Егерме биш битлек беренче мәкаләм мәрхүм К. Нәҗми редакцияләгәннән соң биш биткә калып журналда да чыккач, тәнкыйтьчелек «карьера»сы минә үзенә тартмый кала алмады.

Аннары аспирантура, диссертация яклау, гыйльми тикшеренү эшләре белән бергә бара торган педагогик хезмәт. Менә шул.

СОРАУ. Язучылар җәмәгатьчелеге арасында да, журнал укучыларыннан килгән хатларда да соңгы ике-өч ел эчендә әдәби тәнкыйть йомшара төште, әдәбиятыбызга тирән анализ ясаган проблемалы мәкаләләр бик азайды диган сүзләр ишетелә башлады. Сез бу мәсьәләгә ничек карыйсыз? Әгәр тәнкыйтьчеләребез, чыннан да, пассивлашканнар икән, моның сәбәпләре нәрсәдә дип уйлыйсыз?

ҖАВАП. Соңгы ике-өч ел эчендә тәнкыйть йомшара төшканме-юкмы — әйтә алмыйм. Ихтимал, шулайдыр да. Ә менә бүгенге көн әдәби хәрәкәтенә юл күрсәтеп барырга тиешле тәнкыйтьнең арттa сөйрәлүе турында сөйләүнең күп еллык тарихы бар. Болай дип сөйләү вакыт-вакыт тирән акыллы булып күренү рәвешен алса да, нигездә дөреслеккә туры килә.

Ник шулай, ник әдәби тәнкыйть үзе тәнкыйть объекты булып килә? Минемчә, гаеп аттa да, тәртәдә дә.

Бездә татар әдәбияты тарихын өйрәнә торган утызлап дипломлы галим бар. Әмма тәнкыйть арбасына җигелгәннәрен санау өчен бер кулның бармаклары да җитсә кирәк. Билгеле, үпкә сүзе иң элек татар совет әдәбиятын махсус өйрәнүчеләр өстенә төшә. Ләкин әдәбиятның элеккерәк чорлары белән шөгыльләнүчеләрне азат итәргә дә ашыкмыйк. Ул гына да түгел, андый иптәшләрнең күбесе төпкә җигелеп тартырга тиеш дип уйлыйм мин. Ник? Чөнки әдәбият тарихы — билгеле бер закончалыклар тәэсирендә хәрәкәт итә торган бер бөтен процесс. Әдәбиятның бүгенге хәлен аның үткәне белән бәйләп карамый торып, аны аңлау һәм киләчәген чамалау гаять кыен. Менә ни өчен кулына тәнкыйтьче каләме алган әдәбият тарихчысының күзе, карчыга күзе кебек, бүтәннәр күрә алмаганны да күрергә мөмкин. Тагын шунысы бар: бүгенге әдәбияттан хәбәрдар булмаган, аның турында уйланмаган галимнең мин тарихчы буларак та үз вазифасын тулы үти алуына шикләнеп карыйм.

Бусы аттa булды. Инде тәртәгә килик.

Әлеге өч диста әдәбият белгечләре арасында арбага җигелергә теләүчеләр һәм моңа сәләтлеләре дә юк түгел. Тик менә тәртә бераз кыскарак түгел микән дә тояклары вакыт-вакыт канатмый микән?

Метафорасыз гына әйткәндә, эш болай тора. Бездә бер генә бөртек тә профессиональ тәнкыйтьче юк. Тәнкыйтьчә саналганнарыбыз «производстводан аерылмыйча» гына эшләп киләләр. Ә бит аларның үз «производство планнары» бар, алар өчен дә тәүлек 24 сәгатьтән генә тора. Әйтик, Язучылар союзының идарәсе көннәрдән бер көнне, югары оешмаларга барып, әйдәгез, галимнәрнең фән планнарына бүгенге әдәбият мәсьәләләрен хәл итүне дә кертик дип әйтсә, ничек булыр иде? Минемчә, начар булмас иде.

Ярар, бу эш эшләнми. Киләчәктә эшләнерме, юкмы, белмим. Исчмаса, бар кебек тәнкыйтьче галимнәргә карата кайгыртучанлык күрсәтү, аларга эш шартлары тудырырга тырышу булсын иде. Ә бу җитәрлек түгел. Әйтик, кемгә дә булса түбәндәгечә мөрәҗәгать иткәнебез бармы? Менә сиңа, кадерле иптәш, командировка. Кит әйдә И. Газиның туган авылына. Табигатен күзәт, замандашларын күр, кайтып, әнтәрын, укы, уйлан да иҗат портретын язып бир.

Ниһаять, яшьләрдән тәнкыйть кадрлары үстерү эше дә бездә юк дәрәҗәсендә. Филология факультетларында укучы сәләтле студентларны табып алып, аларны тән-

кыйтькә юнәлтү һәм тәрбияләү буенча нинди чаралар күргәнебез бар? Атап әйтү кыен.

Шулай булгач, ике сүзнең берендә тәнкыйть артта сөйрәлә дип лаф ору белән эш тәмамләначәкме? Бик шикләнәм.

СОРАУ. Үзегезнең киләчәккә фәнни иҗат планнарыгыз турында берничә сүз әйтсәгез иде?

ҖАВАП. Татар әдәбиятында критик реализмның формалашуы һәм үсеше проблемасының әдәби-эстетик һәм иҗтимагый-политик яклары минем диссертациядә беркадәр ачыкланган дип саныйм. Әмма критик реализм әдәбиятының кайбер «кендек әбиләре» анда телгә генә алып кителгән әле. Мин политэкономия, тарих һәм философия кебек иҗтимагый фәннәрне күздә тотам. Критик реализм принципларының урнашуында шул фәннәрнең ярдәме конкрет төстә ни рәвешле булган? Әнә шул сорау борчый мине хәзер. Әлбәттә, бу мәсьәләне хәл итү өчен шул өлкәләрдә эшли торган иптәшләрнең катнашы кирәк булачак. Бүгенге диалог андый белгечләрне табуда беркадәр ярдәм итсә, мин бик шат булыр идем.

СОРАУ. Әдәбият галиме һәм укытучысы булу белән бергә, сез художестволы әсәрләр һәм тәнкыйть мәкаләләре дә язасыз бит әле. Бу өлкәдә эшләрегез ничек тора?

ҖАВАП. Соңгы 2—3 ел эчендә мәгълүм сәбәпләр аркасында тәнкыйтьтән читтәрәк торырга туры килде. Яңадан кайтып, активрак эшләргә исәп бар. Хәер, икенче сорауга биргән җавабым белән үз-үземне бәйләп куйгач, теләмәсәң дә, эшләрсең хәзер. Әдәби әсәрләр мәсьәләсенә килгәндә, мине күптәннән бирле инде Тукай шәхесе дулкынландыра. Әгәр «Тукай Петербургта» һәм «Тукай турында хикәяләр»дән башланган эш, повесть димме, роман димме, берәр күләмле әсәр белән очланса, мин үземне бер зур социаль заказ үтәгән итеп санар идем.

СОРАУ. 1968 елда безнең журналга нинди материаллар тәкъдим итәргә ниятлисез?

ҖАВАП. Бу сорауга җавап бирү шактый хәтәр. Вәгъдә итәрсең — үти алмассың. Оят булыр. Шулай да берничә мәкалә һәм рецензия астында үземнең фамилиямне күрермен дип өметләнәм.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт.

◆ ◆


# яңа китаплар

Азат Әхмәдуллин

## ФӘТХИ БУРНАШ

*Бәясе 24 тиен*

Татар совет әдәбияты һәм матбугатының беренче егерме елын Фәтхи Бурнаш исеменнән башка күз алдына китерү кыен. Иҗатта өлгергәнлеге белән каләмдәшләрен сокландыра торган драматург һәм шагыйрь, ялкынлы публицист, сатира һәм юмор остасы, танылган тәрҗемәче, принципиаль тәнкыйтьче һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Ф. Бурнашның үзе һәм аның әсәрләре белән кызыксыну көннән-көн арта бара. А. Әхмәдуллин үзенең бу китабында күренекле татар совет язучысы Фәтхи Бурнашның тормыш юлы һәм әдәби-иҗтимагый




эшчәнлеге хакында сүз алып бара. Китапта Ф. Бурнашның күп кырлы иҗатына — поэзиясенә, сәхнә әсәрләренә һәм публицистикасына да шактый киң анализ ясалган.

Дмитрий Блынский

## РАЗЛИВ ТУГАЙЛАРЫНДА

Поэма

*Бәясе 27 тиен*

Күренекле рус язучысы Дмитрий Блынскийның В. И. Ленин турындагы бу поэмасын шагыйрь Илдар Юзеев тәрҗемә иткән. Поэма бөтен кешелек дөньясы-




ның даһие В. И. Ленинның Разливта яшәгән көннәрен сурәтләүгә багышланган.

Илдар Юзеев

## ЯШЬЛЕК ДУСТЫМА

Поэмалар

*Бәясе 11 тиен*

Шагыйрь Илдар Юзеевның һәрбер китабы укучылар тарафыннан көтеп каршы алына. Аның әсәрләренә язылган җырлар яшьләр арасында киң таралган. Әмма, барыннан да элек, Илдар Юзеев — поэмалар язучы шагыйрь. Аның бу китабында «Тынлык белән сөйләшү» һәм «Таныш моңнар» исемле поэмалары басылган.




Абдулла Сәләхетдинов

## ИДЕЛ БАҺАДИРЫ

Шигъри повесть

*Бәясе 35 тиен*

Абдулла Сәләхетдиновның бу шигъри повестенда Сталинград сугышы батыры Хафиз Фәттахетдинов




образы гәүдәләндерелгән. Хафиз — авторның авылдашы. Шунлыктан шагыйрь

аның тормышын якыннан белеп сурәтләгән. Әсәрдә совет чынбарлыгында үскән гади авыл егетенең ил язмышы хәл ителгән киеренке көннәрдә күрсәткән батырлыгы тасвирлана.


Риза Халид

**СИН КҮҢЕЛЕМДӘ МИНЕМ**

Лирик шигырьләр

*Бәясе 11 тиен*

Ленинградта яшәүче шагыйрь Риза Халид — бик күп шигырь китаплары ав-




торы. Аның бу җыентыгына Ленин, партия, Ленинград һәм хезмәт кешеләре турындагы лирик һәм фәлсәфи шигырьләре тупланган.

Хисам Камалов

**ЯЗМЫШ**

Шигырьләр

*Бәясе 13 тиен*

Шагыйрь Хисам Камаловның бу җыентыгында төрле темага язылган һәм кешенең ил, халык алдындагы бурычы турындагы уйлануларын чагылдыруга багышланган шигырьләре басылган. Китапта В. И. Ленинга багышланган шигъри язмалар шактый зур урын алган. Җыентык мәрхүм шагыйрь Гали Ху-




җиевның Х. Камалов иҗаты һәм тормышы турындагы мәкаләсе белән башлана.


Мәхмүт Хөсәен

**ҖИР МӘРҖӘННӘРЕ**

Сонетлар

*Бәясе 35 тиен*

Сонет — бөтен дөнья поэзиясенең классик формасы. Шагыйрь Мәхмүт Хөсәен шул формага милли колорит биреп, аны үзенең ли-



рик һәм гражданлык хисләрен чагылдыруда файдаланган. Бу китабында шагыйрьнең 141 сонеты басылган.

Адлер Тимергалин

**ЕРАК ПЛАНЕТАДА**

Фантастик хикәяләр

*Бәясе 29 тиен*

Дуслык, тигезлек һәм бәхет... Адлер Тимергалинның бу китабына кергән «Ерак планетада» исемле озын хикәянең идея юнәлеше әнә шул. Автор бу хикәясендә башка йолдыз




системасындагы бер планетада һәлакәткә очраган космонавтларның ят цивилизация очратуы һәм шул дөнья вәкилләре белән элемтәгә керәп, дуслык мөнәсәбәтләре урнаштыруы турында сөйли. Ә «Мәңгелек» дигән хикәясендә кеше гомерен озайту, яшүсмер Стенның маҗаралары һәм бер ялгызы эшләгән галим де-Лоринның фаҗигале язмышы тасвир ителә. «Шартламасын», «Риб Локсның үлеме» исемле хикәяләрендә барлык нәрсә капиталга корылган дөньядагы шәхси фаҗигаләр сурәтләнә.

# *Безнең календарь*

## Гиз эль-Габиднең тууына 50 ел

(1918—1955)



Фронтларның барында да
Үтәгәч ил кушканны,
Тын океан ярында да
Тез чүктердек дошманны.

Бу шигырь юлларының авторы — бөтен яшьлеген Совет Армиясе сафларында хезмәт итүгә багышлаган фронтовик-шагыйрь Гиз эль-Габид иде.

Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Алар сафта» исемле китаптан аның хакында түбәндәгеләр мәгълүм:

Гиз эль-Габид 1918 елның 7 февралендә Оренбург өлкәсе Свердлов районы Саиновка (Хөсәен) авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Күрше авыл мәктәбендә 7 классны тәмамлагач, 1935—37 елларда ул Оренбургтагы педагогия техникумында укый. Шул елларда Оренбургта чыга торган «Коммунист» газетасында беренче шигырьләре басыла башлый.

1938 елда Гиз эль-Габид Совет Армиясенә чакырыла, Себердә, Забайкальеда, Монголия Халык Республикасында хезмәт итә. Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә Ленинградта, соңыннан Карелиядә, Мурманскида, Финляндиядә һәм Төньяк Норвегиядә сугышчан заданиеләр үтәүдә катнаша, фронт газетасының корреспонденты булып эшли.

Бөек Ватан сугышы елларында яшь шагыйрьнең иҗат эшчәнлеге бермә-бер активлашып, көчәеп китте. Кыска гына вакыт эчендә утызга якын әсәр бирде. Җиңүгә тирән ышаныч, оптимизм хисләре белән сугарылган ул шигырьләрнең күбесе бүген дә актуаль яңгырый, бүген дә укучыларны сөендерә, дулкынландыра ала.

Узган сугыш дөнья халкына күпме кайгы, күпме сагыш китерде. Сугыш узган юлларда күпме корбаннар ятып калды. Үзенең «Вәхшиләр» исемле шигырендә, фашистларга тирән нәфрәт белдереп, Г. Габид болай ди:

**Чымырдата нәфрәт тамырларны,**
**Кан сабыша янган күзләргә.**
**Йөрәкләрдән ташкан кискен ачу**
**Сыя алмый гади сүзләргә...**

Гиз эль-Габиднең сугыш каһарманнарына багышлап язылган әсәрләре арасында аеруча игътибарга лаеклысы «Исемсез күл» диган шигыре. Шагыйрь бу әсәрен Карелия фронтында батырларча көрәшеп үлгән мәшһүр разведчик Кәрим Зәбиров истәлегенә багышлый.

Батыр сугышчының исемен мәңгеләштерү максаты белән язылган шигырь шундый юллар белән тәмамлана:

**Исемсез күл — әйе, исемсез...**
**Атсыз кабер — әйе, атсыз ул...**
**Батыр сугышчыга һәйкәл булып,**
**Мәңге-мәңге җәйрәп ятсын ул.**

«Рыбачийда» исемле көчле романтик рухтагы икенче бер шигырендә Г. Габид совет сугышчысының үлгәндә дә елмаеп үлүен тасвирлый. Шагыйрь үлем белән бугазлашучы авыр яралы сугышчыны табигать белән параллель сурәтли. Болай эшләү батыр сугышчының Туган ил табигатенә булган мәхәббәтен ачарга ярдәм итә. Шигырьнең беренче өлешендә дәһшәтле сугыш ураганнары белән каенның көрәше тасвирлана. Каенның да язмышы авыр, яралы сугышчыныкы кебек. Ләкин ул чыдам, бирешми... Шул урында шагыйрь сюжетта кискен борылыш ясый:

**Бер сугышчы үткер ташлар арасыннан**
**Шуды әрнеп, янып.**
**Шул ташларга саркып дүрт-биш ярасыннан**
**Акты кайнар каны,**
**Һуштан язды...**

һәм укучыда әлек авыр тәэсир калдырып килгән шигырь шунда ук балкып китә, оптимистик көч ала.

**... Соңгы кабат ачып күзен**
**Шул каенны күрде.**
**Киң елмаю нурландырды кансыз йөзен —**
**Әйтерсең, җан керде.**

Үз әсәрләрендә шагыйрь лирик-интим хисләргә дә шактый урын бирә. Андый шигырьләре эчке җылылык, көчле сагыну хисләре белән аерылып тора.

**Бу җыр, хатым кадәр, кайнар түгел,**
**Тик син кичер, аны хат дисәм.**
**Хат юк чакта, аны көйләп, син бел:**
**Мин — синеке, мин сау һәм исән!**

Сугышчы хаты... Ул, солдатның үзе кебек үк, авыр көрәш юлларын уза.

Ул хатларның гомерен пуля кисеп куюы бар. Кайчакта солдатның хат язарга яки язылган хатны салырга да вакыты булмый. Чөнки, сугыш...

**Хәвефләнмә, бәгырем, күз-яшь түгеп,**
**Миннән озак хатлар бармаса,**
**Хатларымның юлы гади түгел —**
**Алар үтә ут һәм кар аша.**

*(«Хәвефләнмә, бәгырем».)*

Гиз эль-Габид фронт юлларын сугышның башыннан ахырына кадәр солдат булып үтте. Шуңа да ул совет сугышчысының эчке кичерешләрен, аның патриотик тойгыларын тирән һәм дөрес чагылдыра алды.

Көрәшнең иң авыр көннәрендә дә совет кешеләре үзләренең җиңеп чыгачакларына нык ышандылар. Чөнки алар немец илбасарларының безнең илебезгә каршы тора алмаслыкларын яхшы беләләр иде. Г. Габид әсәрләрендә сурәтләнгән геройларда да җиңүгә ышаныч көчле булды...

Ул көрешү булыр кайсы вакыт,
Кайсы җирдә, кайсы урында —
Әйтү читен, әмма көн күк ачык:
Күрешербез җиңү кырында!..

*(«Батыр дусларга».)*

Сугыш елларында Гиз эль-Габид Мифтах Вәдут, Демьян Фәтхи, Мансур Гаяз, Касыйм Вахит кебек күренекле фронтовик язучылар белән бер сафта барырлык шагыйрь булып җитеште.

Г. Габид сугыштан соң да көрәшче, тыныч хезмәт җырчысы булып калды. 1946 елда Армия сафыннан демобилизацияләнгәч, ул, Урта Азиягә барып, Үзбәкстандагы Карши һәм Шәһрисябз шәһәрләрендә укытучы булып эшли. Ләкин сугышта алган яралары шагыйрьне 1955 елда безнең арадан алып китә.

Ул иҗат иткән әдәби әсәрләр сугыш чоры татар поэзиясен баеттылар, бу шагыйрьнең зур фикерләр һәм тирән тойгылар җырчысы булып өлгерүен күрсәттеләр.

Әдхәт СИНЕГУЛОВ.

*Гиз эль-Габид*

## Карел язы

Кошлар сайрый сынык ботакларда,
Кояш уйный июль күгендә.
Ак ландышлар күренә баткакларда,
Миләүшәләр ата күнелдә.
Көйгән ылысларны убә җилләр,
Су кызара Суо күлендә.
Якты яңа тормыш шытып килә
Янган авылларның көлендә.
Олы юллар ташый гаскәр белән,
Көнбатышка илтеп ташкынын.
Без атлыйбыз даңлы частьлар белән,
Җиңү өчен алга ашкынып.
Җылы җилләр исә, көннәр аяз,
Кояш төшми Карел күгеннән.
Июль азагында туган бу яз
Бәйрәм булыр инде күңелгә.

Июль, 1944. Хәрәкәттәге Армия.

◆ ◆



# сатира һәм юмор

*Шәүкәт Шәрәпов*

## Линейка-рецензент

Бер линейка сызымнар тикшерә,
Лекало эшенә рецензия язып бирә:
— Кәкре дә бөкре итеп сызгансыз
Һәм шуның белән эшне бозгансыз.
Сызымнарны кабат карап чыгыгыз,
Сызыкларыгызны туры сызыгыз.

●

Мин хатынның кушканнарын
Үтәп киләм һәрчак төгәл.
«Дәшмә миңа!» — дип акырды
Киңәшемә каршы бер мәл.
Ул дәшсә дә, дәшмим хәзер,
Тиздән инде атна тула,
Дәшәр идем (исәп тә бар),
Хатын сүзен бозу була.

## Чәч турында такмаклар

*(Эстрада өчен)*

Чәчнең була үргәннәре,
Була үрмәгәннәре.
— Таракны көн дә күргәне,
Бер дә күрмәгәннәре.
— Чәчнең була сорылары
Һәм була каралары.
— Чүмәлә күк өйгәннәре
(Соңгы мода алары).
— Чәчнең юлларын ачалар:
Турысын һәм кыегын.
— Кайберләре салындыра
Баштан «бия койрыгы»н.
— Озын толымлы чәчләр бар,
Бусы — үрә торганы,
— Очрап куя юк-барга да
Бик тиз үрә торганы.
— Чәчләр чәчкә бәйләнәләр,
Очынабыз бусына.
— Кайчак төене нык булмый,
Борчылабыз шунысына.
Бергә: — Теләгәнчә чәч йөртегез,
Ирек һәрбер иптәшкә,
Тик мәхәббәт учагының
Көле кунмасын чәчкә.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Узган елның декабрь аенда Казанда яшь язучыларның III конференциясе булып үтте. Конференциягә Башкорстаннан, Чувашстаннан, Удмурт, Мари республикаларыннан, Чиләбе, Пермь өлкәләреннән һәм Татарстан районнарыннан, шәһәрләреннән йөздән артык яшь язучы катнашты. Алар барысы да завод-фабрикаларда, колхоз-совхозларда эшлиләр, төрле уку йортларында укыйлар, шул ук вакытта әдәби иҗат эше белән дә шөгыльләнәләр. Кайберләре хикәя, повесть яза, икенчеләре поэзия жанрын өстенрәк күрә, ә өченчеләре драма, очерк жанрларында көчләрен сынап карый.

Конференцияне Тукай исемендәге клубта Татарстан язучылары союзы идарәсе председателе Мирсәй Әмир ачты. Ул әдәбият мәйданына беренче адымнарын атлаучы яшь авторлар алдында торган бурычлар турында сөйләде, аларга яңадан-яңа иҗади уңышлар теләде.

Аннан соң сүз ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты секретаре Р. Фәрхиевкә бирелде. Аның комсомол эше һәм әдәби иҗат мәсьәләләре турындагы чыгышын яшь язучылар кызыксынып тыңладылар.

Казан дәүләт университеты доценты, шагыйрь һәм тәнкыйтьче Зәет Мәҗитов, конкрет авторларның әсәрләренә тукталып, яшьләр иҗатындагы уңышлы һәм кимчелекле яклар турында эчтәлекле доклад ясады.

Конференция вакытында 9 секциядә кырык авторның әсәрләре тикшерелде. Бу әсәрләрне тикшерүдә Х. Туфан, С. Хәким, И. Туктар, Ә. Исхак, Ф. Хөсни, Ә. Еники, А. Расих, Г. Галиев, Г. Минский, Н. Дәүли, Н. Арсланов, Ә. Юныс, башкорт шагыйре Г. Әмири, Х. Вахит, Б. Гыйззәт, Ш. Галиев, Л. Ихсанова, Г. Ахунов, С. Сабиров, Г. Мөхәммәтшин һ. б.лар кебек тәҗрибәле прозаиклар, шагыйрьләр, драматурглар һәм тәнкыйтьчеләр катнашты.

Моннан тыш яшь язучылар поэзия үзенчәлекләре турында филология фәннәре докторы профессор Хатип Госман, Татарстан тарихы буенча тарих фәннәре докторы профессор Рәфикъ Нәфиков, тел-стиль мәсьәләләренә карата филология фәннәре кандидаты Х. Курбатов лекцияләрен тыңладылар. Н. Исәнбәт әдәби мирас, Г. Бәширов талант һәм әдәби тел мәсьәләләре турында сөйләде, Ф. Хөсни үзенең язу тәҗрибәсе белән уртаклашты.

Соңыннан конференциягә катнашучы барлык язучылар Тукай исемендәге клубка йомгаклау җыелышына килделәр.

Беренче сүзне шагыйрь С. Хәким алды. Ул Р. Харисов, З. Гомәрова, К. Мостафин әсәрләренә аерым-аерым тукталды, конкрет мисаллар китереп, алар иҗатындагы үзенчәлекле якларны күрсәтте.

«Ул яхшы шигырьләр яза. Аның шигырьләрендә тормышыбыз сулышы яңгырап тора», — диде Х. Туфан яшь шагыйрь Г. Рәхим турында. Шулай ук ул Ф. Шәфигуллин, А. Хәлим, Т. Камалиевларның да конференциядә тикшерелгән әсәрләренә уңай бәя бирде.

Бу җыелыш конференция вакытында эшләнгән эшләргә отчет бирү формасында барды. Шуңа күрә бик табигый: чыгыш ясаучылар күбрәк үз группаларында тикшерелгән авторларның иҗатына тукталдылар. Мәсәлән, Ә. Исхак, үзеннән алда сөйләгән С. Хәким белән Х. Туфан кебек үк, үз группасындагы яшь шагыйрьләрнең: Х. Хөснуллин, М. Газизов, Х. Гатин, Р. Шакиров, Ә. Синегулов әсәрләрен анализлады; ә Н. Арсланов исә Ә. Ихсанов, Ш. Маннапов, З. Сәмигуллин, Р. Вәлиева, Х. Әюпов әсәрләренә күзәтү ясады, аларны өлкән шагыйрьләрнең уңышлы үзенчәлекләрен дәвам иттерергә чакырды.

Ф. Хөсни яшь прозаиклардан Р. Батуллин, М. Харисов, А. Хәсәнов иҗатларына хас булган уртак сыйфатларны күрсәтте. «Алар өчесе дә өметле, каләмле егетләр, — диде ул. — Аларда схематизм юк, кеше күңеле белән эш итә беләләр. Телне сөя беләләр. Ләкин әдәби иҗат эшенең җитдилеген тулысы белән күз алдына китереп җиткермиләр. Әсәрләрендә гражданлык хисе җитеп бетми. Аннары аз язалар. Үз өсләрендә бик нык эшләргә кирәк».

А. Расих яшь шагыйрьләрне проза жанрында да көч сынап карарга чакырды, аннары М. Маликова, Р. Фәезов, А. Тимергалин әсәрләренә тукталды, аларның һәрберсе иҗатындагы уңышлы һәм кимчелекле якларны әйтте.

Апас районнан килгән М. Рафиковның «Чүрәкәй» исемле китабына Г. Ахунов уңай бәя бирде. Шулай ук ул Д. Вагыйзовның «Казан утлары» журналында басылып чыккан «Принцип», «Балыкчылар» очеркларының телен, аларда сурәтләнгән образларны

мактап телгә алды һәм яшь прозаик М. Хәбибуллин әсәрләренә дә киң туктадды.

Болардан тыш җыелышта Г. Мөхәммәтшин, И. Туктар һәм М. Хәсәнов та Р. Исаев, Р. Фазлыев, Ф. Гыйльметдинов, З. Шакиров, Ә. Галиев, Н. Идрисов, Р. Кәрамиев әсәрләре турында фикерләрен әйтеп, чыгыш ясадылар.

Җыелыш ахырында Татарстан язучылары союзы идарәсе председателе М. Әмир йомгаклау речь белән чыкты.

Конференция көннәрендә яшь авторлар радио, телевидение буенча чыгышлар ясадылар. Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында үткәрелгән чираттагы «Әдәби җомга» да алар иҗатына багышланды. Бу кичәдә яшь язучылар үзләренең әсәрләрен укыдылар.

## ДУСЛАР ХАТЫ

Татарстан язучылары союзына, идарә председателе исеменә бер хат килеп төште.

*«Кадерле Мирсәй Мөсәлимович! — дип башлана ул хат. — Сезне Бөек Октябрьның 50 еллыгы белән котларга рөхсәт итегез. Узган ел без — Леон Небенцаль, Вилли Ловин һәм мин — Сездә кунакта булган идек. Сибгат Хәким белән Гази Кашшаф бездә, Германия Демократик Республикасында, булдылар. Немец язучылары союзы һәм Татарстан язучылары союзы арасында дусларча элемтә ныгый бара. Без сездә күп кенә шагыйрьләр, прозаиклар һәм әдәбият белгечләре белән таныштык. Аларның барысына да чын күңелдән сәламәтлек, бәхет һәм иҗади эшләрендә яңа уңышлар телибез.*

*Татарстан язучыларына багышлап, «Аврора» залпы» исеме астында кайбер фикерләремне язып җибәрәм.*

*Дусларча сәлам белән,*
Сезнең Эрих Мильштат.

## *«АВРОРА» ЗАЛПЫ*

«Аврора» залпы иске, черек дөньяны җимерде. Бөек Октябрь үз сүзен әйтте.

Моңа ярты гасыр вакыт узды. Бу еллар тиңдәшсез хезмәт, җиңү еллары булдылар. Халык, Ленин партиясе җитәкчелегендә, үзенә мәңгелек дан яулап алды.

Ил гүзәл ил булып әверелде, тормыш үзгәрде.

Кырларда куәтле тракторлар бай уңыш әзерли. Суканы инде музей экспонаты буларак кына күрергә мөмкин.

Халык Совет җиреннән төрле илбасарларны себереп түкте...

Ленин иле җиңелмәс, куәтле ил булып әверелде. Аның нигезендә совет фәненең бүгенге казанышлары ята... Ильич утлары, якты кояш кебек, бөтен дөньяга үзенең сафландыргыч нурларын сибә.

Айда да, Зөһрә йолдызда да мәңге үлмәс гимн яңгырады:

«Кузгал, уян, ләгънәт ителгән
Коллар һәм ачлар дөньясы...»

Бу гимн, күкрәү авазы булып, бөтен җир шары тирәли әйләнде. Пентагондагы джентльменнар, Бонндагы әфәнделәр күңеленә курку төште...

Ә совет халкы, бөтен прогрессив кешелек дөньясы белән берлектә, Бөек Октябрьның 50 еллыгын бәйрәм итә...

Җир яшәрде, дөнья яңарды».

## ТАТАРСТАН КОМПОЗИТОРЛАРЫ СОЮЗЫНЫҢ VIII ПЛЕНУМЫ

Татарстан композиторларының 1967 елның декабрендә җыйналган VIII пленумы, РСФСР композиторлары союзы секретариаты утырышы белән берлектә, Казанда үткәрелде. Пленумга Мәскәүдән — В. Фере, С. Баласанян; Ленинградтан — А. Петров; Ростов-Доннан — Артамонов; Башкортстаннан — З. Исмәгыйлов, музыка белгече Мәсәгутов; Чувашстаннан — Ф. Лукин һәм шулай ук Әзербәйҗан, Төркмәнстан, Казагыстан композиторлары катнашты.

Пленум Казан консерваториясенең яңа салынган Актлар залында симфоник музыка концерты белән ачылды. Икенче көнне шунда ук республика композиторларының камера музыкасы әсәрләреннән төзелгән концерт булды. Офицерлар йортында тамашачылар яңа җырлар, төрле музыка коралларь өчен язылган әсәрләр тыңладылар. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры пленум көннәрендә «Түләк һәм Су-Сылу», «Җәлил», «Шүрәле» спектакльләрен күрсәтте.

Концертларга танылган сәнгать осталарыннан: М. Булатова, В. Шәрипова, Р. Билялова, И. Гыйззәтуллин, И. Шакиров, Э. Җәләлетдинов, Г. Ильясов; консерватория педагогларыннан: М. Әхметов, Г. Ходжаев, И. Халитов, В. Тонха, В. Столов, профессор Н. Рахлин, дирижер А. Монасыйпов һ. б.лар катнашты. Ленин исемендәге Культура сараеның Бөтенроссия смотрында диплом алган татар хоры (җитәкчесе С. Шаһиева) программасын да тамашачылар яратып тыңладылар.

Татарстан композиторларының төрле жанр әсәрләре белән танышканнан соң, Россия Федерациясе һәм тугандаш республикаларның күренекле музыка эшлеклеләре татар совет музыка культурасының бүгенге торышы, аның алдында торган бурычлар турында фикер алыштылар.

## ЯҢА ЦИРК

Узган елның декабрь аенда Казанда В. И. Ленин исемендәге Үзәк стадион янында яңа цирк бинасы файдалануга тапшырылды. Аның залына ике мең ярым тамашачы сыя. Манежны 400 прожектор яктырта.

Циркны ачуга багышланган тантаналы җыелышны Казан шәһәр Советы башкарма комитеты председателе А. Бондаренко ачты. КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре Р. Мусин тамашачыларны, төзүчеләрне бу шатлыклы вакыйга белән котлады. Аннары сүз Мәскәүдән килгән «Союзгосцирк» берләшмәсе директоры Ф. Бардианга бирелде. Ул бу бинаны

дөньяның иң яхшы циркларыннан берсе, дип бәяләде.

Татарстан культура министры Б. Гыйззәтуллин бу гүзәл бинаны житкерүләре өчен төзүчеләргә рәхмәт әйтте.

Соңыннан төзүчеләргә илебезнең танылган сәнгать осталары цирк тамашалары күрсәттеләр.

## МУСА РОЛЕНДӘГЕ АРТИСТ КАЗАНДА

Укучыларга билгеле булганча, хәзер «Ленфильм» киностудиясе «Моабит дәфтәре» исемле нәфис фильм өстендә эшли. Бу фильмда герой-шагыйрь Муса Җәлил ролен РСФСРның халык артисты Петр Григорьевич Чернов башкарачак. Күптән түгел П. Г. Чернов Казанга килеп китте. Ул республикабыз башкаласына Муса турында күбрәк нәрсә белергә, аңа кагылышлы документларны өйрәнергә, аны күреп белгән кешеләр белән очрашырга, татар халкының тормышы белән якыннан танышырга килгән иде. Шул максат белән ул Татарстан дәүләт музеен карады, Культура министрлыгында булды, татар язучылары белән очрашты.

## ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ МУЗЕЕНДА

Бөек Ватан сугышы елларында күп кенә Мәскәү язучылары Чистай шәһәрендә яшәде. Шул елларда Чистайда яшәгән врач Д. Авдеев алар белән якын аралашкан. Бу врачның улы биология фәннәре докторы В. Авдеев П. Павленко, Н. Асеев, К. Федин, Л. Леонов, К. Тренев һ. б. язучыларның Чистайда 1941—43 елларда төшерелгән рәсемнәрен Татарстан дәүләт музеена тапшырды.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Әлмәттә яшь язучылар семинары үткәрелде. Семинарда Әзһәр Габиди (Сарман), Флера Гыйззәтуллина (Карабаш), Мөсәгыйт Хәбибуллин (Азнакай), Азат Ганиев (Габдрахман авылы) әсәрләре укып тикшерелде.

Семинар житәкчеләре Г. Афзал, Ә. Маликов, Р. Төхфәтуллин, Г. Ахунов үзләренең чыгышларында әдәби осталык мәсьәләләренә киң тукталдылар, сюжет төзү, портретлар бирү, тел-стиль чараларын ничек файдалану турында өлкән язучыларның әсәрләреннән мисаллар китереп сөйләделәр.

Семинар эшенә КПССның Әлмәт шәһәр комитеты секретаре С. К. Хәкимова, Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясе мөдире С. Сабиров һәм Татарстан язучылар союзының әдәбиятны пропагандалау бюросы житәкчесе Т. Миңнуллин катнашты.

Ә. Габидинең «Аланнарда балан» исемле шигырьләр җыентыгын, А. Ганиевнең хикәяләр китабын һәм М. Хәбибуллинның «Җиде юл чатында» дигән повестен нәшриятның 1969 ел планына тәкъдим итәргә, Ф. Гыйззәтуллина шигырьләрен яшь шагыйрьләр җыентыгында бирергә дигән карар кабул ителде.

Семинар эшләгән көннәрдә Әлмәтнең икенче китапханәсендә Татарстан китап нәшриятының 1968 елгы тематик планы турында фикер алышу үткәрелде. План белән нәшриятның матур әдәбияты редакциясе мөдире С. Сабиров таныштырды. Утырышта шәһәрнең китапханәчеләре, китап сәүдәсе хезмәткәрләре, язучылар катнашты.

Семинардан соң Әлмәт район культура йортында зур әдәби кичә булды. Кичәне Гариф Ахунов алып барды, ул, Бөек Октябрьның 50 еллыгы уңае белән, татар әдәбияты ирешкән уңышлар һәм илдәге хезмәт күтәренкелеге турында сөйләде. Г. Афзал, С. Сабиров, Ә. Маликов, Р. Төхфәтуллин, С. Сөләйманова, М. Хәсәнов, Ә. Габиди, Ф. Гыйззәтуллиналар яңа әсәрләрен укыдылар. С. Сабиров шулай ук Татарстан китап нәшриятының 1968 елгы тематик планы турында да сөйләде.

Кичә район хезмәт ияләренең үзешчән сәнгать концерты белән тәмамланды.

* * *

1967 елның 22 октябрендә Әлмәттә Габдулла Тукайга һәйкәл ачылды. КПССның Әлмәт шәһәр комитеты беренче секретаре В. В. Ермаков Тукайның дөнья әдәбиятында тоткан урыны турында әйтеп, хезмәт ияләрен нефтьчеләр каласында бөек шагыйрьгә һәйкәл ачылу белән котлады. Әлмәт шәһәр Советы башкарма комитеты председателе урынбасары К. Ханнанов «Восход» кинотеатрына «Тукай» исемен бирү турындагы карарны укыды. Татарстанның атказанган укытучысы Мирза Таһиров, Тукай премиясе лауреаты С. Өметбаев речьләр белән чыктылар. Беренче номерлы урта мәктәп укучылары Тукайның «Туган тел» җырын җырладылар.

Аннары Г. Афзал, С. Сөләйманова, Ә. Маликов Тукайга багышланган шигырьләрен укыдылар.

* * *

Әлмәт театры һәм Татарстан язучылары союзының Әлмәт бүлеге драматург Сәет Кальметовның «Тайгак тау» исемле яңа пьесасын укып тикшерде. Пьесаны театрның репертуарына алырга карар кабул ителде.

* * *

Әлмәт районы, Миңлебай авылы клубында зур әдәби кичә үткәрелде. Кичә «Казан утлары» журналына багышланган иде. Г. Ахунов журналның тарихы, анда катнашкан күренекле татар язучылары һәм журналда басылачак әсәрләр турында сөйләде. Г. Афзал, Р. Төхфәтуллин, Ә. Маликов журналга тәкъдим итәчәк әсәрләреннән өзекләр укыдылар. Соңыннан «Казан

утлары»на язылу буенча лотерея уены уйналды. 200 лотерея билеты сатылган иде, 14 кеше ярты еллыкта журнал подпискасы һәм байтак кына кеше Әлмәт авторларының китапларын оттылар. Әлмәт бүлеге лотерея уйнау юлы белән журналга яздыруны узган елны Әлмәт районының Габдрахман авылында шагыйрә Энже Мөэминова инициативасы белән башлаган иде. Бу чараның бик кызыклы икәнен тормыш раслады.

* * *

«Нефтяник» совхозының Югары Мактама бүлегендә совхоз эшчеләре белән очрашып, Әлмәт язучылары зур әдәби кичә үткәределәр. Кичәдә Г. Афзал, Р. Төхфәтуллин, С. Сөләйманова һәм Г. Ахунов катнашты. Биредә шулай ук кичә соңында лотерея уеннары белән «Казан утлары» журналына язылу оештырылды. 12 эшче ярты еллык подписка, 17 кеше китаплар отты.

## ЭКСПЕДИЦИЯ НӘТИҖӘЛӘРЕ

1967 елда Казан дәүләт университеты Казагыстанда яшәүче татарларның халык авыз иҗатын өйрәнү өчен фәнни экспедиция оештырган иде. Университетның тарих-филология факультеты студентларыннан торган экспедиция членнары, доцент Н. Юзиев җитәкчелегендә, республиканың Көкчәтау һәм Төньяк Казагыстан өлкәләрендәге Мәүлет, Имән-Тау, Колҗан, Җил-Тау исемле татар авылларында булып, халкыбызның тарихына, көнкүрешенә, шигъри һәм музыкаль иҗатына кагылышлы бик күп яңа материаллар тупладылар.

Экспедиция эшенә Көкчәтауда яшәүче татар язучысы Ибраһим Салахов та актив катнашты. Аның катнашында Мәүлет һәм Имән-Тау авылларында әдәби кичәләр үткәрелде.

Күптән түгел университетның тарих-филология факультеты каршындагы татар телен һәм әдәбиятын фәнни өйрәнү түгәрәгендә фәнни экспедициянең йомгаклары тикшерелде, шул мәсьәләгә карата студентларның докладлары тыңланды.

## ОЧРАШУЛАР, КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР

Казан шәһәренең 10 нчы интернат-мәктәбендә «Китап — белем чишмәсе» дигән темага әдәби кичә үткәрелде. Бу кичәдә шагыйрь Шәүкәт Галиев үзенең балалар өчен язган шигырьләрен укыды. Аннары укучылар шагыйрь әсәрләреннән үзләре оештырган инсценировканы уйнап күрсәттеләр.

* * *

Казандагы 35 нче мәктәптә Ш. Галиев һәм яшь шагыйрь Р. Мингалимов «Яшь ленинчы» газетасы укучылары белән очраштылар, үзләренең балалар өчен язган шигырьләрен укыдылар, автографлары белән китаплар саттылар.

* * *

Республика күчмә театры, Совет властеның 50 еллыгына багышлап, Г. Мөхәммәтшинның «Тынгысыз төн» исемле комедиясен күрсәтте.

Кукмарада бу спектакль буенча автор катнашында тамашачылар конференциясе үткәрелде.

КПССның Кукмара район комитеты һәм район Советы башкарма комитеты театр коллективын «Мактау грамотасы» белән бүләкләде.

* * *

И. Юзеев һәм Г. Мөхәммәтшин Казан дәүләт педагогия институтында татар теле һәм әдәбияты укытучылары һәм студентлар белән очрашып, татар язучыларының хезмәтләре турында сөйләделәр, яңа әсәрләрен укыдылар һәм автографлар белән китапларын саттылар.

* * *

Менделеевск (Бондюг) шәһәренең культура йорты каршындагы үзешчән драмтүгәрәк язучы Э. Касыймовның «Ходай йомышчысы» дигән комедиясен сәхнәгә куйды.

Фольклор мотивларына таянып язылган бу комедияне тамашачылар яратып карадылар.

Спектакльне тикшерүдә әсәрнең авторы Э. Касыймов та булып, үзешчән артистларга үзенең кайбер киңәшләрен әйтте һәм рәхмәт белдерде.

## «КҮҢЕЛЛЕ ОЧРАШУЛАР КЛУБЫ»НДА

«Казан утлары» журналы редакциясе каршындагы «Күңелле очрашулар клубы»ның чираттагы утырышына археологлар — тарих фәннәре докторы А. Халиков һәм СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият, тарих институты фәнни хезмәткәре Р. Фәхретдинов килде. А. Халиков клуб утырышына катнашучыларны башта археологларның эшләре белән таныштырды.

«Археологлар үз фәнни хезмәтләре өчен фактларны кабинетларда утырып түгел, кырлар гизеп, көрәк белән җир актарып эзлиләр», — диде ул. Һәм җир астыннан табылган, беренче карашка бернигә яраксыз кебек тоелган әйберләрнең, фольклор әсәрләре, теге яки бу халыкның сөйләм теле, көнкүреше элементлары, тарихи фактлар белән тәңгәл китереп карасаң, зур фәнни ачышларга дәлил булырга сәләтле икәнлеген бик күп мисаллар белән күрсәтте. Мәсәлән, татар халкының килеп чыгышын моңа кадәр башлыча болгарларга бәйләп аңлаталар иде. Соңгы еллардагы археологик табылдыклар, төрле көнкүреш, бизәнү әйберләре, эш кораллары һ. б.лар Идел — Кама буйларында болгарларга кадәр үк югары культуралы төрки кабиләләр яшәгәнлекләрен дәлилиләр. Бу бик табигый да: чөнки Идел — Кама буйлары-

ның табигате матур, җирләре уңдырышлы, иген игәргә дә, терлек асрарга да уңай, урманнары җәнлеккә, сулары балыкка бай. Болар татар халкының килеп чыгышына киңрәк планда карарга мөмкинлек тудыралар.

Казан археологларының эшчәнлеге елданел киңрәк колач ала бара. Моннан ун гына ел элек бездә гыйльми дәрәҗәсе булган бер генә археолог бар иде. Хәзер инде алар дистәдән артык. Хәзер инде меңнәрчә еллар дәвамында җир астында яшеренеп яткан нәрсәләрне — халкыбызның ерак үткәненә бәйләнешле бик әһәмиятле әйберләрне эзләп табарга, зур фәнни әһәмияткә ия булган проблемаларны хәл итәргә мөмкинлек бар.

Шәһри Болгарга кадәр ике йөз еллар чамасы Болгар дәүләтенең башкаласы булып торган Биләр шәһәре турында моңа тикле без бик аз белә идек. Чөнки җир өстендә бу шәһәрнең калдыклары да, хәрабәләре дә сакланмаган. 1236 елда монголлар тарафыннан җимерелгәннән һәм яндырылганнан соң, ул яңадан торгызылмаган. Узган ел анда археологлар казу эшләрен башладылар. Гаять зур шәһәр булган ул. Шәһәр урыны 700 гектар мәйданны биләп тора. Биләр шәһәренең кремле хәзерге Казан кремленнән ике мәртәбә зуррак булган.

Биләр шәһәре урынында табылган йорт нигезе, моржалы мич калдыклары анда яшәгән халыкның көнкүреше, культурасы шактый югары булуы турында сөйли. Алар бакырдан, алтын-көмештән бик затлы әйберләр ясаганнар. Меңнән артык бизәк төшерелгән алтын чулпы гаҗәп зур осталык белән эшләнгән. Бизәкле алка эченә авызына энҗе капкан кош сыны ясалган. Бакырдан коеп эшләнгән йозак та бик кызыклы. Кулына бала тотып, бүрегә атланган хатын-кыз гәүдәсеннән гыйбарәт бу йозак.

Болар икесе дә Болгарга ислам дине кергәнче — 9 — 10 гасырда ясалган әйберләр булырга тиеш...

Аннары сүз Р. Фәхретдиновка бирелде. Ул археологик эзләнүләр вакытында табылган материаль культура калдыклары буенча Болгар дәүләтенә кертергә мөмкин булган шәһәрләрне картага төшерүнең барышы турында сөйләде. Хәзерге вакытта картага төшерелгән 150 гә якын шәһәр болгар халкының күбрәк Кама аръягында яшәгәнлеген әйтеп тора. Болгар дәүләтенә кергән шәһәр калдыкларын эзләү хәзер дә дәвам итә.

Соңыннан галимнәр татар, чуваш, башкорт халыкларының килеп чыгышына, башка тарихи мәсьәләләргә кагылышлы бик күп сорауларга җавап бирделәр.

Бу җанлы әңгәмәдән утырышка катнашкан язучылар да, журнал редакциясе хезмәткәрләре дә, кунаклар үзләре дә бик канәгать калды.

* * *

Алабуга культура-агарту училищесында менә берничә ел инде «Кызыклы очрашулар клубы» эшләп килә. Аның җитәкчесе укытучы Һаҗәр Тохтамышева.

Клубның чираттагы очрашу кичәсе язучы Э. Касыймов иҗатына багышланды. Татар әдәбияты укытучысы Динә Каюмова язучының иҗаты турында сөйләгәннән соң, студентлар аның аерым әсәрләренә карата үзләренең фикерләре белән чыктылар.

Кичәгә язучы үзе дә катнашты һәм бик күп сорауларга җавап биреп, үзенең иҗат эше белән таныштырды.

◆ ◆



## ГӨЛСЕМ БОЛГАРСКАЯ

Татар театр сәнгатенең күренекле вәкиле, үзенең гаҗәеп таланты белән 50 елдан артык сәхнәбезне бизәп килгән Татарстанның халык, РСФСРның атказанган артисткасы Гөлсем Болгарская арабыздан китте.

Гөлсем Болгарская сәхнәбезгә реакция елларында килде, кара көчләр куйган киртәләрне җимереп, үзенең гомерен тулысы белән сәнгатькә, театрга хезмәт итүгә багышлады.

«Банкрот»тагы Гөлҗиһан, «Яшь йөрәкләр»дәге Зөләйха, «Ташкыннар»дагы Ханзафа, «Хуҗа Насретдин» комедиясендәге Сәхилә, «Ил» драмасындагы Бикә туташ, «Шәмсекамәр»дәге Гадилә, «Яшенле яңгыр»дагы Катерина, «Чия бакчасы»ндагы Раневская, «Гамлет» трагедиясендәге Гертруда һәм башка ул иҗат иткән образлар үзләренең реальлеге, сәнгатьчә камил эшләнүләре һәм эмоциональ булулары белән аерылып торалар.

Халкыбызның театр сәнгатен үстерүдәге һәм җәмәгать эшендәге зур хезмәтләре өчен 1925 елда Гөлсем Болгарскаяга РСФСРның атказанган артисткасы дигән мактаулы исем бирелде. 1940 елда ул «Почет билгесе» ордены, 1957 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм Бөек Ватан сугышы чорында күрсәткән хезмәтләре өчен медале белән бүләкләнде.

# БУ САННЫҢ АВТОРЛАРЫ



Камил Мостафин 1932 елда Татарстанның Зеленодольск шәһәрендә туган. 1956 елда Казан дәүләт университетының физика-математика факультетын тәмамлый. Хәзер Чиләбе шәһәренең фәнни институтларының берсендә өлкән инженер булып эшли.

Әдәбият мәйданында 1956 елдан күренә башлады.

Беренче китабы «Җыр сафка чакыра» исеме белән 1966 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты. «Һәркемнең үз йолдызы» дигән икенче китабы матбугатта чыгарга әзерләнә.



Рифгать Закиров 1938 елда Татарстанның Актаныш районы Усы авылында туа.

Сигезьеллык мәктәпне тәмамлагач, механизаторлар мәктәбендә укый, совхозда тракторчы булып эшли. 1956 елда Уралга китеп, башта бульдозерчы, аннан шахтер була. Шахтада өч ел эшләгәч, авырып пенсиягә чыга. Хәзер Гремячинск шәһәрендә яши.

Рифгать Закиров әдәбият мәйданына үзенең лирик шигырьләре белән чыга. Соңгы биш-алты ел эчендә аның шигырьләре газета-журналларда еш күренә башлады. Безнең журналда да аның шигырьләре укучыларга бернична тапкыр тәкъдим ителгән иде инде. Тиздән Рифгать Закировның беренче китабы — «Беренче буразна» исемле шигырьләр җыентыгы чыгачак.



Егор Уткин Алабуга районы Бөрешле авылында 1930 елда туа.

Колхозчы, эшче, район газетасы хезмәткәре пәм, Алабуга педагогия институтын тәмамлагач, мәктәп директоры вазифаларын үти. Хәзер Бондюг заводында эшли.

Егор Уткин шигырьләре матбугатта 1958 елдан күренә башлады. Ул безнең журналыбызда да актив язучылардан берсе.



Басыйр Рафиков Вятка елгасы буенда — Мамадышта 1921 елда туган.

Троицкидагы татар-башкорт педтехникумында укыгач, ике ел укытучы булып эшли. Ватан сугышында катнаша. Магнитогорскидагы металлургия комбинатында эшли. Аннан педагогия институтын тәмамлый. Хәзер Троицк шәһәрендә кичке урта мәктәп директоры.

Татарстан китап нәшрияты тиздән аның беренче китабын — «Җырым сиңа булсын»ны басып чыгарачак.

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

# Казан утлары

## (ОГНИ КАЗАНИ)

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210